# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1996



# 1996 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында УКАЗ





Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, КАРАР БИРӘМ:

1996 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген:

1. БӘШИРОВ ГОМӘР БӘШИР улына, «И язмыш, язмыш» китабы өчен (Татарстан китап нәшрияты, 1990 ел);
2. КУДАШЕВА ФӘРИДӘ ЯҺҮД кызына (Татар халык җырларын һәм Г. Тукай шигырьләренә иҗат ителгән җырларны башкарган өчен) бирергә.

Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. ШӘЙМИЕВ.

Казан. Кремль. 1996 ел, 26 апрель.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**(884)**

**1996**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Р. НИЗАМИ. Мәхәббәт мәрҗәннәре. *Шигырьләр* ... 3
Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Утлы таба өстендә. *Роман* ... 9
Н. НӘҖМИ. Минем кулны юасы юк. *Шигырьләр* ... 66
Г. АХУНОВ. Тимерханның авыл юллары. *Документаль повесть* ... 74

ОСТАХАНӘ

К. ШАФИКОВА. Күз яше. *Шигырьләр* ... 70
Р. МӨХӘММӘТДИН. Үзем булып калам. *Шигырьләр* ... 72

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Төрек шагыйрьләре Ю. ӘМРӘ, Ф. ГӨЛӘН, Г. ВӘЙСӘЛ, Н. ФАЗЫЛ, КЫСАКӨРӘК, А. НИҺАТ АСЬЯ шигырьләре ... 123

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. БОРҺАНОВ. Кая бара бу Россия? ... 128

ӘДӘБИ МИРАС

Р. ГАТАШ. Утыз елдан соң да соң түгел ... 141
Х. ТУФАН. «Нюанслар иле»ндәге шигырьләр турында ... 142

ХӨТЕР

Л. ХӘМИДУЛЛИН. Ике дәвер кешесе ... 147
Р. ХАРИС. Тавышсыз җыр ... 154

ӘДӘБИ МИРАС

З. ИСЛАМ. Әхмәт Фәйзи хатлары ... 156

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Ф. ХУҖИН. Борынгы Казан: кичәге һәм бүгенге археологик ачышлар ... 164

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Р. ШӘРӘФИЕВ. Ак күбәләк сафлыкка дәшә ... 177

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ

Р. РИАН. Бил кузгалу. *Юмористик хикәя* ... 183

ӘЗ-МӘЗ ГЕНӘ МӘЗӘК ХӘЛЛӘР

Ә. ЯҺҮДИН. Күргәннәр, белгәннәр, ишеткәннәр, баштан кичкәннәр. ... 185

Безнең календарь ... 181
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Р. МУХАМАДИЕВА «Горячие дни октября 1993 года», документальная повесть Г. АХУНОВА «Сельские дороги Тимерхана», стихи Р. НИЗАМИ, Н. НАДЖМИ, К. ШАФИКОВОЙ и Р. МУХАМАТДИН.
«Из тюркской поэзии»: стихи Ю. АМРЫ, Ф. ГУЛАН, Г. ВАЙСАЛ, Н. ФАЗЫЛ КЫСАКУРАК, А. НИХАТ АСЬИ.
«Публицистика»: интервью А. МУШИНСКОГО с профессором А. БУРГАНОВЫМ.
«Литературное наследие»: статья Х. ТУФАНА, посвященная к начальному периоду творчества поэта Р. Файзуллина и «Письма Ахмета Файзи».
«Память»: статьи Л. ХАМИДУЛЛИНА «Человек двух веков» и Р. ХАРИСА «Песня без слов».
«Из страниц истории»: статья Ф. ХУЗИНА «Древняя Казань: археологические открытия».
«Юмор-сатира»: рассказ Р. РИАНА.
Забавные истории А. ЯГУДИНА.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Саз мой нежный и печальный, слишком мало ты звучал...» — картина художника Ильдара Зарипова; татарские писатели — члены Всемирного ПЭН клуба.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the sequel of R. Mukhamadiev's novel «Hot october days of 1993»; G. Akhunov's documentary narrative «Timerkhan's country roads»; the verses of R. Nizami, N. Nadjmi, K. Shaphikova and R. Mukhamatdin.
«From turkic poetry»: the verses of Yu. Amra, Ph. Gulan, G. Vaisal, N. Phazil, Kizakurak, A. Nikhat Asi.
«Publicism»: the interview of A. Mushinski with the professor A. Burganov.
«Literary heritage»: Kh. Tuphan's article devoted to the early period of R. Phaizullin's creative work and «Akhmet Phaizi's letters».
«Memory»: L. Khamidullin's article «The man of two centuries», R. Kharis's article «The song without words».
«From the history pages»: Ph. Khuzin's article «Ancient Kazan: archeological discovery».
«Humour and Satire»: R. Rian's story.
Funny stories of A. Yarudin.
Our calendar.
«In our covers»: Ildar Zaripov's picture «My tender and sad Saz, you sounded too little»; Tatar writers — the members of Pen Club.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.


*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 25.04.96 ел. Басарга кул куелды 5.06.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 349. Заказ Е-234.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Рашат Низами

### МӘХӘББӘТ МӘРҖӘННӘРЕ

* * *

Малай чакта мәрҗән тезгән идем,
Тезгән идем яшел миләштән.
Үзем генә белгән мәхәббәтем
Әй, «яшел» булган соң ул яшьтә!

Егет чакта мәрҗән тезгән идем
Күк тутырып, кайнар йолдыздан.
Әле дә булса йолдыз сәламнәре
Килеп тора миңа ул кыздан.

Инде менә тагын мәрҗән тезәм,
Берәм-берәм тезәм сүзләрдән.
Җанда сөю — һаман шул ук икән!
Еллар гына бары үзгәргән.

Мәрҗән-мәрҗән тезәм елларымны:
Мин ни кылган,ниләр майтарган?
Күңел — һаман унҗидедә икән,
Еллар гына — бераз картайган...

### Синең җавап

Мин елмаеп кына дөнья үзгәрерме?
Шундый сорау бәргәләнә җанда.
Бер уйласаң, тормыш — соры агым,
Матурлыклар юктыр кебек анда.

Урамнарга чыксаң, сүрән йөзле
Бәндәләргә бик еш юлыгасың.
Билен бөгеп михнәт куа халык,
Түрәләрнең гәүдә туры да соң!

Кая барма, кыса соры ташкын:
Трамвайлар — гүя шырпы кабы.
Ишетелә дөнья арбасында
Мең-мең язмышларның кыштырдавы.

Кояшлы җыр эзләп килә-килә
Байтак канаттым мин тезләремне.
Үз-үземнән сорау алам бүген:
Мин елмаеп кына
Яхшырырмы дөнья, үзгәрерме?

Үзгәрер!
Шулай җавап бирә күзләрең...
Һәм яктырып китә көзләрем.

## Көн уртасы

Үрли кояш, үрли һаман өскәре,
Кыскарадыр күләгәләр гаскәре.

Бал кортыдай син дә карап уз аны,—
Яфракларда бии чәчәк тузаны.

Рәшә җиле. Арыш исе. Кыр юлы.
Күпме башак сәлам бирә берьюлы!

Уйлый-уйлый көннәрнең алгысын,
Әй, дәртләнеп селти егет чалгысын.

Кыз балага сабырлыклар бирсәнә:
Күкрәгендә ике «кояш» тирбәлә!

## Нишләттең?

*(мәхәббәт фасыллары)*

Челтер-челтер сулар типкән чакта
Элек язлар бүтәнчәрәк иде.
Гөрләвекләр тулып йолдыз ага —
Син нишләттең мине?

Шомырт ботагында тибрәп үстек,
Шомырт ашап теш камаша иде.
Шомырт күзләреңнән җан камаша —
Син нишләттең мине?

Урманнарда яфрак яуган чакта
Элек көзләр бүтәнчәрәк иде.

Сары яфрак булып күктән тамам —
Син нишләттең мине?

Узып бозлы тәрәзәләр аша
Синең сулыш битләремә тиде.
Кар өстендә гөлләр чәчәк ата —
Син нишләттең мине?...

## Төнге Казан

Казанымда буран бии!
Шәһәр күккә тоташкан.
Кайда шәрык, кайда гареп —
Дөнья тәмам саташкан.

Алҗыган светофорның
Күзләрендә — кар табы.
Таш урамнар кочагында,
Әй, өлгерә кар тавы!

Буран эчләреннән кинәт
Саркып чыга ябалдаш.
Җиде юлның чатларында
Басып торам яланбаш...

Без яраткан кышкы төннәр
Ничек инде суынсын,—
Кар булып битне яндыра
Синең сулыш, синең сын.

Казанымның күкләрендә
Уйный төнге ак буран.
Тоныкйолдыз булып әнә
Тәрәзәләр яктырган!

## Сәфәр

Автобусның җылы салонында
Төнге сәфәр. Йоклый юлдашларым.
Күңелемә тынгы бирми һаман
Тун эченә поскан иңбашларың.

Чит күзләрдән яшеренеп кенә
Бармакларны тешләп карасак та,
Киртә корып, безнең арабызда
Язмыш үзе уяу тора сакта.

Тәрәзәнең пыялаларына
Тияр-тимәс кагылышып әнә,
Күрәсеңме, ап-ак карлар булып
Минем җаным шулай бәргәләнә!

Эзләр калыр, сүзләр калыр безнең —
Мең елдан соң тагын шушы карлар,

Нәкъ бүгенчә итеп, колагыма
Исемеңне синең пышылдарлар...

Үткәннәргә кайту микән соң бу,
Киләчәккә әллә барышыбыз?
Ни булса да, безнең күңелләрне
Бәйләп тора уртак сагышыбыз.

Безнең күзләр әле очрашырлар,
Сабыр итик таңга чаклы гына.
Бармак түгел, хәтта йөрәгем дә
Килеп капты сөю капкынына!

## Кояш турында җыр

Син миңа әнидер, әнидер...
Күңелең еш кына әрнидер.
Булды бит хәсрәтле чакларым —
Син мине давылдан сакладың.

Син миңа ападыр, ападыр...
Уйларың үткәнгә кайтадыр.
Кул селтим дөньяның малына,
Чын бәхет китерден җаныма.

Син миңа сеңелдер, сеңелдер...
Гомерләр мәңгелек түгелдер.
Алдыңа моң булып түгеләм:
Син — Кояш!
Мин — тамчы, мин — үлән.

Син миңа кыз бала, кыз бала...
Мең төрле гамьнәрем кузгала.
Сөюнең мәгънәсен бел икән —
Яшәүләр, уйласаң, гөл икән.

Янартау йокламый, йокламый,
Кирәксә, йөз елдан уяна.
«Белегез, мәхәббәт бар ул!» — дип,
Чаң сукты йөрәгем дөньяга...

## Сиңа...

Син бит миңа шундый якындасың,
Бер уйласаң инде, һай, ерак.
Мин үземне сиңа бүләк итәм,
Фани дөнья булсын яктырак.

Мин әзермен килер юлларыңны
Кызыл чәчәк белән күмәргә.

Без аңлашыйк, шуңа риза булыйк —
Бары мәхәббәттә үләргә!

## Сагынуым

Йөрәгеңә юл табасым килде,
Ышанасым, бушанасым килде.
Йолдыз тоткан япь-яшь бер егеттәй
Юл чатында басып торам инде.

Күк капусы кинәт ачылгандай,
«Гөлт!» кабынды җанда синең яктың.
Гомер буе сине эзли-эзли
Көтмәгәндә... мин үземне таптым!

* * *

Кададың шашкын йөрәккә
Син мәхәббәт хәнҗәрен!
Чишмә төсле актарылып,
Ташып чыкты гамьнәрем.

Саркып-саркып җәрәхәттән
Әй, тамчылый сагышым.
Сулык-сулык...
Офыкларда —
Минем йөрәк тавышы.

Кайчак төн урталарында
Аваз салам дөньяга...
Сызласын, тынмый сызласын —
Аһ, татлы соң бу яра!

Чәчелгән мәрҗән шикелле
Уем, зиһенем таралды.
Күзләреңнең нуры белән
Инде бәйлә ярамны!

## Яңгыр кызы

Яңгыр булып килдең миңа
Җәйләрнең кочагыннан.
Сибелде безгә йолдызлар
Мәхәббәт учагыннан!

Без янәшә йөгерәбез
Яшеннәр арасыннан.
Сөю җилкәннәре безне
Озата бара сыман.

Яңгыр юа чәчләреңне,
Юатам диеп микән.

Җәйләр бер узар да китәр,
Сөюеңне мин көтәм...

Яңгыр, яңгыр!
Көнләшепме
Чылаттың син күзләрне.
Барыбер юа алмассың
Йөрәктәге эзләрне!

## Яңгыр астындагы мәхәббәт

Гамьсезләрнең тәрәзәсен шакып,
Урамнарның ташын чылатып,
Көлә-көлә узып бара яңгыр
Миллионлы шәһәр буйлатып.

Кылыч белән селтәнә дә яшен
Болытларны үтә яндырып.
Диңгезләргә киткән пароходның
Эзен юа Идел яңгыры.

Акчарлаклар килеп кунар төсле —
Учларыңны ачып куй гына!
Агачларның яшел зонтигыннан
Шыбыр-шыбыр тамчы коела.

Тамчыларны күккә чөйде егет.
Суырды да үпте сөйгәнен...
Яңгыр кылларына чиртә-чиртә,
Дастан сөйли дөнья дигәнең!



## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Ринат Мөхәммәдиев**

# УТЛЫ ТАБА ӨСТЕНДӘ

(БАШТАН КИЧКӘН ФАҖИГА)

1[1]

Халык ташкыны, мәйданны узгач та, туксан градуска кинәт борылып, тагы берничә рәт булып баскан милиция чылбырын өзде. Һәм Бакча божрасын тум-тутырып Үзәк культура паркы юнәлешендә агыла башлады. Утыз-кырык метр киңлектәге колоннаның очы-кырые юк. Иң әүвәл типсә тимер өзәрлек әзмәвердәй таза егетләр узды. Аларга урта яшьтәгеләр, ара-тирә хатын-кызлар, пенсия яшендәге өлкәннәр ияргән.

Без күзәтәбез. Безнең башка чарабыз юк. Йөрәк күкрәктән чыгардай булып тибә, әлбәттә. Әнә, алда баручылар инде Кырым күперенә кереп бара, ә Октябрь мәйданы әле булса бушамаган, бу кадәрле халыкның бергә туплануын шул көнгәчә күргәнем юк иде дисәм, һич арттыру булмас.

— Чү,— диде юлдашым,— Кырым күперен игътибар белән кара әле...

— Ни дигән сүз бу тагы?

Күпернең кыл уртасында кош та очып чыга алмаслык тимер дивар хасил булган икән бит. ОМОН хезмәткәрләре, ни рәвешледер хикмәтләр кыланып, калканнарыннан ике катлы ышык корып куйганнар. Ә үзләренең исәп-хисабы юк.

Йөрәк жуылдап куйды. Халык ташкыны якынлашканнан-якынлаша бит үзләренә. Мәскәү елгасы аша салынган мәһабәт зур тарихи күпернең кыл уртасында коточкыч бәрелеш булачак бит хәзер. ОМОНга бер карыш та ары чигенмәскә дигән әмер бирелгән. Ә инде километрларга сузылган халык ташкынын туктатам дисәң дә, туктату мөмкин түгел хәзер. Бу бит җидешәр булып тигез рәтләргә тезелешеп баскан 1 Май демонстрациясе түгел. Монда табигый стихия, монда нәфрәт, үч алу, ун-унбиш көннәр дәвамына кыйналган, дөмбәсләнгән мәскәүлеләрнең бер-берләренең җилкәсен тойган мәле. Игътибарга лаек факт: монда Россиянең һәммә шәһәреннән җыелган яшьләр. Украинадан, Белорусьтан, Молдовадан килүчеләр бар. Казаннан 36 кешелек группа булганлыгын беләм.

[1] Ахыры. Башы журналыбызның 5 нче санында.

Безнең күзләр күпердә, ә аякларыбыз алга әйди. Халык ташкыны белән тимер дивар арасында унбиш-егерме метр ара калды. Диварның аргы тарафыннан тавыш көчәйткечтән яңгыраган аваз ишетелде:

— Туктагыз! Акылыгызга килегез. Күпернең аргы ягына чыгу катгый рәвештә тыела. Буйсынмасагыз, корал кулланачакбыз. Безгә шундый әмер бирелгән. Туктагыз! Туктагыз...

Бу тавышта, кисәтү белән бергә, хәвеф сиземләү һәм курку да ачык тоемлана иде. Ташкын беркавымга сөрлегеп киткәндәй булды. Киеренке тынлык урнашып алды. Йөрәкләр кысылган. Ни белән бетәр бу?..

Кинәт халык ташкынын әйдәп барган депутатлардан Уражцевның карлыккан калын тавышы яңгырата әйләнә-тирәне. Ул да таләп итә:

— Юлны бушатыгыз! Халыкка юл бирегез... Утыз секунд вакыт бирәм.— Һәм чын-чынлап санарга керешә.— Егерме секунд калды... Унбиш... Ун... Биш секунд!

Тимер дивар белән халык ташкыны арасы күзгә күренеп кыскара бара. Җиде метр чамасы калды... Биш... Өч... Ул да түгел, алдан килүче сафлар кинәт, бәйдән ычкынгандай, җан-фәрман тимер калкан дивар өстенә ташланды. Күпер өстендәге мәйдан иңрәп куйды. Тимер калкан дивар чатнап ярылды. Ике арада сүз белән әйтеп аңлату мөмкин булмаган тартыш, сугыш башланып китте. ОМОН резин күсәк һәм калкан белән дөмбәсли-кисә, ташкын башында килүчеләр йодрык һәм аяк белән карыша. Ә беразга арттарак токарланучылар арасыннан таш һәм тимер-томыр кисәкләре дә ыргыта башладылар булса кирәк. Бусын күргәч, йөрәк жуылдап куйды. Чаманы онытмаска иде бит. Каршы якка шул гына кирәк. Ике дә уйламастан, корал кулланачаклар...

Шап та шоп... Дөп тә дөп... Ах та ух... килгән авазлар гына ишетелеп торды бер мәл. Ул да түгел, кемнәрнедер күпер өстеннән тотып-тотып ыргыттылар. Артка чигенер урын, котылыр җай таба алмыйча, ОМОН егетләре үз ирекләре белән дә сикерделәр булса кирәк.

Гомеремдә беренче тапкыр шул мизгелдә мин халык массаларының, бергә тупланган тәкъдирдә нәрсәгә сәләтле булуын, ташкынга тиң нинди зур көч-гайрәткә ия булуын үз күзләрем белән күрдем. Дивар булып ярты күперне тум-тутырып торган таза-таза егетләр йомычка урынына чәчелде һәм таркалып калды. Ташкын Смоленск мәйданына таба хәрәкәтен дәвам иттерде.

Бераз кичегеп Кырым күперенә килеп кергәч, андагы тамашага карау кыен иде. Яшь кенә егетләр күпер читендә ух-ах килеп ята. Берәвенең башы ярылган, икенчесенең кулы кош канатыдай каерылган, яисә аягы сынган. Һәр ике тарафтан да бер үк төрле йөзләр, бер үк күзләр... Бер үк телдә сөйләшәләр. Җидешәр катлы итеп аты-юлы белән сүгенәләр. Бер үк урамда уйнап, бер мәктәпләрдә укып, бергә армиядә хезмәт иткән егетләр ләбаса. Эшче һәм крестьян балалары. Черегән байлар чыкмый монда. Түрәләр дә юк. Беләм, хәтта балаларын, оныкларын җибәрмиләр алар монда. Сәясәтчеләр дә күренми. Барысы бер иш, лидерлар Президиумда утыруны кулайрак күрә, мәйданда сугышуны түгел... Ә бит сугыштыручылар, Иванны Иваннан үтертүчеләр, Мөхәммәтне Мөхәммәттән кыйнатучы шулар. Мәйдан тутырып сугышкан ОМОН егетләренең дә, каршы яктагы бичараларның да бу хакта уйланырга аралары юк. Алар көрәшә, мөнәсәбәт ачыклый, берсе — яхшыга түләгәнгә кыйный, икенчесе — югалтыр нәрсәсе калмаганга чыга урамга. Ә түрәләр хакимият бүлә, һәм әлбәттә, акча!..

— Ринат,— дип дәште, аркама кулын салды юлдашым.— Карале, әнә теге багана төбендә яткан ОМОНның әллә күзен чыгарганнар инде?

Мин дә шул тарафны күзәтеп килә идем. Әмма җентекләп карарга курыктым. Йөзен, яңакларын кан баскан. Ә канга мин, гомумән, карый алмыйм. Үз гомеремдә әтәч суйган кеше түгел.

— Бик мөмкин,— дим.— Монда күз генә түгел, башын өзгәннәр дисәң дә гаҗәпләнерлек түгел. Күрәсең ич, тимер һәм таш белән ачыклыйлар мөнәсәбәтне.

— Барыйк әле, хәлен сорашыйк. Бер-бер ярдәм күрсәтик үзенә,— ди юлдашым. Профессионал сәясәтче үзе, сәясәтчедә дә җан булыр икән...

Яралы егетнең янына ук килдек. Хәлен сорашкан булабыз. Телəр-теләмәс кенә җавап бирә.

— Хәлең авырмы?— дибез.

— Сез сораганнан җиңеләймәс бит,— ди. Әллә авыртуга түзә алмыйча, әллә ярасын күрсәтергә теләмичә канга баткан кулы белән сул күзен каплады.

— Күзгә эләктермәгәннәрдер бит?— дим, мин дә сүзгә кушылам.

— Чепуха,— ди.— Маңгай гына.

— ОМОНда күптән хезмәт итәсеңме?

— Язгы дембельдән соң...

— Мәскәүнекеме?

— Юк. Смоленск ягыннан.

— Авылданмы?

— Әйе.

— Нигә ОМОНга килергә булдың соң?

— Фатир кирәк. Акча...

Эчке кесәдән кулъяулыгымны чыгарып суздым егеткә. Авыл — минем йомшак җирем, ул миңа ошап китте. Авыл кешесе — русмы ул, татармы, чувашмы, әллә америкалымы — аңарда ихласлык һәм кешелеклелек сыйфатлары мулрак сакланган була.

— Кирәкми,— ди егет. Карыша. Әмма бераздан алырга мәҗбүр булды һәм ярасын каплады.

— Нәрсә белән суктылар соң?

— Таш эләкте бугай.

— Үзең дә кыйнадыңмы соң берәрсен?

Егет, уңайсызланып, тартынып куйды. Авыл егете шул!

— Кыйныйсың инде. Эшең шул булгач... Шунын өчен акча түлиләр. Офицерлар карап, күзәтеп торалар ич.

— Моңардан соң да шулай итәрсеңме?

— Кая барасың!.. Фатир кирәк бит. Хатын бар, бала бар. Алар авылда, миннән чакырту көтеп яталар.

Сөйләшер сүз бетте. Егетнең хәле алай без уйлаганча ук бик начар булып чыкмады. Баганага сөяп, иплерәк итеп утырттык та ары китеп бардык.

Шунда гына бер ачыш ясадым үзем өчен. Һәр ике тарафтан да яралanучылар һәм үлүчеләр байтак булгандыр бу көнне. Әмма, шунысы хикмәт, чарасыз калып утырган яисә үзен гаепле санап каядыр сөялеп уйга калган яралылар — барысы да дип әйтерлек милиция хезмәткәрләре. Ни эшләргә, ни кылырга белми иде кебек алар. Ярдәмгә килүчеләр дә юк үзләренә, сүз катучы да юк. Хәтта үзара сөйләшү, хәл белешүдән дә тайчына сыман иде алар.

Ә каршы яктагылар ни дәрәҗә генә кыланмасын, тизрәк торырга ашыга, кабалана. Хәле булганнары канын сөртә-сөртә мәсләктәшләренә ияреп китә. Һич булмаса бу тирәдән тизрәк качып котылу җаен эзли. Боларына ярдәм кулы сузучы, ярдәмгә атлыгып торучылар да бермә-бер күбрәк.

Без дә Кырым күперен чыгып киләбез. Шактый калыша төшкәнбез. Вакыйгаларны күздән ычкындырасы, халык ташкыныннан калышасым килми. Алар киткән тарафны күзәтәм. Инде Смоленск мәйданына якынлашып киләләр төсле... Без үзебез дә битараф тамашачы гына түгел бу урамда, алда ни буласы барыннан бигрәк безнең һәм үзебез кебек парламент тоткыннары өчен гаять әһәмиятле, хәтта хәлиткеч әһәмияткә ия булуы ихтимал. Адымнарыбызны бермә-бер тизләттек, ташкыннан калышыбрак тамаша кылып барган әбиләрне һәм яшь җилкенчәкне аралый-аралый киң урамның кыл уртасыннан алга таба ашыктык. Бакча

божрасындагы юл уртасыннан кайчан шулай җәяүләп йөри алыр иден әле. Башка чакта тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә аркылы да чыгып булмый торган трасса бит бу, тум тутырык машина...

Октябрь мәйданы һәм Кырым күперендәге вакыйгалар нәни бер күнегүләр генә булган икән. Смоленск мәйданына, ягъни Тышкы эшләр министрлыгына якынлашкан борылышта халык ташкынын пожар сүндерүче машиналар көтеп торган. Алар киң урамны аркылы буып куйган сыман тезелгәннәр иде.

Барган мәлгә сискәнеп киттек. Көтмәгәндә, бөтен әйләнә-тирәне сискәндереп, көчле шартлау авазлары яңгырады. Ни булганын без әлегә күрмибез, шуңа аңламыйбыз да... Аталармы, җимерәләрме, ваталармы — һич аңларлык түгел.

— Ата башладылар,— ди юлдашым.— Вәт имансызлар. Көпә-көндез!

— Юк,— мин әйтәм, белгән атлы булып, тәзәтмә кертәм, янәсе.— Атмыйлар. Нидер шартлаталар гына бугай.

Чынлыкта да нык ялгышмаганмын икән. Пожар сүндерүче машиналарга якынлашып килгән халык төркеменә кузачкысыз тотен чыгара торган «черемуха» дигән газ җибәргәннәр. («Черемуха» дигәнен тәрҗемә-фәлән итеп тормыйм әле. Татарчада тәрҗемәсе булмасын. Татарстанда исе чыга күрмәсен. Һич кенә дә шомырт чәчәге исе килми аңардан).

Кычкырышкан, ухылдаган-ахылдаган авазлар ишетелде. Без дә бер мәлгә туктала төшкән халык ташкынына килеп кушылган идек инде. Әмма алгы тарафта паника башланмаган. Күрәсең, алар өчен бусы да көтелмәгән нәрсә булып чыкмаган. Киресенчә, көрәшкә күтәрелү өчен чакыру сыманрак кабул иткәннәр моны. Һәр тарафтан дәррәү килеп, «Урра!..» кычкырган, «Алга... Һөҗүмгә...» әйдәгән авазлар ишетелде.

Андагы хәлләрне күз белән күреп бетерү, күрсәң дә, колачлау мөмкин булмагандыр. Тагы бер залп җибәрделәр кебек «черемуха» белән. Һәм берьюлы егермеләп машинадан кешеләр өстенә күбекле су сиптерергә керештеләр.

Халык шыплап тулган мәйдан тоташ ташкынны хәтерләтә иде. Инде менә ул чын-чынлап диңгезгә әверелде, суы да күп, күбеге дә... Кешеләр күбекле су эчендә күмелде. Ә янгын сүндерүче машиналарның аргы ягында тагы да ОМОН сугыш чукмарлары көтә икән...

Каршы тараф та югалып калмады. Машиналарның тәрәзәләренә олы-олы ташлар очты. Ул да түгел, кабина түбәләренә менеп кунаклаган янгын сүндерүчеләрнең үзләрен бәреп төшерергә, быргырга керештеләр. Ә инде бераздан тулы көчкә эшләп торган янгын сүндерү җайланмалары бер-бер артлы каршы тарафка — ОМОН өстенә юнәлтелде. Күбекле су милиция хезмәткәрләре өстенә агарга кереште. Алар чигенде. Колонналар кан һәм җаннар бәрабәренә һәр адым өчен көрәште. Без ул бәрелеш урынына килеп җиткәндә, янгын сүндерү машиналарының берничәсе аударылган, калганнары юл читенә чыгарып атылган иде инде. Ә берсенә ут капкан, яна...

Янгын сүндерү өчен җайланган машина дөрләп яна. Ни бу? Кешеләрнең иминлеген сакларга чакырылган милиция һәм ОМОН үз халкын кыйный. Ни бу?! Ак күлмәкле, галстуклы ир-атлар милициягә төбәп таш ыргыта. Ни бу!!! Берсе үле, икенчесе җансыз, өченчесе хәрәкәтләнә алмый, канга баткан... Йә Ходаем, үзең сакла, ахырзаман дигәннәре шушы була түгелме соң...

Смоленск мәйданының кыл уртасында, Тышкы эшләр министрлыгының каршысында ук узган тамаша бу. Кая карама, анда кан, яралылар, канга батып җан биреп ятучылар. Сәясәтчеләр, житәкче даирәләр уйлап чыгарган уен чын гражданнар сугышына әйләнеп бара түгелме? Без бит әле нәкъ шул ук минутларда Мәскәүнең тагы ике төбәгендә шундый ук

митинглар башланып киткәнлеген белмибез. Аларда да йөзәр меңләгән халык, канәгатьсезлек һәм нәфрәт ташкыны кайнаган.

Смоленск мәйданы «алынгач», ташкын булып агылган халык массасының башында атлаучы яшь һәм гайрәтле егетләр тәмам үз-үзләренә ышандылар булса кирәк. Чөнки максатка ирешү өчен күп калмады. Калинин проспекты, әнә, күренеп кенә тора. Анда барып җиткән тәкъдирдә шәһәр мэриясе (ул элекке СЭВ бинасында урнашкан иде) һәм унбиш көн дәвамында блокадага дучар ителгән Югары Совет бинасына өч йөз метр чамасы ара кала. Әмма анда үтеп керүләре генә ничек булыр. Ул тарафларга әлегәчә кошларның да очып узганы юк дип сөйләшәләр иде кебек.

Мәгълүм булганча, Бакчалар боҗрасы Калинин проспекты белән кисешми, ә күпер астыннан уза. 1991 елның август вакыйгаларында вафат булган өч егетнең гомере әнә шунда өзелде инде. Күпер астына керә торган юл бу юлы да «Урал» машиналары һәм автобуслар белән шыплап тутырылган иде. Кузовларында милиция хезмәткәрләре. Ни сәбәпледер, аңламыйм, болары халыкка каршы күтәрелмәде, резервта иделәрме, тик утыруларында дәвам иттерделәр. Бөтенесе канга баткан, бөтенесе сугыша. Ә болары мәрткә киткәнмени... Әллә инде арырак урнашкан җитди бина — Америка Кушма Штатларының илчелеген саклау бурычы йөкләтелгән иде үзләренә. Һәрхәлдә, бер-бер хикмәте булгандыр, юкка гына шул дәрәҗә сабырлык күрсәтмәсләр иде.

Халык ташкыны ул машиналарга таба бармады, сул яктагы юлдан Калинин проспектына турыдан бәреп чыкты. Ә проспект буп-буш. Бер-бер дәүләт делегациясен каршы алу өчен дип уйлый күрмәгез, ял көне иде бу. Түрәләр үзләренең дачаларында ял итә, диделәр.

Ә ни өчен соң алай булгач транспорт хәрәкәтен туктатканнар. Һәм әле генә түгел, ике сәгать чамасы әүвәл туктатылган ул хәрәкәт. Кемне көтәләр?.. Халыкны монда килер дип уйласалар, Кырым күпере һәм Смоленск мәйданындагы барьерлар нигә кирәк булды? Әллә соң болар һәммәсе алдан планлаштырылган эшме? Кемнеңдер алдан хәстәрләнгән сценариесе буенча уен уйнамас бит инде халык. Шулай да үзалдыма шикләнә калдым.

Колонналарның алгы сафы Калинин проспектына килеп чыгуы булды Мәскәү мэриясе тарафыннан берьюлы дистәләгән автоматтан халык өстенә атарга керештеләр. Ул залптан үлүчеләр булдымы-юкмы, әйтә алмыйм. Миңа калса, бу, барыннан да бигрәк кисәтү һәм куркыту өчен эшләнде. Шулай да урам уртасыннан пулялар сызгырып очты, тәрәзәләр коелды...

Халык янә бер мәртәбә сөрлегеп куйды. Кемнәрдер чүгәләде, кемнәрдер ятты. Икенче берәүләр тротуарларга таба сыенды яисә артка таба чигенеп куйды.

Без тротуар читләп атлый идек. Калинин проспекты читенә үк килеп җиткән идек инде. Алга узу мәгънәсезлек, әлбәттә, анда аталар. Гомеремдә беренче мәртәбә үзебезгә каршы очкан пуля авазларын ишетүем. Май кондызлары сыман «выжылдап» очалар икән. Әмма болар май кондызы түгел, шаяра торган нәрсә түгел... Янәшәбездән, өстебезгә менәрдәй булып, нидер ният иткән яшь җилкәнчек йөгереп узды. Ул да түгел, араларыннан берәү чакыру ташлады:

— Машиналарны кулга төшерергә. Күпер астына... Күпер астына.

Бу очракта инде юлдашым белән мин вакыйгаларның үзәгендә дип әйтерлек торып калдык. Һәммәсе күз алдыбызда булган хәл.

Теге төркемгә көтү-көтү яңалары кушылды. Алар шактый күпсанлы булып чыкты. Йөгерә-сикерә «эх» дигәнче күпер астында торган машиналар янына барып җитте болар. Кузовларда утырган милиционерларга дәшмәделәр, тимәделәр, кабиналарда утырган офицерларны һәм шоферларны йолкып төшерергә керештеләр. Тегеләре дә артык каршылык

күрсәтә алмады кебек, ә бәлки теләмәгәннәрдер дә. Егетләр берәм-берәм руль артына кереп утырды, «Урал» машиналарын кабызырга керештеләр. Кузгалып киткән машиналарның кузовында йокымсырап утырган егетләр, ни дә булса аңладымы-юкмы, әйтә алмыйм, барган шәпкә берәм-берәм коелып беттеләр. Ә сугышчан егетләр исә дәррәү аларның урынына менде. Күз ачып йомган арада булып узды бу хәлләр. Алдан ук әзерләнгән һәм күп мәртәбәләр күнегүләр үткәргән тәкъдирдә дә бу кадәр шома узмас хәрби операция. Милиция тарафында паника идеме, әллә битарафлык — һич аңламассың. Арадан ник берсе каршылык күрсәтергә омтылсын...

Ул гына түгел, машинасыз, ышык урынсыз калган яшь милиционерларны, сугышчан егетләрдән араларга теләп, хатын-кыз, күбрәк әбиләр төркеме уратып алды.

— Тимәгез, аларның гаебе юк. Алары да безнең балалар. Православныйлар...— ди-ди, сакладылар үзләрен, һичкемне якын җибәрмәделәр. Хәер, теге егетләрнең уенда болар кайгысы идемени...

Рус халкы гаҗәп инде ул. «Православныйлар» дип сөйлиләр бит әнә. Әйтерсең, бер милләтле дәүләттә яшиләр. Әйтерсең, «православный» булмаса, аны кыйнарга да, үтерергә дә ярый булып чыга. Әйтерсең, бу дәүләттә татар, башкорт, чуваш һәм башкалар, гомумән, юк. Баксаң, кайда куркыныч, кайда үлем, һәр икенең берсе татар, башкорт булып чыга. Чечняда да, Әфганда да, Таҗикстанда да шулай иде, югыйсә...

Кулга төшкән «Урал» машиналары хәрби колонна булып тезелде. Әллә йөртүчеләре, яңа хуҗалары шундый иләмсез, чамасыз үкертәләр үзләрен. Хәер, шулай итми хәлең дә юк, урам тулы халык, урамда паника, кая карама, анда кеше, тәгәрмәч янәшәсендә кеше урала. Үлемнән курку бетте монда, нәкъ фронттагы кебек...

Шул мизгелдә үзем өчен бер нәтиҗә ясадым мин. Резин күсәк һәм тимер калкан-каскалар белән куркыту мөмкин түгел икән ярсыган халыкны. Кырым күперен истә тотып әйтәм. Исерткеч газ һәм сабынлы су ташкынын да күтәрә, ерып чыга икән җаны өзгәләнгән халык. Смоленск мәйданындагы хәлләр мисал булып тора ала. Ә көтмәгәндә-уйламаганда, утлы коралдан атарга керешсәләр, табигый инстинкт кешене сагаерга мәҗбүр итә.

Ниһаять, борылыштан бушап калган Калинин проспектына (бүген ул Арбат дип атала инде) двигательләрен иләмсез үкертеп бер-бер артлы җиде-сигез «Урал» килеп чыкты. Һәм алар уңга-сулга борылмыйча буш урам уртасыннан тәртипсез рәвештә бер-берсен узыша-узыша Югары Совет бинасы тарафына җилдерделәр.

Ара ерак түгел. Машиналар өчен исә нибары утыз-кырык секундлык ара. Шуның өстенә, тоташ автоматтан атып торган милиционерлар әллә каушап калды, әллә югалып, бер мәлгә атуларыннан туктадылар. Килүчеләре дә тегенди-мондый гына түгел, хәрби машиналар бит. Күпер астындагы хәлләрне проспект башында торучылар күрмәде. Хәбәр җиткерергә дә өлгермәгәннәр иде булса кирәк, барысы да санаулы минутлар эчендә булып узды. Машиналар якын ук килеп җиткәч аңлаганнардыр, әлбәттә, әмма соң булгандыр.

Үкереп өсләренә килгән машиналар милиция хезмәткәрләре күңеленә шом салды булса кирәк. Тәртипсез рәвештә чит-читкә сибелде алар, командирларының «Төбәп атарга» бирелгән әмерләрен ишеткәне-ишеткәндер, ишетмәгәне юк. Андый чакта әмер үтәүдән бигрәк, баш кайгысы беренче планга калкып чыга, күрәсең. Чын мәгънәсендә паника башланды. Тимер калканнарын ташлап калдырып йөгерә иде кайсыберләре.

«Урал»ларга төялеп килгән егетләр идарә итә иде инде вакыйгалар барышы белән. Алар килгән шәптән кузовлардан сикереп төшәләр дә һәм арлы-бирле йөгерешкән милициядән калканнарын, башка җиһазларын тартып ала. Җитмәсә, Калинин проспектын иңләп, җинүче кы-

яфәтендә «Урра!» авазлары чыгарып йөз меңләгән ташкын ашыга ярдәмгә. Шул мизгелдә без үзебез дә шул ташкын эчендә идек. Мавыгу шулкадәр булган ки, көн дәвамына бергә йөргән юлдашым белән дә берберебезне югалтышканбыз. Бәла зур түгел. Андый чакларда һәркем теләктәш, һәркем юлдаш тоела икән.

Бәйдән ычкынгандай йөгерешкән халык өстенә, кинәт, берәү озын итеп автоматтан кургаш сиптереп алды. Кемнәрдер яраланды, кемнәрдер егылды. Мин үзем дә ерак түгел генә ике пуляның сызгырып узганлыгын ишеттем. Ирексездән, тезләр бөгелә төште, баш иелде — үләсе килми. Атучы шул берәү генә булды, башка кабатланмады. Каскаларын, калканнарын югалткан милиция, тәртипсез рәвештә күпер аша чыгып, «Украина» кунакханәсе тарафына китеп таралды.

Калканнар егылды. Милиция таралды-таралуын, әмма Ак йортка үтеп керү алай җиңел генә түгел иде әле. Тоташ дивар сыман тезеп куелган су тутырылган машиналар бар бит әле. Аларны кая куярга, алар хәрәкәтсез...

Гавәм тотынса — туктап калмый икән. Кайсын йолыктылар, кайсын төрттерделәр, шулай да узарлык юл арчыдылар маташа торгач.

Аннан, ни рәвешледер, теге куркыныч Бруно божрасы — чәнечкеле тимерчыбык ятмәдән арындырдылар юлны. Машиналар белән дә таптаттылар бугай, шактый озак газапландылар. Һәм, шулай итеп, ниһаять ун көннән узып ашкан блокада өзелде. Югары Совет бинасы әйләнәсендәге мәйданнарга халык кереп тулды. Йончыган, арган-талган депутатлар берәм-берәм урамга чыкты.

Ул көнне, шул сәгатьтә Мәскәүдә булып узган вакыйгаларны тулаем күз алдына китерү, гомумән, мөмкин түгелдер дип уйлыйм. Чөнки Югары Совет бинасының дүрт тарафын түгел, бер ягындагы мәйданны гына күздән кичерү өчен дә өч-дүрт киң панорамалы күзәтү җайланмасы кирәк булыр иде. Халык диңгез кеби, вакыйгалар тиз алмашынып тора. Масштаблар искиткеч зур. Берәүләр тантана итә. Икенчеләре көрәшә, нидер даулый. Кемнәрдер көн дәвамында үзләренең кылган батырлыклары белән мактана. Ө калганнары тамаша кыла яисә күзәтә. Юк-юк та, анда-санда автоматтан аткан авазлар ишетелеп куя...

Ни эшләргә, кая барып бәрелергә белми аптырашта калдым. Бер ялгызым ич мин... Өстәвенә тамак ач. Иртәдән бирле ашаган-эчкән юк. Янәшәмдә генә бер төркем Тула гармуны тартып частушкалар әйттерергә кереште. Бииләр, җырлыйлар. Халык талант иясе, әйтсә — туры әйтә, усал. Такмаклары сәяси темага. Ельцинны ишәләр, Гайдарны һәм Еринны. Бурбулисны Чубайска рифмалыйлар. «Шахрай»ны «малайка» дип үстереп җибәрәләр. Соңгы рифма исә күңелемә аеруча хуш килгәне булды. Ак эт бәласе — кара эткә булса булыр, көне буена беренче ишеткән татар сүзем иде бит «малайка».

Онытылып частушка җырлаган һәм биегән «бәхетлеләр»гә карап торам. Халык, кайсы гына телдә җырласа-биесә дә, ихлас, беркатлы һәм самими бит ул. Гомумән, халык иҗаты, кайсы телдә башкарылуына карамастан, чит була алмый. Аны йөрәк кабул итә, ул җанга якын була. Руслар исә частушкада аеруча йөгәнсезләнә, эчкерсезгә әйләнә. Частушка — рус халкының җанын ачкан иң ихлас авыз иҗатыдыр ул.

Шунда берәү җилкәмә кулын китереп салды. Танылган язучы Борис Можаев икән.

— Йә, ничек? — дип сорады ул, кочаклашып күрешкәннән соң.

Әллә хәлемне сорашуы иде, әллә мәйданда барган вакыйгалар белән кызыксына. Әллә частушкага мөнәсәбәтлеме?..

— Яхшы, — дидем, өстәмә сорау биреп тормый гына.

— Халык көчле ул, — диде Борис Можаев, шулай ук күп мәгънәле итеп. Дулкынланган, шактый нык хисләнгән иде аксакал әдип. Ак йортны саклаучы депутатлар арасында булуым өчен ул миңа үзенең рәхмәтләрен җиткерергә ашыкты.

— Бу минем бурычым,— дип, җавап бирдем.— Ни белән бетәсен әйтеп булмый бит әле. Мактарлармы, тотып ябарлармы, ахыры билгесез...

Ул үзенең дус-ишләре һәм гаиләсе белән килгән икән. Күрешергә вәгъдәләшеп аерылдык.

Югары Совет бинасының кырыкмаса-кырык ишеге бар. 14 нче хисап номерлы ишек төбендә Югары Совет Рәисе урынбасары, күрше Чуваш Республикасыннан сайланган депутат Валентин Агафонов белән очраштык. Янәшәсендә ике тән сакчысы.

— Син кайда югалдың?— дип, кул суздьı ул күреп алуга ук.

— Югалмадым. Әнә, мәйданга халыкны алып килдем,— дигән булам, шапырынып.

Авызы ерык Валентин Алексеевичның куанычы эченә сыймый. Нинди генә югары дәрәҗәгә күтәрелсә дә авыл кешесе — авылныкы инде, эчендәгесе тышында.

— Әйдә, якташ, без болай итик. Дүртенче катка меник тә, шуннан күзәтик. Монда торсак, берни күрми калабыз, югыйсә,— диде ул.

— Киттек,— дидем. Көне буе ач карынга урамда йөрүдән шактый йончыган чак. Туңдыра, калтырата да башлаган иде инде. Көн кояшлы булса да, октябрь ае бит.

Лифтлар эшләми. Җәяүләп күтәрелдек. Йрекле Россия мәйданының Мәскәү мэриясе тарафына караган тәрәз каршысына килеп бастык.

— Рәхмәт, Валентин Алексеевич,— дидем, ихластан.— Моннан караганда мәйдандагы вакыйгалар бөтенләй башкача күренә икән.

— Мин дөньяда күбрәк яшәгән шул, беләм,— диде ул, кәеф күтәренкелеге белән.— Күрәсеңме, әнә «Мир» кунакханәсеннән кемнәрнедер алып чыгып киләләр.

Күрми диләрме соң. Җиде-сигез милиция полковнигын һәм Мәскәү мэры Лужковның кайсыдыр урынбасарын, ялгышмасам, аның фамилиясе Бахновский иде, «кулга төшергәннәр». Ак йортка таба алып киләләр. Як-якка тайпылып юл бирә халык. Әмма үзләренә теләсә ни кычкыралар, йодрыклар белән кизәнәләр, кундырып та алалар булса кирәк. Алып чыгучылар тегеләрне «самосуд»тан саклый.

— Чү,— дип куйдым, үзалдыма.— Рәфкать Заһидуллович түгелме соң аларны алып чыгучы.

— Әйе, әйе, Рәфкать Чеботаревский,— дип җөпләде Агафонов.— Ул бит анда Мәскәү мэриясе һәм эчке эшләр министры Еринның урынбасарлары белән сөйләшүләр алып бара иде.

Рәфкать Югары Советның Оборона һәм хәрби эшләр комитеты рәисе, контр адмирал, ана телен камил белгән татар егете. Якын дусларымның берсе иде. Аның белән горурланып куйдым. Мэр урынбасары һәм бер генерал аның тәмам куенына кереп елышканнар. Юкса, халык нәфрәтеннән котылыйм димә, һәркайсының кулы йодрыкланган һәм югары күтәрелгән. Рәфкатьне беләләр, таныйлар, ул яклаган кешегә эләкми, әнә. Гаҗәп күренеш иде бу.

Әмма игътибарыбыз читкә тайпылды шунда. Каршы яктагы шәһәр мэры бинасының югары катыннан берьюлы дистәләгән утлы коралдан шатыр-шотыр атарга керештеләр. Мәйданда паника купты, халыкның барыр җире юк — ул дулкынлана, офтана гына ала. Ул да түгел, без як-якка елышып өлгергән арада, әле генә йөз белән капланып диярлек күзәтеп торган тәрәзәбезгә автомат белән сиптермәсеннәрме!..

Йөрәк жуылдап куйды. Җан тәслим кылуың да бар бит шулай. Кайчан да булса шул рәвешле үзебезгә төбәп атарлар дип кем уйлаган. Башка сыймый торган хәл бит бу.

— Бу безгә адресланган кучтәнәч булды, Ринат,— диде Валентин Алексеевич.

— Читләшеп өлгермәгән булсак, беткән идек бит,— дим, йөрәк сикерүен тавышыма чыгармаска тырышып.

Сүзебезгә Агафоновның тән сакчысы кушылды. Ул хәрби кеше, озак еллар КГБда хезмәт иткән офицер.

— Курыкмагыз,— диде ул.—Үтерим дип түгел, куркыту өчен аттылар. Аларның һәммәсендә оптик төзәү җайланмалары бар. Әмер булса, чигәгезгә генә атарлар, чигәләрегезне саклагыз. Тәрәзә ватып тору да кирәкми аның өчен, бер пуля, тәрәзә пыяласындагы нәни бер тишек җитә.

— Рәхмәт. Җиңел булып китте,— дидем, уенын-чынын бергә кушып. Кирәк бит, шаркылдашып көлеп тә алдык әле шунда.

— Нигә кирәк булды бу атыш?— дип сорады Агафонов.

Әлеге дә баягы тән сакчысы җавап бирде:

— Каршы тарафны җавапка чакыру өчен. Провокация дип атала бу,— диде.

Һәм шулай булып чыкты да. Ике-өч минут ара уздымы икән, халык арасыннан автоматлар белән коралланган җиде-сигез егет мэрия бинасына илтә торган сөзәк баскычлардан күтәрелеп эчтән бикләнгән ишекләргә һөҗүмгә ташланды. Болары, күренеп тора, чын профессионаллар иде инде. Автоматларын бил тиңентен тоталар. Кыска очередьлар белән аталар да, печән чабу җайланмасы кебек әле сулга, әле уңга таба сикергәлиләр, йөгереп китәләр... Тагын аталар һәм тагын җигелмәгән яшь тай сыман уйнаклап алалар. Карап торсаң, исең-акылың китәр, шул кадәрле көтелмәгән хәрәкәтләр ясыйлар ки, күз иярми артларыннан. Каршы яктан да аталар үзләренә, әмма тегеләре күренми, тегеләре ышыкланган, качкан. Болар — ачык мәйданда. Шулай да әлеге егетләрнең икесенә тидерделәр. Берсе гөрселдәп йөзтүбән егылды да хәрәкәтсез калды. Икенчесе озак кына борсаланды, торырга итенеп, тезләнеп тә карады. Әмма тагы аттылар үзенә һәм тагы тидерделәр. Башын ташка салды бичара.

Нәкъ шул мәлдә, зур түрәләрнең машиналары ишек төбенә үк менеп туктасын өчен җайлап ясалган күпер-юлдан, югарыга өч «Урал» машинасы килеп менде. Таныш машиналар. Берсе борылырга да өлгерми калды, тәрәзәсен коеп төшерделәр. Йөртүчесе рульгә башын салды һәм тукталды. Икенче машина зур тизлек белән мэриянең пыяла ишегенә килеп кадалды. Яңадан артка чикте. Тагы пыяла диварга килеп бәрелде. Һәм шуның белән тынды, башкача хәрәкәт итмәде. Ә өченче машинаның йөртүчесе хәйләкәррәк булып чыкты. Ул машинасын арты белән борып куйды. Һәм артка таба хәрәкәт итеп тишепме-тишә пыяла диварларны. Тоташ дип әйтерлек җимереп чыкты беренче катны. Һәм үзе дә исән калды.

Ә теге пыяласыз калган диварлардан бина эченә атыш-сугыш белән кораллы егетләр бәреп керде. Аларның сафлары шактый ук ишәйгән иде инде.

Китапка охшатып эшләнгән әүвәлге СЭВ, хәзер шәһәр башлыгы бинасы эчендә булган вакыйгаларны күрү мөмкин түгел иде. Әмма атыш һәм шартлау авазлары шактый озак дәвам итте анда.

Бераздан шәһәр башлыгы бинасыннан кулларын аркага куйган милиция колонналары чыга башлады. Кулга төшүчеләр... Бирелүчеләр ике йөздән артык булганнардыр. Болар әле икенче көнне дә, ягъни тупка тотылган 4 октябрьдә, Югары Совет бинасының 8 нче ишегеннән кергән җирдә, үз язмышларын үзләре аңламыйча идәндә тезелешеп утырдылар.

Агафоновның тән сакчыларыннан берсе баядан ук кулындагы нәни элемтә аппараты белән кайнаша. Колак төбендә генә «шыгыр-шыгыр...» килеп, тәмам ачуны чыгара башлаган иде. Хуҗасы дәшмәгәч, мин түздем... Шулай да бу үҗәтлекнең үзенә күрә бер хикмәте дә булган икән. Теге нәни тартма сөйләшә башлады бит кинәт:

— «Бөркет...», «Бөркет»..., хәбәр ит. Сез кайда, ничәнче катта хәзер?..

— «Үзәк», ишетәсезме... Без дүртенче катны алдык. Каршылык күрсәтү зур булмады. Солдатлар үзләре бирелә. Нигездә, офицерлар күрсәтә каршылыкны. Гранатометтан аталар.

— Югалтулар зурмы? Җавап бир, «Бөркет».
— Яраланучылар байтак. Үлүчеләр... безнең тарафтан өч-дүрт сугышчыдан артык түгел.
«Үзәк» дигәне Югары Совет бинасыннан. Аның тавышы яхшы таныш иде миңа, Александр Руцкойның ярдәмчесе. Ә «Бөркет», яшеренбатырын түгел, элекке СЭВ, хәзерге Мәскәү мэры бинасын штурмлаучылардан.
— «Бөркет», ишетәсеңме, күрәләтә башыгызны утка тыкмагыз. Егетләрне саклагыз. Максат — үтерү түгел, азат итү...
— «Үзәк», мин сезне аңладым. Алар бишенче катны бирергә җыенмый. Ныклап әзерләнгәннәр, сейфлардан корыч стена корылган... берөзлексез аталар, баш тыгарлык түгел.
— «Бөркет», һөҗүмне туктатып торыгыз. Элемтәгә керегез үзләре белән. Югары Совет бинасына һәм мәйданга атуларын туктатсыннар. К...гыма китсенмени алар, күңелләре булганчы бикләнеп ятсыннар шунда — бишенче катта. Атмасыннар гына. Ашыйсылары килгәч, чыгарлар.
— «Үзәк», мин сезне аңладым. Сөйләшүләргә керешәм...
Сөйләшүләр уңай нәтиҗә бирде булса кирәк, тора-бара автоматтан аткан авазлар сирәгәя барып, тынып калдылар.
Без дә иркенләп сулыш алдык. Валентин Агафонов сәгатенә карап куйды һәм үзенең Хасбулатов янына барырга җыенуын хәбәр итте. Мине дә үзе белән чакырды.
Рәхмәт белдереп, аерылу җаен карадым. Түрәләр артыннан колын кебек тагылып йөрүне табигатем өнәми.
Бер ялгызым калып, өченче катка төштем. Һәм кайчандыр тәмлетәмле ризыклар сатылган буфет каршындагы тоташ пыяладан гыйбарәт тәрәзә каршысына барып утырдым. «Азат Россия» мәйданы халык белән шыгрым тулы. Шунда бу мәйданның исеме сәер тоелды миңа. Бу исем 1991 елның август вакыйгаларыннан соң бирелгән иде бугай. Ялгышмасам, рәсми рәвештә. Ачык кына итеп әйтеп буламы: соңгы елларда Россия һәм аның халкы азатителдеме, әллә, киресенчә, кабалага төшерелдеме?
Ярар, ни булса, шул булыр. Без үзебез дә әллә кая китмәгән бит, әнә. Совет чорында да Татарстаныбызны «бәхетле, иректә һәм гөрләп чәчәк ата торган ил» дип, җырлар җырладык, мактап туймадык. Бүген исә, тәмам һуштан язып, «без мөстәкыйль» дип күкрәк сугабыз. Мөстәкыйльлек нинди була икән, бер-бер күргән, яисә тотып караган кеше бармы икән шуны?!
Шәһәр һәм поселок саен «Азатлык» һәм «Ирек», «Бәйсезлек» урамнары. Урамнары бар-барын, әмма чын азатлык, ирек һәм бәйсезлек кенә юк. Һәм, гомумән, адәм баласы өчен җир йөзенең бер-бер почмагында бармы икән ул чын ирек?..
Мәйдан тулы. Ә үзенә һаман халык агыла. Ул да түгел, ни рәвешледер, «Баррикадная» метросы тарафыннан да юл арчылып, аннан да халык ташкыны бәреп керде.
Америка Кушма Штатлары илчелеге урнашкан тар тыкрыкта ниндидер ыгы-зыгы дәвам итә иде. Аннан «әсирлеккә төшерелгән» өч-дүрт бөркәүле йөк машинасы алып кайттылар. Һәм шактый биек антенналы хәрби элемтә машинасы. Бөтен байлыкны мәйданга куалар иде.
Ул машинада, имеш, бөтен Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенә көче җитә торган радиотапшыргыч та бар икән. Ике-өч минуттан, көйләп, үзен эшләтеп тә җибәрделәр. Чират торып диярлек халыкка мөрәҗәгать итәргә керештеләр. Руцкойның мөрәҗәгатен укыдылар, Хасбулатовныкын. Бабурин сөйләде кулларын болгый-болгый.
— Сергей, — диделәр үзенә. — Кулларың кесәдә генә торса да ярый. Телевизордан күрсәтмиләр әлегә...
Владимир Исаков бу машинага хәтта мине дә алып кереп чыкты. «Татарча бер-ике авыз сүз әйт. Мәскәү татарларына...» — дигән тәкъдим-

не ишеткәч, каршы алмадым. Кыскасы, азмы-күпме күзгә бәрелеп торган һәр депутат, сәясәтче хакимиятне, аерым алганда, Ельцинны сүгеп чыгарга өлгерде шул машинада. Бирделәр кирәкләрен, тетмәсен теттеләр.

Соңыннан, бу вакыйгалар шау-шуы тынгач кына мәгълүм булды: «Радиотапшыргыч булмаган икән ул. Махсус органнар китергән язу җайланмасы булган». Менә шулай!

Югары Совет бинасы эченә дә җан керде.

— Җәмәгать, митинг... Биш минуттан митинг башлана,— дип хәбәр тараттылар.— Халыкка Руцкой һәм Хасбулатов мөрәҗәгать итәчәк...

Митинг яхшы нәрсә, әлбәттә. Эх, бер тамакны ялгап алсаң иде ул. Аякларымны чак-чак өстерәп мин дә икенче катка, мәйдан каршындагы трибунага уздым.

Хасбулатов тәбрикләде халыкны. «Ни белән тәбрикләде?» дисезме. Җиңү белән! Ул да табигать баласы шул — хисле, мавыгучан һәм вакыт-вакыт артык беркатлы. Аңарга башкалар кушылды: Аксючиц, Астафьев, Уражцев, Бабурин... Болар һәммәсе форсат чыккан чакта микрофонны урап узмый торган егетләр. Яшәү рәвешләре шундый. Микрофон күрсәләр — күзләре йомык булса да сикереп торалар.

Ялкынлы нотыкчылардан берәве шул мизгелдә шәһәрнең икенче бер почмагында, ягъни Останкинода, күпсанлы халык төркеменең тыныч демонстрация рәвешендә телевидение үзәгенә якынлашып килүе хакында хәбәр итте. Табигый инде, мондый хәбәрне мәйдан «Урра» кычкырган авазлар белән каршылады, шатланмас җиреңнән шатланырсың. Телевидение ни теләсә, шуны эшләде бит ул заманнарда. Акны да кара итте, караны ак итте.

Шул хәбәрдән башланды да бугай инде. Микрофонга чыккан һәр трибун «Останкино»дан бер-бер яңа хәбәр җиткерергә тырыша. Дөрес сөйлиме ул, түгелме — хикмәт андамыни. Хәбәр саллырак, сенсациягә якынрак булсын. Ә халык ул яңалыкларны үз җиңүе кебек дәррәү кул чабып каршы ала. «Урра» кычкырулар кабатланып тора.

Уйлап куйдым: телевидение үзенең тоташ ялган сөйләп торуы белән кешеләрнең тәмам теңкәсенә төшкән. Дөрес информациягә, үзләренең җаннары теләгән хәбәргә сусаган икән бу гади халык. Тормыш авырлыгыннан да авыррак кабул ителә икән ул көн-төн тоташ агып торган ялган. Шул вакытта, шул сәгатьтә, иманым камил, мәйданда җыелган халыкның бик зур күпчелеге, шул җөмләдән халык депутатлары да, илдәге бәла-каза чыганагы Кремль сарайларына кереп оялаган сәясәтчеләр булуын хәтерләреннән чыгарган иде. Дөньяның кендеге «Останкино»да булып тоелгандыр: тормыш-көнкүрешнең авырлыгы да, халыкларның бәхетсезлеге дә, илдәге тәртипсезлекләрнең дә очы шунда. Һәммәсе дә көйләнсен өчен, әйтерсең лә, «Останкино»ны гына кулга төшерәсе калган...

Хәер, бер карашка, болар нигезсез дә түгел. Информация чыганагы булмаса, пропаганда ысуллары булмаса, кем соң ул хакимият башлыгы?! Сәясәтче кем?! Хәтерләүчеләр булырга тиеш, Ельцинны үз вакытында ни рәвешле герой ясадылар. Бер үзе җиде башлы аждаһа елан белән көрәшкәндәй, Политбюрога каршы чыгучы ул иде бит! Горбачевтан да курыкмады, эшсез калса-калды, көрәште! Шәһәр транспортына, троллейбусларга утырып эшкә йөрде. Гади хезмәт кешеләренең тормышын яхшырту, түрәләрнең өстенлекләрен киметү һәм бөтенләй юк итү өчен көрәште! Тормыш дәрәҗәсе төшә-нитә кала икән, рельска аркылы ятарга вәгъдә бирде. Өстәвенә нинди генә бәла-каза, сынаулар узмады бит әле: үзен капчыкка салып суга да агыздылар («Таһирны сандыкка салып агыздылар суларга...», дигәнне кыйссалардан укып өйрәнгәнмени...). Испания күгендә ул утырган самолет катастрофага юлыкты. Мәскәү үзәгендә машинасына машина белән китереп бәрдерделәр. Хәтерегездәдер,

Кызыл мәйданга берсе аны ату өчен ау мылтыгы тыгып килгән иде берзаман. Ә теге Себер якларыннан килеп Кремльгә үтеп кереп аны атарга хәстәрлек күргән офицерны онытып буламы соң!.. Рембо ясадылар Борис Николаевичтан. Президент кына түгел, югары класслы зур теннис мастеры гына да түгел, үлү кая, җиңелүне белмәс кино йолдызы Рембо ясадылар. Телевидение һәм радио әнә шундый хикмәтләргә ия көч ул. Мин үзем Борис Николаевичны гына түгел, Шахрайны, Бурбулисны, Филатовны, Шумейконы һәм тагы әллә кемнәрне якыннан күреп, аралашып беләм. Һәркайсының көчле яклары бар, җитешсезлекләре дә... Әмма аларны дөньякүләм шәхесләр ясаган көч, үзләреннән элек, телевидение! Баксаң, гап-гади уртакул аксөякләр алар.

Менә ни өчен 3 октябрь кичендә «Останкино»га штурм башланды. Рембо, Шварцнегер, Тарзаннардан да көчле булырга теләүче аксөякләр икенче тарафта да байтак иделәр шул. Ә иң хикмәтлесе һәм үзенә тартып торганы — хакимияттер, әлбәттә.

Ул көнне «Останкино» әйләнәсендәге вакыйгаларны мин күрмәдем. Ләкин анда булган дистәләрчә кеше белән күрешеп-сораштырып чыктым. «Останкино» телевидениесендә эшләгән егетләр-кызлар да бар иде болар арасында. Хәтта ул көннәрдә «Останкино»ның җитәкчесе булып эшләгән Вячеслав Брагин белән дә иркенләп сөйләшеп утыру бәхетенә ия булдым. Әлеге хезмәткә алынганга кадәр ул Россия Югары Советында, минем кебек үк, комитет рәисе булып эшләгән иде.

Ә инде каршы тарафтагылар арасында таныш-белешләр буа буарлык. Югарыда искә алынган каләмдәшем Валерий Хайрюзев, үзенең хатыны һәм ике улы белән, баштан ахыргача халык арасында булган ул көнне.

Анда да вакыйгалар якынча Парламент бинасына килгән хәрәкәтне кабатлаган. Рига вокзалы тирәсендә йөз меңгә якын халык җыйналган. Гаҗәп түгел, кояшлы көзге көн иде бит, өстәвенә ял көне. Аларны да башта ОМОН һәм милиция хезмәткәрләре урап алып чолганыштан чыгармый торган. Соңрак, ике арада этеш-төртеш булып алганнан соң, юл ачылган. Тынычлык проспектыннан Королев урамына борылган җирдә тагы бер мәртәбә тоткарлык ясарга ниятләгәннәр. Бу юлы да милиция һәм ОМОН халык ташкынына әллә ни зур каршылык күрсәтмәгән. Киресенчә, аларның ул гамәлләре тыныч хәрәкәт иткән кешеләрне беркадәр кыздырып тору өчен генә эшләнмәдеме икән, дигән гоман кылу да бар. Аларны яңа штурмга илһамландыру өчен генә каршылык күрсәткән булып кыланмадыларммы...

«Останкино»ны байтактан кораллы ОМОН саклый иде инде. Югарыда искәртелгәнчә, гаять җитди объект шул. Хәтта ул көнне иртә таңнан берничә бронетранспортер килеп кушылган була телевидение үзәген саклаучыларга. Шунысы гаҗәп, халык хәрәкәте якынлашып килгән сәгатьтә генә ул машиналар бөтенләй кире тарафка китеп югалалар.

Урам тутырып килгән халыкны «Останкино» үзәгенә якын ук үткәрәләр. Утлы коралдан ату түгел, хәтта юлларына каршы төшеп яңаучы, кисәтүче дә булмый.

Шул сәгатьтә, ниндидер юллар белән, Югары Советтан хәбәр килеп җитә: «Блокада өзелгән... Халык массалары Ак йортны камалыштан азат иткән. Армия, Конституциягә тугрылыклыгын саклап, халык депутатлары тарафына күчкән», имеш. Әйе, әйе, тавышкөчәйткечләр аша халыкка нәкъ менә шундый хәбәр җиткерелә. Бу бит җиңү дигән сүз! «Останкино»га үтеп керәсе генә калган түгелме соң?! Үтеп керәсе һәм тоташ ялган сөйләп торган дикторларны сүзләреннән бүлеп, бөтен ил алдында хакыйкатьне ачып саласы. Барысы да табигый, җиңел һәм гади генә бит!

Күрәсең, нәкъ шул вакыттадыр, Югары Совет утырышына җыелган депутатларга куанычлы хәбәр җиткерелде: «Останкино» азат ителде. Тагы берничә минуттан Россия Федерациясендә акны — ак, караны — кара дип, дөресен сөйли торган халык телевидениесе эшли башлаячак».

Килде-китте кеше түгел, Россия Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов авызыннан чыккан хәбәр булды бу.

Зал тутырып утырган халык вәкилләре урыннарыбыздан сикереп торып, дәррәү кул чаптык, бер-берләребезне котларга, тәбрикләшергә кереттек. Илгә демократия кайта, илдә демократия принциплары ныгый икән болай булгач, дигән өмет уянды минем күңелдә дә. Табигый инде, күпләр әлеге куанычлы хәбәрне дуслары, танышлары белән бүлешү өчен шундук залдан чыгып йөгерделәр. Ике-өч кайнар йөрәкле трибун әле дә булса мәйданда дәвам иткән митинг каршысына чыгып та хәбәр итә бу яңалыкны. Ә без исә, шул исәптән мин үзем дә, тагы да олырак беркатлылык күрсәткәнбез.

Кабинетка кереп, телевизорны кабыздым. (Ул кичне ике сәгать чамасы ут биреп тордылар). Дусларым, танышларым җыйналды. Илдә яңа телевидение нинди сүздән башланыр икән? Ничегрәк булыр икән бу хәлләр. Россия каналында ялган сөйләүче таныш диктор — Сорокина. Ул «Останкино»дагы хәлләр турында сөйли. Ниндидер сугыш, чын штурм бара икән бит анда. Хәтта автоматлардан аткан авазлар да ишетелеп киткәндәй була.

— Беренче программага күчер. Беренчегә, «Останкино»га,— дип киңәш итте коми егете Николай Ген. Күчердем. Анда исә хәлләр тагы да киеренкерәк. Диктор ачкан авызын яба алмыйча югалып-югалып тора. «Юк,— диде ул, ниһаять, мондый шартларда эшләп булмый. Һәр тарафта атыш бара... Чү, безнең катка да менеп җиткәннәр түгелме соң инде». Һәм телевидение тапшырулары «Останкино»да вакытлыча туктатылып торды. «Россия» каналы исә, үзенең резервтагы икенче студиясенә күчте.

Менә сиңа, мә, дигәндәй, бер-беребезгә карашып куйдык. Илдәге ыгы-зыгыны тәмамлап, кул кушырып телевизор карарга утырдык кына, югыйсә. Юк бит, ә... тынычлап яшәргә бирмиләр. Тагы нинди атышу дигән сүз инде ул!

Безнең кебек уннан артык көн дәвамында электр утының ни икәнлеген онытып торучылар өчен, телевизорның берни күрсәтмичә чыжылдап кына утыруы да казаныш иде, әлбәттә. Шулай да, телевизор самавыр түгел, аның чыжылдавы тиз туйдыра икән. Утларны сүндереп, кайнап торган урамга чыгып киттек.

Урамдагы халык, табигый инде, безгә караганда да хәбәрдаррак булып чыкты. Чынлап та, «Останкино»да вакыйгалар шактый куера бара төсле. Сөйләүләренә караганда, түбәндәгечә булган: халык ташкынын телевидение үзегенә якын ук үткәргәннәр. Югыйсә, соңгы ике елда бик нык сакланган ул тарафларга аерым-аерым гына да якын җибәрмиләр иде. Килүчеләрнең кулларында урак-чүкеч төшкән кызыл байраклар һәм төрле сәяси лозунглар язылган комачлар була. Колонналарны әйдәп килүчеләрдән бер төркемне бинаның эченә үк үткәрәләр. Халык тынычланып кала. Талчыккан аякларын язу теләге белән, кемнәрдер яшел чирәм өстенә барып утыра, кемнәрдер коймага барып сөялә. Ара-тирә гармун тартып частушка әйттерергә керешкәннәр.

Һәм шулчакны, көтмәгәндә, телевидение үзәге тарафыннан халык өстенә ут ачалар, атарга керешәләр. Ышанырлык түгел, бер-бер сәбәп, һич булмаса, бер-бер кисәтү-фәлән булгандыр, булырга тиешледер кебек тоела. Дистәләгән кешедән сораштым, булмаган андый кисәтү. Кисәтү яисә куркытып ату гына да булмый бу, берәзлексез атып торалар халык өстенә. Аны-моны аңламаган халыкның асфальт өстенә сузылып ятудан башка чарасы калмаган. Һәм берничә сәгать дәвамында баш калкытырга бирмәгәннәр.

Күрәсең, нәкъ менә шул мизгелдә «Останкино» каналы эшләүдән туктагандыр. «Аталар, һөҗүм итәләр. Эшләп булмый...»— дигән сүзләре чираттагы ялган булырга охшаган. Чөнки, тикшерүләр күрсәткәнчә, ул вакытта халык арасында коралланган кешеләр булмый әле.

Югары Совет бинасы «Останкино»дан, ким дигәндә, бер ун чакрым ераклыкта булыр. Менә шул хәбәрләр килеп ирешкәннән соң Александр Руцкой Югары Совет каршындагы митингка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булгандыр. Мин мәйданда халык арасында идем. Үз колакларым белән ишеттем Руцкойны.

— Хөрмәтле иптәшләр, туганнар,— диде ул.— «Останкино» янында меңләгән гаепсез кешеләрне шушы минутларда утка тоталар, үтерәләр. Аларга ярдәм итми хәлебез юк безнең. Хәзер үк, генерал Ачалов җитәкчелегендә, машиналарга төялеп ярдәмгә ашыгырга кирәк... Сугышу өчен түгел, безгә ышанган, безгә ярдәмгә килгән ватандашларыбызны, мәскәүлеләрне коткару өчен. Сөйләшүләр алып бару өчен...

Бер сәгать, сәгать ярым гына әүвәл кулга төшерелгән машиналар эшкә ярап куйды шунда. Алдагы ике машинада автоматлар белән коралланган хәрбиләрне дә күрдем, дөресен әйтергә кирәк. Яшь-җилкенчәк егетләр төялде машиналарга. Иң алдагы машина өстендә Кызыл байрак күтәрделәр. Халык ташкыны як-якка аерылып хәрәкәтләнергә керешкән машиналарга юл бирде. Кузгалдылар... Тартмалары кеше белән тум-тутырык машиналарның артыннан яшүсмерләр йөгерә, куып җитә алганнары югары күтәрелә иде әле һаман. Барган шәптән машина өстенә сикерәләр — зур вакыйгаларның шаһиты булырга теләүчеләрнең исәбе-хисабы юк.

Кайсыберәүләрнең әниләре, хатыннары да шунда икән. Киңәш бирәләр. Артларыннан кычкырып калалар:

— Андрей, саграк бул...

— Вася, егыла күрмә, ябышыбрак утыр...

— Николай, кая барасың, сиңа ни калган анда...

Шул рәвешле, дүрт-биш машинаны озатып калды мәйдан. Һәммәсе берөзлексез сигнал бирә-бирә, Кызыл байракларын җилфердәтеп, Мәскәү урамнарына кереп югалдылар. Башкаланың үзәк урамнары аша машиналар бер тоткарлыксыз һәм югалтусыз «Останкино»га барып җитәләр.

Боларны анда көтеп торганнар. Машиналарның өстенә, килгән шәптән, ут яудыралар. Күп кенә егетләр шыплап тулган машина тартмаларыннан сикереп төшәргә дә өлгерми ятып кала.

Ярдәмгә килүчеләр арасында утлы корал белән коралланган утыз-кырык сугышчы була. Алар, борчак кебек сибелеп, йөгерә-шуыша халык өстенә әле булса ут яудырудан туктамаган телевидение үзәге эчендәге махсус гаскәри берләшмә — «Витязь»лыларга каршы хәрәкәт итәләр. Ике арада атыш башлана. Ә мәйдан җиргә сыенып яткан коралсыз кешеләр белән тулы. Арада үлүчеләр, яралылар байтак...

Нәкъ шул мизгелдә ВДНХ тарафыннан бронетранспортерлар килеп җитә.

— Ярдәмгә БТРлар килә, ур-ра!— дип, кычкыра берәү.

Кем кычкыруын ачыклап тормыйлар, ышаналар, әлбәттә. Әле генә асфальтта хәрәкәтсез яткан кешеләр сикереп үк тора, һич югында башларын калкыталар.

Ул да түгел, Ак йорт тарафыннан ярдәмгә тагы өч-дүрт машина тум-тутырык яшь-җилкенчәк килеп җитә. Бу вакытта элгәрерәк килгән машиналарның кайсыбер пассажирлары исән була әле. Телевидение үзәгенә барып ук җитүчеләр, аның беренче катына үтеп керүчеләр шулардан.

Башкасына сан юк хәзер. Әнә, БТРлар тәмам якынлашып ук киләләр. Тигез бер колонна булып килгән җирдән як-якка сибелеп тизлекләрен киметәләр алар. Һәм... Иң элек, әле генә килеп туктаган машиналардан төшүчеләрне кырып салалар. Аннан соң ике яктан да ут эчендә торып калган кешеләрне кысрыкларга керешәләр. Эре калибрлы пулеметлар тегермән тарта. Менә сиңа армиядән килгән ярдәм!..

Билләрне турайттык, ниһаять, дип иркен сулыш алучылар яңадан яшел чирәмгә яисә тузанлы асфальтка капланырга мәҗбүр. Һәм шул

хәлдә караңгы төнгә кадәр яткыралар үзләрен, башка һичбер вакытта да «демократик Россия»дагы сәясәткә каршы чыкмам дип тәүбә иттерәләр.

Исән-сау калганнар, төн уртасында гына шул тикле мәхшәрдән котылуларына ышаныр-ышанмас, өйләренә таралыша. Җәрәхәтләнүчеләрне дә фронт сызыгында калдырмыйлар, камалыштан кайсын өстерәп, кайсын җилкәгә салып коткарырга тырышалар. Ә үлүчеләр ятып кала...

Аларын таң беленгәнгә кадәр хәрбиләр җыеп ала. Берсе дә онытылып калмый, барысын да җыештыралар. Икенче көн иртән мәйданга һичкемне үткәрмиләр. Ерактан, күпкатлы йортларның тәрәзәләреннән карагандa, күлдәвекләр булып җыелган кан эзләре аерымачык күренми. Әллә кан ул шунда, әллә БТРлардан агып калган май яисә дизел ягулыгы эзләре.

Югары Совет бинасында һәм аның әйләнәсендәге мәйданнарга тупланган халык ул кичне, ул төнне киеренке бер көтү белән яшәде. Бер карасаң, барысы да иплe кебек иде. Теләсәң, кер, теләсәң, чык, блокада өзелгән. Теләсә кая бар, теләсә ни сөйлә — хөррият. Ярамый, дип кисәтүче юк. Милиция хезмәткәрләре Ак йорт тирәсендә генә түгел, гомумән, Мәскәүнең әйләнә-тирәдәге урамнарында да күренмәгән ул кичне.

Әмма, барыбер, аңарга карап киеренкелек кимемәде. Баштарак, минутларны санап, «Останкино»дан хәбәр көттеләр. Матур, куанычлы хәбәр көттеләр, әлбәттә. Килмәде ул хәбәр. Киресенчә, «Останкино» әйләнәсендә үлүчеләр, яраланучылар бик күп икән, дип сөйләделәр. Халыкны тоташтан кырып салганнар икән, дигән имеш-мимешләр дә йөрде. Ә соңрак исә, ярдәмгә дип киткән дистәләгән машинадан икесенең кире әйләнеп кайтканлыгын күрдем. Ул машиналардан үз аяклары белән сикереп төшүчеләр саны, күп булса, ун-унбиш булгандыр. Ә калганнарын ташыдылар... Мәйдан пышылдап сөйләшергә дә кыймый торды бер мәл. Тоташ сыкрау, ыңгырашу авазлары яңгырап торды. Шифаханәләр Мәскәүдә, гомумән, юк диярсең, ашыгыч ярдәм машиналары хакында әйтеп тә тормыйм, барысын да мәйданның каршы ягындагы ике катлы бинага ташыдылар...

Анда-санда елаган авазлар ишетелде. Үз улларын таба алмаганга изаланып, үкереп-үкереп еларга кереште аналар. Ай-һай, авыр, йөрәкләр күтәрә алмас дәрәҗәдә авыр һәм газаплы икән ул аналарның кайгы-хәсрәт авазын ишетү.

Бәгырьне өзгәләгән ул авазлар озак дәвам итте. Әмма тора-бара мәйданга барыбер беркадәр җан иңә башлады. Төрле гоманлаулар, фикер алышулар кузгалды. Тыңласаң, исең-акылың китәрлек. Ельцин белән Гайдар шәхси самолетларына утырып илне ташлап үк китеп барганнар, имеш. Попов белән Яковлев бик ялынып-ялварып сорасалар да, тегеләр үзләре белән алмаганнар икән. «Альфа» группасы депутатларны якларга җыена, имеш. Мәскәүгә Югары Советны яклау өчен Туладан танк дивизиясе һәм Рязаньнан парашют-десантчылар юлга чыккан икән... Ниләр генә сөйләмиләр...

Ярый, хәерлегә булсын, дидем дә, тынгысызланып, бер ялгызым мәйданның тынычрак почмагын эзләп китеп бардым.

Тимер-томыр һәм таш кисәкләреннән ясалган баррикадалар читендә үзенә күрә бер нәни генә палаткалар шәһәрчеге хасил булган иде. Читләтеп узып киткәндә һәрчак игътибарым җәлеп итә иде болар. Ак йорт тәрәзәләреннән карап, күзәтеп торган чакларым бар иде бу тарафны. Болар монда даими яшәүчеләр. Бер карасаң, һәммәсенең язмышы уртак кебек аларның. Әмма ныклабрак, якынгарак килеп күзәтсәң, болар да төрле-төрле. Үзләрен бу тынгысыз таш мәйданга төрле-төрле язмыш, бәхетсезлекләр китергән.

Сакал-мыек үстереп, иске бушлат киеп, нәни генә учак янында ботка пешереп, чәй кайнатып көн күрүчеләре бар. Нинди яшьтә булуларына карамастан, арыган-талчыккан, күзләре тоныкланган, төрле сәбәпләр

аркасында яшәүдән дәртләре сүнеп барган кебек тоела боларның. Кайсыберләренең кулында гитара да күргәнем бар, ләкин ул уен коралы аларның кулында, кагыйдә буларак, дәшми. Чиерткәләп алсалар да, бу мәйдан өчен түгел гитара тавышы — ишетелми, һичкемне җәлеп итми ул үзенә.

Баеп килгән шәфәкъ, сүнеп барган учак, төсе уңган зәңгәр күзләр... Һични белән шаккаттыру, игътибарларын җәлеп итү мөмкин булмагандыр аларның. Яннарына ук барып, бер ары үтеп, бер бире килеп күзәттем. Әллә бар идем мин алар өчен, әллә юк. Кәефемне кырды бу минем. Инде дә килеп әрсезлек күрсәтергә җөрьәт иттем. Кайчакта безнең кебек язучы-журналист халкына килешә ул.

— Нигә болай күңелсез утырасыз, егетләр?— дим, үземне бик бәхетле һәм күтәренке күңеллегә чыгарып.

Ничә егет утыралар, ник берсе шунда борылып карасын. Ашыкмадылар, кабаланмадылар. Шулай да бик көттереп кенә бер карлыккан тонык аваз ишетелде.

— Че, кашку захотели?

Эчкә җылы кереп китте, миңа мөрәҗәгать иттеләр булса кирәк. Әмма ышанып җитеп булмый, ым кагучы, башын боручы булмады.

— Рәхмәт, егетләр, ашыйсым һич килми,— дидем, гәрчә көннең көн буена бер кабым икмәк түгел, бер йотым су эчмәгән булсам да. Суда пешкән бодай боткасының кай җиренә кызыгасың. Үзләре дә әнә ничә кашык...

— Теләмәсәң, кыстамыйбыз,— диде шул ук тавыш. Әмма сүзләрнең кайсы авыздан чыгып, кайсының иреннәре кыймылдап алганны бу юлы да сиземләми калдым.

Инде сөйләшер сүз, эндәшергә сәбәп калмады кебек. Кистеләр ич, төптән кистеләр — ботка иснәнеп килдеңмени диделәр.

Үзара фикерләшергә кереште тегеләр.

— КГБшниктыр әле. Иснәнеп йөри,— диде берсе.

— Күргәнебез бар... Шаккатмыйбыз,— диде, бөрөзлексез ботка болгатып утырганы.

— Юк,— мин әйтәм.— Халык депутаты мин. Сезнең белән танышырга теләп килгән идем.

Башлары борылмады, күзләренә җан кермәде барыбер. Шулай да арадан берсе, әлеге дә баягы ботка болгатучысы, күңелгә охшаган тапкыр сүз әйтеп куйды:

— Депутат — ул яхшы... Шулай да ботка тәмлерәк.

Миңа күңелле булып китте. Эчкә җан керде. Ә тегеләрнең йөзләренә ник бер шаяру, елмаю чаткысы чыксын икән. Гаҗәп кешеләр болар. Андыйларны ул көнгәчә дә, аннан соң да күргәнем, очратканым булмады башка. Сәрхүш тә түгел болар, айнык дип тә булмый үзләрен, башка бер дөнья кешеләре.

— Ярый, егетләр, тәмле булсын боткагыз,— дип, ары китеп бардым.

Рәхмәт үзләренә, яман гадәтләре юк икән, артымнан сүз әйтеп, гайбәтемне сатып калмадылар кебек.

Бер-ике палатка аша шактый өлкән яшьләрдәге карт белән карчык урнашкан икән. Өсләрендә сырган фуфайка, күкрәкләрендә — орден-медальләр. Сәер кешеләр. Әмма боларның исә теле телгә йокмый. Ерактан ук күреп, бер-берен бүлдерә-бүлдерә чөкердәшеп каршыладылар үземне. Чакырып, көттереп килгән олы кунакны каршылыйлармыни...

— Җиңү белән тәбриклибез... Җиңү белән, улыкаем,— дип, кулларын суза, билен бөгә төшеп каршылады җитмеш-сиксәннәр чамасындагы бабай. Ул нәкъ менә рус халык әкиятләрендәге күпне күргән һәм хикмәтле карт образын хәтерләтә иде. Чаларып беткән куе җирән чәч һәм җирән сакал-мыек баскан үзен. Күзләре генә елтырап балкып күренеп тора. Үзенең булсын, карчыгының булсын, ихласлыклары сүзләренә, күзләренә, хәрәкәтләренә чыккан.

«Нинди җиңү белән?.. Җиңү юк һәм ул күренми дә әле...»,— дип әйтергә иде дә бит, дәшә алмадым. Кеше күңелендәге шатлык-куанычны җимерүдән курыктым. Җиңү дип саный, тантана итә икән, итсен әйдә. Бер кич, бер төн булса да бәхетле хис итсеннәр үзләрен.

— Сез белсәгез икән, безнең бүгенге шатлыкны,— дип карчыгы кушылды сүзгә.— Аны ни белән тиңләргә дә белгән юк. Кышкы сарайны алган кебек булды. Бөтен гади халык, хезмәт ияләренең җиңүе бит бу. Безнең кебек гомере буе социализм төзегән карт-карчыкларның җиңүе.

— Мин үзем бүген Берлинны алгандагыдай куандым, улыкаем,— дип шундук аны карты күтәреп алды. Шунда мин тагы бер мәртәбә өлкән яшьләрдәге рус картының күкрәгендә челтер-челтер килгән орден-медальләргә күз төшереп алдым. Минем игътибарны ул үзе дә күрде. Һәм бер горурлык хисе белән аларны сыпырып, рәтләштереп куйды. Әле шактый нык һәм матур бабай иде ул.

Карчык шигырьләр яза икән. Табигый инде, сәяси шигырьләр. Һәм ул аларның берничәсен укып та күрсәтте. Ельцин, Ерин, Бурбулис, Чубайс, Шахрай һәм Шумейко фамилияләрен шул тикле оста рифмалаштырган ки, исең китәрлек. Кызганыч, хәтердә калдырмаганмын яисә язып алмаганмын.

Телләре-телгә йокмый карт белән карчыкның, һәрчак шулай сүзгә оста булгандырмы алар. Ул кадәрле дә чишелеп, таныш булмаган кеше белән онытылып сөйләшергә ашкынып торган өлкәннәрне күргәнем юк башка һичкайда.

Үземнең дә беркадәр әдәбиятка мөнәсәбәтле булуым хакында дәшмәдем. Юкса, такмак артыннан такмак әйтеп торган карчыктан ычкыну юк иде.

Карты танкист булган икән. Волхов фронтында сугышкан. Чолганышны өзеп чыккан санаулы гына танкистларның берсе булган.

— Абзыкаем, сез легендар кеше икән бит,— дип, аркасыннан кагып алдым аның. Болай итүемнең сәбәбе бар. Минем үз әтием дә танкист бит. Ул да Волхов фронтында булган. Һәм чолганышка эләккәч, власовчылардан аерылып, үзебезнең якка бәреп чыккан танкистларның берсе — минем әти — Мөхәммәтсафа Мөхәммәдиев.

Бу хәбәрне әйтсәм, китә алмый идем мин ул кичтә әлеге шәрран ачык күңелле карт белән карчык яныннан. Бик ихтимал, картның минем әтине хәтта танып белгән булуы бар. Чөнки ул чолганыштан исән калып чыгучылар санаулы гына булган. Әтием хакында әйтсәм, туганнар булып аерылышасы кешеләр бит... Әйтмәдем. Башка бер вакытта сөйләшербез-аңлашырбыз әле, боерган булса, дидем.

Аларның күңелендә бәйрәм. Ә минекендә тынгылык юк. Алар җиңү белән тәбриклиләр, җиңүне тантана итәләр. Ә мине җиңелү ачысы, «Останкино» янында һәм Мәскәү урамнарында түгелгән кан эзәрлекли. Бу кешеләр мисалында җаным сусаган әңгәмәдәш таптым, бер карасаң. Ә үзем алардан тизрәк арынырга, качарга омтылдым, күңелнең, гади сүзләр белән генә әйтеп, аңлатып булмый торган шундый чаклары була икән.

— Сез миңа бик тә ошадыгыз,— дидем.— Мин әле сезнең янга, һичшиксез, киләчәкмен,— дип, вәгъдә бирдем.

— Улыкаем,— дип, бу юлы да үз итеп, юк, юк тәчеләнеп түгел, яратып дәште рус карты.— Син безгә ошадың. Тагын кил, көтәрбез...

Һәм исемемне сорады.

Фамилиямне әйтергә курыктым. Юкса, ул аңарга таныш булып кую да ихтимал. Исемемне әйттем.

— Татар егетеме?— дип балкыды шундук.

— Әйе.

— Татарлардан дусларыбыз, таныш-белешләребез бик күп безнең,— дип, карчыгына карап, аңардан да хуплау тапты ветеран. Һәм уйга

чумып калды.— Фронтта да күп иде татарлар. Хәтта үзебезнең танк ротасында... Шәп егетләр...

Тагы бер сүз, тагы бер сорау бирә калсам, күңелем сиздe, кочаклашачак идек.

— Күрешербез, сөйләшербез әле...— дидем. Һәм кабалана төшеп, китәргә ашыктым. Ни сәбәпледер, Алла боерсамны күңелдән генә булса да пышылдарга онытканмын.

Бәхетләр теләп, юлларыма ак җәймәләр җәеп, яңадан килүемне көтеп, үз итеп, исемем белән дәшеп озатып калды алар.

Кире борылмадым. Юлымны дәвам иттем. Соңгы палаткага кадәр барып әйләнеп кайтам, дип чыккан идем бит. Кире борылсаң, тагы да шул сәясәттән кайнап торган мәйданга юлыгасың. Таныш-белешләргә... Ә минем, нигәдер, йөрәк җилкенүдән туктамый, җан тынычланмый әле. Ни теләгән, ни эзләгәнемне үзем дә белмим. Йөрисем, күзәтәсем, күрәсем килә... Әмма берәү белән дә озаклап, чишелеп китеп сөйләшергә түземлегем җитми. Берни эшләтеп булмый, шундый халәт менә...

Ниһаять, соңгы палатканы урап уздым. Стадион коймасына эленгән карикатураларга карап тордым бертын. Халык талантлы икән шул, Тукай белми әйтмәгән. Үз эшенең осталары чыгарган сатира журналларында да ул тикле тормышчан дөреслек, оста тотып алынган образ һәм төсмерләр еш очратмассың.

Кушма Штатлар илчелеге һәм «Мир» гостиницасы тарафында ниндидер талгын һәм беркадәр шомлы тынлык эленеп тора. Минем күңелемдәге кебек... Шуңа күрә ул як тартмады, җәлеп итмәде үземне. Кайтыр юлга чыктым...

— Розалия... Розалия, ерак китмәгез...

Чү, бу нинди тавыш тагы? Онытылып барган җирдән, сискәнеп ук куйдым. Балачакта, туган авылга кайтып төшкәндәй булдым. Чиләккөянтә асып суга төшеп барган күрше Хәдичә апа үзенең кызы Розалиягә дәшәме әллә...

Тукталып, тавыш килгән якка борылдым. Нәни генә палаткадан чәчләрен озын толым итеп үргән чем кара күзле ханым карап тора иде. Үзенә таба йөгереп килгән ике кызчыкны күргәч, итәкләрен тарткалыйтарткалый каршы чыкты ул.

— Кайда йөрисез... Мин нәрсә дип әйттем сезгә,— диде ул, кызларына саф татарча һәм үз исемнәре белән дәшеп.

Розалиягә ун яшь чамасы булса, аның әле биш-алты яшьләрдә Гүзәлия исемле сеңлесе дә бар икән. Әниләре кебек янып торган чем-кара күзле, чем-кара чәчле үзләре. Куе кызылга яшел чәчәк төшкән комачтан пар күлмәк кигәннәр. Муеннарында зәңгәр яулык.

— Сез кем? Нишләп монда килдегез? Татарларга монда ни калган?— дип сорадым, аны-моны уйлап тормастан. Күрәм, өсләрендәге киемсалымда Урта Азия төсмерләнә.

Кызлар, ягъни Розалия белән Гүзәлия, кош балалары сыман, шундук әниләренә елыштылар. Әниләре дә югалып, онытылып торды бер мәлгә. Мәскәүнең нәкъ уртасында, русларның милли азатлык хәрәкәте кайнаган мәйдан читендә очраклы бер кешенең саф татарча мөрәҗәгать итүе аларга да сәер тоелгандыр.

— Без — качаклар,— диде ханым.— Таҗикстаннан. Өебезне яндырдылар. Егерме дүрт сәгать бирделәр үзебезгә.. Кая барыйк?! Килдек менә...

— Ә ни сәбәпле Мәскәүгә кайттыгыз? Мәскәүдә хәзер сезнең кайгы түгел, күрәсез. Сез монда килеп ялгышкансыз...

— Шулаен шулай да... Кая барыйк соң?!— диде ханым, ике канаты астына сыенган кызкайларын үзенә кыса төшеп.

— Татарстанга, мисал өчен. Казанга... Үзебезнең Казанга ник кайтмадыгыз?

Хатын бер мәлгә, зур гаебе бар кеше сыман, уңайсызланып калды. Ни әйтергә белми аптырап торды.

— Минем ирем рус шул,— диде аннан, тартынып кына.— Татарстанга катнаш гаиләләрне кертмиләр, дип ишеттек...

Сүзен тыңлап бетермәстән, чәчрәп каршы төштем.

— Юк сүз! Каян ишеттегез аны? Кем әйтте?

Сорау бирүен бирәм. Әмма күңелемдә башка уй: «Әнә нинди нәтиҗәләргә китерә икән уйлап әйтелмәгән бер сүз. Ә бәлки, бер гайбәт... Газеталар дөньяга чәчкән бер провокация...»

— Казан газеталары язган ул хакта. Безнең Таҗикстанда да күчереп бастырдылар аны. Үзбәкстанда да... Казанда бер депутат хатын бар икән...

— Юк,— дип бүлдерергә мәҗбүр булдым тагын.— Юк андый хатын. Гайбәт кенә бар...

Ханым тыныч, ипле холыклы күренә. Күндәм.

— Ишеткәнне генә әйтүем,— диде ул, бәхәсләшергә җыенмаганлыгын искәртеп.— Казанда туганнарыбыз да юк бит. Ирем Магаданнан. Анда да кайту файдасыз.

— Ул кайда соң әле?

— Останкинога китте. Телестудияне алырга,— диде ханым, тыныч һәм битараф кына. Күренеп тора, анда төялеп китүчеләрнең нинди фаҗигага юлыгулары турында ул әле ишетмәгән. Хәер, кемнән ишетсен. Ул үзенең дөньяда калган бар җиһазы — шушы нәни палатканы һәм ике кызын саклый. Ире кайда, ни хәлдә, исәнме-юкмы — Ходай үзе генә белә. Ә ханым тыныч, ул-бу сизенми иде әлегә.

Монда да бәхетсезлек, монда да кайгы-хәсрәт, дип уйладым үзалдыма. Болар нишли инде, кая бара? Әтиләре кайтмый калган тәкъдирдә ни була үзләре белән. Бу Таҗикстан түгел, таш мәйданда кыш чыгып булмый бит. Киемнәре дә, әнә, бик юка күренә.

Ни булса, булыр, үземне кызыксындырган бер-ике сорауга җавап алырга ашыктым.

— Ул Останкинода ирегезгә ни калган иде соң?

— Белмим шул,— диде ханым.— Азат итәргә дип китте ул. Русларны да, татарларны да кертмиләр ди бит анда хәзер.

— Анда кереп нәрсә?

— Белмим шул. Ишеткәнемне әйтәм...

Мин дә белмәгән атлыга сабыштым. Ярый, житеп торыр. Үземне, күрешкән мизгелдән үк бик тә кызыксындырып торган икенче сорау да бар иде бит әле.

— Сез рус кешесенә тормышка чыккансыз икән,— дип сак кына, җайсыз яисә артык сүз әйтүдән куркыбрак сүз башладым.— Безнең хатын-кыз чыга инде ул. Кырык-илле процент татар кызлары чит милләт вәкилләренә кияүгә китә. Була торган хәл. Сезнең ирегез дә рус кешесе икән әнә. Ләкин сез башкалардан нык аерылып торасыз. Мине хәйран калдырдыгыз хәтта...

— Ни белән?

— Ирегез — рус. Ә балаларыгыз татарча сөйләшә. Хәтта Мәскәүнең кыл уртасында татарча сөйләшәсез. Исемнәре дә татарча икән кызларыгызның — Розалия һәм Гүзәлия... Нинди матур исемнәр!

— Ә-ә, аны әйтәсез икән,— дип, җанланып алды ханым.— Без Дүшәмбедән ерак түгел генә урнашкан поселок кебегрәк җирдә тордык. Урамыбызда ике таҗик, бер үзбәк гаиләсе бар иде. Калганнары барысы да татарлар. Үзбәкләр дә татарча сөйләшә иде анда...

— Башка милләткә чыккан татар хатыны үз баласына татар исеме куштырмый торган иде. Үзенекен үзгәртсә үзгәртә, әмма...

— Бу — кешенең үзеннән торадыр. Башкалар өчен җавап бирмим. Исемнәрен үзем сайладым, әтиләренең фамилиясен йөртәләр,— диде

хатын, һәм көтмәгәндә, нидер тоемлапмы, каушый һәм борчыла төшеп, сорап куйды.— Белмисезме, Останкинодан кайтмадылармы икән әле?

— Белмим шул...

Дөресен әйтә алмадым. Ялганладым.

Шунда нәни кызчык Гүзәлия кызыклы сорау биреп куйды үземә.

— Абый,— диде, муенына зәңгәр яулык салган сабый.— Сезне дә өегездән куып җибәрделәрме әллә? Сез дә «беженец»мы?

Сабый авызыннан чыккан сорау тез астына китереп суккандай тәэсир итте. Бер мәлгә югалып калдым хәтта. Ни дип җавап бирергә белми тордым. Уенга яисә шаяруга борыр идем, мөмкин түгел, мөлдерәп үземә текәлеп торган чем-кара күзләрдә шаяру кайгысы түгел, моң...

— Нигә алай дип сорыйсың, сеңлем?

— Безнең урамда торган татарларның барысын да куаладылар. Барысы да «беженец» булды. Татарлар барысы да «беженец» бит, абый.

— Татарлар гына түгел, русларны тоташ куалар ич. Алар арасыннан да бик күп качак бар.

— Сезне дә таҗиклар кудылармы, абый? Сез дә «беженец»мы?

— Качак түгел, түгелен... Мин, Гүзәлия, язучы. Татар телендә китаплар язам.

Үзем шулай дидем, ә үзем «качак та булмагач, абыкаем, язучыга монда ни калган соң?» дигән сорау бирә күрмәсеннәр дип сагаеп калдым. Күрәм, ул сорау аларның күзләрендә, тел очларында тора. Алла рәхмәте, бирелмәде андый сорау.

Моңарчы сүзгә катнашмыйча, әнисенең итәге артына яшеренеп торган өлкән кыз Розалия кушылды сүзгә:

— Татар телендә дә китаплар буламы, абый?

— Бер дә күргәнең, укыганың юкмыни?— дим.— Үзең татарча шундый матур итеп сөйләшәсең. Казан кызларын көнләштерерлек итеп.

— Күргәнем юк шул, абый,— диде сабый ихластан.— Татарча без урамда гына сөйләшәбез. Мәктәптә русча һәм таҗикча укыйбыз.

Гаҗәпләнү катыш карашымны тоеп, кызларның әниләре килде ярдәмгә.

— Татарча китап юк иде анда. Баштарак, «Азат хатын» журналын яздыра идем. СССР таратылгач, ул да килми башлады.

— Аңлашылды,— мин әйтәм.— Менә ничек икән...

Гүзәлия белән Розалия, ятсынудан туктап, янымa ук килеп җиткәннәр иде инде. Башларыннан сыйпап куйдым үзләрен. Минем дә ике кызым булуы хакында әйттем. Аларның исемнәре белән кызыксынды нәни Гүзәлия. Кызларым — Чулпан белән Алсу — бу исемнәр ят түгел икән алар өчен. Алсу — әниләре исеме икән. Чулпан атлы иптәш кызлары булган.

Үз гомерләрендә татар телендә китап чырае күрмәгән, әмма ана телләрендә чиста итеп авыз тутырып сөйләшеп йөргән бу ике кызчыкка сокланмау мөмкин түгел иде. Искиткеч матур иде алар, тыйнак иделәр. Күз тимәсен үзләренә дип, күңелемнән теләкләр дә теләгән идем, югыйсә.

Иртәгәсен кечкә балалар өчен татар телендә төсле рәсемнәр белән чыгарылган китаплар китерергә вәгъдә иттем. Үз китабым гына түгел, Фатих Кәримнең «Гармунчы аю белән җырчы маймыл хикәяте», Шәүкәт Галиевнең «Шәвәли» һәм тагын татар халык әкиятләре бар иде үзем белән. Ике йөз метр чамасы еракльта, кабинетымда гына иделәр, югыйсә. Әрсезлек күрсәтү булмасын дип, иртәгәсе көнгә калдырдым бу эшне. Һәркемнең үз гаиләсе, үз мәшәкате, әтиләренең кайтып төшүе бар. Вакыт та шактый соң иде бит инде. Саубуллашып китеп бардым.

Бераз киткәчтен борылып карамый булдыра алмадым үзләренә. Розалия белән Гүзәлия дә күзләрен алмаганнар иде әле. Нәни кызчык Гүзәлия муенына шуып төшкән зәңгәр яулыгын җәт кенә кулына алды да, ерак диңгезгә кораб озаткандагыдай, озак кына болгап торды.

Күңелең таш булса да нечкәрми калмас... Әй, бу язмыш дигәннәрең. Бугазга төер килеп тыгылды. Үз-үземнән качарга теләгәндәй, җәт-җәт атлап тизрәк китеп бардым. Халык диңгезе эченә кереп югалдым.

Мәйдан бераз басынкыланып калган. Останкинодан килеп торган соңгы хәбәрләр тәэсире иде, күрәсең. Әмма халык таралырга җыенмый. Түгәрәк-түгәрәк булып тупланып үзара әңгәмә кылучыларның телләрендә әледән-әле бер фикер кабатланып тора: «Мәйданны ташлап китәргә, таралырга ярамый. Язмышлары кыл өстендә торган югары даирәләр, юкса, теләсә нинди авантюрага барырга мөмкин. Шушы мәйданда һәм шушы төндә, кем белә, бәлки ил язмышы, Россия халыклары язмышы хәл ителәдер булса кирәк. Китмибез...»

Тукайны укыганнармы-юкмы, «китмибез»не һәр тарафта тәкърарлап чыктылар ул төндә.

Сигезенче хисап санын йөрткән тышкы ишек аша Югары Совет бинасына уздым. Монда махсус рөхсәте булганнарны һәм халык депутатларын гына кертәләр. Шулай да ишек катындагы киң мәйдан милиция хезмәткәрләре белән тулы иде. Барысы да яшь кенә егетләр. Бил каешларын ычкындырып, шинельләрен ача төшеп кайсы кая мәрмәр идәндә утыралар. Башлары салынып төшкән, йокы баскан үзләрен. Әмма тынычлап йоклый алдылармы икән. Чөнки кондиционер эшләми, форточкалар юк. Суык та, бер үк вакытта тынчу да иде анда.

Кемнәрнеңдер кадерләп багып үстергән балалары бит инде болар. Армиягә дип, Ватанны сакласыннар дип, озатып калганнардыр үзләрен. Ә алар монда әсир кыяфәтендә утыра. Коралсызландырылганнар. Бүген ниләр генә узмаган боларның башыннан һәм иртәгәсен ниләр көтә үзләрен... Белсә дә, Ходай үзе генә белә... Күзләрендә — билгесезлек, күзләрендә — моң-сагыш.

Анда-санда пыскып янган шәм яктысында күзгә ташланган бу күренеш шактый авыр тәэсир калдырды.

Миңа караңгы баскычлар буйлап ике кат югары күтәреләсе бар иде әле. Кесә фонаремне чыгардым. Батареялары утырган, яктылык шактый сүрән иде, тычкан уты сыман гына. Абынмаска-сөртенмәскә ярап тора шунда.

— Кем бар анда? — дигән кырыс тавыш ишетелде. Бу минем ишектән җиде-сигез адым гына ераклыкта сакта торган өлкән яшьләрдәге офицер тавышы. Ул монда үз теләге белән килеп, инде бер атнадан артык даими рәвештә сакта тора. Кулында автомат.

— Сезнең күршегез... Мөхәммәдиев, — дим.

Офицер, инструкциядә каралганча, йөземә утын юнәлтеп тикшереп тормады. Тавышымнан таныды, ахры.

— Мин инде, бу кайтмадымы әллә дигән идем, — диде калын тавыш.

— Куркакка чыгардыгызмы? Качкан, дип уйладыгызмы?..

— Куркак дип әйтмим. Әмма, юк йомышларын бар итеп, шәһәргә шылучылар байтак булды бүген...

Әңгәмә кыла торган чак түгел, офицерга сәлам биреп эш кабинетыма уздым. Гомер булмаган хәл, мин җитәкләгән даими комиссия әгъзалары тулысынча дип әйтерлек җыелышкан. Мине көтүләре икән.

— Равик Смирновтан кала, барыбыз да эш урыннарында, — дип, бер горурлык белән әйтеп куйды комиссиянең сәркатибе Валентина Озерова. Бу ханым Орел өлкәсеннән сайланган халык вәкиле, укытучы.

— Равик Михайловичка ни булган, бер-бер хәбәр юкмы үзеннән? — дип кызыксынды Юрий Симуков. Депутатлыкка кадәр ул Коми Республикасының Югары Совет Рәисе булып эшләгән.

— Авырып киткәндер, — диде, чечен егете Сәетхамзат Нунуев.

— Авыру түгел, качты, — диде, гүя кистереп куйды һәрчак турысын әйтеп сөйләшергә күнеккән Валерий Хайрюзев. Гомере буе очучы булып эшләгәнгәме, сөйләшсә, турысын әйтеп сөйләшергә күнеккән ул. Язучы,

якын дустым буларак та үзенең шул турылыгы, дөреслеге белән кыйммәтле иде ул.

Валерий Николаевич бу юлы хаклы иде. Чынлап та, өч елдан артык минем урынбасарым булып эшләгән Р. М. Смирнов үзенә тәкъдим ителгән эшкә алданып, безнең барыбызны да хыянәтчел төстә ташлап киткән иде. Аның каравы ул бүген дә Россия Президенты аппаратында Дәүләт бүләкләре идарәсе рәисенең урынбасары булып эшли. Кара машинада йөри, бәлки дәүләт дачасы да биргәннәрдер үзенә. Нишлисең, һәркем үз язмышына үзе хуҗа бит һәм ул аны үзе теләгәнчә һәм булдыра алганча язарга хаклы.

Кабинетка җыелучылар барысы аңлый һәм сиземли иде кебек: хәлиткеч сәгатьләр якынлаша. Шушы төн һәм иртәгәсе көн эчендә вакыйгаларга ачыклык керер төсле тоела. Чияләнгән төен, ниһаять, чишелергә охшаган. Йә чишелә, яисә аны өзеп үк ыргыталар — башка юл юк. Ә бәлки хәрбиләр әйтергә җыенадыр ул соңгы сүзне... Ә инде хәрбиләрнең Конституцияне яклап сүз әйтергә кыюлыгы җитми икән, ул очракта безнең эшләр харап. Югары Совет бинасын җир белән тигезләп куярга да күп сорамаслар. Чөнки хакимияттәгеләр өчен моннан да уңайлырак форсат чыкмавы ихтимал. Беренчедән, Югары Совет бинасында гаять нык коралланган явыз көчләр бикләнеп ята дигән ялганга инде күпләрне ышандырдылар да булса кирәк. Икенчедән, Мәскәү урамнарында һәм аеруча Останкинода шактый гомерләр өзелде, кан акты. Моны бит ничектер акларга, кемгәдер аударырга кирәк булачак. Өченчедән, җәмәгатьчелек фикере һәр көн, сәгать саен Югары Совет файдасына үзгәрә тора. Яннарында чит ил киңәшчеләре мыжлап торган олы хуҗалар моны гына аңларлык хәлдәдер бит әле...

— Нишлибез?..— дигән сорау тора безнең каршыда. Бүлмәдә тынлык урнашып торды. Комиссия әгъзаларының күзләреннән, үз-үзләрен тотышларыннан күреп торам, сорау бар. Әмма җавап та әзер, икеләнүче юк. Һәм шулай булып чыкты да.

Электрга көйләнгән стена сәгатьләре туктап калган. Әмма тормыш тукталмаган, дәвам итә. Вакыт та шактый соң икән бит инде. Ыгы-зыгылы 3 октябрь тәмамланып, чираттагы көннең тәүге сәгате узып бара. Төнге бер якынлаша. Йоклап булмаса да, ял итәргә вакыт. Тәрәзәләре урам якка караган кабинетларга керү тыелганлыкны искәрттек бер-беребезгә. Хатын-кызлар минем кабинетта калырга булды, ә без, ир-атлар исә, кабул итү бүлмәсендә һәм аның аргы тарафында урнашкан комиссия рәисенең ярдәмчеләре кабинетында.

Әмма йокларга җыенучы юк иде. Минем югарыгы катларга менеп, җитәкчелектән хәл-әхвәл белешеп төшүемне үтенделәр. Чөнки имеш-мимеш һәм гоманлаулар күп, ә хәлләрнең хакыйкатьтә ничек булуын, үзебезне ниләр көткәнлеген тәгаен генә әйтеп биргән кеше юк.

— Хасбулатовның үзенә керсәгез, яхшы булыр иде. Кабул итсә, ул сезне кабул итәр,— дип, салпы якка салам кыстырып куйды Любовь Ростбитова.

Үз күңелемдә дә шундыйрак теләк булгандыр. Ничек итеп тынычлап ятып йоклыйсың.

Фонарь тәмам утырган иде инде, кулыма шәм алып, караңгы коридорга чыктым. Почмак саен, чат саен «Калашников» автоматы белән төнге сакта торучыларны искә алмаганда, караңгы коридорлар бушап, тынып калган. Шәм яктысы барыр юлны яктыртмый, күбрәк үзеңә төшә икән ул, күзне чагылдыра. Диварларны капшый-капшый тар коридорлар аша үттем, баскычлардан югары күтәрелдем. Төнгә каршы күп ишекләр бикләнү сәбәпле, урап-әйләнеп узарга туры килде.

Чү, мин әйтәм, Рамазан Абдулатыйпов кабинеты яныннан узып барам түгелме соң... Кабул итү бүлмәсеннән төшкән шәм яктысында кемнәрнеңдер ыгы-зыгы килгәнен дә шәйләп өлгердем.

Ярдәмчесе Галаев мине танып алды.

— Ба, Ринат Сафиевич, бу хәвефле төндә ничек килеп юлыктыгыз безнең тарафларга,— диде ул, көтмәгән бу очрашудан беркадәр югалып калгандай хис итеп. Картон тартмаларга кәгазь төргәкләре тутыру белән мәш килә иде бугай.

— Рамазан Гаджимуратович мондамы соң?

— Ничек дип әйтергә...— дип, икеләнеп калды Милләтләр Советы Рәисе ярдәмчесе.

Күрәм, аңарга сораучы була-нитә калса, «юк» дип әйтергә кушылган, ә миңа ул ялган сөйли алмый. Алдый икән, шундук тотылачак, үзара дустанә мөнәсәбәт тә бар иде арабызда. Галаев ыкы-мыкы килеп торган арада, мин турыдан-туры Рамазан Абдулатыйповның кабинетына барып кердем.

Көтмәгән иде, әлбәттә. Каушап калды. Караклыкта тотылган кешедәй ни эшләргә белми, хәтта сәламләргә онытып торды бер мәл. Әмма табигатьтән бирелгән җорлыгы ярдәмгә килде бу юлы да.

Моңа кадәр узган гомеремдә таулы Дагыстан илендәге авар халкы вәкилләреннән миңа нибарысы ике кеше белән дустанә мөнәсәбәттә аралашып яшәргә туры килгәндер. Боларның беренчесе, әлбәттә шагыйрь Рәсүл Гамзатов. Юлдаш булырга туры килгәне бар аның белән, язучыларның съезд һәм төрле киңәшмәләрендә янәшә утырырга туры килгәне бар. Мәҗлестәш һәм якын әңгәмәдәш булып утырган һәм йөргән сәгатьләр байтак булды. Хәтта бик нык хасталанган вакытында үзен баш очында саклап чыктым берчак. Шундый сәгатьләрдә дә ул мине үзенең җорлыгы, тапкырлыгы белән хәйран калдырды.

1989 елның октябре иде. Шагыйрьнең башын күтәрә төшеп, иреннәренә су китердем. Иреннәрен чылатты-чылатуын, әмма эчәр хәле юк иде. Шулай да авырлык белән генә мыгырданып алыр көч тапты үзендә:

— Рәхмәт,— диде,— иреннәремнән кызлар үпкән кебек булды.

— Эчәргә кирәк иде,— мин әйтәм.

— Син дигәнчә булсын, ярар әйдә, сал бер илле грамм коньяк,— ди бу.

Ә инде сәламәт чагында Рәсүл агайга сүз әйтеп өлгермисең, алдан ятлап куйгандай, ул шундук җавап та биреп куя. Көлми түзеп кара, тапкырлыкта аңарга җиткән кеше юк.

Шулай да «сүз башым бит Шүрәле» дигәндәй, Рәсүл Гамзатов хакындагы сүземне туктатып торыйм әле мин. Беренчедән, сүз аның хакында түгел. Икенчедән, күпме генә өзгәләнсәм дә, Гамзатов хакында Гариф Ахунов миннән күбрәк белә һәм аңарга җиткереп сөйли дә алмаячакмын.

Рамазан Абдулатыйпов шагыйрь түгел, сәясәтче. Фәннәр докторы. Элгәре елларда КПСС Үзәк Комитеты аппаратында эшләп чыныгу алган. Хәйлә дә, кирәксә, мәкер дә җитәрлек үзендә. Шагыйрь Гамзатовтан аермалы буларак, хис кешесе түгел. Ә менә җорлыкта, тапкырлыкта аңардан һич калышмый.

90 нчы еллар башында Борис Ельцин әйләнәсендә һич кенә дә өнәп бетермиләр иде үзен. Ничек кенә рәнҗетмәделәр аны, ә ул максатына ирешү юлында булды, ишектән кусалар — тәрәзәдән, тәрәзәдән кусалар, форточкадан килеп керде. Мисал өчен, ниндидер бер әңгәмә вакытында, әле яңа гына Россиянең Югары Совет рәисе булып сайланган Борис Ельцин аңарга турыдан-туры әйтеп салды:

— Безнең юллар аеры, бер командада була алмыйбыз, Рамазан Гаджимуратович,— диде.

Җавапка әйтер сүз калмады, югыйсә. Ә Рамазан югалып калмады.

— Сезне, Борис Николаевич, бик яхшы волейболчы диләр. Мин дә волейболны яхшы уйныйм. Сез һөҗүм итәрсез, ә мин туп биреп торырмын, бер командада уйнарбыз, Борис Николаевич,— диде.

Ельцинның күңеленә хуш килде җавап, канәгать елмаеп куйды. Рамазан волейбол уйный белгәндерме-юктырмы, әйтә алмыйм, әмма милли сәясәттә Борис Ельцин һөҗүмгә күчкән сәгатьләрдә һәрчак «аңарга туп

биреп торучы»ларның берсе Абдулатыйпов булуы бүген яшерен-батырын түгел.

Башыңа төшсә, башмакчы булырсың, диләр бит. Шул рәвешле, Рамазанны волейбол коткарып калды. Ә бәлки кемнәрдер теннис тубы биреп торып та шактый югары күтәрелгәндер. Заманы шундый.

Бер сүзем юк, Рамазан талантлы шәхес. Аның тагы бер чагыштыруы искә төште әле. Сергей Шахрайны да, башка берәү түгел, нәкъ менә ул «басу буйлап җан-фәрман чабып барган куянның мамыгын кыркып кала торган егет» дип бәяләгәне бар. Сессия барышында әйтеп салган сүз бу. Ә никадәр төгәл һәм образлы!

Шахрайга дөрес бәя булган ул сүзләр бер үк вакытта Рамазанның үзенә дә туры килә. Мамык куянын ычкындыра торган ир-ат түгел ул да.

— Карыңгыда да таныйм үзеңне. Ринат, син икәнсең,— диде Абдулатыйпов. Һәм шундук үз-үзен кулга алды. Көттереп килгән кунагына да ул кадәр шатланмас.— Менә, бер Дагыстан коньягы калган. Борис Николаевичны чакырыйммы әллә дип тора идем. Ярый әле син кереп өлгердең...

Шыплап тутырылган картон тартмаларга ымладым.

— Китәргә... күченергә җыенасың, ахры...

Шулай икәнлегенә һич шөбһә юк. Ә ул сер бирми, җаен таба.

— Кулга ала-нитә калсалар, әзер булып торсын дим. Степашин үзебезнең кеше бит, аңарга мәшәкать кими торыр,— ди бу.

Коньягы бар икән, чынлап та. Кешедә ризык түгел, шырпы, шәм калмады. Ә моңарда затлы Дагыстан коньягы, шоколад, конфетлар...

Нәни рюмкалардан йотып куйдык. Ач карынга шул да җитә калды, тел ачылды.

— Бүген үк китәсеңме, әллә иртәгәме?— дим, әрсезләнеп.

— Кая?— ди бу.— Алырга килгәннәрме әллә... Шунсыз китү юк.

— Рамазан,— дим мин.— Чынын гына әйт әле, ни белән тәмамланачак бу бака туе? Мәңге шул рәвешле дәвам итә алмый бит.

— Бака туе...— дип, уйланып торды ул бер мәлгә. Һәм рюмкаларга агызды.— Матур әйттең, ишеткән юк иде әле.

— Мине берни дә аңламый дип, беркатлыга чыгарма. Күреп торам, соңгы араларда Шахрай белән араларыгыз көйләнде. Үзең әйтмешли, сез бер командада уйныйсыз кебек. Ә Югары Советка каршы оештырылган бу фетнәдә Шахрай соңгы рольне уйный... Сине аңлап булмый, нииндидер килештерү комиссияләрендә йөргән буласың. Ә Хасбулатов һәм Руцкойлар барыбер ышанмый бит үзеңә. Воронин да ышанмый. Сыроватко да... Кем белән кемне килештерергә уйлыйсың соң син?!

— Олаксыннар ла алар. Искә төшермә әле шуларны. Әйдә, телне чылатып куйыйк ичмаса.

Мин әйткәннәр тәэсир итте кебек аңарга. Байтак кына уйланып утырды. Әмма сер бирү түгел иде исәбендә.

— Беләсеңме, Ринат,— дип, эчкерсез сөйләшкән атлы булды ул.— Без синең белән Носовец яисә Подопригора түгел. Үзен мордва дип санаган Медведев та түгел. Алар үз адымнары өчен үзләре генә җавап бирәчәк. Ә синең белән миңа андый хокук бирелмәгән. Мөхәммәдиев качты, димәсләр, татарлар качты диячәкләр. Абдулатыйпов та үзе өчен генә түгел, бөтен аварлар, хәтта бөтен Дагыстан өчен җаваплы бүген. Үзем югалмас идем әле, Мурманск кебек бер-бер почмакка китәр идем дә, укытыр идем шунда... Синең белән без ташлап чыгып китә алмыйбыз бу Ак йортны. Каһәрләнгән булса да китә алмыйбыз. Куркак дигәнне, сатлык җан дигәнне күтәрү авыр булачак.

— Рәхмәт,— дидем мин аңа. Сүзләренә ихлас ышандым, кулым бирдем.— Нәкъ минем дә тел очымда торган сүзләрне әйттең бит әле син. Ни булса булыр, киеренкелек тәмамланмый торып, без моннан китә алмыйбыз.

Иртәгәсен исән-сау очрашып-күрешү теләкләре белән аерылыштык. Хушлашмадык...

Караңгы тар коридорлар буйлап бераз узгач югарыга, Хасбулатов катына күтәрелдем. Ике җирдә туктатып, кем булуым белән кызыксындылар. Әмма озакка түгел, кулымдагы кызыл кенәгәгә кесә лампасы яктылыгын юнәлткәч тә ары үткәрделәр.

Гадәттә, балкып, кыйммәтле дәү люстралары белән хәйран калдырып торган кабул итү бүлмәсендә ике сакчы бар иде. Һәм шәм яктысында нидер язгалап утырган ярдәмчесе.

— Руслан Имранович йоклый торгандыр?— дип сорадым мин, үземнең әрсезлегем өчен бераз уңайсызланып. Шулай вакытсыз, соңлап йөрү чынлап та бик үк килешеп бетми торгандыр.

— Өченче көн инде йокы алмый үзен,— диде Югары Совет Рәисенең ярдәмчесе.— Таблеткалар да эчеп карады, әмма файдасыз.

— Хәзер кеше бармы соң үзендә?

— Әле генә киңәшмәдән чыктылар. Үзе генә калды.

— Хәбәр итмисезме? Алай зур йомышым юк иде югын да, мине дә шул күңел тынгысызлыгы йөртә.

Югары Советта бюрократлар да булгандыр, әлбәттә. Әмма Хасбулатов әйләнәсендә андыйлар тоткарланмады. Теләсә кайчан һәм теләгән вакытта һәр депутат өчен ачык була иде аның ишеге.

Ярдәмче бер минутка калын ишек артында югалып торды. Һәм ишекне киереп ачып, керергә чакырды.

— Руслан Имранович сезне көтә, Ринат Сафиевич.

Кердем. Өстәл артында Руслан Хасбулатов төребкәсен имеп утыра. Мине күргәч, урыныннан торды, каршы килеп кулын сузды. Хәл-әхвәл белешеп, утырдык.

Биш-алты минут утырдык микән, рация аша кемдер хәбәр бирде. Игътибар белән тыңлады Хасбулатов. Һәм үзалдына көлемсерәп куйды.

— Шулай буласын белеп тора идем. Абдулатыйпов әйберләрен төяп кара «Волга»сына утырып китеп барган,— диде тыныч кына.

Мин телсез-өнсез калдым. Әле яңа гына, күп булса, ун минут әүвәл күргәнем-ишеткәннәрем белән әлеге хәбәрне янәшә куюы аек акыл өчен кабул ителмәс дәрәҗәдә авыр бирелә иде. Хәер, Рамазанны белүчеләр өчен башка сыймаслык зур яңалык булмады бу. Үзен шактый хәйләкәргә, башкалардан акыллыга санаса да, аның нинди шартларда ни кылырга сәләтле икәнлеге күпләр өчен мәгълүм булган. Хәбәргә исләре китмәде. Тагы бер көннән соң, үзе җитәкләгән Милләтләр Советы әгъзалары кайсы кая тән һәм җан җәрәхәтләреннән ни эшләргә белми иза чиккән бер сәгатьтә Президент Ельцинның Рамазан Абдулатыйповны яңа бер җаваплы эшкә билгеләве турындагы Указы да табигый кабул ителде.

6 октябрь кичендә Яңалыклар программасыннан бу хәбәрне ишеткәч, чәчләрем үрә торды. Үзен авар халкы һәм бөтен Дагыстан өчен җаваплы хис итеп сөйләгән кеше бит бу, дип уйлап куйдым.

Аллага шөкер, шул аерылышудан минем Абдулатыйповны күргәнем булмады. Һәм күрәсем дә килгәне юк. Мөгаен, аның да минем күзгә чалынасы килми торгандыр. Чөнки үз кабыгын алыштырганнан әүвәл, аны иң соңгы күргән кеше мин икән бит.

Шулай итеп, Россия Федерациясе Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов белән икәүдән-икәү генә аның кабинетында утырабыз. Төнге бер тулып узган. Димәк, 4 нче октябрьга чыгылган. Бу көннең ничек башлануын күрсәк тә, ни белән тәмамланасын әле күз алдына да китерә алмый идек. Ә югыйсә, Ельцинга якын даирәләрдә, һәм бу көнгәчә беркатлы хуҗалык җитәкчесе булып уйнаган Черномырдин кабинетында инде барысы да хәл ителгән, хәстәрләнгән була. Россия телевидение һәм радио компанияләре хәбәрдар булмагандыр бәлки, ә Кушма Штатларның СНН агентлыгы камералары бер атна алдан тиешле урыннарга урнаштырылган.

Иртәгәсен башланачак вакыйгалар хакында Рамазан Абдулатыйпов та хәбәрдар булган, әлбәттә. Чиксез нәфрәтемнең чыганагы шуңардан да: «дөмексәләр-дөмексеннәр» дип ташлап киткән ич ул безне.

Хасбулатов шактый гына тартылып калган, ябыккан иде. Берөзлексез төребкә тарта. Сөйләшер сүз күп була андый чакта, әмма нәрсәдән башларга белми изаланасың. Һәм газапланып биргән беренче соравың бик үк урынлы да булып чыкмый.

— Бераз йоклап алырга кирәк түгел идеме, Руслан Имранович? Шактый талчыккан күренәсез?

— Син дә йоклаганга охшамыйсың,— дип, җавап бирде ул миңа. Һәм үзалдына сукранып алды.— Йоклый торган чакмыни... Илдә Конституция тапталган, иң югары хакимият — Югары Совет мыскыл ителгән бер чорда ничек итеп йокы турында уйларга мөмкин, Ринат?!

— Бер-бер яңалык, куанычка нигез булырлык хәбәр юкмы соң, Руслан Имранович?

— Сүз күп булды, Ринат. Хәбәрләр, вәгъдәләр дә аз түгел. Тик гамәлгә ашканнары юк.

— Нindидер хәрби частьлар ярдәмгә килә дигән хәбәрләр ишетелә, дөресме шул?

— Беләсеңме, Ринат,— ул миңа һәрчак шулай дәшә торган иде. Үземнең рөхсәт белән, әлбәттә.— Мин ни дияргә дә белмим инде. Янымда күзгә-күз утырып, яисә Руцкой һәм Ачалов белән кереп ничәмә-ничә генерал менә шушы кабинетта әллә нинди вәгъдәләр биреп чыгып киттеләр. Берничәсе кулга алынды, икесе, имеш, үз-үзен атып үтергән, калганнарыннан хәбәр юк. Хәлләр менә шундыйрак.

— Туладан танк дивизиясе килә дигән хәбәр йөри. Һәм тагы нindидер десантчылар...

— Хәбәрләр күп ул. Син әйткәннәре дә дөреслеккә якын. Ләкин, шунысы кызганыч, сүз чыккач, аны булдырмау чаралары да күрелә. Күрербез, ничек булыр... Безгә сугыш түгел, Югары Совет бинасына каршы әзерләнгән фетнәне туктатырга сәләтле көчләр кирәк. Җинаятьчел режим үзенең соң сәгатьләре якынлашканлыкны сизә, шуңа теләсә нинди вәхшилек күтәргә була үзләреннән. Яраланган ерткыч сыман алар...

— Руслан Имранович, Югары Совет җитәкчелеге бердәмлекне югалта бара түгелме?— дигән сорау куйдым тагын.

— Үзең күрәсең, Абдулатыйпов белән Соколовка ышанырлык түгел. Һәм мин аларга ышанмадым да. Исправниковныкын да белгән юк, шушы сәяси хәлдән файда күреп каласы килә аның, шуңа әле анда, әле монда бәргәләнә. Воронин нык тора. Агафонов ышанычлы кеше. Руцкойга һәм өч министрга — Ачалов, Баранников һәм Дунаевка шик белдерер урын юк. Әмма конкрет кылган эшләре дә күренми, сүз һәм вәгъдәләре күбрәк иде...— Озак кына уйланып утырды ул. Тел очында торган сүзен әйтергәме-юкмы дип, икеләнә калды булса кирәк.— Кешеләрне, Ринат, һич кенә дә аңлап бетерерлек түгел икән ул. Үз-үзеңә ышанып булмый кайчак. Арка терәге, дип санаган кешеләр дә хыянәт итә икән. Бу, аеруча, югары даирәдәге, хакимият, дәрәҗә һәм байлыкның бөтен рәхәтлеген татып өлгергән кешеләргә хас сыйфат. Иманлы кешеләр күп түгел икән ул. Гади хезмәт ияләре яисә авыл кешеләре арасында булган дуслык юк һәм була да алмый югары даирәләрдә.

— Руслан Имранович,— дип, кабаланып әңгәмәдәшемне бүлдерергә ашыктым.— Кешеләргә ышанычны югалту ярамый безгә. Сезгә — аеруча!

— Үзең күрәсең, мин кешегә хәтта артыграк та ышанам кебек, шуның ачы җимешләрен татып яшим. Хәтереңдәдер, Ельцинга ни дәрәҗә тугрылыклы хезмәт иттем үз вакытында. Шумейко, Шахрай, Яров, Рябов, Степашин — болар бит барысы да минем беркатлылыгым аркасында

хакимият баскычларыннан космик тизлек белән күтәрелгән кешеләр. Филатовны да, эшсез йөргән җиреннән күтәреп алып, Югары Совет Президиумының секретаре иттем. Бер алдыма төшә торган иде, бер артыма... Хәзер шулар барысы да Югары Советка, Конституциягә каршы күтәрелделәр.

— Минем күз алдында узган хәлләр. Дөрес сөйлисез,— дидем.— Бәлки, Юрий Яров кына ул кадәр үк зыянлы эшләргә катнашмагандыр... Ул тормышны башкалардан күбрәк белә иде булса кирәк, Ленинград өлкәсе хакимият органнарында эшләү тәҗрибәсе дә зур.

— Син хаклы,— диде Хасбулатов.— Юрий Федорович, чынлап та, сәяси каршылыклардан читтәрәк торуны кулай күрә. Яхшылыкка яманлык белән җавап кайтармый.

— Республикалар һәм өлкәләр актив рәвештә Югары Советны яклап чыккан иделәр,— дим, сүзне читкәрәк каера төшеп.— Соңгы көннәрдә бу хәрәкәт тукталдымы, әллә информация килеп җитмиме? Тулеев, Илюмжинов һәм Аушевтан кала башкаларның тавышы-тыны бик ишетелми.

— Республикалар һәм өлкәләр аерым-аерым да, бергәләшеп тә күп мөрәҗәгатьләр кабул итте, мөмкин булганча тырыштылар, минемчә. Аларның тавышына колак салырга теләүче юк. Һәм булмас та. Демократия сүзе хакимияткә килү өчен генә кирәк булды безнекеләргә. Бабайның башына ни килсә, Шахрай ничек язса — шулай була хәзер. Регионнардан сорап тормыйлар. Ә халык турында, гомумән, оныттылар. Килешмәгәннәрне, күрәсең, кыйныйлар яисә үтерәләр генә.

— Минем башыма сыймый болар,— дидем, ихластан.

Ә Руслан Имранович яңадан төребкәсен тергезеп җибәрде. Йотлыгып тәтен имәргә кереште.

— Активлык дигәннән, синең сүзләрдә дә хаклык бар анысы,— диде, бертын имеп алгач.— Республика һәм өлкәләр белән, нигездә, акыллы, зирәк кешеләр идарә итә Россиядә. Әмма, күпчелеге — партноменклатура. Партноменклатура дип әйтергә генә җиңел, бу бит үзенә күрә бер академия узган каста. Алар югары карап фикер йөртергә өйрәнгән «бабай» яисә «абзый» сүзеннән чыгарга ярамаганлыкны яхшы беләләр. Бүгенге дәрәҗә һәм карьера җиңел бирелмәгән аларга, түшләре белән шуышып йөрми торып үсү, күтәрелү мөмкин түгел иде партноменклатура баскычыннан. Арыслан йөрәкле каһарман булганнары да, соң чиктә, куркак бит аларның. Шул куркаклыклары белән үзләре табынган партия — КПССны тараттылар тавышсыз-тынсыз гына, шул куркаклыклары белән СССРны дөньяга чыгарып җилпеделәр. 1991 елның август вакыйгаларында күрдек инде без кемнең кем булуын. Кулларында нинди көчләр була торып дер калтырап төштеләр... Партноменклатура мәктәбе кичмичә, тамырдан корымый торып демократия буласы юк Россиядә.

— Димәк, бик озак көтәргә туры киләчәк икән.

— Көтәргә яисә көрәшергә туры киләчәк,— дип өстәп куйды Хасбулатов һәм бертын уйланып утырды.

— Ярый,— дидем.— Вакытыгызны бик күп алдым, миңа китәргә дә вакыттыр.

— Утырып тор бераз,— диде ул, тирән сулыш алып. Менә-менә елап җибәрер сыман тоелды миңа, рәнҗетелгән бер сабый карашы иде аңарда. Холкы җиңел булмаса да, үз вакытында аңардан байтак авыр сүзләр ишетергә туры килгән булса да, аңлаешлы һәм якын кеше иде бит ул миңа. Икейөзле түгел. Туры сүзле. Кеше хәленә керә белә торган, ярдәмчел. Һәм риясыз, үч саклый белми торган. Әмма шул ук вакытта үзсүзле, киребеткән.

— Руслан Имранович, сез ул кадәр бетеренмәгез, кулдан килгән кадәр көрәштегез. Моны һәркем аңлый, күреп тора. Илдә, республикаларда да сезне яратучылар бик күп. Руслар арасында аеруча күп алар. Дөнья җәмәгатьчелеге каршында да мәртәбәле исемегез бар. Бар иде...

һәм сез ул исемгә кер кундырмадыгыз. Барысы да узар, дөньялар көйләнер, Алла боерса,— дидем мин, хушлашу сүзем итеп. Һәм, китәргә дигән катгый фикер белән, урынымнан тордым.

Өстәл аша кулым суздым. Җавап бирергә ашыкмады Хасбулатов. Төребкәсен калдырып, иң элек өстәл артыннан чыкты һәм яныма ук килде. Кулын җилкәгә салды.

— Хәтереңдәме,— диде ул,— соңгы мәртәбә синең белән шул рәвешле Истамбулда «Хилтон» кунакханәсендә эчкерсез сөйләшеп утырган идек. Киләсе очрашуыбыз кайда булыр, әйтү кыен... Әмма очрашырга язсын. Очрашырга...— Озак кына дәшми торды. Аның күзләрендә нидер балкып, җемелдәп киткәндәй булды. Әллә күңеле нечкәрде, белмим, гөнаһына кермим. Ипле генә ишек катына кадәр уздык, кулын җилкәдән алмады.

— Һәрхәлдә, исәнлектә күрешергә язсын, Руслан Имранович,— дидем.— Һәм иректә...

Бу теләкне теләгәндә һич кенә дә киләсе төнен Хасбулатов Матрос тынлыгы төрмәсендә ялгыз камерада каршылар дип уйламаган идем...

Ишек катына ук килеп җиткәч, бер-беребезнең кулын кыстык.

— Бәлки, сиңа хәзер үк шәһәргә чыгып китәргә кирәктер, Ринат,— диде ул, тирән сулыш алып.— Иртәгә ни буласын әйтеп булмый. Сиңа яшәргә, үз халкыңа хезмәт итәргә кирәк әле...

— Рәхмәт,— дидем, киңәшенең ихласлыгына һич шигем калмыйча.— Минем монда дусларым, фикердәшләрем күп, Руслан Имранович. Аларны ташлый алмыйм. Ни язган булса, шул булыр, мин монда калам, сезнең белән.

— Үзең беләсеңдер,— диде Хасбулатов.

Мин чыгу ишеген ачкан идем инде. Тоткарланмадым. Юлым дәвам иттем.

Тагын караңгы коридорлар... Почмак саен «Кем килә... Документларыгызны күрсәтегез» дигән коры сүзләр. Автоматларын «шалт-шолт» китереп, «юкса атып егам» дигән сыман кисәтүләр.

Шәм яндырып тормадым. Кармалап-кармалап барсам бардым, таптым үзебезнең катны һәм үзебезнең ишекне.

Көткәннәр... Йокламаганнар.

— Ничек, ярдәм киләме?— булды беренче сораулары. Һәркем өмет белән яши иде әле.

— Ачык кына билгеле түгел,— дидем.

Сорау артыннан сорау. Ни хикмәт, берсе дә үз җаннары өчен түгел, туган илләре һәм аның киләчәк язмышы өчен борчулы иделәр. Төче сүзләр, дип кабул итмәгез, хакыйкатьтә шулай.

— Иртәгә иртәнге җидедә Югары Совет утырышы булачак,— дигән хәбәрне җиткердем, һәм хәерле төннәр теләдек бер-беребезгә.

Хатын-кызлар яңадан кабинетка кереп китте. Кемнәрдер кабул итү бүлмәсендә урнашты. Мин — Хәсән Хәбибуллин һәм азсанлы эвен халкының танылган әдибе Андрей Кривошапкин белән берлектә — компьютерлар урнаштырылган кысан кабинетка уздым. Кем кая чумәште, тәгаен генә хәтерләмим. Һәрхәлдә, мин креслога утырдым... Урын-җир юк. Бүлмә салкын. Җаннан тынгылык качкан. Беребезнең дә күзләренә йокы кермәде. Әмма сөйләшмәдек, һәркем үз уйлары чоңгылында боргаланып чыкты.

Йокламадым, дисәң дә күз йомыла, әлбәттә. Уйланып яттым дисәң дә, фикер шактый таркаулана, күзаллары томалана икән ул йокысыз төннәрдән соң. Үзем уяу. Һәм шул ук вакытта төш тә күреп ятам кебек. Нindидер хәрәкәт, гөрелте купты кинәт. Танклар килгән кебек. Кызыл мәйданда Октябрь бәйрәменә әзерләнәләрме әллә?.. Бәйрәмгә дә күп калмый. Авыр машиналарның асфальт мәйданны тырнап барылган авазлары ишетелеп тора. Шау-шу, гөрелдәүләр... Тагы танк тавышлары...

Чү!.. Бәйрәм булса «Ур-ра!» кычкырырлар иде, шатлык авазлары ишетелеп торыр иде. Кемнәрдер каравыл кычкыра, елаша, ярдәмгә үк чакыра башлады түгелме...

Ул да түгел, колак төбендә генә шатыр-шотыр атарга керештеләр. Юк, бу кичәге Калашников автоматлары авазы түгел иде. Пулеметлардан аталар. Эре калибрлы пулеметлардан...

Төш түгел ләбаса, өндә икән ич. Сискәнеп сикереп тордым.

— Хәсән... Андрей...— дип кычкырдым ни эшләргә белмичә.— Штурм башланган ич, нишләп ятасыз сез!

— Син ятканга ятабыз,— диде Андрей, елкылдап торган кысык күзләрен челт-челт йомып.— Син комитет җитәкчесе. Син ни кушсаң, шуны үтибез хәзер, сугыш вакытындагы кебек.

— «И-и табигать баласы, дип уйлап куйдым күңелемнән, мин үзем дә мондый хәлдә калган кеше түгел шул. Ни эшләргә икәнлекне каян белим...»— Шаяртма. Шаярта торган чак түгел,— дим.

— Ә мин шаяртмыйм,— ди Андрей Кривошапкин. Кырыс тундра шартларында туып-үскән ул, карашлары җитди.— Анда каршы як бүлмәдә хатын-кызлар кая барырга, ни кылырга белми. Син җитәкче, син бер карарга килергә тиеш, дим.

— Син ни киңәш итәсең, Андрей Васильевич?..

— Мин каян белим. Сезнең Мәскәү тәртипләрен мин, гомумән, белмим. Тундрада яисә тайгада булсак, әйтер идем.

Хәсән дә дәшми. Өнемме бу, төшемме, дигәндәй, күзләрен челт-мелт йомгалап тик утыруын белә. Азнакайда калган сөйгән ярын, балаларын хәтергә төшергән булса кирәк.

Ишекне ачып, кабул итү бүлмәсенә чыктык. Әллә безнең тарафтагы хәрәкәтне ишетеп, хатын-кызлар ягыннан да ачылды ишек. Никадәр генә батыр һәм куркусыз дисәң дә, хатын-кызлар тәмам чарасыз калганнар иде.

Пулеметлар бертуктаусыз атуларын дәвам иттерделәр. Ниһаять, Югары Совет бинасыннан да автоматлар җавап кайтарырга керешә кебек. Чын сугыш башланган иде. Берән-сәрән генә түгел, тоташ ату авазлары...

Сак кына килеп, коридорга чыга торган ишекне ачтым. Нәкъ шул вакыт очраклы бер пуля коридор башындагы тәрәзәне тишеп үтте. Урам яктагы кабинетларда чәлпәрәмә килеп тәрәзәләр коелып төшә, пуля тишекләреннән ишекләр чәрдәкләнеп беткән.

Каршы як кабинетларның берсеннән халык депутаты Ильенков үрмәләп килеп чыкты. Ул озак еллар Калинин өлкәсендә беренче секретарь булып эшләгән өлкән яшьтәге кеше, зур гәүдәле. Яшьтәшләре һәм яшьләр арасында да абруйлы санала иде. Ачык ишекне күреп, безнең янга узды Ильенков.

— Менә шулай, Ринат,— диде хәйран калуын белдереп.— Анда, мәйдандагы халыкны чалгы белән чапкандай иттеләр. Турактадылар...

Гомер кичергән, олы яшьтәге нык ир-атның күзләрендә курку түгел, яшь тамчылары булуын тойдым шунда.

— Монда калырга ярамас, җәмәгать,— дидем, чарасыз торудан бер чыгу юлын эзләп.— Сак кына Милләтләр Советының утырышлар залына таба хәрәкәт итик булмаса. Башкача юк котылу юлы.

Ильенков беренче булып кузгалды. Аның артыннан, тыйнак каз бәбкәләредәй, башкалар иярде. Кабинет хуҗасы буларак, соңгы кеше чыкканчы көтәргә мәҗбүр идем. Ишекне бикләп маташкан арада, каршы яктагы икенче бер кабинеттан, Новосибирскидан сайланган алтмыш алты яшьлек депутат Боков күренде.

— Ах, сволочлар,— диде ул, башын чайкап... һәм кесәсеннән ачкыч эзләргә керешә.— Фашистлардан явызрак кылана болар. Кешелеклелекнең әсәре калмаган үзләрендә.

Боков минем милли республикалар һәм аларның хокуклары хакында еш сөйләвемне өнәп бетерми торган иде. Шул искә төште дә, телгә тәртмәле сүз килде.

— Кемне хурлыйсыз, бүленмәс Россия солдатлары ич алар?
— Белмим, руслармы икән?
— Әллә татарлар яисә чеченнар дип әйтергә җыенасызмы? Шунда гына ул мине аңлады. «Түгел» дигәнен аңлатып башын чайкады.
Кулындагы ачкычын йозак тишегенә кертә алмый изаланган күрше янына килдем. Ул калын күзлекле, өстәвенә, дулкынлана, ярдәм итим, дим.
— Аз гына көтегез, зинһар, мәйданга күз ташлап алыйм әле. Сез әйткәннәргә ышанасым килми,— дидем.
— Баш тыгарлык түгел, Ринат. Киңәш итмим.— диде Боков җиңемнән тотып туктатмакчы булды. Өлгермәде.
— Гафу итегез, зинһар, карыймчы,— дип, аның ай-ваена игътибар итмичә дивар ышыгына елышып әчкә уздым.
— Нишлисең, син, тезләп. Чүгәлә,— дип, боерык бирде күршем.— Бик сак бул анда, күрәсең ич, тәрәзне тишкәләп бетерделәр.
Чүгәли төшеп тәрәз каршысына уздым. Һәм стена читләтеп бер күз белән генә мәйданга күз салдым...
Аяк астымда җир чайкалып куйгандай булды кинәт, баш әйләнеп китте. Чарасыз, баганадай катып калдым. Үз күзләремә үзем ышанырлык түгел. Һәм бүген дә ышанып бетмим кебек. Шул минутта күз алдымда пәйда булган ул коточкыч күренешне сурәтләп тә, сөйләп тә күрсәтерлек, аңлатырлык түгел иде.
Каз көтүе өстеннән исерек шофер идарә иткән йөк машинасы узып киткәнмени!.. Канатлары каерылган. Муеннары асылынып төшкән. Берәү йөзтүбән, икенчесе арка белән ауган. Өченчесенең аяклары тартышып-тартышып куя — җан бирүе. Берәү, икәү, өчәү дип, санарлык булса икән ул... Мәйданда диңгез булып кайнашкан, ничәмә-ничә тәүлекләр дәвамында көн дими, төн дими Югары Совет бинасын җанлы калкан сыман уратып, саклап торган фанатиклар һәм фидакарьләр ич болар. Мәйданның дүрт почмагына килеп туктаган БТРлардан эре калибрлы пулеметлар кургаш яңгыры белән әле булса тураклап тора үзләрен. Куркыту өчен түгел, үтерү өчен аталар. Аяктан егу өчен генә дә түгел, юк итү өчен. Тамырларын корыту өчен. Үлем исереклеге белән баш калкытканны, шундук кисеп дигәндәй, аударалар.
Бина эченнән мәйданга кинәт ак халат киенгән ике ханым йөгереп чыкты. Кулларында ак кульяулык: «Атмагыз, без ярдәмгә килүче»,— дигән сүзләре булгандыр. Мәйданда борсаланып кан эчендә яткан берәүгә ярдәм кулы сузып иелүләре булды, шундук бер-бер артлы үзләре канатсыз калды. Ай Аллам, ак канатларын кызылга манып алдылар, диярсең... Очраклы бер пуля тию генә түгел иде бу, эре калибрлы пулемет гүя аркылы кисте, тураклады үзләрен. Ярдәм сорап югары күтәрелгән авыр яралы өстенә аудылар. Берсе йөзтүбән ятты. Икенчесе чалкан барып төште. Башын артка ташлады, аксыл бөдрә чәчләре таралып җилфердәде, соңгы тапкыр булса да зәңгәр күккә багып калыйм, диде булса кирәк.
Чигәләремдә нидер зеңгелдәп куйды шунда. Әйтерсең, бик тә мөһим булган бер кыл өзелергә җитеп киерелде. Кичәге палатка кайда соң? Розалия һәм Гүзәлия?! Таҗикстаннан үлемнән качып кайткан кызлар исәнме анда?
Кыл өзелде... Теткәләнеп беткән таныш палатка, тыны чыккан көпчәк сыман, салынып төшкән. Әледән-әле исеп торган иртәнге җилдә ул җилфердәп куя, гүя очарга талпына. Әмма дүрт почмактан тарттырып куелган җепләрнең берсе, ничектер, пулялардан котылып өзелми калган. Һәм җил исеп куйгач та очарга дип күтәрелгән палатканы шул бер нечкә җеп тотып кала...
Мин моның шулай булуына игътибар да итмәгән булыр идем, әлбәттә. Хикмәт шунда: «Мир» кунакханәсе почмагында урнашкан өр-яңа бронетранспортердан берәзлексез шул палаткага таба аталар. Эре калиб-

рлы пулеметтан. Куе яшел комач тетколәнеп беткән, тузгый, парча-парча кисәкләргә бүленеп читкә очып китә. Игътибар иттем, бер пулемет ата иде моңарчы, бераздан икенчесе кушылды аңарга. Палатка калдыкларын юк итү кирәк иде, күрәсең. Бер-берсен уздырышып ата тегеләр. Һәм, ниһаять, кара челтәргә әверелгән комачның соңгы кисәкләре тузгып аерылды җептән.

Кинәт, ачыргаланып искән көзге җил яшел комачның соңгы кисәген йолкып алды һәм бөтен мәйдан өстеннән очыртып алып китте. Әле тәннәре суынмаган, кайнар кан эчендә яткан мәскәүлеләр һәм россиялыларның шул рәвешле җаны очып бара иде гүя.

Чү, ни күрәм: күтәрелгән җил палаткадан калган тимер казыкка ниндидер башка бер комач, юк, комач түгел, миңа бик тә таныш булган зәңгәр яулык китереп сылады түгелме соң?! Зәңгәр яулык... Бу бит Розалия яисә Гүзәлия яулыгы түгелме. Нәкъ үзе, таныш яулык... Йөрәк жу-у итеп куйды. Ходаем, кызлар, кызларны үтергәннәрме әллә? Аларның, ул нарасыйларның ни гаебе бар? Алар кемгә зыян иткән? Черномырдингамы? Ельцингамы?!

Күзләремне шул зәңгәр яулыктан аера алмадым мин. Чөнки уңга да, сулга да карау мөмкин түгел. Арыга да ташлап булмый карашны, бирегә дә. Һәр тарафта кан һәм җансыз гәүдәләр... Мәйданда бердәнбер җанлы нәрсә — ул да булса шул зәңгәр яулык. Белмим, Розалия башындагы яулык булгандырмы ул, Гүзәлиянең нәфис толымнары читеннән салынып төшкәнеме?.. Әйтү кыен. Һичкемнән сорап та булмый моны.

Икенче яулыкмы? Кем белә, бәлки ул яулыкларның икенчесе зәңгәр кошка әверелеп, сыеныр җир һәм яклаучы эзләп Татарстан тарафларына очып киткәндер...

Ә кызлар — Розалия белән Гүзәлия кая?.. Үзем сорау бирәм, үзем карашымны түбәнгә таба борырга куркам. Палатка торган урында шомлы җансызлык хакимлек итә. Үле тынлык. Карарга, тыңларга куркыныч. Кызлар... Эх, сез кызлар... Матур кызлар... Алар хәрәкәтсезләр иде. Гүя тирән йокыга талганнар. Карашым, сак кына барлап чыкты үзләрен. Уяныргa уйларында да юк. Уянмыйлар... Әтиләре дә кайтмаган булган, күрәсең. Янәшәләрендә ир-ат күренми. Әниләре шунда. Әниләре ике кызын ике кочагына кыскан дә йөзтүбән егылган. Кызларын күкрәге белән капларга теләгәндер, өлгермәгән.

Күзләремнең бар булган җегәрен туплап ана кочагында яткан сабыйларга текәлдем. Исән түгелләрме?.. Ярдәмгә мохтаҗ түгелләрме?.. Күңелдә өмет сүнмәгән иде әле. Бәлки алар менә-менә башларын калкытыр. Һич булмаса, берсе торып, уятырга теләп, әниләренең җилдә тузгыган озын кара толымнарына сарылыр.

Болай булырга тиеш түгел иде бит. Мин бит әле сабыйларны бүген бәхетле итәргә тиеш идем. Кичтән үк үзләре өчен төсле рәсемле татарча китаплар хәстәрләп куйган идем. Ничек тапшырыйм үзләренә... Ни рәвешле ярдәм итим. Шулкадәр дә көчсезмени инде мин... Шул ике сабыйга да ярдәм итә алма инде...

Таҗикстаннан сөрелдек дигәннәр иде. Россиянең башкаласы Мәскәү әнә ничек каршылады үзләрен. Нинди кунакчыллык, гомергә үз кочагына алды.

Розалия белән Гүзәлиянең соңгы тамчы каннары тамган мәйданны хәзер биек тимер-таш койма белән уратып алганнар. Дәү-дәү кара машиналарга утырып зур-зур житәкчеләр генә узып йөри ул мәйданнан. Язу-фәлән һәм хисап номерлары да булмаган бронетранспортерлар инде киткән, югалган ул тарафлардан. Аларны кырып салган пулеметчылар, бәлки, хәзер үз кызларын кулларына алып үчти-үчти итә торганнардыр... Ә тимер казык очына эләккән зәңгәр яулык һаман күз алдында. Әле дә җилферди. Әле дә тынгылык бирми... Эшкә барырга дип урамга чыксам

да, кече кызымны мәктәпкә озата барганда да мин әле булса югарыга, зәңгәр күккә күз салып алам. Казанга таба канатларын җилпеп очкан кошлар арасыннан Розалия һәм Гүзәлиянең зәңгәр яулыкларын эзлим...

* * *

— Ринат, күпме көтәргә була сине? Үләсең киләме?! — дип кычкырдылар. Боков агай булып чыкты. Ул әле булса мине көтеп ишек катында тора икән.

Тагы бер кат Ирекле Россия исемле үле мәйданга һәм җилфердәүдән һич туктамаган, зәңгәр акчарлактай берөзлексез канатларын җилпеп торган зәңгәр яулыкка күзләремне тутырып карадым да, кире борылдым. Чигәмдә менә өзеләм, менә өзеләм дип күпме тартылып торган теге кыл шул мизгел, ниһаять, шартлап өзелде. Бу илдә кайчан да булса тәртип бер урнашыр дигән хыял җимерелдеме? Өмет өзелдеме? Сәясәтче хакимнәргә булган ышанычмы мәңгегә юк булды?! Кистереп кенә әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, шул мизгелдән әллә нәрсә булды үзем белән, аңа кадәрге халәтемә әле булса кайта алганым юк. «Кайтулар булмас инде...»

Кайда чүгәли, кайда үрмәли төшеп, тар коридор буйлап ары уздык. Без шактый ук тоткарланган булып чыктык. Бина эчендә булып исәнаман калганнар инде күптән Милләтләр Советының утырышлар залына узган. Ә безгә әле өченче катка күтәреләсе бар. Юл бер генә — дивар урынына тоташ пыяла тәрәзә булган буфет аша узу. Баскычтан күтәрелә башлагач ук, йөрәк жуылдап куйды, тәрәзәләр тишкәләнеп беткән, урам яктан берөзлексез аталар. Салкын җил исә. Чалтыр-чолтыр пыяла коела, бәллүр люстралар зеңгелдәп тора.

Без туктала төштек. Әмма баскыч читендә тору да куркынычсыз түгел, пулялар әле анда, әле монда йөрәк яргыч аваз чыгарып, колак читеннән генә очып уза. Күп булса, биш метр ачык җирдән узасы бар, аннан стеналарга елышып юлны дәвам итү мөмкин булачак.

— Кем беренче? — дип сорады Боков агай.

Дөрес аңладым булса кирәк, син яшь, әйдә, тәвәккәлләп карыйсыңмы әллә, диюе иде.

— Ярый, мин киттем,— дидем. Һәм автомат очередьлары бераз тыныч торган арада, башны ия төшеп, алга ыргылдым.

Ике атладым һәм өч сикердем дигәндәй, күз ачып-йомган арада мин каршы як диварга барып сыенган идем инде. Ләкин минем хәрәкәт тышкы яктан атучыларның игътибарын җәлеп итте, шатыр-шотыр атарга керештеләр. Очраклы очучы пулялар түгел иде бу, нәкъ менә әле генә мин йөгереп узган эздән аталар. Мин сакланып торган диварның чыгып торган почмагын теткәләп бетерделәр инде.

— Ашыкмагыз. Бераз көтик. Туктарлар,— дип киңәш бирдем Боков агайга.

Старт сызыгына баскан йөгерешче сыман иелә төшеп көтә иде ул. Көтеп-көтеп тә форсат чыкмагач, билен турайтырга мәҗбүр булды.

— Каян ата болар? — дип гаҗәпсенде ул.— Без өченче катта. Ә алар үрмәләп узганны да күреп торалар...

Чынлап та кызыклы һәм гыйбрәтле сорау иде бу. Безгә атучылар мәйданда яисә каршы яктагы бакчада була алмый. Димәк, бер урын — ул да булса, тәрәзәдән күренеп торган бердәнбер бина — Америка Кушма Штатлары илчелеге кала... Әмма бу мөмкинме? Һич юк, мөмкин түгел. Тәрәзә каршысында вертолетлар күренми, башка атар җир юк. Димәк, уйларга, нәтиҗә ясарга куркыныч хәтта...

Шулай да аталар. Безне болар, башкача түгел, бинаны саклаучы хәрбиләр дип кабул итте бугай.

— Нишлибез инде,— дип сорыйм агайдан, ату авазлары тынып торган арада.— Болар безне атып үтерергә дә мөмкиннәр бит. Башыгызны тыга күрмәгез.
Өлкән кеше, өлкән кеше инде — ул үзенчә нәтиҗә ясады.
— Безне әлегә бары бер автоматчы эзәрлекли,— диде ул.— Әмма аның кулында оптик төзәү җайланмасы булган автомат-мылтык. Шаярырга ярамый... Бар син, болай ит әле. Диварга сыенып бераз ары китсәң, анда бер шкаф булыр. Шуны каерып ачсаң, йә бер-бер чиләк, кирәк ише нәрсә табарсың. Алып кил әле. Үзен алдыйбыз аннары, әллә кем түгелдер әле...
Нәкъ ул кушканча эшләдем. Кирәк юк иде, югын. Әмма, бер кечкенә багор һәм кып-кызылга буялган озын төпле чиләк табып килдем.
— Ни эшләтим боларны? — дим.
— Багорын куеп тор. Ә чиләген баш югарылыгында күрсәткәләп ал.
— Аңладым. Әмма сез иелә төшеп йөгерегез, баш калкыта күрмәгез.
Килештек, дип хәбәр салды Боков агай. Чиләк төбен күрсәтеп алуым булды, аны өч-дүрт пуля шул ук мизгелдә тишкәләп чыкты, һәм кулымнан каерып алып атты. Ә аралыкны кыр куяны сыман сикереп узган кешене вакытында абайламый калды теге. Кичегә төшеп күрде, өлгермәде...
Шунда гына икебез дә иркен итеп сулыш алдык. Тәки алдадык бит үзен...
Рәхмәт йөзеннән, куллары белән аркама кагылып узды Боков агай.
— Коткардың, Ринат,— диде.
Мин дә аңарга, гомеремдә беренче мәртәбә, олылап дәштем. (Әйткән идем ич, ул мине Татарстан мәнфәгатьләрен яклаган өчен өнәп бетерми торган иде.)
— Котылдык, Владимир Анатольевич, котылдык...

* * *

Ирләр бәдрәфе каршындагы тәмәкечеләр мәйданында бертөркем танышларым басып тора. Алар янына килдем. Сергей Бабуринны уратып алганнар. Тыңлыйлар... Әмма Бабуринның үзен түгел, аның кулындагы радиотелефонны.
Очраклы рәвештәме, белмим, әмма Югары Советка һөҗүм ясаучы хәрбиләр каналына тоташкан иделәр.
— «Меркурий»... «Меркурий»... Мин — «Марс». Ишетәсеңме?
— Ишетәм, анаңны шулай иткере... Ник ишетмәскә, кабер тактаңны шулай иткере... Сөйлә, (җиде катлы сүгенү).
— Иптәш командир, безнең танклар Кутузов проспектына чыкты. Әмма хәрәкәт итү кыен... Урамда халык. Нишләргә боерасыз?
— Приказны үтә диләр сиңа... (җиде катлы сүгенү).
— Аңладым, иптәш командир. Кешеләр барырга ирек бирми, аркылы чыгып басканнар...
— Нинди кешеләр?! Боерыкны үтә диләр сиңа, авызыңны (җиде катлы сүгенү), денеңне (җиде катлы сүгенү).
— Хатын-кызлар, орден-медальләрен таккан ветераннар, бала-чагалар, иптәш командир. Хәрәкәт итүе кыен. Мөмкин түгел.
— Алга... Алга диләр бит сиңа, (җиде катлы сүгенү). Ветераннарын, орден-медальләре белән бергә... (шулай иткерләре — тагы ким дигәндә, җиде-сигез катлы сүгенү).
— Танкистлар туктады. Хәрәкәт итә алмыйлар, иптәш командир. Хатын-кызлар юлга аркылы сузылып яткан, танк астына ташланалар. «Җибәрмибез, анда безнең балаларыбыз. Ватаныбыз сакчылары!» — диләр.

— Таптат. Сыт үзләрен. (Үз колагың ишетеп тә ышанмаслык сүгенү). Берочтан әйт, балалары юк инде... Ватаннарын, сакчылары белән бергә... (шулай итеп ыргыт).

— Ташланалар... Сытылалар, иптәш командир. Хәрәкәт итеп булмый болай. Җавапны миннән сорарлар...

— Сыт, дигәннәр бит сиңа. Синең эшең алга бару. Хатын-кызмы, ветеранмы... Тараканмы анда... Бернигә карама, алга, авызыңны-денеңне... Аңладыңмы?!

— Аңладым, иптәш командир.

— Танк булгач, сытарга да, таптарга да, җимерергә дә туры килә, майор. Тизрәк, җәтрәк булыгыз анда. Юкка гына бер көн өчен ике айлык хезмәт хакы вәгъдә ителми. Аңлашылдымы, майор!

— Аңладым, иптәш генерал.

— Алга... Алга... Чыккан җирләренә олаксын барысы да.

Шул урында элемтә өзелде.

— Башка дулкынга күчтеләр,— диде Коровников.

Ул — хәрби кеше, һәрхәлдә, белә торгандыр.

Бабурин кабалана-кабалана, башкаларның зарыгып көтүен күреп, яңа бер дулкын эзләргә кереште.

Автомат һәм пулеметлар тыкылдаганы бераз басыла төшкән арада, якында гына вертолетлар авазы ишетелде. Бер түгел, берничә вертолет иде, күрәсең... Депутатлар ишегалдына чыга торган тәрәзәләргә ябырылды.

— Кемнәр икән? Әллә ярдәмгә килүчеләрме? — дигән сорау, өмет иде телләрендә. Һәм, әлбәттә, күңелләрдә.

— Рязаньнан һава десантчылары килергә тиеш дигәннәр иде. Шулардыр...

— Рязаньнан булмас. Анда Ельцинның баш куштаны Рюмин хакимлек итә.

— Дөрес, Рязань булмас. Смоленск вертолетларыдыр...

— Яисә Мәскәү хәрби округыннан. Анда Руцкойның якын дусты бар, дигәннәр иде.

— Ярдәмгә килделәр... Ярдәмгә... десант килде...— дигән сүзләр әллә ни арада Милләтләр Советы залына шыплап кереп тулган депутатлар һәм аппарат хезмәткәрләренә дә барып ирешкән иде инде.

Кемнәрдер «Урра» кычкырып куйды. Кемнәрдер утырган җирләреннән аякларын тыпырдатып кул чәбәкәп алды.

Мин дә тәрәзә янына узып, башкалар өстеннән муенымны югары суздым. Бер... ике... өч вертолетны абайларга өлгердем. Югары Совет бинасы өстенә эленгән сыман баш очында торалар.

Ул да түгел, болар бер-бер артлы атарга керешмәсенме... Кара төтен чыгарып очкан яндыргычларын үз күзләрем белән күрдем...

Бинаның югары катларыннан берәү автомат белән җавап кайтарды үзләренә.

«Ух-ах» килде һәммәсе, тәрәзә каршысы бушап калды. Депутатларның эзе дә юк. Ай күрде — Кояш алды. Җимергеч снарядлар түгел, бинада паника уяту өчен яндыргычлар сибеп китте бу өч вертолет.

Аңлашылды. Болай булгач — ныклап тотынганнар болар. Җаннар киселәчәк, кан күп түгеләчәк... Вакыйгаларның ни белән тәмамланасын, белсә дә, Алла үзе генә белә торгандыр. Шундый уйлар, һәм өметсезлектән салынып төшкән башымны күтәрә төшеп Милләтләр Советының утырышлар залына килеп кердем. Рәиссез калган Милләтләр Советы залына...

Борынгы грек театрларына охшатып эшләнгән җыйнак зал сельд балыгы тутырылган агач кисмәкне хәтерләткәндер ул сәгатьләрдә. Буш урын кая инде ул, баскычлар тум-тулы, идәндә алма төшәр, аяк басар урын калмаган. Сәхнә сыман күтәрә төшеп эшләнгән Президиум өстәле

тирәсендә дә бу илнең ятим уллары, ятим кызлары тезелешеп утырган. Һәммәсе диярлек таныш йөзләр.Әмма аларның күз карашлары гына башка. Гүя бер-берен күрмиләр, һәркайсы үз уена чумган, онытылган...

Ишек катында басып торган көйгә карап хәйран калдым. Үз вакытында Республика һәм өлкәләрдә компартия оешмаларының беренче секретарьлары булып эшләгәннәр дә бар иде монда. Аларны «партократ» дип, фаш итеп, ике сүзнең берендә «демократия» һәм «кеше хокуклары» дип кычкыручылары да. СССРны җимерү өчен җир тырмашкан депутат, бу эшнең тарих һичбервакыт гафу итмәячәк җинаять булачагын аңлатып чыккан замандашы белән янәшә утыра. Язмышлары уртак хәзер. Беренче съездда Ельцинны рәис итеп сайлау өчен тавыш җыеп йөргәннәр бар монда. Шул көннәрдә үк бу сәясәтченең Россия өчен куркыныч диктатор булу ихтималын кисәткән күрәзәчеләр бар... Салынмас жиреннән салынып төшәр газиз башларың. Өстәвенә бу көннең ни белән тәмамланачагын, алда үзеңне ниләр көткәнен дә ачык кына күзаллау мөмкин түгел.

— Врачлар бармы?... Табиблар, табиблар кирәк,— дигән көчле чакыру авазы яңгырады залга керә торган сул як ишектән.—Кешеләрнең гомере кыл өстендә. Ярдәм кирәк.

Йөрәк «жу» итеп куйды. Димәк, үлем җиле, мәйданны кырып чыкканнан соң, бина эченә дә килеп кергән. Болай да шактый басынкы торган залга үлем тынлыгы иңде.

Табиблар аз түгел иде безнең арада. Әмма, әллә каушап калдылар, дәррәү сикереп торырга җыенмадылар. Иң беренче булып Чувашстан Республикасы сәламәтлек саклау министры Николай Григорьев ашыкты. Аңарга ияручe дә чуваш егете Станислав Николаев иде. Аннан бер-бер артлы хатын-кызлар калка башлады. Казаннан сайланган депутат Вячеслав Пырков кушылды тегеләргә.

Ишек катыннан тагы игълан ишетелде:

— Ир-ат табибларны гына чакырабыз. Хатын-кызлар әлегә кирәкми.

— Табибларны иргә, хатын-кызга аермыйлар инде,— ди-ди, канәгатьсезлек белдереп, кире борылды ханымнар. Алар арасында Башкортстаннан сайланган татар кызы Роза Низаметдинова да бар иде.

Залга яңадан-яңа хәвефле хәбәрләр килеп торды: Руцкойның бер-бер артлы ике ярдәмчесен атып үтергәннәр... Пуля икесенең дә чигәләрен тишеп чыккан... Кабинет өленгеләр белән капланган, югыйсә, үтәдән күрү җайланмалары бар, күрәсең... Үзәк бинаның югары катларында байтак кешеләр янып үлгән... Котылу чаралары калмагач, жанлы факел сыман түбәнгә сикерүчеләр дә бар икән...

Утырыр җир тапмагач, залдан чыгып бераз әйләнеп керергә булдым. Ишек төбендә кизүлеккә баскан хәрби егет: Чыкмаска,— киңәш итте.— Чыккан тәкъдирдә дә шушы тирәдә генә булырга.

Шушы тирә дигәне, залны уратып алган ярымкараңгы тар аралыклар. Кичектергесез йомышларым булмаса да, кире борылмадым. Егетләр йөри бит, әнә, тыз-быз чабышалар. Адашкан пулялар нәкъ минә мине эзләп тапмас әле. Күңелемнән генә «Алла сакласын...»ны өч мәртәбә кабатладым да, бераз гизеп кердем.

Исем-акылым китте. Күп булса, әле ярты сәгать булып чыкканмындыр ул залда. Шул арада күпме үзгәреш. Тар аралыктан атлап узарлык түгел, идән тулы яралы егетләр. Берәүләре яраларын кысып тотканнар да, ипле генә уйга чумып утыралар. Икенчеләре, ыңгыраша, газаплана. Хәрби киемдәге бер ир-ат исә, әллә саташып, әллә үлем өянәге белән, идәнгә сузылып яткан жиреннән «Ельцинны һәм аның бандасын» каһәрли, аты-юлы белән сүгенә. Берочтан үзе кемнәрнедер куркаклыкта да гаепли тагы.

Ул да түгел, янәшәмнән генә өр-яңа куе-яшел гәләфиләр һәм ялтырап торган хром итекләрен шыгырдатып ниндидер бертөркем хәрбиләр узып китте. Мондый сәер кыяфәтле егетләрне беренче күрүем иде. Аеруча игътибарымны җәлеп иткәне, боларның беләкләрендәге сәер символ

булгандыр. Фашистларның тәресен хәтерләткәнгәдер, мин алардан чирканып ук куйдым.

Боларның артыннан ук бик тә эшлекле кыяфәт белән атлап баручы Илья Константиновтан сорарга мәҗбүр булдым.

— Болары кемнәр тагы?

— Болармы? — диде Илья, шуны да белмисеңме дигәндәй, эре генә.— Баркашовчылар. Россиянең таянычы булачак егетләр.

Соравыма җавап алдым. Константинов үз юлында булды. Белмим шул, дигән уй узды башымнан, төс-бит һәм кыяфәтләре бер дә алай яхшы тәэсир калдырмады. Асыл максатлары ни булгандыр тагы...

Бинада Россиянең таянычы булырдай егетләр чынлап та күп иде ул көнне. Баркашовчылар хакында да кистереп кенә хөкем итә алмыйм, үзләре белә торганнардыр. Әмма әлеге егетләргә карата шикле мөнәсәбәтем һич очраклы булмаган икән бит. Үзләрен «баркашовчы» дип күрсәткән шул ук төркемне мин кичкырын күреп калдым тагы. Югары Совет бинасында кулга төшерелгән кешеләрне сортларга аерып торган ике офицер янына, күз кысышып көлешә-көлешә узып китте болар. «Баркашовчы»ларга андый мөмкинлекләр бирелмәгәндер ул.

Гизүемне дәвам итәм. Тантаналар залы каршындагы үзәк баскыч яныннан узганда ике кат арасында утырган бертөркем яшүсмерләргә игътибар иттем. Уннан артык иделәр булса кирәк. Үндүрт-унбиш яшьләрдәге егетләр һәм кызлар. Аларны бина каршындагы мәйданда берничә мәртәбә күргәнем бар иде инде. Кемнәр һәм кай тарафтан булуларын гына белмим. Киемнәренә караганда, мәскәүлеләр түгел, хикмәт эзләп, сәяхәткә чыгучылар булса кирәк.

Якын ук килдем үзләренә. Муенына ап-ак шарф ураган бер кыз гитара уйный, башкалары кушылып җырлый. Җырлары да андый-мондый түгел, «Катюша»ны.

— Сез кай тарафлардан? — дип, мөрәҗәгать иттем, үземә якынрак торган үсмер егеткә.

— Харьковтан...

— Ул кадәр җирләрдән, чит илләрдән ничек килеп чыгарга булдыгыз?

— Мәскәүне күрергә килгән идек. Шушы хәлләр башлангач, сезне сакларга килдек...

Сезне дигәне, депутатларны, Югары Советны дигән сүзе. Чөнки, минем яка уртасындагы депутатлык билгесен ул күреп тора.

— Урамнан ни рәвешле исән-сау котылдыгыз? — дим.

— Ике кызыбызны атып үтерделәр. Ишеккә якын идек, башкаларыбыз качарга өлгердек...

— Әйе, хәлләрегез бик тә авыр икән бит. Кайгыгызны бүлешәм,— дидем дә, үз юлымда булдым.

Матур җырлыйлар үзләре. Беркадәр украин акценты белән «Катюша» тагы да байый төшкән сыман тоелды.

Ике-өч адым үтәргә өлгердемме икән, җыр кинәт өзелеп калды. Ачыргаланып кычкырган тавышка борылып карасам, гитара уйнап җырлаган ак шарфлы кыз бөгелеп төшкән. Колак төбеннән шаулап кан ага. Араларында иң матур бер кыз иде. Игътибарым җәлеп иткән иде. Күзем дә каты түгел, югыйсә, әллә күз тиде үзенә.

— Табиб... Табиблар кая?! Монда, баскыч янына килегез,— дип, кычкырып җибәрдем үз-үземне белешмичә.

Ярдәм килде бераздан. Әмма ак шарфлы кыз ул ярдәмгә мохтаҗ түгел иде инде. Унбиш яшьлек кыз өстенә ак җәймә каплап куйдылар.

Яшьләрнең башкаларын, мәҗбүр итеп диярлек, Милләтләр Советы залына кертеп җибәрдек. Күзләрендә канлы яшь иде һәммәсенең... Егетләре, гозерләп диярлек, үзләренә автомат яисә бер-бер корал бирүне таләп итәргә кереште. Үч алу иде теләкләре.

— Нигә алар кызларны гына үтерә. Өч кызыбызны юк иттеләр. Нигә егетләргә атмый алар? Автомат бирегез безгә. Автомалар... Өч кыз үчен кайтарасыбыз бар...

Кемнән?! Кемнән алырга соң ул үчне?

Югары Совет бинасында корал таләп итүче, үлгәннәр өчен үч алырга атлыгып торучылар күп иде ул көнне. Ишәйгәннән-ишәя барды андыйлар. Әмма корал өләшүче булмады.

Бина эчендә, минем белгәнемчә, җиде генерал бар иде ул көнне һәм бер контрадмирал. Контрадмирал дип әйтергә генә авыр, ул — Рәфкать Заһидулла улы Чеботаревский. Ишек катында аның белән маңгайга-маңгай белән бәрелешә яздык.

— Ба...— дип, куйды ул гаҗәпсенеп. Һәм шундук татарчага күчте.— Син дә мондамыни?

Кул кысыштык.

— Кайда булырга тиеш идем соң?

— Син — язучы, безнең халыкка кирәк кеше.— Өенә кайтып йокларга кирәк иде,— дип, балкып елмайды ул.

— Син дә халыкка кирәкле кеше, Рәфкать. Дөрес, генералларсыз, контрадмиралларсыз да яшәү мөмкин булыр иде. Ләкин, аларның да синең кебекләре булуы хәерле.

— Ярар инде, салпы якка салам кыстырмасана...— Һәм җитдиләнә төште ул.— Киңәшем шул, кара аны, коридор буйлап арлы-бирле йөрүеңне туктат. Пуляның үтеп кермәгән җире юк аның.

— Рәхмәт,— дидем. Һәм күптәнге сөйләшүебезне искә төшердем үзенә.— Татарстанга кайтам дигән вәгъдәң бар, моннан чыккач та бергәләп китәбезме әллә?..

— Сиңа әйтмәдемме?.. Мин бит Татарстанда булдым быел.— дип җанланып куйды Рәфкать.— Сәлимханга кайттык ич. Петровкада Сабан туе күрдек. Иван Савченко белән кайткан идек.

— Үпкәләттең,— дидем мин.— Сәлимханга кайткансың. Ә Казан аша узып, миңа хәбәр дә бирмәгәнсең. Яхшы түгел!

— Чаллыга очтык, Ринат. Үпкәләмә. Казанны шушы көнгәчә күргәнем юк әле. Бер кайтасым килә, Минтимер Шәрипович та чакырды бит... Һичшиксез, кайтам Казанга, әниемә дә күрсәтәсем килә Казанны.

— Вәгъдә,— дип, кул кысыштык.— Инде турысын гына әйт әле, Рәфкать. Ни белән тәмамланачак бу мәхшәр?

— Ахыры яман булу мөмкин. Таман һәм Кантимир дивизияләре Мәскәү читендә. Алар Ельцин һәм Грачев боерыгын үтәргә дип ашыгалар. Ә Мәскәү хәрби округы Югары Советка каршы арудан баш тарткан.

— Ә кемнәр ата безгә?..

— Бэйтаровчылар дип сөйлиләр... Хактырмы-юкмы, анысын белмим. Босерт җитәкчелек итә диләр.

— Нинди Босерт тагы?

— Хәтереңдәме, РАФ заводына директор итеп куйганнар иде аны берзаман... Хезмәт коллективы сайлаган иде, янәсе.

— Менә ничек...

Шул урында әңгәмәбез өзелде, Рәфкатьне Виталий Сыроватко чакырып алды. «Анда Ачалов эзли үзеңне...» — диде, һәм икәүләшеп китеп тә бардылар.

Рәфкатьнең киңәшен тотып, тынчу залга кердем. Халык арган, йончыган. Үлем куркынычы баскан әйләнә-тирәне. Утыру түгел, басып торыр җир юк.

— Табиблар кирәк... Хатын-кызлар, сезнең ярдәм сорала,— дип, мөрәҗәгать иттеләр каршы якадан.

Шуны гына көтеп торган кебек, берьюлы җиде-сигез ханым урыннарыннан кузгалды.

— Ринат Сафиевич, минем урынга утырыгыз — дип, хәтта урынын тәкъдим итте берсе. Бу, әлеге дә баягы, уфалы Роза ханым

Низаметдинова иде. Башкортстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары.

— Үзегез килгәнче саклап торырмын,— дигән вәгъдә белән, тәкъдим ителгән урынга кунакладым.

Як-ягымда утыручылар белән бер-ике авыз сүз алмашкач, ике яңагымны учларыма салдым да уйга чумдым. Президиум өстәле читендә ике игезәк ханым — депутат Вера Бойко һәм аның кардәше — гитарага кушылып үзләре чыгарган җыр җырлыйлар. Үзләре Дон казаклары, моң да шул тарафлардан. Профессиональ күзлектән җырның сүзләре һәм музыкасы әллә ни булмагандыр да бәлки, ләкин шул мизгелдә шактый тәэсирле кабул ителә иде: күңелләрнең, хисләрнең кылдан да болайрак нечкәргән чагы бит, нишлисең...

Күңелләрнең, чынлап та, нечкәргән чагы иде. Әмма, кинәт, без утырган бина уртага ярылгандай булды, тетрәп куйды. Җырчы кызларның аяк очына кайсыдыр бер республиканың байрагы шапылдап килеп төште. Милләтләр Советы залының түрендә Россияне тәшкил иткән һәмма милли республикаларның байраклары тезелеп тора иде. Шул байраклардан берсе...

Басып торучылар башларын тотып идәнгә чүгәләде. Кемнәрдер «ух» итте, кемнәрдер Алланы искә төшерде.

Мин үзем бинага бомба ташладылар, дип уйлаган идем иң элек. Чөнки диварлары берәр метрга җиткән һәр дүрт тарафка берәр квартал мәйданны биләп торган бинаны чайкалдырып кую өчен, ай-һай, зур җегәр кирәктер ул... Сәгатемә карап куйдым. Иртәнге 9 сәгать 45 не күрсәтә иде. 4 октябрь, 1993 ел. Менә кайчан язган икән бу дөньядан китәргә... Нәрсә-нәрсә, әмма үлү турындагы уйның шушы көнгәчә башыма килгәне юк иде бит әле. Шулай көтмәгәндә, уйламаганда китә дә бара торгандыр инде ул кеше. Әти-әни, туганнар һәм гаиләгә кыен булыр инде. Тормышлары көйләнмәгән ике кызым кала, дигән уй узды баштан. Дус-ишләрдән дә үземне сагынып искә төшерүче булыр бәлки... Дөнья булгач, үзалдына куанып куючылары да табылыр...

Һичкем дәшми. Шыгрым тулы залда үлем тынгылыгы. Минем баштан гына узды микән андый уйлар. Әллә башкалар да шул ук хакта уйланамы?..

Һәрхәлдә, беренче бомба башыбызга төшмәде. Кайдадыр, кемнәрдер, бәлки, каза кичергәннәрдер, үлүчеләр булуы да бик ихтимал, әмма залда утыручыларның барысы да исән иде әлегә.

Күңелдән шом таралмый, өмет тә уянмый. Качар, китәр урын да юк моннан. Газеталарда әллә ниткән «бункер»лар турында язалар. Булсын иде алар. Үле мәйдан һәм кая карама мәет, яралылар белән шыплап тулган коридорлар китми күз алдыннан. Юкка гына күпчелек халык залга кереп тулмагандыр инде. Әнә, Юрий Воронин, Алексей Агафонов һәм Виталий Сыроватколар да монда икән...

Бомба кадәр бомбага тотынгач, берне генә атып туктамаслар бит болар. Икенчесе нәкъ менә шушы залның уртасына ягъни мәсәлән, минем баш түбәсенә килеп төшсә...

Ул да түгел, бина тагы тетрәп куйды, коточыргыч гөрселдәү ава[illegible] янә кабатланды. Кайдадыр пыялалар коелды, тагы ниләрдер җимерелеп төште. Ни булыр бу?! Шартлау баш очында түгел, каршы як дивар тарафыннан икән бит. Әллә бинаны чын-чынлап җимерергә, юк итәргә җыеналар инде?

Чираттагы мәртәбә шәм яктысына китереп сәгатемә карап куйдым: ун тулып ике минут киткән. Димәк, беренче шартлаудан соң җиде минут узган. Күршеләрем каршысында торган шәмне үземә табарак тартып куйдым һәм сәгать угы йөрешен күзәтәм. бу залның урамга түгел, коридорга чыккан тәрәзәләре дә юк, шуңа бердәнбер яктылык чыганагы — шәм яктысы монда.

Залда тынлык. Җыр тынды. Үзара сөйләшүләр басылды. Һәркем үз-үзенә бикләнде, үз гомеренең мизгелләрен барлый, бәлки, соңгы мизгелләрен барлый...

Башкалар ни уйлый торгандыр, сорап булмый бит. Сөйләшәсе дә килми икән андый чакта. Мин үземә шөгыль таптым — секунд угы әйләнгәнне күзәтәм, минутларны саныйм... Дүрт минут узды... биш... алты... Җиде дигәндә, янә калтыранып куйды бина, каты гөрселдәү ишетелде. Үземчә нәтиҗә ясап өлгердем, димәк җиде минуттан, җиде минутка шул рәвешле атып торачаклар. Кайчанга кадәрле?.. Бинаны җимергәнчеме?.. Хәер, бинаны җимерүдән кемгә файда? Дәүләткәме?.. Болай да очын-очка ялгап бара алмый иза чиккән кешеләргәме?! Фашист булып, фашистлар да үз шәһәрләрен шул рәвешле җимермәгән, үз кешеләрен чебен урынына кырмаган... Башка сыймаслык, акылга килмәслек күренеш иде бу.

Бинаны җимереп, шаһитларны үтереп бетерергә уйлыйлардыр, бәлки... Соңыннан, бер-бер ялган сылтау табып, йомып куярлар шунда.. Күрүчеләр күп түгел чөнки. Ә журналистлар, радио һәм телевидение хезмәткәрләре, нигездә, сатылып беткән. Акча түләсәләр, акны — кара, караны — ак итеп язу яисә күрсәтү алар өчен берни түгел. Соңгы елларда бер түгел, мең мәртәбә исбат итте инде алар үзләренең нигә сәләтле булуын. Җәмгыять өчен сатлык журналисттан да куркынычрак башка һичкем юк...

Шулай уйладым уйлавын, әмма беркадәр ялгышканмын булып чыкты. Вакыйгаларны Америка Кушма Штатларының «Си-Эн-Эн» агентлыгы туры эфирда телевидение аша күрсәтеп торган икән бит. Бер атна алдан хәстәрен күреп, камераларын тиешле урыннарга урнаштырып чыкканнар. Әнә бит ничек оста эшли безнең Дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итәргә тиешле оешмалар, иң әүвәл океанның аргы тарафындагы хуҗаларыннан хәер-фатиха алалар. Ә безнең журналистларга эш тә калмады. Хәтта ялган өчен...

Үзебезне ни рәвешле тупка тотканнарын бөтен дөнья хәйран калып күзәткән бит. Тамаша кылган... Кеше хокуклары яисә демократия дип берсе дә чаң сукмаган, менә сиңа кирәк булса!

Ә мин, ахмак, үзебезгә ни белән һәм кайсы тарафтан атканнарын да белми, сәгать угы ничә мәртәбә әйләнгәнне санап утырам. Җиде минуттан җиде минутка төгәл кабатланып тора теге гөрселдәү. Колак иләнеп бетте инде. Баш очындагы люстраларның да бәллүрләре коелып бетте. Шәмнәр сүнде... Кан исе белән генә түгел, үзенең караңгылыгы белән дә бина эче каберне хәтерләтә башлады. Күп булса, җиде-сигез шәм калгандыр. Җиде минуттан җиде минутка алары да менә сүнәм, менә сүнәм дигән сыман, калтыранып куя.

Утырган урыным үтеп-сүтеп йөрү өчен җайланган аралык читендә иде. Берәү аркама кулын салып узды. Җыйнак гәүдәле, ак плащ кигән. Шул рәвешле капшана-капшана алга узып баруы икән. Чыгып-кереп йөрүче байтак булганга күтәрелеп тә карамадым. Баксаң, ул Руслан Хасбулатов булган. Сәхнәгә күтәрелде ул. Үзенә юл бирделәр һәм бер урын бушаттылар. Каршысына ук, кемдер кулындагы шәмен китереп куйды. Нәкъ шул мизгелдә, чираттагы җиде минут узып, тагы бина калтыранып куйды, гөрселдәү авазы ишетелде.

Залда утырган халык депутатлары һәм аппарат хезмәткәрләре дәррәү кул чабарга керештеләр.

— Сезгә танктан аталар, 120 миллиметрлы пушкадан... Шуңарга кул чабасызмы? — дип, шаяртыр көч тапты ул үзендә. Югыйсә, йөзендә төс, адымнарында көч калмаган.

— Юк, бу сезгә хөрмәт йөзеннән, — дип, ачыклык кертергә ашыкты алгы рәтләрдә утырган берәү. Әйтерсең, Хасбулатов шуны да аңламаслык кеше.

Тынлык урнашты... Руслан Имранович ике-өч мәртәбә тамак кырып, йөткергәләп алды. Урнашып калган тынлык өчен үзен гаепле хис итә кебек иде ул. Һәм тын гына, басынкы гына сүз башлады:

«Гафу итегез, минем кадерле дусларым... Мин гаепле сезнең алдыгызда. Бик зур гаепле...

Һәркемнең гомере бер генә бит. Һичкемнең шулай мәгънәсез рәвештә үләсе килми торгандыр. Бөтен Россия халкы сайлаган депутатлар бит сез. Берегезне дә башкалага шундый язмыш юрап җибәрмәделәр. Дөньялар имин булсын, азмы-күпме тормыш яхшырсын дигән өметләр бағладылар сезгә...

Турысын әйтим, Россия Югары Советы, тулаем, акламады бу ышанычны. Ил челпәрәмә килеп таралды, икътисад җимерелде һәм, иң аянычы, әхлакый кануннар таркалды. Милләтләр, республикалар берберсенә каршы куелды, күпме кан коелды, кеше гомере өзелде...

Җинаять арты җинаятькә өстерәп китерделәр безне. Берәүләр карышты, икенчеләр, битараф булды... Ә безне шушы җинаятьләрдә әйдәп баручылар бер-бер артлы Президент аппараты һәм дәүләт структураларына качышып беттеләр. Парламентның кирәге калмады аларга, инде ни теләсәк, шуны эшли алабыз, дип нәтиҗә ясадылар.

Әмма халык депутатлары арасында вәгъдә ителгән байлыкларга, министр кәнәфиләренә, югары дәрәҗәләргә сатылмый торганнары, шулай да, күпчелек булып чыкты. Алар, менә шушы залда. Рәхмәт аларга!.. Россияне һәм анда яшәгән халыкларны упкынга өстерәгән куркыныч көчкә каршы чыктыгыз сез... Соңгы сәгать, соңгы мизгелгә кадәр көрәштегез. Шуның өчен дә язмышыгыз кыл өстендә калды бүген...

...Үләсе килми, әлбәттә. Нишлисең, дошманның да чигенер җире юк. Йә талап җыелган байлыклардан, хакимияттән баш тартырга һәм гадел хөкем каршысына басарга. Йә үзләренең чын йөзен фаш иткән намуслы халык депутатларын утка тотарга, юк итәргә. Башка, өченче юл юк алар өчен.

Югары Советка таба барган танкларны туктатырга тырышып, дистәләгән кеше танк башмаклары астында калып, җан бирде бүген. Бронетранспортерлардан 24 миллиметрлы ядрәләр белән атып, коралсыз карткарчыкларны, яшьләрне, балаларны кырып чыктылар аннан соң. Һәм, ниһаять, дөньяның теләсә кайсы илендә иң изге саналган бинага, Югары Совет, ягъни Парламент бинасына һөҗүм башладылар. Кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас, коралсыз депутатлар утырган бинаны 120 миллиметрлы көпшәдән, авыр танклардан атып җимерәләр. Вертолетлардан атып яндыралар...

Бинадан каршылык күрсәтү туктатылды. 10 сәгать 38 минутта Руцкой: «Атмаска. Каршылык күрсәтмәскә...» — дигән әмер бирде.

Ә каршы яктан, киресенчә, Россия армиясендә булган һәммә төр коралдан кургаш сиптерәләр. Туктарга җыенмыйлар. Бинага һичкемне кертмиләр. Чыгармыйлар... Халыкара Кызыл Хаҗ җәмгыяте яралыларны һәм мәетләрне чыгарырга омтылып карады. Өсләренә пулеметтан ут яудырдылар. Югары Совет бинасыннан ак флаг күтәреп чыккан «Интерфакс» агентлыгы журналисты Тереховны аркасына атып үтерделәр...

Хәлләр менә шундый, минем кадерле дусларым. Болай килеп чыгар дип һич уйламаган идем. Дөреслекне... Конституцияне... Парламентны шулай мәсхәрә итмәсләр, мәсхәрә иттермәсләр дип ышанган идек. Халыкка ышанган идек... Республика һәм өлкә җитәкчеләренә... Һәм Конституция сагында булырга тиешле армиягә... Хокук саклау органнарына... Нишлисең бит.. Рәхмәт сезгә!.. Һәм... бәхил булыгыз...»

Руслан Хасбулатовның соңгы сүзе белән бер үк вакытта чираттагы шартлау яңгырады. Бина чираттагы мәртәбә тетрәнеп куйды, гөрселдәү авазлары ишетелеп торды...

Хасбулатов гүя шартлау авазын ишетмәде. Ипле генә торды. Һәм бугазына килеп тыгылган төер, күзләренә килгән кайнар тамчыларны күрсәтүдән тайчынган кебек, уңга-сулга каранмыйча, килгән юлыннан ипле генә китеп тә барды.

Янымнан узып барышлый, янә сак кына иңбашыма кулын салып узды. Тукталмады... Шыпырт кына, бары икебез генә ишетерлек итеп пышылдаган авазын ишеттем аның: «Син дә мондамы, Ринат...»,— диде ул. Һәм ары узды, күзләребез очрашмады.

Залда тынлык эленеп калды. Ниһаять, көн кебек ачыкланды, бернинди ярдәм дә килмәячәк. Язмышыбыз бинаны дүрт тарафтан һәм һавадан камап алган үтерү машиналары һәм үтерүчеләр кулында. Ни теләсәләр, шуны кылачаклар. Инде кеше түгел, чебен дә очып чыга алмаячак хәзер бу бинадан. Үлем сәгатебез якынлашты гына түгел, килеп үк җиткән түгелме?! Бер карасаң шулай... Ә икенче карасаң, һич үләсе килми. Бердәнбер гомерне һич кенә дә шулай мәгънәсезгә йомгаклап куясы килми. Ни белән бетәр бу мәхшәр?..

Икенче көн инде авызга ризык капкан юк. Алай гынамы, су эчкән юк! Һәм ашау-эчү хакында уйлап та караган юк. Кемнәрдер эзләнәдер бәлки һәм табалардыр... Ни хикмәт, ачлык-сусау тоймадым мин. Һәм «тамагым ачты, ашарга бирегез... эчәргә су бирегез...» дип авыз ачкан депутатны очратмадым. Тынчулык газаплады, әлбәттә. Булды анысы... Мурманск өлкәсеннән сайланган врач-депутат узып бара иде янәшәмнән. Урынымнан торып каршысына чыктым. Аның инде иртәдән бирле яралылар белән мәш килүен белә идем.

— Ничек анда, Иван Сергеевич?—дим.— Яраланучылар күпме? Ярдәм итә аласызмы?

— Тырышабыз,— диде ул башта рәсми генә. Аннан, үземне танып алды булса кирәк. Тукталып калды ул һәм башын чайкады.— Биш кабинет тулды үлүчеләр белән. Ә яралылар... Яралыларның исәбе юк. Йөздән артык кеше кан эчендә ята. Ярдәм итәр өчен һичбер нәрсә юк кулыбызда. Бинт юк, йода юк... Сөйләп торырлыкмы соң?!

Үзенең дә йөзләре тартылып калган. Чарасызлык, ни кылырга белмәү йөзенә чыккан иде аның. Әйтер сүз таба алмадым мин дә, өстендәге пиджагы астында күлмәк-фәләне юклыгына игътибар иттем нибары.

— Яралыларны бәйлибез, башка чара юк,— диде ул һәм юлын дәвам итте.

Китеп барганда мин аның чигә чәчләренең кар сыман ап-ак булуына игътибар иттем әле тагы. Ялгышмыйм, дип уйлыйм, ул көнгәчә һичбер ак чәч әсәртесе юк иде кебек аңарда.

Бинага тигез бер вакыт аралыгында даими атып торган танкларга тәмам ияләндек. Иң әүвәл диварлар тетрәп, чайкалып куя, аннан, бераз кичегә төшеп, шартлау авазы ишетелә. Байтак вакытлар шулай кабатланып торды бу. Хәтта, алар атудан туктагач, нидер җитми сыман тоелып торды бераз. Әмма, аның каравы, атышу һәм шартлау авазлары ишәйгәннән-ишәя, якынайганнан-якыная барды...

Атышлар бина эчендә иде инде. Колакка әле бер тарафтан, әле икенче тарафтан хәбәрләр ишетелеп тора. «Беренче катны алганнар икән... Икенче катка һөҗүм башланган... Югарыда, унөченче катка кадәр бина дөрләп яна икән... Дүртенче катка ут капкан...»

Ул да түгел, аяз көндә яшен яшьнәдеме дисәм, без утырган залга элгәре Дәүләт куркынычсызлыгы комитетын җитәкләгән, бүген парламентны саклаучылар сафына баскан генерал Баранников килеп керде. Үзе генә түгел, янәшәсендә, кыяфәтләрен күргәч үк йөрәк жуылдап куярлык, чуар елан төсендәге кием кигән тагы ике хәрби. ОМОН дисәң, ОМОН түгел болар...

— Игътибар, хөрмәтле депутатлар,— диде Баранников, үзенә генә хас сабырлык һәм тыйнаклык белән күзләрен челт-мелт йомгалап.—

Минем белән менә «Альфа» группасы офицеры һәм сугышчысы керде. Сүзне аларга бирәм...

Озынча буйлы, каратут йөзле, утыз биш-кырык яшьлек ир-ат алгарак чыкты. Баш киемен кулына алган, корал-фәләне күренми. Нинди хәрби дәрәҗәдә булуын да ачыклау мөмкин түгел. Үз-үзенә ышанган калын тавыш белән сүз башлады ул:

— Мин «А» группасыннан. Подразделение командиры. Сезгә түбәндәге шартлар тәкъдим итәм. Бина эченнән каршылык күрсәтүне хәзер үк туктатырга. Һәм эвакуациягә әзерләнергә. Бинаның ишекләре төбенә караңгы пәрдәләр белән капланган автобуслар китереләчәк. Һәм сезне шул автобуслар якын тирәдәге берәр метро тукталышына илтеп төшерәчәк. Һичнинди тикшерү, эзәрлекләү булмас. Автобуслар безнең тарафтан сакланаячак, гарантия бирәбез. Әгәр дә шушы шартлар сезнең тарафтан кабул ителсә, без хәзер үк Руцкой янына менеп, бу хәбәрне аңарга җиткерәбез. Һәм бер сәгать яисә 30—40 минут эчендә вәгъдәбезне үтәү өчен әзер булачакбыз.

— Барып чыкмас! Капитуляция тәкъдим итәсезме? — дип, кычкырды арткы рәтләрдән кемдер.

Сулыш та алмый тыңлап утырган зал үзара фикерләшергә, бәхәсләшергә кереште. Җан керде залга. Өмет кайтты.

— Ә сезнең башка чарагыз юк,— диде «Альфа» офицеры, ишек катыннан ишетелгән ир-ат тавышына җавап итеп.— Мин сезгә бердәнбер исән калу, котылу юлын тәкъдим итәм.

— Сораулар бирергә мөмкинме? — дип, кулын күтәрде хатын-кызлардан берәү. Зоя Ойкина иде булса кирәк.

— Юк! Мин монда әңгәмә өчен кермәдем,— дип, кырт кисте офицер.

Кисүен-кисте, ә үзе, барыбер, әле бер, әле икенче тарафтан яңгыраган сорауларга җавапсыз кала алмады.

— «Альфа» группасы бу фетнәдә бер якка да катнашмаска сүз биргән иде. Вәгъдәгезне нигә боздыгыз?

— Без фетнәдә катнашмыйбыз. Сезне азат итәргә дип килдек.

— Александр Владимирович Руцкой 10 сәгать 38 минутта Ак йорттан «Атмаска!» дигән әмер бирде. Ә сез һаман да атасыз. Кешеләрне үтерәсез. Бинаны җимерәсез. Бу эш нигә кирәк?

— Безнең сугышчылар сезгә төбәп бер патрон да атмадылар. Без — коткарырга дип килдек.

— Соң, алай булгач, барыгыз, әйтегез, танклар атудан туктасын, пулеметлар... Һәм башкалар.

— Безнең шартлар кабул ителсә, ату тукталыр. Мин сезгә вәгъдә бирәм.

— Ә ышанып буламы соң сезгә?.. Фамилиягез ничек, фамилиягез?..

Офицер кырыслана төште. Үзе белән таныштырырга теләмәде.

— Минем сүзем бетте. Сездән җавап көтәм. Ихтыярыгыз... Нишлисез? — диде дә, бер адым артка чигенде.

— Сезгә ышанып буламы соң? Фамилиягезне дә яшерәсез әнә...— дип борчылды хатын-кызлар.

— Була. Безгә ышанып була.

Зал тынып калды. Һәркем үзалдына уйлана иде. Җаваплы мизгел. Яшәү һәм үлем үлчәү тәлинкәләренә салынган чак. Кайсы җиңәр, кайсы аска тартыр икән.

— Безнең бүтән чарабыз юк, җәмәгать, ризалашырга кирәк,— диде бер ир-ат тавышы. Әлеге сүзләр кем авызыннан чыкканлыкны аермачык күрдек. Ул хәзер дә Мәскәүдә, олы даирәләрдә кайнаша.

Бер төркем хатын-кыз күтәреп алды үзен.

— Ризалашмый хәлебез юк,— диделәр.

Башка чара булмагандыр, чынлап та. Алар белән килешмәү мөмкин түгел иде. Дәшмәүчеләр күп булса да, каршы чыгучы табылмады диярлек. Мин үзем дә шулар арасында. Чынлап та, ул сәгатьтә безнең башка чарабыз инде калмаган булгандыр. Ни чарадан-бичара идек ич.

Генерал Баранников һичбер сүз дәшмәде. Чыгу юлына юнәлде. «Альфа» бөркетләре аңарга иярде. Руцкойга, дүртенче катка менеп киттеләр.

Тынлык урнашып калды залда. Күңелләрдә нииндидер бушлык эленеп калды. Бу — җиңелү дигән сүз иде бит! Җиңеләсе килми берәүнең дә, әмма, нишлисең... Һәркем үзалдына шул хакта уйлангандыр булса кирәк. Максатыбыз изге иде дә бит...

Әмма бу тынлык озак дәвам итмәде. Кинәт, ишек катыннан берәүнең ачыргаланып кычкырган авазы ишетелде:

«Сатлыкҗаннар... Сатлыкҗаннар... Без бит сезгә ышанган идек. Шулай җиңел генә кул күтәрү, бирелү өчен кан түктекме?! Минем дусларым нәрсә өчен үлде?! Безне ни дип алдадыгыз. Депутатлар түгел, куркаклар сез. Беләсезме кем — куркаклар! Танктан бер-ике атуга ук астыгызга җибәрдегез. Сатлыкҗаннар!..»

Ирексездән, аягүрә торып басып, ишек катына карадым. Анда яшь кенә бер егет бәргәләнә, күзләрендә яшь, үзен залга кертүләрен таләп итә. Ике кулыннан каерып тотканнар, кертмиләр. Тавышы да утырып бетмәгән унҗиде-унсигезләр чамасы бер егет. Үз-үзен онытып, ачыргаланып бәргәләнә. Безне — депутатларны битәрли ул, ахыргача көрәшергә чакыра.

Аңладым мин аның хәлен. Туган илен, аның Конституциясен, парламентын яклап килгән бит ул монда. Безне яклап килгән... Социаль тигезлекне яклап...

Нәтиҗә, әнә ничек булып чыкты. Яшь егет ничек килешә алсын инде бу хәл белән.

«Кертегез мине... Миңа автоматымны бирегез. Мин аларны... сатлыкҗаннарны, үзем атып бетерәм. Сезне бит болай да утыртып куячаклар, яисә атып үтерәчәкләр. Ни эшләдегез сез!..» — дип бәргәләнә иде һаман.

Кертмәделәр үзен. Әзмәвердәй ике ир-ат, кулларын артка каерды аның һәм ишек төбеннән йолкып алып каядыр бер читкә алып киттеләр. Ул карыша, тыпырчына, тавышлана иде. Янау авазлары ерагайганнан ерагая барып, бераздан тынып калды.

Игътибар иттем, нинди генә гаепләр ташламасын, залдан ник бер кеше торып, әлеге егеткә бер каршы сүз әйтсен, килешмәвен белгертсен икән. Аны аңлау, хәленә керү идеме бу...

Түземсезлек белән көтәбез. Кайчан ату тавышлары туктар икән дә, кайчан зарыгып көткән тынлык урнашып калыр. Юк, һич кенә дә тукталырга җыенучы юк. Һәр тарафтан аталар. Берьюлы унар-унбишәр автомат тукылдый. Пулеметлар авазы тынмый. Әледән-әле туплар гөрселди. Колак тонган. Бина дер селкенә... Килешү барып чыкмады бугай, дигән шик керде күңелгә. Руцкой каршы төште микәнни?!

Ул да түгел, нидер көтеп-көтеп тә яңадан өметсезлеккә тәгәри башлаган тынчу залга Югары Совет Президиумы секретаре Виталий Сыроватко килеп керде. Түргә узды һәм югары күтәрелде. Кулындагы кәгазьләрне шәм яктысына куеп мөрәҗәгать итте.

«Әйдәгез, диде ул, үзенә хас иплелек белән, соңгы тапкыр булса булыр, бер исемлек барлап чыгыйк әле. Тарихта калсын...»

Аның «соңгы тапкыр» һәм «тарихта калсын» дигән сүзләре күпләрне уйландырды, хәвефкә салды булса кирәк. Һәрхәлдә, күңел күтәренкелеге юк иде залда. Нииндидер шом, хәвеф якынлашкан сыман булды. Һәрчак уен-көлке белән сөйләшкән Сыроватконы да әнә, гомер булмаган җитдилек баскан.

Иш өстенә куш дигәндәй, нәкъ шул вакыт, аллә каян гына видеокамералар тоткан ике егет килеп чыкты. Һәм болары, сайлап-сайлап кына түгел, залда утырган һәр кешене әле уңнан, әле сулдан, маңгаена терәп диярлек төшерергә керештеләр. Сорауга да җавап бирмиләр. Кемнәр булды алар, каян килеп керделәр — белүче юк.

— Егетләр, эш харап, безне архивка тапшырырга хәзерлиләр,— диде минем каршымда гына утырган Илья Константинов.

Шаяруы булгандыр бәлки. Әмма аның сүзләрен шаяру дип кабул итмәделәр. Һәм соң чиктә ул хаклы да булып чыкты.

Ә Сыроватко үз эше белән мәшгуль, депутатлар исемлеген барлый. Соңгы бер төн эчендә генә дә байтак депутатлар шуган, китеп барган булып чыкты. Калган, «мин монда» дип җавап биргән һәр кешене алкышлап кабул иттеләр.

Ниһаять, минем фамилия яңгырады. Кул чаптылар. Кемдер, арка тарафтан, бер-ике җылы сүз кыстырып куйды. Мин бик мәмнүн булдым.

Мактаулар ишеткән бар иде анысы. Төрле дәрәҗәдә бүләк һәм мактаулы исемнәр дә алган бар. Әмма бусы, әлеге кул чабулар һәм җылы сүз, һәммәсеннән кыйммәтле һәм кадерлерәк иде минем өчен. Шул сәгатьтә генә түгел, бүген дә ул шулай. Гомерләр кыл өстендә торганда күңелләр бермә-бер нечкәрә, шәхесләр ихласлана икән ул.

Беләм, ул исемлек югалмаган. Ул әле дә бар. Аны яман нияттә файдаланырга омтылучылар да аз булмады. Бүгенге хакимият өчен ул сәяси ышанычын югалтучы, оппозициядә торучылар исемлеге. Ә дөнья, дөнья — ул куласа, бер әйләнә, бер баса, дигәндәй, гел үзгәреп тора. Минем үземә калса, ул исемлектәгеләр кайсы милләт һәм нинди мәсләк кешеләре булуларына да карамастан, ышанычлы затлар, намусын — акчага, иманын — югары кәнәфиләргә сатудан баш тартучылар. Алар һәммәсе минем күңелемдә һәм күз алдымда. Әгәр Ватан өчен кирәк булган үтә җаваплы һәм куркыныч бер-бер эш йөкләсәләр, икеләнмичә, мин аларның теләсә кайсын үземә юлдаш итеп алыр идем. Чөнки болар жиде кат иләк аша үтеп, үлемнең күзенә карап сыналган егетләр-кызлар.

Баксаң, без бер-беребезне барлап, кул чәбәкләп утырган арада дөнья тынып калган икән. Ник бер кеше атсын, ник бер шартлау авазы ишетелсен. Үз колакларыңа үзең ышанырлык түгел. Ни дияргә белми гаҗәпләнеп калдым. Башкалар да, ышанырга-ышанмаска белмичә, бер-берләренә карангалап утыралар. Җиңмәдек-җиңүен... Ә күңелдә барыбер ниндидер куаныч, тантана бар кебек. Чөнки без җиңелмәдек тә, һичкем безгә бармак төртеп күрсәтә алмас.

Өстенә ак плащ киеп алган Юрий Воронин килеп керде залга. Күрәм, сизеп торам, якташның да йөзләренә яшәү һәм өмет чаткылары йөгергән. Бер сәгатьләр чамасы әүвәл күрешүебездә ул бөтенләй коелып төшкән иде...

— Ничек анда, Юрий Михайлович, яшибезме-үләбезме? — дип сорадым аңардан.

— Яшибез, Ринат... Яшибез...— диде ул, куанычын һич яшермичә.

— Руцкой килештеме? Атулар тукталды кебек...

— Александр Владимировичның атарга дип әмер биргәне юк,— диде ул.

— Димәк, тиздән чыгарачаклар? — дим, түземсезләнеп.

— Ашыкма, кабаланма, якташ, барысын да әйтерләр, аңлатырлар,— диде ул.— Һәр ике тарафтан да хәрбиләр идарә итә бүген. Без синең белән кечкенә кеше.

Бераздан без утырган залга игълан җиткерделәр:

«Килешү көченә керде. Атышлар туктатылды. Бинадан чыгу оешкан төстә узачак. Кәтегез...» — диделәр.

Көтәбез... Көтүчегә дә җиңел түгел икән. Көтеп изаланган шул мизгелдә янәшәмә Андрей Кривошапкин килеп басты. Якут-Саха иленең төньягындагы тундрада яшәүче азсанлы эвен халкы вәкиле.

— Киттек,— ди бу миңа.— Ничек түзеп утырырга мөмкин. Киттек, бер әйләнеп керик булмаса.

Баш тартып буламыни, шул чакыруны көтеп кенә утырган чак. Тордым һәм аның артыннан иярдем. Якташым Азнакай егете Хәсән Хәбибуллин да кушылды үзебезгә.

Ишек катындагы мәйдан һәм тар аралыклар кеше белән шыгрым тулы. Кешесенә түзәр идең, тәмәкечеләр!.. Балта эленеп торырлык төтен.

Без өчебез дә тартучы түгел, читкәрәк тайпылдык. Берочтан җимерелгән, тузгыган бинаны да күрәсе килә. Мәскәү елгасы тарафына караган баскычка таба уздык. Электр уты булмагач, шактый ук караңгы. Мин читләтебрәк атлый идем булса кирәк, ниндидер йомшак нәрсәгә сөрлеккән кебек булдым. Игътибар беләнрәк карасам, ни күрәм, кеше аягы икән. Кешесе юк, бот төбеннән өзеп атылган канлы аяк ята. Әле суынып та өлгермәгән...

«Абау», дип читкә сикердем, читкә тайпылдым. Юлдашларым күрдеме, абайладымы моны, әйтә алмыйм. Бераз алданрак киткән Андрей безгә дәшә иде, аның тавышы җәлеп итте игътибарны:

— Ринат... Хәсән... Монда килегез. Монда... Карагыз әле, Россия гербыннан нинди натюрморт ясаганнар.

Аскы каттан менә торган үзәк баскычның ак мәрмәрдән чигеп ясалган култыксасына сөялеп хәйран калдык. Дәүләт җитәкчеләре, чит ил делегацияләре йөри торган юл бу. Диварда әйләнәсе бер метр-метр ярымнар чамасы булган, затлы металлдан коеп эшләнгән РСФСР гербы эленеп тора иде. Танктан атылган снаряд дулкыны шуны ике ир-ат өстенә алып ыргыткан. Тегеләрнең, бәлки ышыкланып, хәл алып утырулары булгандыр, ә бәлки узып кына барышлары. Язу түгел, әйтергә авыр күренеш иде бу. Егетләрне танырлык түгел. Алар чәрдәкләнгән гербка чуалып беткәннәр. Кайда баш, кайда аяк — һич аңларлык түгел.

— Карагыз әле, егетләр, боларның берсе теге, безнең катта эшләгән Иван Васильевич түгелме соң? — дип төпченде Кривошапкин.

Тану кая, кабат күз ташлап алу да мөмкин түгел иде ул тарафка. Бер мизгел дә ни гомер күз алдыннан китми, йөрәктән китми йөдәтә.

— Каян алдың, нидән чыгып сөйлисең? — диде аның төпченүен ошатып җиткермәгән Хәсән.

— Свитеры шуныкы... Башы гына менә, башы кайда икән, башын таба алмыйм, — дип, өйрәнүен, күзәтүен дәвам иттерде Андрей. Кеше гәүдәсе кисәкләре һәм каннан һич кенә чиркана, курка белмәс адәм булса, булыр икән.

— Җитте, Андрей, җитте, китик моннан, — дип ашыктырды үзен Хәсән.

Читкәрәк китү җаен каердым мин дә. Игътибарымны атна саен диярлек үзебез киңәшмәгә җыелган Президиум залы җәлеп итте. Егерме метр гына читтә басып торабыз икән, ләбаса. «Зал» дип әйтүен-әйттем, ул залдан ни калган иде икән. Аның калын пыяладан эшләнгән тәрәздиварлары тоташ кырылган, Мәскәү елгасы тарафыннан җил исеп тора. Ул җил бина эченә дары, төтен һәм кан исе тарата. Баш очында эленеп торган зиннәтле алтын-бәллүр люстралар идәнгә төшеп чәлпәрәмә килгән. Кая карама, кәгазь. Ельцин имза куйган Президент Указлары очып йөри. Руцкой имза куйган Президент Указлары очып йөри. Хасбулатов имза салган Югары Совет кануннары киштәләрдән ишелеп аяк астында ауный. Ахырзаман дигәннәре шулдыр, күрәсең...

Чалтыр-чолтыр пыяла ерып бер кинооператор Президиум залына кереп китте. Хәер, зал дип әйтү дөресме икән, Мәскәү елгасы яры буена таба үтте. Тәрәзәләр юк, пәрдә-өлгеләр юк, тасмаң җиткән кадәр төшер дә төшер, бер рәхәтлән.

Алдын-артын уйлап тормый гына мин дә уздым Президиум залына. Ишек-фәлән эзлисе, ачасы юк, рөхсәт кәгазе дә сорамыйлар. Таш һәм пыяла ватыкларын ерып, залның Мәскәү елгасына чыккан тарафына килдем. Һәм хәйран калдым. Шәһәр үз урынында икән, ләбаса. «Украина» кунакханәсе тора тырпаеп. Берни булмагандай, Мәскәү елгасы ага. Яңа Арбат белән Кутузов проспектын тоташтыручы таш күпер дә үз урынында. Машиналар йөрми-йөрүен, көндәлек ыгы-зыгы тукталган кебек. Аның каравы танклар тезелешкән күпер уртасында. Елганың аргы тарафында да танклар... Хисап номерлары да юк үзләренең. Зур

кара танк... Көпләләре миңа төбәлгән. Кая карама, анда чуар зебра кыяфәтендә киенгән хәрбиләр. Ә игътибарымны аеруча җәлеп итеп өлгергәне — Югары Совет бинасына якын ук килеп тезелешкән егетләр төркеме булды. Атышу туктатылгач та, аларны монда махсус китереп тезгәннәр булып чыкты. Югары Совет бинасыннан чыгарылачак депутатларны каршы алу, йодрыкларын болгый-болгый битәрләү, янәсе, гади халык нәфрәтен күрсәтү өчен килгән болар. Шунысы гаҗәп, барысы да бер чама яшь һәм бер чама буйда. Тук яңаклылар. Гайдар егетләре — «лавочниклар» диделәр үзләрен. Ул кемнәр була торгандыр инде, әле дә ачык кына әйтә алмыйм.

— Нинди башбаштаклык бу?! Кем рөхсәт итте тәрәзә янына килеп басарга? — дигән тавыш ишетелде арка тарафтан.

Борылырга мәҗбүр булдым. Бер ялгызым басып торам икән ләбаса.

— Башың икеме? Бер пуля житә бит үзеңә. Анда тәрәзә саен снайпер утыра... Ни уйлап чыгып бастың? — дип кул изәде йөз чалымнары таныш булган бер офицер.

Буйсынмый чарам юк, чынлап та, акылсызлык эшли язманмын ич. Шактый ук шөлли төшеп, тиз генә кире борылдым. Алла саклады. Утырышлар залына таба үттек.

Котәбез-котәбез, үзгәреш юк. Ату тавышлары ишетелми, һөҗүм тукталып тора. Үзебезне бинадан чыгарырга җыенучы да күренми. Тынлык... Тәмәке төтене һәм ыгы-зыгы...

Тартмаган кеше өчен тәмәкечеләр өере янында басып торудан да зуррак газап юктыр ул. Сүзләре дә яңа сүз түгел.

Шулвакыт төтенгә буылып йөткерә-йөткерә яныма Хәсән Хәбибуллин килеп басты.

— Әйдә, абзый, — ди бу. — Синең кабинетка барып килик әле. Анда минем папка калган иде. Югалтырга ярамаган эш кәгазьләрем бар.

— Киттек, — дидем. Ике уйлап тормадым. Атышу бөтенләйгә туктатылды дип вәгъдә бирделәр ич. Кемнән куркырга?! Үземнең дә байтак кирәк-яракларым, кәгазьләрем шул кабинетта.

Караңгы аралык аша китеп барганда артыбыздан абына-сөртенә кем йөгерә икән дисәк, әлеге дә баягы Андрей Кривошапкин куып житте.

— Мине калдырып качмагыз, мин сезнең белән, — диде. Һәм башка һичбер сүз дәшмәде.

Дәшәрлекме соң, кая карама, анда яралылар һәм кеше гәүдәләре ауный. Күлдәвекләр булып имән паркет идәнгә кан җәелгән. Кеше каны... Баскан саен аяк чыпыр-чыпыр килә.

Яралылар су сорый, ыңгыраша... Каян табарга икән ул суны?! Үзебезнең дә авызда төкерек юк, иреннәр кибеп яргаланып беткән. Башкача ярдәм итә алмагач, бер-бер җылы сүз әйтәсең дә, китү җаен каерасың.

Баскыч катында бер яшь егет канга батып ята. Аны диварга терәтеп утыртып киткәннәр. Башкача ярдәм итү мөмкинлеге юк бу бинада. Ул үзалдына инде яртылаш чишенгән. Ачык корсагында өч-дүрт канлы тишек. Башын күтәрә алмый. Ул да ярдәм сорый.

— Абый, — ди, өзгәләнеп. — Автоматымны алыгыз да, атып кына китегез әле, — ди. — Мин барыбер үләм бит... Авыртуга түзеп булмый. Атыгыз, зинһар.

Чынлап та, автоматы үзеннән ерак түгел, идәндә аунап ята, сузылып та карый ул аңарга таба, әмма буе житми, үрмәләп китәргә хәле юк. Күз карашы белән ымлап күрсәтә коралына.

— Атыгыз... Янсә автоматымны бирегез миңа. Мин үзем... автоматны бирегез.

Табигый ки, егеткә без ярдәм итә алмадык. Үтеп барган бер офицерның игътибарын аңарга җәлеп иттек тә ары китеп бардык.

Мәрмәр баскыч өстенә сибелгән пыяла ватыкларын таптап, икенче катка төштек. Пыяла диварлар тоташтан кырылган, ачык. Аскы катта

ниндидер ыга-зыгы. Кемнәрдер йөгерешә. Безнең исә үз юлыбыз. Караңгы булса да таныш юл. Минем кабинетка ашыгабыз.

Коридор башында сейфларга ышыкланып торган офицерга сәлам бирдек. Исән-аман үз урынында иде әле һаман. Сер бирергә исәп юк дигәндәй, башын калкытып, безне сәламләргә онытмады ул.

— Бүген исәнләшкән идек түгелме?—дигән булдым, башка сүз таба алмагач.

— Дүрт-биш сәгать тоташтан аттылар монда. Атыштык та...—дип куйды карт офицер.—Сезне күргәч, яңа көн түгел, яңа гомер башланган кебек булды.

— Анысы шулай. Исән булыгыз инде,—дидем.

— Монда ник килеп чыгасы иттегез?—дип сорады ул үз итеп.

— Аласы әйберләр бар иде,—дим, кабинет хуҗасы буларак.

Нәкъ шул чакны, әле генә без үткән тарафтан атышу авазлары ишетелде. Кем сәбәпче булгандыр да, ни бүлешә алмаганнардыр, бер түгел, дистәләгән автоматтан атарга керештеләр. Ату авазлары урамда түгел, бина эчендә иде.

Баскыч тарафыннан шомлы аваз ишетелде.

— Әй, сез, кулларыгызны күтәрегез. Коралларыгызны ташлагыз. Һәм уртага чыгып басыгыз!

Без сискәнеп куйдык. Һәм өчәүләп ишек уентысына сыендык. Әле генә мыекларын сыпырып үрә басып торган офицер сейфлар артына яшеренде.

Коридор тар һәм караңгы. Аның баш-башыннан якты төшеп тора. Уң якта өч шәүлә барлыкка килде. Сул тарафта сейфлар артына поскан офицер.

— Мин сезгә әйтәм, кемнәр анда? Яшеренмәгез, уртага чыгыгыз,—дип кабатлады шомлы аваз.

Аның кемгә эндәшкәнлеген кем белә. Без шым булдык, тел койрыкта.

Сейфлар артыннан җавап ишетелде үзләренә.

— Сез кемнәр? Үзегез җавап бирегез иң элек. Мин иминлек сагында торучы. Советлар Союзы офицеры...

— Советлар Союзы юк,—дип җавап кайтардылар, канәгатьлелек хисе белән.—Россияне сезнең ишеләрдән чистартабыз. Махсус батальон сугышчылары...

Тынлык урнашып торды, кулым белән куртка кесәсен капшыйм, ачкычлар кая... Таптым. Бер бәйдә өч ачкыч. Кул белән капшап түгел, күз белән дә аера алмый идем үзләрен. Өч ел газап чигәм. Нәкъ бер төрлеләр, әмма берсен икенчесе алмаштырмый. Аптырап беткән чакларым була иде. Ачкычларның берсе тышкы ишектән, икенчесе эчке ишектән. Өченчесе элемтә һәм компьютерлар бүлмәсеннән. Эш харап. Кулга беренче эләккәнен сак кына йозак тишегенә төртәм. Гәүдә үрә каткан, бөгелергә дә, иелергә дә ярамый. Пуля алуың да бик ихтимал.

— Чыгасызмы-юкмы?—дип кычкырдылар аргы баштан.—Өчкә кадәр саныйм. Кул күтәрмәсәгез—юк итәм.

— Чыгыйкмы әллә?—дип пышылдады Андрей.—Болар атып үтерергә дә күп сорамас.

Хәсән тынып калган, дәшмәде. Ни дияргә белмәдем мин дә. Минем бит әле өмет өзелмәгән, бәлки йозакны ача алырмын. Кабинетка кереп качарбыз.

— Ә син куркытма, сездә булган корал бездә дә бар ул,—дип җавап кайтарды сейфлар артындагы офицер.

Аның авызы ябылырга өлгермәде, коридорның аргы тарафыннан бер-бер артлы ике гранатомет залп бирде. Безнең борын төпләреннән ачы гүелдәп реактив самолетлар очып уздымыни. Алар сейфларга барып бәрелеп коточкыч шартлау авазы чыгардылар. Колаклар томаланды, күзләр күрмәс булды.

— Беттек, егетләр. Инде кул күтәрергә дә соңардык,— диде Андрей.— Бер дә шулай үләрмен дип уйламаган идем. Тундрамда гына калган булсам...

— Чалбар төбеңдә ни кармалыйсың инде анда? Ачсаң ач, ачмасаң юк,— дип, гомерендә беренче тапкыр Хәсән миңа тавышын күтәрде. Үлем куркынычы, ни тыныч һәм түзем кеше, әнә, аны да ярсытты.

— Егетләр, дәшмәгез ичмасам,— дип пышылдыйм.— Хәлләребез хөрти икәнлекне үзем дә беләм бит. Йозак тишеге чалбар төбенә туры килгән икән, нишләмәк кирәк.

— Алга таба борылып басмыйсыңмы соң...

Бу Хәсән киңәше. Без татарчага күчтек. Тундра егете дәшми, татарча белмәвенә үкенәдер.

— Арт шәрифкә атып тидерсәләр ни диярсең?..

— Ал шәрифең кадерлерәк түгелмени?

— Кадерлесен-кадерле дә, күп сөйләшми тор, Хәсән, Шәрифәңне искә төшерсәң, төшер, шәрифләрне онытып тор әле, яме. Шаярырга таптың вакыт...

Безнең мыеклы офицер да исән икән әле. Ул шатыр-шотыр автоматтан атарга кереште. Теге тарафтагылар автоматик мылтыктан һәм гранатометтан җавап бирәләр. Борын төбендә генә кузачкысыз буран, ядрә бураны купты. Ут бураны... Тар гына коридорның ике тарафыннан да сиптерәләр генә. Ә без уртада. Безне егерме биш-утыз сантиметр эчкә уеп ясалган ишек тобе каплап тора.

Нәкъ шул мәлдә ачкыч келтерәп борылмасын да, ишек ачылып китмәсенме... Бар икән ул Алла, билләһи дим, бар икән. Ул гына коткарды. Беренче эләккән ачкыч туры килде, гомер булмаган хәл. Ничә еллар шушы ишектән йөреп, ут яктысында туры китерә алганым юк иде. Минем ишекне ачып җибәрүем булды, өчебез дә эчке якка авып төштек. Ә нәкъ шул мизгелдә, кинәт тәрәзәдән төшкән яктылык җәлеп иттеме, ишек яңагын аргы баштан атылган граната умырып китте. Бер секунд кына әүвәл яңагым куеп басып торган ишек яңагы чәрдәкләнгән иде. Безне күреп атулары булгандырмы, әллә яктылыкка атулары, әйтү кыен. Ишек яңагы юк, ә без исән идек. Исән!

Бераз тишкәләнгән, чәрдәкләнгән булса да имән ишекне шартлатып йозакка бикләп куйдым. Үзебез эчке бүлмәгә уздык. Коридорда, бөтен әйләнә-тирәдә атышлар, чын сугыш башланып китте. Ә без, иркен сулыш алып, кайсыбыз кай почмакка идәнгә утырдык. Кабинетта тәрәзәләр исән иде әле. Чөнки алар урам якка түгел, ишегалдына чыга. Ләкин ишегалдында да тынычлык юк, анда да шартлау һәм ату авазлары яңгырап тора икән.

Өчебез өч почмакта, һәркайсыбыз үзалдыбызга уйланып, тынып калдык. Котылдык дигәнебез хата түгелме соң безнең?! Киресенчә, тотылдык түгелме? Башка депутатлар һәммәсе бер урында. Аларның шунда булуы һөҗүм итүчеләргә дә мәгълүм. Депутатларга гарантия бирделәр бит, инде шәт, иншалла, тимәсләр. Ә без — бина эчендә каршылык күрсәтүчеләр арасына килеп юлыкканбыз. Мөнәсәбәт тә башка булачак. Күте кычыткан — Әстерханга киткән, диләр иде. Безнең белән дә шулай килеп чыга.

— Хәсән, дип эндәштем татарчалап.— Теге папкаңны ник алмыйсың. Әнә тегендә, өстәл өстендә ятадыр ул.

— Шаяртма әле,— ди ул.— Күреп торасың, папка кайгысы түгел бит, башны исән-сау алып чыксак, ярый ла...

— Белмим шул,— дим.— Без зур хата ясадык бит. Депутатлар анда — залда. Аларга тимәсләр. Ә менә безне, каршылык күрсәтүчеләр дип, атып егулары бик ихтимал.

— Ялгыштык шул,— ди Хәсән.— Мин гаепле. Мин башладым ул эшне.

Андрейның түземлеге бетте ахыры. Безнең ни сөйләшкәнне аңламый бит.

— Нәрсә, әллә мине тотып ашарга җыенасызмы?—ди, бахыр.

Шаркылдап көлеп җибәрдек. Гаҗәп икән бит ул кеше дигәнең. Йөрәк дөп-дөп тибә. Чәчләр үрә торган. Сулышны да кай җирдән алганны белмәссең. Ә үзебез, әнә, көләбез.

Атышу бераз басыла төште. Һәрхәлдә безнең коридор тынып калды. Кайсыдыр тараф җиңелде. Әмма күпкә сузылмады бу тынлык. Безнең ишеккә китереп типтеләр.

— Тиз булыгыз анда, ачыгыз!—дип кычкырдылар аргы тарафтан.— Монда кеше барлыгын беләбез, ачыгыз. Юкса, көлегезне күккә очырабыз...

Күзләребез ялт та йолт, бер-беребезгә карашып алдык. Ә ишеккә тибәләр... Имән ишек җиңел генә бирелмәс, әлбәттә, ләкин үзебез ачмасак, алар аны барыбер ватып, шартлатып булса да ачачак. Монысы көн кебек ачык.

— Хәсән, Андрей,—дим.—Ни эшлибез, ишекне дим, ачмыйча булмас бит.

— Ачарга кирәк,—диделәр бертавыштан. Ләкин, «син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?» дигәндәй, кем ачар икән ул ишекне. Ачам дип, килүең булыр, тегеләр атып җибәрер. Ә болай бит әле, без беркадәр читтә.

— Хәсән,—дим, җаваплылыкны үз өстемә алган атлы булып.—Бәлки син ачарсың, ишеккә дә якынрак утырасың. Ачкыч йозак тишегендә.

Озак уйлап тормады якташым.

— Син бу дөньяда күбрәк яшәгән кеше, син картрак, бәлки үзең генә ачарсың,—ди.

— Алайга китсә,—дим, «агай казны ничек бүлгән», дигән сыман, бердәнбер дөрес нәтиҗәгә килгән атлы булып,—Андрей дус, сиңа ачарга туры килә ишекне. Син тагы да күбрәк яшәгән бу дөньяда.

Андрейның да җавабы кыска булды.

— Сез, татарлар сигез миллион бит,—ди.—Ә мин азсанлы милләт вәкиле. Без болай да санаулы гына...

Ишеккә тагын типтеләр. Ватам дип түгел, кисәтеп тибүләре иде.

— Сездән мәрхәмәт көтеп булмый, егетләр,—дип мыгырдана-мыгырдана ишек катына уздым. Башка чара калмаган иде.

— Дөрес эшлисең... Дөрес,—дип, хуплады юлдашларым. Шул сүзләре өчен рәхмәт инде.

— Ишетәсезме, анда, юкмы,—дип кычкырдылар аргы тарафтан.— Ачыгыз ишекне. Юкса...

— Ачам, хәзер ачам,—дип, җавап кайтардым.—Сез кемнәр соң?

— Барыбер түгелмени. Без «Альфа» группасыннан. Кәнфитләнер арабыз юк, ачыгыз.

— «Альфа» группасы булгач, керегез алайса»,—дидем дә, беткән баш—беткән дигәндәй, ишекне киереп ачып куйдым.

Инде ишек ачык. Беркая да качып, котылып булмый. Сер бирмәгән атлы булып, уртага чыгып бастым. Каршымда баштанаяк пулядан саклый торган киемгә төренгән ике әзмәвер тора. Күзләре генә ялтырый, башка һичбер җирләре күренми. Оптик төзәү җайланмалы автоматик мылтыклары минем күкрәккә төбәлгән. Иңсәләрендә гранатомет.

Бер мизгел күзгә-күз карашып тордык шулай. Исем китми, янәсе, эчке бүлмәдән чыгып килгән Андрей белән Хәсәнгә күз ташладым.

Борылып каравым булды, арт яктан аяк йөзеннән югарырак сөяккә китереп типтеләр һәм этеп җибәрделәр. Аны-моны абайламый калдым, йөзтүбән гөрселдәп идәнгә килеп төштем.

— Нишлисез, егетләр?—дигән соравыма игътибар итүче булмады. Берәве дәү, авыр ботинкасы белән муен тамырына китереп басты. Икенчесе әллә ике, әллә өч мәртәбә касыкка тибеп алды.

— Падла,— дип сүгенде ул.— Хәрәкәтләнмә, падла. Башыңны калкытсаң, атам да үтерәм, падла.

Баш күтәрерлек идеме соң, өнсез-тынсыз калып тордым. Болар кая тибәргә һәм ничек тибәргә икәнлекне белә инде.

— Әй, мыеклы, кил әле,— дигәннәре колакка чалынды. «Мыеклы» дигәч, Хәсән була инде. Аны да минем янәшәгә аудардылар. Бер-ике мәртәбә тибеп тә алдылар булса кирәк. Берочтан ул да «падла», ягъни «үләксә» булып чыкты.

— Ә син, кысык күзле, нигә торасың анда? Кил әле, кил монда,— дип, ниһаять Андрейны чакырып китерделәр. Һәм үз чиратында ул да «падла» дигән ат алып, идәнгә йөзтүбән килеп төште.

— Башка типмәгез, башка типмәгез, дип, өзгәләнде бичара. Андрейның чигәсеннән кан ага иде.

— Егетләр,— дип мөрәҗәгать иттем яткан көйгә.— Нигә рәнҗетәсез аны? Ул — Себердән, болан көтеп үскән кеше. Аңарда ни ачуыгыз бар?

Телең тик тормаса, үзеңә эләгә икән шул. Тагын кабыргага китереп типте берсе.

— Кем синнән сорады? Дәшмә!

Гәүдә иңрәп куйды. Кабырганы шунда сындырдылар ахыры.

— Дәшмәскә! Тынычызны чыгармаска! Күзләрегезне ачмаска!..— дип, кабатлады башка берәве. Әмер бирде.

Буйсынырга мәҗбүр булдык. Алар берәм-берәм безнең кесәләрне тентеп чыктылар. Депутат кенәгәләрен табан асларына салган идек, тапмадылар. Кесәдәге һәммә кәгазьләрне ерткалап ыргыттылар. Ә акчаларны ертмадылар һәм кире дә кайтарып тормадылар. Ташламадылар да, әлбәттә.

Торырга әмер бирделәр. Тордык, кулларны югары күтәреп баш аркасына куйдырдылар. Буйсындык. Һәм коридорга чыгарып тезделәр. Тезелдек... Каршы килүнең гомер бәясенә тиң икәнлегенә, шул рәвешле, бик тиз төшендек.

Ике сугышчы безнең күршедәге сейфлар артыннан авыр яраланган әлеге дә баягы мыеклы офицерны өстерәп чыгарды шул чакны.

— Бу падланы ни эшләтик?— дип сорады берсе. Таныш тавыш, әле генә безне типкәләгән үзебезнең егет.

— Аның хәле авыр, ярдәм ит үзенә,— дип җавап кайтарды безнең ишек янында торганы. Командирлары булды ахры.

Исем-акылым китте, һич уйлап тормады теге. Мылтыгын бер кулда тоткан көйгә чигәсенә төбәде дә атты. һәм китеп тә барды. Шул булды «ярдәм» дигәннәре.

Отставкадагы диңгез офицеры тирән «ух»ылдап куйды һәм йөзтүбән егылды. Ничәмә-ничә көннәр дәвамына шунда сакта торган, тәмам үз кеше булып өлгергән иде бит ул. Алтмышлар чамасында булса да, һәрчак ачык йөзле, бик тә кешелекле кеше иде ул мыеклы абзый. Кызганыч, фамилиясен сорап калынмаган. Туганнары, балалары ничек үлүен беләләрме икән...

— И-их,— дигән җан авазым бәреп чыкты, ирексездән.

— Нәрсә сиңа да ярдәм кирәкме,— дип, яңакка китереп сыладылар.— Бездә патрон җитәрлек, кирәк дисәң, ярдәм итәбез сиңа да...

Аскы иреннәремне тешләдем. Юкса, бер ялгыш сүз, авыздан чыккан бер ухылдау җан бәясе торуы бик ихтимал.

— Куллар... кулларыгызны үз урыннарына,— дигән әмер яңгырады кабат.

Куллар талчыкты. Ирексездән, шуып төшәргә итәләр. Кулны баш аркасында тоту, ай-һай, авыр икән ул.

Тар коридор буйлап алып киттеләр үзебезне. Таныш юл, югыйсә. Шушы коридор буйлап Югары Совет сессияләренә йөри торган идек. Атнага бер мәрәбә Югары Совет Президиумы утырышына бара идем шушы юлдан. Йөзләрчә генә түгел, дүрт елга якын вакыт эчендә меңнәр-

чә мәртәбә үткән таныш коридор, югыйсә. Төрле кәеф, каршылыклы төрле уйлар белән дә үткән чакларым булгандыр. Гаять киеренке һәм ыгы-зыгылы еллар булды бит. Ә мин рәсми төстә багымсызлык игълан иткән Татарстанның, гәрчә, андый вәкаләт йөкләтелмәгән булса да, Мәскәүдәге бер илчесе кебек хис итә идем үземне. Татарстанга, аның җитәкчеләренә тел-теш тидерсәләр, үрә торып каршы чыга идем. Ихластан иде болар. Беркатлылык күрсәткән чакларым да булгандыр. Төрле вакытлар булды. Ә менә шушы рәвештә, кулларны баш артына куеп, башны түбән иеп, тоткын кыяфәтендә беренче мәртәбә узуым бу юлдан. Шул хәлгә төшәрмен, һәм шул хәлгә төшерерләр дип кем уйлаган бит аны.

— Туктагыз. Идәнгә сузылып ятыгыз. Тиз булыгыз, сезгә әйтәм,— дигән әмер яңгырады кинәт. Безне озатып килүче түгел, каршыга очраган маскалы карачкы әмере иде бусы. «Карачкы» диюем очраклы түгел, кешенең йөзе ачык була, ә болар кеше кыяфәтеннән качканнар, йөзләрен яшерә.

«Без инде идәндә яттык. Безне тентеделәр. Тагы ни кирәк инде» дигән уй белән бер-бер артлы үзебезне озатып килгән сугышчыга карап алдык.

— Ятыгыз,— дип киңәш итте ул да. Әмма усаллык белән түгел, аның тавышында хәлебезгә керү төсмере дә булмадымы икән әле.

Пыялалар сибелгән, гильзалар аунаган идәнгә сузылып яттык. Баш очыбыздан гына егерме-утыз ОМОН сугышчылары йөгереп узды. Тоташ тимер-бетоннан коелган диярсең, дәбер-дәбер китерәләр әйләнә-тирәне.

— Торыгыз...

Тордык. Нәкъ шул мизгелдә якында гына автоматтан атарга керештеләр. Ул да түгел, безне әле генә идәнгә сузып салган пәһлевандай ОМОН сугышчысы күзләрен тотып чалкан авып китте. Югары катка илтә торган тар баскычтан атып тидергәннәр.

Без ышыктарак торабыз. Ә ату дәвам итә. Теге сугышчыны безнең аяк очына тартып китерделәр. Ике күзе дә актарылып чыккан. Сулыш алудан да туктаган иде булса кирәк.

— Әй, син, озын гәүдәле интеллигент,— дип акырып җибәрде янымда гына басып торган бер карачкы кыяфәтендәге егет. Мылтык көпшәсен миңа төбәгән, миңа ишарәле иде.— Сиңа әйтәм. Сиңа... Нәрсә анда теге нәрсәм кебек катып торасың. Кил монда...

Ике адым алга атладым. Янына килдем. Ә ул автоматик мылтык көпшәсен минем аркага китереп терәде. Шалт-шолт китереп корып куйды, атарга әзерләде мылтыгын.

Башкача чарам юк. «Нәрсә өчен?» дигән сорау белән мин аңарга борылып карадым. Теге, минем күз алдымда, куркыныч бер сәрсәнлек белән, башына кигән пуля үткәрми торган битлеген йолкып алды үзеннән. Күзләре котырган үгезнекедәй кызыл һәм яшьле иде аның.

— Атла...— дип, кычкырып җибәрде ул җан-фәрман, буйсынмасам, атып егу гына түгел, ботарлап атарга ук әзер булып.— Атла диләр... Баскыч каршысына чык.

— Атласам, ул бит мине дә атып егачак,— дип, бәрәзлексез автоматтан ут яудырып торган баскыч тарафына атлаудан баш тарттым. Җигелгән үгез сыман, аягымны терәп карыштым.

Сугышчы исә мылтык көпшәсен аркама тагы да батыра төште, тәмам этә, төртә башлады.

Ике-өч адым алга китсәм, пулялар кисеп кенә чагачак үземне. Теге аның саен этә. Мин — карышам.

— Каршысына чык һәм аңлат. Хәзер үк туктасын атуыннан. Ул инде минем ике дустымны үтерде. Барыбер яшәү юк үзенә. Сөйләш, аңлат...

— Мин бит аны белмим... Мин берегезне дә белмим,— дидем, үлем куркынычын тоеп.

Һәм шул рәвешле без төрткәләшеп-аңлашып торган арада, икенче бер маскалы сугышчы, диварга сыенып ишек катына кадәр килде дә югарыга граната ыргытты...

— Ятыгыз...— дип, аваз салды шундук.

Без чүгәләргә дә өлгермәдек, коточкыч шартлау яңгырады. Баскыч тарафыннан ут һәм һава дулкыны бәреп чыкты. Пыяла уалды, кирпеч ватыклары очты. Кемнәрнеңдер авыр ыңгырашып егылганын тойдым. Берәве баскычтан бире тарафка тәгәрәп үк төште булса кирәк.

Маскасын салып ыргыткан егет мине онытты, тузан һәм таш кисәкләре утырып бетмәс борын, баскычка ташланды. Үч алырга кереште.

— Кабахәтләр, сволочьлар, менә сезгә, менә сезгә,— дип сүгенә-сүгенә аңсыз калып егылган ир-атларны ату белән мәшгуль булды. Куркыныч, куркыныч кына түгел, коточкыч күренеш иде бу.

Зур эш кырган кебек килеп төште бераздан. Аякларын киереп җәеп иптәшләре каршысына килеп басты. Һәм, әлбәттә, мактанырга онытмады.

—Өчәү булган, кабахәтләр. Тонган балык кебек аунап яталар иде. Теге дөньяга озаттым өчесен дә.

Канлы күзләрендә яшь, ә авызы—ерык. Башка һичкемгә түгел, кыргый җанварга, җанварның да котырганы, үтә ерткычына охшаган иде ул шул мизгелдә.

Безне озатып килгән егет, ым кагып, түбәнге катка төшәргә боерды. Әмма икенче каттан беренче катка төшеп җиткәнче, ялгышмасам, нәкъ өч мәртәбә кулларны күтәртеп, аякларны киң җәйдереп йөзләребезне диварга терәделәр. Белмим, ни табарга теләгәннәрдер, кесә тентеделәр. Һәм берочтан пуля үткәрми торган авыр, озын кунычлы ботинкалары белән бер-бер җиргә тибеп яисә приклад белән аркага кундырып үттеләр.

Ни хикмәт, бар көчләре һәм кодрәтләре белән типсәләр, суксалар да авыртмады тән, күтәрде. Әйләнә-тирәдә тоташ кан һәм үлем хакимлек иткәндә, тән ярасы һәм сынык кабыргалар берни дә түгел икән ул. Аларның сызлавын, сыкравын соңрак, йокысыз төннәрдә кичерергә насыйп булган.

Беренче катта булган икән әле ул чын мәхшәр. Тәрәзәләр, ишекләр һәм пыяла диварлар көл булган. Кая басыйм дисәң, анда аяк балтырын күмәрлек пыяла ватыгы. Яралылар һәм үлүчеләрне почмакларга ыргытып чыкканнар. Мәйдан уртасындагы ике дәү мәрмәр багана арасына кулга алынган халык депутатларын тезеп куйганнар. Әмма бина эчендә булган депутатларның монда бер өлеше генә. Аларны төркем-төркем бүлгәләп төрле ишекләрдән алып чыкканнар бу көнне. Сөйләүләренә караганда, берәүнең дә чыгу юлы җиңел генә булмаган. «Альфа» группасы офицеры биргән вәгъдә үтәлмәгән. Алдаганнар булып чыкты....

Аргы башта икенче төркем. Күрәмсең, болары бинаны сакларга дип килгән мәскәүлеләр һәм Россия гражданнары булгандыр. Аларга басып тору тыела, идәнгә яткырганнар үзләрен. Үтеп-сүтеп йөрүче ОМОНның кайсыберләре тегеләрнең башларына басып йөри.

Үзебездән сораучы да булмады кебек, югыйсә, өчебезне дә депутатлар янына китереп бастырдылар. Барыбыз да танышлар, бер-беребезне исән күрүебезгә шатланып, ымлап һәм күз карашы белән генә сәлам бирешәбез. Дәшәргә, сөйләшергә ярамый. Үзебезне озатып төшкән тоташ маска һәм броня киемдәге егеткә пышылдап кына булса да рәхмәт әйттек. Чөнки ул бер-ике җирдә үзебезне чираттагы типкәләүдән йолып алган, исән-аман саклап озатып төшкән егет.

— Исемең кем? Үзең кайсы яклардан?—дип, кешеләрчә соравыма җавап бирергә теләмәде. Ул да хезмәт кешесе, аның эше дә җиңел түгел, әлбәттә, хәерлегә булсын.

Халык депутатларын азат итәргә вәгъдә иткәннәр иде. Ә чынлыкта аларны кулга төшерделәр. Офицер алдады. Әллә аның үзен алдадылармы?! Һөҗүм дәвам итә. Югары катларда каршылык күрсәтү тукталмаган әлегә, атышулар кызганнан кыза гына бара. Каршылык күрсәтүчеләрнең дә хәлен аңларлык. Аларны кулга алмыйлар. Әмер шундый икән, кайда

очрасалар, шунда атып үтерәләр. Качып котылыр урын, китәргә җай юк. Бина танклар һәм БТРлар белән утлы боҗра эченә алынган. Махсус өйрәтелгән хәрбиләргә каршы тора алмаячак алар, үзләре дә аңлый, белә торганнардыр. Югарыгы өч-дүрт кат кара күмер булып яна, күптән ут эчендә. Ә түбәннән ут ташкыны белән кырып-себереп, яндырып махсус частьләр күтәрелә. Бинаны сакларга дип үз теләге белән килүчеләр каядыр бишенче-җиденче катлар тирәсендә бүленеп, тулы изоляция эчендә торып калдылар. Юлдан язган Россиянең алданган бәхетсез уллары...

Шул минутта әле, якынча дүрт йөз-биш йөз кеше була әлеге чолганышта. Сау-сәламәт ир-атлар, егетләр. Кеше малын талап баючылар түгел иде алар. Эчкечеләр, юлдан язганнар да түгел. Намуслы, гади кешеләр, Россиянең ватанпәрварлары...

Ләкин һәр мизгел үткән саен алар сан ягыннан азая бара. Аларны кыралар, үтерәләр. Соңыннан күпләре янып көл булачак. Кем белә, аларны әле дә әниләре менә кайтыр, менә кайтыр, ди-ди көтә торганнардыр. Күпләренең ятим балалары үсә торгандыр. Ул балалар, искә алу, чәчәк салу өчен генә булса да әтиләренең каберен эзләр...

Тукта да, килеш, сөйләш һәм уртак бер фикергә кил, югыйсә. Юк, тәкәбберләр һәммәсе! Сәяси сәрхүшләр!..

Махсус көчләргә ярдәм агылып кына тора. Беренче катка яңадан-яңа хәрби төркемнәр бәреп керә, гел урынсызга аталар бертөзлексез. Кешеләргә түгел, баш очында эленеп торган зиннәтле бәллүр люстраларны, өчәр-дүртәр метр биеклектәге көзгеләрне кыралар. Баш өстенә бәллүр ватыклары коела, махсус шулай эшлиләр, күрәсең, куркыту, өркетү өчен. «Менә без нинди көчлеләр, безгә каршы чыгасы булмагыз моннан соң. Югары Совет дип, Конституция дип лаф орасы, алданасы булмагыз! Замана безнеке. Көчленеке замана!»

Төркем-төркем басып торган депутатларга да игътибар иттеләр, ниһаять. Бер кавымга онытып торганнар иде үзебезне. ОМОН уратып алды. «Сагындырып өлгергәннәр иде».

— Барыгыз да депутатлармы? — дип сорадылар.

— Юк. Аппаратта эшләүчеләр дә бар,— дип җавап кайтардылар.

Тегеләрнең кемнәрнедер эзләве икән. Төркем эченнән бер-бер артлы ике-өч ир-атны йолкып алдылар һәм идәнгә сузып салдылар... Болар, чынлап та, депутат яисә аппарат хезмәткәрләре түгел иде. Тентергә керештеләр. Берсенең кесәсеннән ике автомат патроны килеп чыкты. Шундук башына китереп типтеләр үзенең.

— Бу нәрсә?! — дип акырды кесә тентүче.

— Патроннар. Идәннән алган идем. Сувенир итеп. Улыма күрсәтермен дип.

Бу озын буйлы егет безнең янәшәдә генә басып торган иде. «Барыгыз да депутатлармы?» дип сорагач та, каушап китүен, як-якка карангалап куюын хәтерләп калдым. Яхшы зәңгәрсу чалбар, кара күн куртка иде өстендә. Ә аякларында, ни гаҗәп, очсызлы гади кедалар. Шул кедалары белән җәлеп иткән иде дә инде ул игътибарымны. Шул егетне хәзер, әнә, ике ягыннан ике ОМОН сугышчысы өстерәп алып китеп бара. Башы, куллары пыяла ватыклары өстеннән шуып, күз алдында кара канга б гты.

Егетләрне ерак бер почмактагы идәнгә илтеп ыргыттылар. Кичке эңгер-меңгер җитеп килгәндә исә һәммәсен дә Югары Совет бинасының каршысында гына урнашкан стадионның тимер-бетон коймасы читенә тезеп атканнар. Бусы да чын булган хәл, аянычка каршы, бусы да хакыйкать.

Әле генә янәшәмдә басып торган егетнең язмышы шул мизгелдә үк пошаманга салган иде мине. Аның артыннан калган кан эзе аеруча авыр тәэсир калдырды, тәмам тетрәндерде. Баш әйләнгән сыман булды кинәт. Зур мәрмәр баганага барып сөялдем...

Ул да түгел, иңбашыма төртеп куйдылар:

— Карале, Ринат, әнә теге кием элгечләренең аргы тарафындагы тәрәзә төбенә кара. Таныйсыңмы?

Битараф кына шул тарафка бактым. Һәм анда әле генә күңелдә булган кешеләрне күреп шаккаттым. Өч генерал басып тора иде, танылган, мәртәбәле исемнәре булган генераллар: Ачалов, Баранников һәм Дунаев. Боларның беренче икесе Татарстанда туып-үскән. Әле бер ел гына әүвәл Баранников Россиянең Дәүләт куркынычсызлыгы комитетын җитәкләсә, Дунаев Эчке эшләр министры иде. Югары Советны саклаучылар арасына ниндидер карьерага омтылу түгел, киресенчә, офицер намусына тугрылык китергән булса кирәк аларны.

Хасбулатов һәм Руцкой кая икән? Ачалов, Баранников һәм Дунаевны кулга төшергәчтен, ниләр кыланыр икән болар дип уйланып куйган идем бая гына. Баксаң, аларны да кулга төшергәннәр икән. Билгесезлектә, тәрәзә каршысында басып торалар. Йөзләре уйчан, моңсу. Безне ни көтә, дип уйланалармы икән... Генерал Ачаловның башы, гадәттәгечә, горур, югары күтәрелгән, аягында хром итек, өстендә очучылар кия торган кыска күн куртка. Кулларын кая куярга белми, әле кесәсенә тыга. Шундук тартып ала да, ике учын бергә кушып бармакларын уарга керешә. Карап торышка, үзе болай тыныч та кебек, югыйсә, ә куллары җан тынгысызлыгын ача да сала.

Баранников, гадәтенчә, моңсу, каядыр еракка, бер читкә карап тора. Ике кулы ике кесәсендә. Туган яклары, Алабуга районында калган карт әнкәсен искә аламы икән... Әллә алда ни көткәнне гоманлыймы, үзе генә белә. Кызганыч, ул инде бүген якты дөньяда юк. Хушлашмый да китеп барды намуслы генерал Баранников...

Өченче генерал — Дунаев. Зәңгәрсу кара плащ кигән, башын түбән игән. Әллә туңган, әллә уңайсыз иде аңарга шундый хәлдә басып тору, озын гәүдәсе сорау билгесенә әверелгән. Әледән-әле күзлеген сала да, кесәсеннән ак кульъяулык чыгарып аны сөртеп-сөртеп ала. Парланганмы?! Күзлекме... җанмы бәргәләнә?..

Караңгы, салкын бинаның кием элгечләре арьягындагы ул күренеш — өч генерал әле дә минем күз алдымда. Аларны битен-күзен, бар гәүдәсен чуар пантера кыяфәтендәге комбинезон-маска артында яшергән солдат саклый. Тегеләр янында көзге чебеш кенә үзе. Берничә адым читтәрәк баскан да, качсагыз — атам дигән сыман өч рус генералына мылтыгын төбәп тора. Кая качасың?! Кемнән?! Үз-үзеңнән, Россиядән качсаң гына инде... Ә болары үз ватанын сатып кача торган хәрбиләргә охшамаган.

Ишек катындагы суык мәйданда безне ике сәгатьләр чамасы бастырып тоттылар. Сөялер урын юк, утыру тыела, аяк балтырлары шешеп чыкты. Сөйләшергә, ымлашырга да ярамый, җиде катлы сүгенү белән искәртеп кенә торалар. Берни эшләр хәл юк, буйсынасың. Атып егарга да күп сорамас болар. Әнә бит, кирәксә дә, кирәкмәсә дә аталар да аталар берөзлексез. Алай да әле ашаган-эчкән юк, Алла рәхмәте. Юкса, бер-бер ихтыяҗың булса, ни эшләр идең болар белән.

Әңгер-меңгер якынлашып килгәндә, яңабаштан барлый-барлый рәтләргә тезделәр үзебезне. Хатын-кызларны алгарак уздырдылар. Ни хикмәттер, колоннаның иң ерак койрыгына, соңгы итеп мине бастырдылар. Һәм шундук, махсус үртәгәндәй, кисәтеп тә куйдылар.

— Атып үтерсәләр, үзегезнекеләр була, бинадан атучылар, — диде «чуар тәнле» ихахайлап көлеп.

Күңелгә шом салып куйды болар. Ләкин буйсынмый чараң юк.

— Тигез рәтләр белән генә чыгабыз. Йөгермибез. Һәм артка да калмыйбыз, — дип әмер бирде араларында өлкән саналган «чуар тәнле». Хәрби киемдә түгел болар, милиция формасында да түгел. Погон-фәләннәре булмагач, башкача әйтеп, аерып булмый үзләрен.

Кузгалдык. Ишек-капкалардан түгел, җимерелеп көл булган пыяла дивар тишегеннән чыгардылар үзебезне.

— Сөйләшмәгез. Кулларыгыз баш аркасында булсын. Туры юлдан тайпылсагыз, үзегезгә үпкәләгез,— дип кисәтеп тордылар.

Мәйданнан үләләрне беркадәр җыештырып өлгергәннәр иде инде. Әмма аяк астындагы асфальт өстендә тоташ кан һәм кызыл таплар, карарга куркыныч. Безне «Мир» кунакханәсе белән Америка Кушма Штатлары илчелеге арасындагы тыкрыкка төбәп куаладылар. Әллә махсус, әллә очраклы рәвештә без мәйданга килеп чыккачтын да, бина эченнән котырынып атарга керештеләр. Пулялар янәшәдән генә сызгырып оча, ирексездән чүгеп-чүгеп куясың. Бер метр, метр ярым читтә генә асфальтны каезлый пулялар. Таш һәм тузан кыйпылчыклары өстебезгә чәчелеп тора. Арка сөякләре чымырдап ала, менә тидерәләр, менә атып егалар бит, дип барасың. Һәр адым атлаган саен, Аллага шөкер итәсең. Исән бит, исән... исән әлегә...

Озатып чыгучы «чуар тәнлеләр» юк булды кинәт. Баксаң, алар Югары Советтан әсир итеп чыгарылган хатын-кызлар һәм депутатлар арасына кереп поскан икән. Чүгәләп үк баралармы әллә. Җан кадерле икән бит үзләренә дә...

— Сезнекеләр ата... Үзегезгә төбәп аталар. Әнә, кемнәрне җыйгансыз ул бинага,— дип сөйләнеп барды берсе. Миннән ике генә рәт алга кереп кысылган, поскан. Ә тел тегермәне тарта...

Белмим, кем аткандыр, әйтү кыен. Әмма бу куркыту, акылга утырту өчен генә эшләнгән эш булмадымы икән, дигән шик калды күңелдә. Парламент йортын «азат итүчеләр» үзләре башкарды кебек бу тамашаны. Юкса, безгә төбәп атсалар, бер-бер кеше егылып калган, соң чиктә, яраланган булыр иде.

Бинаның аргы тарафыннан чыгарылган депутатларны да шундый ук шартларга куйганнар. Аларга да берөзлексез атканнар. Ни хикмәт, пулялар колак төпләреннән генә очуга карамастан, ул тарафта да һичкемгә тигезә алмаганнар.

Ярты юлда туктатып, ике йөзгә якын депутатны бер йортның подвалына куып кертәләр. Шыплап тутыралар һәм бикләп тә куялар. «Тавыш-тынсыз гына посып утырыгыз», янәсе, «атышулар басыла төшкәч, чыгарырбыз». Тик бер нәрсә аңлашылып бетми, ни өчен ул баздан аерым депутатларны берәм-берәм чакырып чыгарганнар һәм сөякләрен, кабыргаларын ватканчы кыйнаганнар икән?! Баз авызын ачып идән астына әледән-әле автоматтан атулары нигә кирәк булды тагы?!

Күз алдына китерәсезме? Тынчу подвал. Анда ике йөзләп кеше. Шул подвалның бердәнбер ишегеннән ачалар да, кычкырып җибәрәләр.

— Бабурин чыксын... Фәхретдиновны чакырыгыз... Исаков мондамы?

Тегеләр чыга. Бер читкә өстерәп алып китеп ишәләр үзләрен. Ә подвал авызында калган «чуар тәнле» үзенчә бер рәхәт уен тапкан.

— Депутатлар! Сез күселәр... Почмакларга качыгыз. Өчкә тикле санагач та, ата башлыйм,— дип кычкырып, акырып җибәрә бар тавышына.

Һәм сүзендә тора. «Өч» дигәндә, автоматтан сиптерергә керешә. Үзе ата, үзе кыргый авазлар чыгарып көлә...

Магазинын һәм берочтан эчен бушата.

— Әй, кайда сез анда?! Нигә почмакларга посышып беттегез? Сезгә әйтәм, коммунистлар... партократлар... демократлар... чыгыгыз, якынрак килегез... Куркасызмыни?.. Куркасыз шул! Ха-ха-ха...

Мәйдан уртасына җитеп килгәндә сак кына арткы тарафка борылып карадым. Карадым һәм исем-акылым китте... Телевидение бөтен дөньяга күрсәткән тараф түгел иде бу, шуның нәкъ киресе. Аргы тараф. Ике ел әүвәл Ирекле Россия мәйданы дип исемләнгән — үле мәйдан. Без — халык сайлаган депутатлар — кулларыбызны баш аркасына куеп, тоткын сыйфатында шул үле калган Ирекле Россия мәйданын кичеп барабыз. Югары Совет бинасының карарлык җире калмаган. Яна... Нинди нәфис һәм мәһабәт бина иде бит ул. Өч-дүрт җирдән яна. Ялкынланып түгел,

кара сөрем, кара төтен булып пыскый. Яңа Арбат тарафына караган дүртенче каттан ялкын телләре дә күренеп-күренеп кала. Тоташ кара төтен эченнән бәреп чыккан ялкын, карап торышка, аеруча шомлы була икән ул. Ә югары катлар тоташтан яна. Бина түбәсендә, нәкъ очында ук җилфердәгән Россия байрагы да кара сөрем эчендә. Шунысы гаҗәп, кемнәрнеңдер шул байракта да үче булган икән. Байрак теткәләнеп беткән, бер чите, ялгышмасам, хәтта умырылып төшкән иде аның. Исең-акылың китәр, чит ил баскынчылары да ул тикле кыланмас. Мәскәүлеләр — Мәскәүне, россиялылар — Россияне шулкадәр дә кыралмас, шулкадәр дә мәсхәрәләр икән.

— Әй, нигә анда терәлеп каттың, маңгаең кычытамы?! — дип кычкырды депутатлар арасына кереп поскан теге сугышчы. Миңа дәшүе икән. Мәрткә киткәндәй, үз уйларыма бирелеп, тукталып калганмын. Тиз генә башкаларны куып җиттем.

Ул да түгел, «Мир» кунакханәсе почмагында тезелешеп торган бронетранспортерлар арасына килеп кердек. Монда милиция һәм хәрбиләр формасындагы төрле югары чиннар мыжгып тора. Безне тар аралык буйлап, җиде кат иләк аша үткәреп, ары уздыручылар. Милиция хезмәткәрләре ясаган ул аралыктан берәм-берәм генә узасың. Һәммәсенең игътибары синдә. Күзләреңә текәлеп, сынап карыйлар. Бер-бер шик уяттыңмы — беттең, шундук йолкып кына алалар. Һәм аннан соңгы язмышыңны белсә дә, бер Алла үзе генә белә.

Америка Кушма Штатлары илчелеге янәшәсеннән Бакчалар боҗрасына кадәр шундый иләк аша уздыралар. Ә анда урам тулы халык икән, тамаша кылырга чыкканнар. Мәскәү уртасында шундый тамаша барганда өйдә утыру мөмкинме соң?!

Безне озатып чыгучы ОМОН егетләренең «Таралыгыз... Читкә тайпылыгыз» дип кычкыруларын әллә ишетте алар, әллә юк. Бар дип тә белмәделәр. Киресенчә, тар аралыкны тагы да кысрыклый төштеләр түгелме икән әле. Тәртип бетте. ОМОН егетләре югалып калды беркавымга. Бер алга йөгерәләр, бер артка — ни кылырга белмиләр. Дилбегәне кулдан ычкындырды болар.

Минем алдан гына барган егет бер адым янга тайпылды һәм юк булды. Күрмәделәр... Сизмәделәр кебек.

Минем күңелгә дә өмет нуры йөгерде. Юлдашларымнан Андрей алгы рәтләрдә бара иде, ул ерак. Хәсән якын гына. Аңарга дәштем.

— Чуар тәнле күрмәгәндә, уңга таба кереп качабыз. Аңладыңмы?

Хәсән, борыла төшеп, күз кысты. ОМОН егете дә ишетте кебек үземне, борылып та карады әле хәтта. Аңламады. Ә безгә шул гына кирәк тә. Хәсән уң канатка якын ук килде дә кеше арасына кереп юк булды. Мин аның артыннан. Басып торучылар, юл бирә төшеп, йомып калды үзебезне.

Маңгаебызда тамга юк, инде хәзер иркенләп сулыш алырга да мөмкин.

Якташым белән, берни булмагандай, яшь егетләр янәшәсенә барып бастык. «Чуар тәнле»ләрнең берсе бик текәлеп-текәлеп карады-каравын үзебезгә, әмма танымады кебек. Дәшмәде, китеп барды. Күзләрендә әллә курку иде, әллә битарафлык...

Аның каравы, тешләре ярымчерек бер яшь-җилкенчәк танып калган булып чыкты үзебезне. Каршыга ук килде дә, шул черек тешләрен ыржайтып көлде ул:

— Йә, ничек, утырышлар тәмаммы?..

Йөрәккә кадалды аның шул мыскыллы көлүе. Сүзләре, майлы күз карашлары әле дә төшләремә керә. Башка бер вакыт булса, берне кундырып кына аласы да бит үзенә. Юк, ярамый. Бик кыйммәткә төшүе бар...

Берни ишетмәгән, аңламаган кеше атлы булып, җир асты юлы аша каршы тарафка чыгып киттек. Аннан, ирекле кеше хәлендә, әүвәлге Калинин проспекты, хәзерге Яңа Арбатка...

Октябрь башларында гына була торган салкынча, рәхәт һава. Аяк астында сары яфраклар кыштырдый. Җил юк. Ягылмаган таш бинаның тәнне өтәләп торган юеш салкыны да юк монда. Үләләр юк. Кан юк. Һичкем ыңгырашмый. «Кулларыңны баш артына» дип тә кычкыручы юк. Көчләп яткырмыйлар, тентемиләр, типмиләр. Хәтта атмыйлар да икән монда. Белсәгез, аңласагыз икән шул минутта без кичергән ул рәхәтлекләрне...

Күп булса, йөз илле, ике йөз метр араны үткәнбездер, Яңа Арбатка килеп чыктык. Урамны тутырып танклар килә.

— Туладан танк дивизиясе килә,— дигән аваз ишетелде.

— Руцкойны, депутатларны яклап килүчеләр, урра...— дип кычкырды таякка таянган бер ветеран бабай.

Кызык табып йөрүчеләр аңарга кырын-кырын карап куйдылар.

«Юк инде, бабай, Руцкойга да, депутатларга да ярдәм кирәк түгел хәзер. Соң инде. Соң...— дип уйлап куйдым үзалдыма.— Исән булсалар, Хасбулатовны да, Руцкойны да күптән бер-бер зинданга кертеп ябып куйганнардыр инде. Халык депутатларын да кайсын-кайда таратып-туз-гытып бетерделәр. Югары Совет бинасы җимерелде, дөрләп-пыскып яна әнә. Ярдәмгә килсәгез дә, соңардыгыз, кичектегез, туганнар».

Бабайның сүзләре хак булдымы әллә?! Яңа Арбатның каршы тарафыннан, Мәскәү хакимияте һәм Югары Совет ягыннан урамны иңләп шулай ук танклар килә иде. Болары зур, авыр танклар. Көне буе без утырган «Ак йорт»ка, безгә аткан, хисап номерлары да язылмаган танклар. Канга буялган танклар...

Ике тараф та туктап калды. Уңда да танклар, сулда да танклар... Арада, күп булса, йөз метр ачыклык калгандыр. Киң урам уртасында көпшәләре бер-беренә текәлгән танклар арасында торып калдык. Шулкадәр кечкенә, шулкадәр ярдәмсез икән ул кеше танк каршысында...

Нәрсәне аңлата? Ни дигән сүз икән бу?.. Күршеңдәге кешегә дәшеп, күршең ишетерлек түгел, үкертепме-үкертәләр танкларын. Әйләнә-тирәне карасу-зәңгәр төтен каплаган. Җир өсте калтыранып тора. Яңа Арбатның күккә ашкан пыяла биналары калтырана. Тәрәзәләр зеңгелдәп коела. Ни бу?! Ахырзаманмы әллә...

Бумы? Бу — Россия!

*1990—1995 еллар.*
*Казан-Мәскәү.*



# ШИГЪРИЯТ



## Нажар Нәҗми

### Минем кулны юасы юк

*...И некому руку подать.*

М. Лермонтов.

Кемгә кул бирергә? Теге
Дус дигәнгәме?
Ул бит инде кичәгенең
Ялганлык яме.
Тик хәят кичәге түгел,
Бүгенге хәят.
Хәйлә һәм алдашу тора
Күзеңә карап.
Чукынды адәм акчага,
Корып бара рух.
Җан әрни, нишләп калыр, дип
Бу — рухсыз тормыш.
Кемгә кул бирергә хәзер?
Кул кулны юа.
Минем кулны юасы юк,
Юынмаган дөнья!

### Бүгенге тәфтиләүләр

Үткәннәрдән чыңлап килә
Ерткычлык, эзәрләүләр;
Килә каргыш җыры булып,
Тевкелев — «тәфтиләү»ләр,
Денен һәм иманны сатып,
Чукынып урысларга,

Үз бәхетен тапкан алар
Күз-яшь, кан коешларда.
Һәр заманның да,— кызганыч! —
Бар үз тәфтиләүләре.
Аларны аңлавы җиңел,
Читен тәфсилләүләре.
Узган замандагыларның
Кулында гаскәр, корал,
Аларга корал ясарга
Байлыгын биргән Урал.
Бүгенгеләрнең коралы —
Вазифа, урын, исем.
Без шундый акыллы башлар,—
Уйласаң — китә исең.
Азатлыкны теләнәбез
Булмасын белә торып,
Кыланабыз урыска һич
Чукынмаганнар булып.
Чукынганнар белән җаным
Бөртек булмады уртак.
Ә иманымны яклап мин
Кермәдем утка — куркак!..
Нәрсәдән икән куркырга —
Дөнья бит үзгәрүчән?
Ә аны җыр язып кына
Үзгәртеп булса икән?!
Шуңадыр да ялагайлык
Ярыкларына посып,
Хәкимнәрнең сәдакасын
Иманга бутап, кушып,
Сәмруг кошлы тәреләрне
Милли җаннарга тагып,
Урыс белән без мәңге дус
Булдык, дип чаңнар кагып,
Кеше аңын томаларга
Без оста булып киттек.
Кап-кара тарихны ап-ак
Җеп белән ямап беттек.
Үзен гел кол итеп тойган,
Азатлык, дип канын койган,
Илдә яу чаба-чаба...—
Шушы ялганнан гарьләнеп,
Каберләрендә әйләнеп,
Куядыр ата-баба.
Бүген дә рус үз терәген
Тәфтиләүләрдә күрә.
Төрле-төрле хәйлә корып,
Милләт көрәген тоттырып,
Милләтне көрәттерә.
Тик бер Чечня коя канын,
Үз өстенә алып барын —
Башкалар тора карап.
«Нинди сугыш бу?» дигәнгә
Ишетелми беркемнән дә
Ачык һәм дөрес җавап.
Еллар үтә... Кеше күнә...
Әкренләп шым, шып-шым сүнә
Милләтләр, илләр, гөлләр...



5*.

Куркыныч һәм яманырак
Бүгенге тәфтиләүләр!..

* * *

Тагын килде бер яз... Күрерләргә
Насыйп икән исән-сау булгач.
Тик чакыра кәккүк әллә ничек,
Әллә ничек сайрый сандугач.
Алар моңы үзәгемне өзми
Сихри җаны булып дөньяның.
Сайраулар да сайрау түгел икән —
Сайрамаса әгәр үз җаның.

## Табышу

*Роберт Миңнуллинга*

Бу дөньяга синең килгән елда
Белмәдем туганыңны,
Тик беләм мин бер карт буйдак булып,
Утыздан узганымны.
Бүгенгедәй хәтеремдә әле
Януым, көюләрем:
Сөйгәнемнән сөелмәгәнемә
Әрнеп тә йөрүләрем.
Шул вакытта бәхет, ай, елмайса,
Мин атай булыр идем.
Бүген килеп: «Минем улыма син
Яшьтәш»,— дип тукыр идем.
Ләкин шатмын: алдан белгән кебек
Шагыйрь, дус булырыңны.
Туган елыңда ук язганмын, шәт,
Кыска бер шигыремне:
«Дөнья матур дуслар белән генә,
Дуссыз яшәүче сирәк;
Ләкин дуслар арасында да дусны
Таба белергә кирәк».

Без табыштык!.. Бетте яшь арасы,
Араларда — Шигырь тантанасы.

* * *

*26 декабрь, 1995.*

Бер минутка бүген озайды көн —
Уйны уйга катам.
Гомеремне озайтыр өченме
Больницада ятам?
Бу минутны кабат күрер өчен
Бер ел вакыт кирәк.

Минем яшьтә бер ел гомер дә бит
Кабатланмас бүләк.

Тырыша ла йөрәк...

## Зур үсегез

Хуш, тәрәзәм! Синең аша төште
Бу бүлмәмә кышкы ак нурлар.
Синең аша карап торды миңа
Кар ябылган ямь-яшь чыршылар.
Әй чыршылар! Мин бит гомер буе
Шигырь белән авыру кешегез.
Бу көнемне ямьләп торган өчен
Рәхмәт сезгә: зу-ур үсегез.

Малай чакта күрше-тирәдә:
«Зур үс!» — диләр иде миңа да...

## Тынлык

Тынлык... Тынлык... Миңа — тынгысызга
Син бер ләззәт һәм тын гарәсәт.
Сызлауыннан туктап тора синдә
Йөрәктәге төрле җәрәхәт.
Бу минутлар дәвам итсен, дисәм,
Әйтер төсле Ходай тәгалә:
«Бер ярасыз йөрәк белән, улым,
Яшәвеңдә нинди соң мәгънә?»

* * *

И мактыйлар... Күреп торам:
Мактау сүзләре ялган.
Ә бит ялганга ышану
Макталучыга яман.
Макталучы ышансын да
Башканың яманына...
Яманрак ышануы
Үзеңнең ялганыңа.

* * *

Шагыйрьләргә хәзер илле... алтмыш...
Илһамлана җитмеш яшьле дә.
Күпме еллар яшәп, җиттекме тик —
Җитәрбезме Тукай яшенә?!

*1995—1996*

# УФАДА ЯҢА КИТАП ЧЫКТЫ...




**Кәүсәрия Шафикованың беренче шигъри язмаларын укыганда, дөресен әйткәндә, мин аның шагыйрә булып өлгерүенә ышанмаган идем. Кимчелекләрен күрсәтеп берничә ел дәвамында язган хатларым, үзе белән очрашып сөйләшүләрем уңай йогынты ясагандырмы, тора-бара ул матбугатка тәкъдим итәрлек шигырьләр, нәсерләр иҗат итте. Хәтта Илһам Шакиров үзенең репертуарына кертерлек җырлар язуга кадәр күтәрелде. Хәзер Кәүсәриянең шигырьләрен Башкортстанда да, Татарстанда да әдәбият яратучылар яхшы беләләр. Ул минем якташым, Башкортстанның Яңавыл районыннан.**

**Рәфис Мөхәммәтдин дә шул ук районнан. Аның исеме әлегә бик үк таныш түгел. Ул да, Кәүсәрия кебек, авыр язмышлы егет. Икесе дә, ачы язмыш урын-җиргә бәйләгән каһарман һәм шигъри җаннар, Кәүсәрия белән икесе эчкерсез рухи юлдашлар: поэзиядә дә, тормышта да.**

**Күптән түгел Уфада татар телендә нәшер ителгән «Ике аккош» исемле шигырьләр җыентыгын җибәреп, алар мине тагын бер тапкыр сөендерделәр. Төзүчесе, мөхәррире шагыйрь Фәрит Габдрәхим китапның кереш сүзендә дөрес әйтә: «Кәүсәриянең кызларча йомшак, нәфис тавышына Рәфиснең ир-егетләрчә ышанычлы, ныклы тавышы өстәлеп, менә дигән дуэт барлыкка килә».**

**Җырларыгыз аккош юлыннан төшмәсен, кадерле якташларым!**

**Илдар ЮЗЕЕВ,**
Татарстан Язучылар берлегенең
шагыйрьләр остаханәсе җитәкчесе.

## Кәүсәрия Шафикова

### Күз яше

Күрсәтмәдем сине беркемгә дә,
Иреннәрем генә тешләдем.
Килгән кайгыларны борып салдым,
Көчле идем, әллә нишләдем!
Нишләдем мин бүген, җиңеләмме?
Юк, горурлык исән күңелдә.

Син, күз яшем, әйлән таң чыгына,
Үләннәргә сибелеп җемелдә!

## Кояшлы буран

Торып калдым хисләр буранында,
Ап-ак икән хисләр бураны.
Сине эзләп шул ак бураннарда
Бу дөньяны ничә урадым.
Мин таптыммы, синме, булганбыз ич
Бер үк юлда, бер үк буранда.
Юлыбызны мәңге югалтмабыз,
Бураннарда кояш булганда!

## Шомырт — мәхәббәт агачы

Әйт әле, шомырт агачы,
Син шуны әйтеп кара,
Чәчәкләрең ап-ак синең,
Җимешең нигә кара?
Яктылык өсти дөньяга
Төлгәшләрең аклыгы.
Анда керсез күңел төсе,
Анда сөю сафлыгы.
Ак тәңкәләр сибеп җиргә,
Әйтте шомырт агачы:
«Җимешләргә сөйгәнеңнең
Күзе итеп карачы!»
Шомыртлар ап-ак чәчәктә,
Салкын җилләр, исмәгез.
Җимешен өлгертсен сөю,
Өметләрне кисмәгез!

## Тал икән

Үзендә таудай көч бар икән.
Бөгелде, сынмады, тал икән.
Көчлене имәнгә тиңлиләр,
Имәннәр нык була, диләр дә.
Яр буе таллары булу да
Бик җиткән авырлык килгәндә.
Җил-давыл котыра, дулкыннар
Үксиләр кочаклап ярларны.
Мин күрдем коточкыч бу мәлдә
Бирешми тибрәлгән талларны...

Бөгелде, сынмады,
Тал икән.

* * *

Мәхәббәт дип сөенеп яшимен,
Мәхәббәт дип үксеп елыймын

Мәхәббәт дип көләм-елмаям,
Мәхәббәт дип өзелеп җырлыймын.
Мәхәббәттә күрәм бар ямьне,
Мәхәббәтне яклап көрәшәм.
Мәхәббәт дип утлар йотамын,
Мәхәббәт дип ярсыйм, көнләшәм.
Мәхәббәт өченгә яхшылык
Кылырмын мин хәтта яманга.
Тик бер генә нәрсә, бер генә:
Мәхәббәт дип бармам ялганга!

### Бүген җилләр талгын исте

Ак болытны мендәр итеп,
Җил йоклый төшләр күреп.
Төшендә дә йөридер ул.
Каен чукларын үреп.
Үтәдер ул элгән керне
Җилфердәтеп чак кына.
Тирбәтәдер чәчәкләрне
Кочып алып сак кына.
Су буена йөгереп төшеп
Дулкыннарны куадыр.
Бөгелгән тал бөдрәләрен
Агым суда юадыр.
Кояш батты, ай калыкты.
Таң белән җил уяныр.
Бүген нинди җил исәр, дип,
Дөнья күргән уйланыр.

## Рәфис Мөхәммәтдин

### Үзем булып калам

Әйткәннәре булды миңа:
«Тормышта хаклык сирәк.
Күзле килеш сукыр булып
Калуың хәерлерәк!»

Ишетмәдем, әллә шуңа
Бик күпләр иш итмәде.
Хәтта дустым табынында
Кайчак урын җитмәде.

Үзем булып калам һаман,
Сөйлимен үз сүземне.
Хаклык күреп яшәр өчен,
Ачтым ласа күземне.

## Таш бәгырь

Ана күтеп газиз улын,
Инде күпме таң ата.
Шахтер егет — аның улы,
Ничәмә ел таш вата.

Ялгыз ана яшен түгеп,
Йота соңгы ашларын.
Нигә егет ватмый икән
Үз бәгыре ташларын?!

* * *

Яралы кош килеп кунды,
Кан тама ярасыннан.
Канатлы да бит, барыбер
Сызлана минем сыман.

Ярдәм кулларымны сузып,
Үрелдем, җитми буем.
Аңладым, бүген аңладым,
Язмышлар түгел уен.

## Кошлар күрсәм...

Язгы җилләр талгын гына
Тәрәзәмә килеп какты.
Урамнарда гөрләвекләр
Борма-борма юлын тапты.

Шаулап-шаулап гөрләвекләр
Елгаларга карый акты.
Моңлы-җырлы очар кошлар
Туган җирләренә кайтты.

Кошлар кайта язлар саен,
Сагынып туган ояларын.
Әллә нигә кошлар күрсәм,
Үз-үземнән оялзмын.

* * *

Ага чишмә чылтыр-чылтыр,
Яннарында таллары.
Суын алып авыз итсәң.
Яктыра күз аллары.

Чишмә буе таллары да
Җаннарга якын, үзгә.
Сандугач та моң телендә
Әйтергә тели безгә:

«И кешелек, туган җирдә
Синең күрер шатлыгың.
Саклап кына тот, кадерләп,
Талларының яшеллеген,
Чишмәләрнең сафлыгын!»



**Гариф Ахунов**

# ТИМЕРХАННЫҢ АВЫЛ ЮЛЛАРЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## Беренче бүлек

Баш өстендә кояш балкып торганда, зәңгәр күктә сабан тургайлары сайраганда — авыл юлларыннан йөрүе рәхәт, бик рәхәт! Ләкин гел җәй булып, гел кояш кына балкып тормый шул. Бәйләнчек салкын яңгырлары белән берзаман көз килә, күз ачмаслык өермә-бураннары белән аннары кыш ябырыла.

Кыш ябырылу бер хәл — синең өскә күңелсезлекләр дә ябырылса, эшең хөрти инде.

Мөслим районының авыл хуҗалыгы бүлегендә инструктор-бухгалтер булып эшләгәндә күңелсезлекләр аз булмады. Урлау, әртил малын үзләштерү кебек тайгак хәлләрне күргән чагында җаннары гасабилана иде Тимерханның. Райбашкарма рәисенең урынбасары белән киңәшеп, ул бер колхоздагы урлау-үзләштерү актын прокуратурага тапшырды.

Район прокуроры Исрафилов аны ачык йөз белән кабул итте. Тимерхан язып алып килгән актны укыган чакта аның күперенке кара мыегы гел үзенчә дерелдәп торды. Димәк, җинаятькә ул битараф түгел, җинаять аның ачуын кабарта. Актны укып бетергәч, Исрафилов урыныннан торды, читлеккә ябылган арыслан кебек, ишекле-түрле йөренә башлады.

— Кара син аларны, мошенникларны! Колхозны таламакчылар диген, ә?! Без аларны, безме аларны... Без аларны буш калдырмабыз! Без аларны сагайский биетербез! Ник туганнарына үкенерлек итәрбез.

Исрафилов ике кулының да бармакларын җәеп, баш өстенә күтәрде, шапылдатып учын учка куйды:

— Күрәсеңме моны, Борһанов?

Тимерхан күрде: аркылы-торкылы куелган бармаклардан «рәшәткә» ясалган иде. Төрмә! Прокурор колхоз милкенә кул сузучыларны төрмәдә черетәчәк икән...

Тимерхан җинаятьчеләрнең җәза алачакларын хатыны Миңлеасиягә сөйләп бирде. Хатыны кул гына селтәде.

— Нигә селтәнәсең? — диде Тимерхан, ачуы килеп.

— Юк белән йөрисең...— дип, Миңлеасия самавырга нарат күркәсе сала башлады, иренә чәй кайнатып эчертергә җыена иде.

— Туктале, җанкисәгем. Нигә дип син, юк белән йөрисең, дидең әле?

— Әй, картым,— диде хатыны.— Әйт әле, кайчан соң карга карганың күзен чукыганын күргәнең бар? Ә?

Гомер буе гаделлек ягында торган Борһановка бу сүзләрне ишетү гарьлек иде, әмма хатынының хаклы икәнен белгәннән соң, ул тагын да ныграк гарьләнде.

Атна узды, ун көн узды, көтә-көтә көтек булып, бер ай узды. Карак председатель дә, аның белән бергә урлашкан бухгалтер да һаман урыннарында утыралар.

Нишләргә соң? Нишләп карарга?

Уйлый торгач, вәсвәсәләнеп йөри торгач, Тимерхан ныклы бер карарга килде: беренчегә кереп карарга кирәк. Ул чагында Мөслим райкомының Беренче секретаре булып Салих Искәндәров эшли иде. Тыныч табигатьле, йомыш белән килгәнне тыңлый белә.

— Кереп дөрес иткәнсез, иптәш Борһанов. Әле үзем дә хәлләрегезне белешергә ниятләнеп тора идем. Тыңлыйм сезне, сөйләгез.

Борһанов, мөмкин чаклы кыска итеп, прокурор белән килеп чыккан хәлне сөйләп бирде.

Искәндәров, кулы белән иягенә таянып, аны сүзсез генә тыңлады, тыңлап бетергәч:

— Аңлашылды,— дип бер генә сүз әйтте.

Бәхәсләшмәде дә, җинаять кылган председатель хакында сүз дә куертмады. Тик Борһанов китәргә дип кузгалгач кына:

— Иптәш Борһанов, миндә шәхси йомышыгыз юк идеме?— дип сорады.

Тимерхан аптырап калды.

— Юк...— диде, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

Шәхси йомышы бар иде аның. Аларның фатир ягы бик кысен иде. Кеше өстендә яшиләр, өйдәш булып! Ул хакта сүз кузгатсаң ярар иде дә, ләкин бит ул шәхси йомыш белән кермәде, җәмәгать эше белән керде. Фатир сорый башласаң, Искәндәровның әллә ниләр уйлавы бар. Прокуратура сылтау гына икән, дияр, төп йомышы фатир алу, дияр.

Искәндәровның үзе кабул иткән кешеләр хакында ике-өч җөмлә белән генә бәяләмә язу гадәте бар иде. Борһанов ишектән чыгып китүгә, ул әлеге гамәл дәфтәрен алды.

«Бүген миндә инструктор-бухгалтер Борһанов булды. Намуслы егеткә охшаган. Квартир ягын, хатынын эшкә урнаштыруны кайгыртырга кирәк булыр».

Тимерхан исә бу вакытта Мөслим урамы буйлап атлый, күңеленнән Искәндәров турында: «Ул мине дөрес аңлады»,— дип уйлый иде. Искәндәровның Тимерханны дөрес аңлаган булуы эш-гамәлендә дә күренде. Ике атна чамасы вакыт узуга, карак председатель белән бухгалтерны эшеннән алдылар. Беренче секретарь ул колхозга үзе барып, яңа кешеләрне сайлатып кайтты.

Әмма... әлеге председательне Мөслим урамында күреп, Тимерхан шаккатты. Күн пальтодан, бүре мехыннан теккән тубал чаклы бүректән, кошовка чанага киерелеп утырып, кара туры айгырны җилләр уйнатып бара иде. Карак председательнең айгыры бераздан кире борылды, Тимерхан Борһанов утырган үрәчәле чананы аудара язып китте. Янәсе, күрәсең килсә күр, бухгалтер-инструктор: синең пүчтәк казынуларыңнан берни дә барып чыкмады!

Бераздан Тимерхан тикшереп белде: ул никадәр көч куеп урыныннан алдырткан председатель-җинаятьче Мөслимнең кулланучылар җәмгыятенә җаваплы бер эшкә урнашкан булып чыкты.

«Карга карганың күзен чукымый»,— дип хатыны Миңлеасия әйткән сүзләр исенә төште Тимерханның.

Миңлеасия дигәннән, уйламаган-көтмәгән чакта, аңа да эш табылды. Районның сәламәтлек саклау бүлеге фәрманы белән аны үзәк хастаханәгә шәфкать туташы итеп алдылар. Тимерхан моңа чынлап торып шатланды. Ник дигәндә, үзенең хезмәт хакы 550 сум (нормаль акча белән санаганда 55 сум дигән сүз!). Бу исә гаилә тормышын алып бару өчен түгел, икесенә тамак туйдыру өчен дә такы-токы гына булып кала. Миңлеасиягә 375 сум билгеләделәр. Әлеге хезмәт хакларын бергә кушкан суррәттә дә, әлләни мантый алмыйсың алуын, әмма шулай да, иш янына куш булыр әле.

Ул вакытларда район оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә фатир хакында сүз кузгату да рөхсәт ителми иде. Җитәкчең үзе белеп, хәлеңә кереп дигәндәй, бирсә бирә, бирмәсә — юк. Каян урын таба аласың, шунда яши бирәсең. Риза түгел икәнсең, эшеңне ташла да кит. Беркем дә синең арттан, китмә инде, дип ялынып йөрмәячәк...

Ык буендагы Кооператив урамында ярым җимерек бер ташландык йорт бар иде. Хуҗасы күптән инде Ташкентта яши икән. Шуның белән Мөслимдәге туганнары аша элемтәгә кереп, фатир хакын ярты елга алдан түләп, Тимерхан белән Миңлеасия бергә тора башладылар. Ул елларны йорт җиһазы Тимерханнар кебек әле яңарак өйләнешкәннәрнеке генә түгел, озак еллар гомер кичергәннәрнеке дә юк иде. Тимерхан киң генә бер тактаны шомартып, тәрәзә төбенә өстәмә итеп кадаклады да шуны өстәл итеп тоттылар. Тугыз җиренә ямау салынган иске самавырлары бар. Ул әле яшьләргә хезмәт итәрлек. Файдаланырга ярамаганлыктан, лапаска чыгарып ташлаган иске караватны алып кереп, стена буена беркеттеләр.

Башка мебель турында уйларына да кертмәделәр, алар өчен бергә булудан да кадерлерәк бер нәрсә дә юк иде. Яраталар да иде соң бер-берсен! Эштән бушагач, китап-мазар укырлар иде дә бит, ут юк, радио кертелмәгән. Кичне ничек үткәрсеннәр? Китәләр кулны-кулга тотынышып! Олы Чакмак юлы буйлап атлыйлар. Чакмак ун чакрым, сигез чакрым баргач, тау башыннан авыл күренә.

— Әйдә, кайтыйк инде, җаным! Караңгы да төште, кешедән дә уңайсыз...— ди Миңлеасия.

Көн саен шулай. Ике яшь йөрәк бергә тибә, ике пар аяк бергә атлый. Рәхәт-рәхәт!

...И гомерләр, и ваемсыз еллар! Искә төшәсез дә Тимерхан абзыйның үзәкләрен өзеп аласыз.

Шул елларны Тимерханны профсоюз оешмасына сайладылар.

— Син хәзер комитет әгъзасы, сиңа культура-масса эшләрен тапшырабыз! — диделәр.

Сиңа халык ышана икән, ышанычны аклый белергә кирәк. Моны Тимерхан яхшы аңлый иде, бер генә җәмәгать эшеннән дә баш тартмады ул. Ихтимал, аңардагы ачык күңеллелек, ягымлылык, кешеләр белән бик тиз уртак тел табу шул заманнарда ук тәрбияләнә башлагандыр. Хромка белән тальян гармун аның юлдашы булудан туктамадылар. Ялга каршы көннәрдә Тимерхан, Миңлеасиясен култыклап, райүзәкнең культура йортына танцы көйләре уйнарга йөри, бармаклары арып китсә, гармунын икенче бер уйнаучыга тоттырып, әйлән-бәйлән уенына чыга, уртага алсалар, төрле мәзәкләр ясап бии, авыл хезмәтчәннәре өчен оештырыла торган җыеннарны үткәрүдә башлап йөри, гомумән, ул райүзәкнең җаны, тылсымчысы иде.

Хәзер уйлап карасаң, исләрең китәрлек: нинди затлы белгечләр бар иде районда! Сибгат Хәкимнең авылдашы, Әтнә районының Күлле Киме егете Галләмов Барый — баш агроном, Ольгино авылыннан урыс егете Иванцов Евгений — баш зоотехник, орлык әзерләү буенча лаборатория мөдире Исмәгыйлева Рокыя — боларның абруе район халкы арасында нинди югары иде! Эшләгән эшләре дә, үзләрен тотулары да бик затлы

иде шул аларның. Өстәвенә, алар әле культура йортына киләләр. Тимерхан башкарган эшләрне мактыйлар, гел аның күңелен үсендереп торалар иде. Болар беркайчан да алгы планга матди файда алуны куймадылар. Хәзерге яшьләрне, хәзерге белгечләрне тыңлый башласаң — чәчләр үрә тора. Акча, акча, акча! Бүтән сүзне белмиләр дә бугай бүгенге белгечләр!

Тимерханның районда тагын бер дусты бар иде. Бер генә кичәне дә калдырмыйча, барлык концертларда катнашып килгән Әюпов! Бу юлларны укыган чакта күңелгә бер уй килүе бик мөмкин: туктале, сүз Наил Әюпов турында бара түгелме? Әйе, бик дөрес: Наил Әюпов — Мөслим егете ич. Әйе, сүз нәкъ менә Татарстанның халык артисты Наил Әюпов турында бара. Ул чагында бик яшь һәм бик чибәр үсмер егет Наил Әюпов моңлы җырлары белән дә, сөйләү осталыгы белән дә кешеләрне таң калдыра иде. Бигрәк ихлас күңелле бала иде ул!

Ул еллардан соң шактый вакыт узгач, Тимерхан Борһанов белән Наил Әюпов, Татар дәүләт академия театрында очрашып, ничектер үзара әңгәмә корып җибәрделәр.

— Тимерхан абый, сез хәзер дә гармун тотасызмы? — диде Наил.

— Наил энем, — диде Тимерхан, — менә син яшьтән үк талантлы булгач, артистлыкны сайладың, шуңа укыдың, зур исемгә лаек булдың. Синең өчен мин бик шатланам. Ходай сәламәтлегеңне бирсен дә сәхнәдән аермасын сине! Ә миңа килгәндә, гармун, җыр, бию кебек күңел ача торган нәрсәләрне мин үзебезнең гаилә шартларында гына башкарам... — Ул үзе дә сизмәстән сәер генә көрсенеп куйды: — Инде хәзер шул кадәренә дә канәгать...

Наилнең сәхнәдәге ихлас уенын, тормыштагы чынлыгын бик ярата Тимерхан. Арчада яшәгән елларында, академтеатр районга килсә, Миңлеасия белән Тимерхан иң беренче рәткә килеп утырырлар иде. Наил үзе бу хәлне аңлый, тамаша барышында сәхнәнең алдына ук килә дә, бер генә секундка тын калып, Тимерханнарга күз кысып ала. Моны берәү дә сизми, Тимерханнар белән Наил үзе генә белә. Бер секунд һәм бер күз кысу — бу үзешчән артист булып Мөслимдә уйнаган еллар. Бу күз кысуда — Тимерхан белән Наилнең яшьлек еллары. Йөрәк түрләрендә әллә нинди хисләр уята бу ишарә!

Тимерханның Наилне өйләренә дә чакырып караганы булды. Җәелеп бер сөйләшсә, Мөслим елларын искә төшерәсе килә иде.

— Наил, син бүген бездә кунып кит, иртәгә иртән иртүк үзем машина белән Казанга илтеп куярмын, — диде аңа Тимерхан.

Наилнең сөйләшүе бик җайлы, ышандыра торган. Якташының хәтерен калдырасы килми иде бугай аның.

— Тимерхан абый, — диде ул иплән кенә, — артистлар арасында шундый бер язылмаган закон бар: коллектив белән бергә килдең, бергә әйләнеп кайтасың. Булыр әле: гомер булса, очрашырбыз да, яшьлекне дә искә төшерербез. Минем спектакльгә килгәнегез өчен дә, кунакка чакырганыгыз өчен дә мең-мең рәхмәт. Үпкәләштән булмасын, мин иптәшләрем белән Казанга кайтыйм инде...

Тимерхан абзый, әлеге күңелле истәлекләреннән айнып, Мөслимнең авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләгән чакларын исенә төшерә. Бүлектәге б...лгечләрнең күбесе югары белемле иде. Алар сугышка кадәрле үк институтларда укыганнар, фронтта булганнар, сәясәт ягыннан да әзерлекле кешеләр. Көндәлек эштә, алар белән очрашканда, бергәләп колхозларга чыкканда, Тимерхан алардан өйрәнә, агротехника һәм зоотехника буенча элементар кагыйдәләрне төшенә башлый. Төшенү кирәк, төшенү мәҗбүри, чөнки авыл хуҗалыгының теләсә кайсы тармагы башлангыч белемне таләп итә. Әкрен-әкрен ул авыл хуҗалыгын алып баруның төрле юлларын күрә, акыллылар белән акылсызларны, булсынга эшләүчеләр белән һава төтәтүчеләрне аера, таный. Бу битараф бер тану түгел. Битарафлыкны-пассивлыкны Борһановның җене сөйми. Ул тормышта нәрсәнедер белгән икән, шуңа үз башы белән барып җиткән икән, нигә

аны үзендә яшереп асрарга? Белсеннәр башкалар да! Күңелендә туган фикерләрне ул башкаларга да сөйли. Шуны искә алып, аны районның җаваплы җитәкчеләре белән бергә колхозларга вәкил итеп тә җибәргәлиләр. Әгәр берәр мәсьәләне райбашкарма утырышына куялар икән, белешмәләр әзерләү, карар проектлары язуны аңа тапшыралар. Ул аларны төп-төгәл итеп, вакытында башкара. Күрәсең, хәрби хезмәттә эш башкаручы булып эшләү, еллар буе фәрманнар, боерыклар, юлламалар язу, штаб кәгазьләрен әзерләү аның фикер йөртү рәвешен, ул фикерләрне документлар аша бәян итүен камилләштергән, ә бу менә хәзерге эш шартларында бик тә ярап куйды. Бу документлар эчтәлеге ягыннан авыл хуҗалыгы турында булса да, формасы белән бер үк иде. Карасана, аның хәрби хезмәте дә файдага булып чыкты бит әле. Егет кешегә дөнья күрү, күп һөнәр белү ярап куя шул...

## Икенче бүлек

**1951** елның сентябрь башларында Тимерханга райкомның оештыру бүлегеннән шалтыраттылар.

— Хәзер үк иптәш Искәндәров янына керегез!

Тимерхан каушады. Нинди гаебен таптылар икән? Тиктомалдан беренче секретарь янына чакырмыйлар бит инде. Бер ел эчендә үзе башкарган эшләрне күңеленнән барлап чыкты: гаепкә санардай гамәл кылганы юк шикелле.

Искәндәров исәнләшү белән сүзне бик капыл гына, үгезне мөгезеннән тотып дигәндәй башлады:

— Иптәш Борһанов! Райком аз гына вакыт эчендә сезнең хакта уңай фикер туплады. Моны раслау өчен сезгә төрле порученияләр бирелде, колхозларда аерым чаралар үткәрүне йөкләде. Сез сынауны намус белән уздыгыз. Безгә бүген «Мөслим» совхозына партоешма секретаре кирәк. Үзегезгә мәгълүм, районда ул — бердәнбер совхоз. Зур хуҗалык. Җире генә дә унҗиде мең гектар. Совхоз үзе җиде авылны берләштерә. Иптәшләр белән фикер алышканнан соң, совхозга секретарь итеп сезнең кандидатураны тәкъдим итәргә булдык. Бу эшне булдыра алырсыз дип ышанабыз.— Чәчен артка сыпырып, ияген учы белән ышкып торганнан соң, өстәде:— Хәзер эшли торган секретарь Исмәгыйлев олы яшьтә, үзен ул эштән азат итүне сорап килде. Совхозның партоешмасы зур, коммунистларның күбесе производствода эшли. Йә, үзегез ничек карыйсыз моңа?

Тимерхан каушаган иде. Искәндәров моны сизде, җавап көтеп ашыктырмады.

— Сизеп торам, Салих Искәндәрович, сез миңа үтә дә җаваплы эш тәкъдим итәсез. Ләкин минем ул эшне тартырлык көчем юк бит. Ник дигәндә, гомуми белемем дә, махсус белемем дә секретарь булып эшләргә җитәрлек түгел.

— Менә минем дә белемем җитәрлек түгел иде — укыттылар. Сезне дә, бераз эшләгәч, укырга җибәрербез. Совхозның үзендә секретарь итеп сайларлык кеше юк. Башка кандидатура юк та, эзләмибез дә...— Секретарь елмайгандай итте. Тимерханга төбәлде.

Борһанов, аның өмет белән карап торуыннан уңайсызланып, карашын идәнгә юнәлтте.

— Ярар, рәхмәт. Сайласалар, эшләрмен,— диде. Бик әкрен, ишетелер-ишетелмәслек кенә итеп әйтте.

1951 елның 15 сентябрендә «Мөслим» совхозы коммунистлары Тимерхан Борһановны үзләренең партоешма секретаре итеп сайладылар.

Тимерхан партиягә 1945 елның сентябрендә, японнар белән сугыш барган чакта кергән иде. Партбилетны аңа дивизиянең бик җаваплы кешесе, подполковник Сарлейский тапшырды.

— Борһанов, хезмәт урыны тыйнак кына булса да, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ике ел буена батальонда комсомол комитеты секретаре булып эшләде. Намуслы, тәртипле солдат...

Совхоз партоешмасының секретаре булып сайланган көннәрдә Тимерхан әнә шул елларын да уйлады. Солдат хезмәтендә чакта ул сәяси эшләрнең үзәгендә булды, димәк оештыру, башлап йөрү кебек эшләрдә аның беркадәр тәҗрибәсе бар, авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләү аңа авыл турында, игенчелек һәм терлек-туар асрау турында мәгълүмат бирде. Димәк, аңа хәзер кешеләр белән тыгыз мөгамәләгә кереп, аларда үзенә карата ышаныч тудырырга кирәк. Иң беренче һәм ныклы танышу, әлбәттә, совхоз директоры Комаров белән булырга тиеш. Леонид Иванович аны беренче мәртәбә күреп сөйләшкән чакта ул ачыктан-ачык әйтте:

— Бик энергичный кеше белән эшлисем килә иде. Теләгем кабул булды бугай...— диде.

Совхоз үзәге Михайловка исемле урыс авылына урнашкан, Мөслимнән егерме чакрым ераклыкта. Сайланып куелуына атна-ун көн узса да, Тимерханның әле өенә кайта алганы юк. Сөйләшер иде, Миңлеасияның телефоны юк. Хәер, ул вакытларда, хәзерге төсле, төчеләнеп яши торган заман да түгел иде.

Бер көнне Комаров әйтте:

— Тимерхан Борһанович, гел болай әрле-бирле йөри алмассыз. Егерме чакрым якын ара түгел. Гаиләгезне китертергә кирәк. Мин монда бик әлләни әйбәт булмаса да, кечерәк бер бүлмә әзерләдем, хәзергә шунда торып торырсыз. Тора-бара әмәле табылыр әле, монысы өчен миңа рәнҗеп йөри күрмәссез,— диде.

Тимерханның түбәсе күккә тиде. Комаровка нинди генә рәхмәтләр әйтсә дә, аз булыр кебек тоелды. Шатлыгын Миңлеасиясенә әйтер өчен ул Мөслимгә кайтып китәргә җыенды, шул хакта Комаровка әйтергә дип кергән иде, Леонид Иванович үзе башлап сүз кушты:

— Ярый, Тимерхан Борһанович, сез алайса кайта торыгыз. Әйберләрегезне җыеп бетерергә ике көн җитәме?

— Хәтта артып та китә. Безнең җиһазыбыз юк,— диде Борһанов.

— Яхшы,— диде совхоз директоры, чәчен сыпырды, иягеннән учы белән каплап торды, аннары әйтте:— Ялдан соң синең үзеңне дә, Асия ханымны да алырга машина җибәрәм. Төенчекләрегезне әзерләп куегыз.

Миңлеасия ирен өзелеп сагынган иде. Ул аны муеныннан ике кулы белән кочаклап, бармакларын аралаштырган көе, чатырдатып кысып, сандугач булып сайрады:

— И-и, Тимерханым! Егетнең дә егете икәнсең. Мин теләгән көнне генә түгел, мин сагынуларымнан шашар дәрәҗәгә җиткәндә кайтып кердең! Әллә-лә!.. Яңа хәбәр әйтимме? Әллә приказны гына күрсәтимме? Менә апаеңны кая билгеләделәр...— Ул йөгереп кенә сандыктан бер кәгазь әләктереп килде, аны Тимерханның борын төбендә кыштырдатып алды.

Тимерханның күз очлы: ни дисәң дә гомер буе документ белән эш иткән адәм, Миңлеасиясе кәгазьне борын төбендә селки башлауга, түгәрәк мөһерен күргәч үк, аңлап алды — аны эшкә билгеләгәннәр.

Нәкъ шулай булып чыкты да.

Миңлеасия инде «Мөслим» совхозына фельдшерлык-акушерлык пунктына мөдир итеп билгеләнүе турында районның сәламәтлек бүлегеннән боерык алган, шуны башкалар төсле тыныч кына күрсәтми, холкына хас сабырсызлык белән Тимерханның борын төбендә селки иде.

Икенче көнне, иртәнге алтылар тирәсендә ишек кактылар.

— Бурганов здесь живет? — дип сорады баһадир гәүдәле адәм.

— Әйе, әйе, Борһанов мин булам,— диде Тимерхан, килүчене түргә узарга чакырды.

Баһадир адәм, ләм-мим бер сүз дәшмәстән, кире борылып чыгып китте, үзеннән дә баһадиррак бер кешене ияртеп керде.

— Без сезнең әйберләрне машинага төяшергә килдек. Директор Комаров җибәрде,— диде баһадир егетләр.

Тимерханга уңайсыз булып китте. Машинага төяр нәрсә юк, машина әрҗәсенең төбенә куярлык ике чемодан гына бар иде. Бүлмә уртасында тырпаеп басып торган тугыз ямаулы самавырны баһадирларның берсенә алып бирде, икенчесенә чемодан тоттырды, бер чемоданны үзе белән алып чыкты.

Өйне биклэп, ачкычын күршеләргә тапшырдылар.

Машина әрҗәсенә үрмәләп менделәр дә икесе ике чемодан өстенә чүмәшеп, самавырны кулга тоттылар, юкса аның буш әрҗәдә бәрелеп-сугылып, бөтенләй дә эштән чыгуы бар иде.

Сау бул, Мөслим! Хуш, кадерле иске йорт! Безнең яшьләр яңа урынга күченә, яңа фатирга.

«Яңа фатир» дигәнебез бик тә бәләкәй булып чыкты.

Михайловкада утызынчы елларда ук усак бүрәнәдән салынган барак тибындагы бер йорт бар икән. Егерме ике фатирлы. Тимерхан белән Миңлеасия шул йортның бер бүлмәсенә кереп урнаштылар. Бүлмә ун квадрат метр чамасы булыр, тәрәзәсе бер генә, бернинди дә җиһазы юк. Алып куйыйм дисәң — складта да җиһаз юк. Монда алар тагын өстәл-урындыкны ничек кирәк алай әмәлләп куйдылар.

Совхоз бөртекле ашлык үстерә, шул нигездә бик күп сарык, сыер, дуңгыз асрый, тавык үрчетә икән. Эшче көче җитәрлек. Сабандыр, тырмадыр, чәчү машиналары, атлар үз чорына карата начар түгел, колхозныкыннан өстенрәк. Совхоз эшчеләре акчага эшли, вазифаларын да, эш нормаларын да яхшы белә. Монысы Тимерханны шатландырды. Таләп итәргә була, димәк. Әнә, тишекле сутыйга бил бөккән колхозчыдан нәрсә таләп итәсең дә, аның үзенә нәрсә бирә аласың?! Әмма каралты-кура бик иске, көнкүреш шартлары юк диярлек, мәктәпләр иске-москы бәләкәй йортларда көн күрә. Шулай да совхоз белән янәшә колхоз авылларында совхоздагыларга көнләшеп карыйлар, аларның яшәү шартлары бигрәк начар иде шул. Колхоз кешесе ел тәүлеге кырда эшли, урман чыгара, задание икмәген элеваторга илтә, тагын әллә нәрсәләр майтара, эшләгәненә сукыр бер тиен ала алмый. Адәм мәсхәрәсе! Ала алмый гына түгел, бакчасыннан өч центнер бәрәңгене дәүләткә тапшыра, ике йөз литр сөт, егерме килограмм ит, үзара салым, страховой түли, аның әле шулар өстенә заем түләтеп җанын алалар. Акчага эшли торган совхоз эшчесеннән көнләшмәс җиреңнән көнләшерсең, валлаһи!

Бер ай тула дигәндә, ул совхоз кешеләренең барысы белән диярлек танышып чыкты. Татарларны исеме белән, урысларны әтисенең исеме белән дә әйтергә күнекте. Мәктәпләр, уку йортлары, сәүдә челтәре, профсоюз, комсомол оешмалары аның карамагында иде, ул алар белән якыннан торып эш йөртә башлады. Авылларда телефон юк, монысы уңайсызлык тудыра, кирәкле эшеңне сәгате-минуты белән үтәтә алмыйсың. Әмма бер начарлыкның бер яхшылыгы да бар: телефонга ышанып ятканчы, эшчеләр янына — кырларга, төзелеш барган урыннарга килеп чыксаң, канәгатьлек табасың. Сине телефоннан юк-барга ышандырмыйлар, эшне син үз күзең белән күрәсең, кешеләр белән аларның күзенә карап сөйләшәсең, һәммә нәрсә урында хәл ителә. Эшчеләр канәгать булып кала. Директор белән дә «күз йомышлы сукыр тәкә» уйнамыйсың, совхозның тормышын якыннан белеп сөйләшәсең.

Тимерханга директор приказы белән яхшы дирбияле туры алаша беркетелде. Ул бик көчле, чыдам: коеп-коеп яуган давыллы яңгырларга да, кышкы салкын бураннарга да бирешми, сине әллә кайлардан совхоз ихатасына алып кайта.

Партком секретаре итеп сайлап, райком бюросына раслату өчен керткәч, Искәндәров әйтте:

— Борһановны бер генә бюро утырышыннан да калдырмагыз, эшкә өйрәнсен, район хәлләреннән хәбәрдар булып торсын,— диде.

Ул елларны бюро утырышлары, гадәттә, кичке сәгать алтыларда башлана иде. Һава шартлары исәпкә керми: буранмы, давылмы, пычракмы, еракмы — син күрсәтелгән вакытка килеп җиткән булырга тиеш. Шундый чакларда директор Комаров — Теләче районының Кибәхуҗа керәшене — чын татарчалап:

— Иптәш Борһанов, әйдәгез, сезнең ат белән барыйк, юлны беркайчан да адаштырмый ул,— дия торган иде.

Райком бюросының 1951 елның 2 ноябрендә үткәрелгәне Тимерханның бик исендә калды. Миңлеасия беренче баласын табарга әзерләнеп йөри иде. Төш вакытларында ул тулгаклый башлады. Тимерхан чыдам алашасын тарантаска җигеп алып кайтты, кайтышлый Комаров кабинетына кереп әйтте:

— Леонид Иванович, гафу итегез инде, мин сезнең белән бергә бара алмыйм, миңа алданрак кузгалырга туры килә,— диде.

— Нәрсә бар? — диде Комаров куркынып.

— Миңлеасия авырый башлады. Мин аны Мөслим больницасына алып барам инде...

Җиргә кар төшмәгән әле, әмма юл шакыраеп каткан иде инде, тарантасның чокыр-чакырлы юллардан бик дыңгырдап килүенә түзә алмыйча, хатыны каты ыңгыраша иде. Шулай да Тимерхан аны бала табу йортына исән-имин килеш китереп тапшыра алды.

Райком бюросы барган чакта Тимерхан Борһановны улы туу белән котладылар. Бюро утырышы тәмамланганны да көтеп бетермичә, Тимерхан бала табу йортына чапты! Аны бюро әгъзалары барысы берьюлы аяк өсте басып, озатып калдылар.

Юлда Тимерхан бик дулкынланды. «Хафизым туган, Хафизым туган»,— дигән уй аның күңеленнән китмәде.

Балага исемне алар алдан ук әзерләп куйганнар. Малай туса — Хафиз, кыз туса — Хафизә. Исемне бергәләп сайладылар. «Җ» хәрефе кергән исем булмасын, урысчалатып паспортка язган чакта «җ» хәрефе мотлак «з»га әйләнә. «Тимерхан», «Гыйлемхан» кебек исемнәрдән икенче исеме төшеп кала да Тимер яки Гыйлем генә торып кала. Малай туса — Хафиз, кыз туса — Хафизә, бетте-китте, вәссәлам!

Бюро утырышыннан чыккач, башы әйләнеп китеп, Тимерхан бала тудыру йортына җәяүләп йөгерде, тик бераздан соң гына, кара туры алашасы барлыгы исенә төшеп, аны тарантаска җигеп алып чыкты.

Күңелендә аның шатлык өермәләнә, хатыны Миңлеасиягә, беренче баласын ир бала итеп тапкан Асия-җанкаена ул хәзер ниндидер бүләк алырга тиеш, әмма нинди бүләк икәнен ул әле үзе дә юньләп белми иде.

## Өченче бүлек

1952 елның язы иртә килде.

Чәчүне тиз тоттылар. Игеннәр тигез тишелде, һәркемне куандырырлык булып үсте. Урып-җыюны да югалтуларсыз башкарып чыктылар. Дәүләт амбарына совхоз тарихында беренче тапкыр кырык мең центнердан артык ашлык озатылды.

Тимерхан бөтен эшнең уртасында булды.

Комаров аны бик тә үз күрә, совхоздагы бердәмлекне, халыкның тату яшәвен, ярышның чын мәгънәсендә кешелекле һәм дөрес итеп оештырылуын яңа парторгның исеме белән бәйләп сөйләргә ярата иде. Бәлки, шуңа күрәдер, Борһановны һәр җирдә үз кеше дип кабул итәләр, тыңлыйлар, бик кыен хәлләргә очраганда, аңардан киңәш тә сорыйлар иде.

Совхозда да Борһанов оста белгечләр, тәҗрибәле җитәкчеләр белән кулга-кул тотынып эшләде. Комаров — агроном, кешеләрне тигез күрә, берәүне мактау, берәүне таптау белән шөгыльләнми, эшне фән кушканча да, практика белән, күпьеллык тәҗрибәләр белән дә бәйләп алып бара. Баш агроном Смирнов авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, әле аңа кадәрле үк, колхозлашканчы, Минзәләдәге совхоз-техникумда үз кулы белән иген үстергән. Механизаторлар аның өчен «Артомон дәдәй» дип үлеп торалар. Совхозның өлкән бухгалтеры Хәсән Шәйдуллин — көчле экономист, хуҗалык алып баруның терәге иде.

«Мөслим» совхозында бер ел эшләү дәверендә Тимерхан Борһанов халык белән уртак тел табарга, кешеләрнең күңелләрендә бөреләнгән уйларны аңларга өйрәнде. Моңа аның бухгалтерлык эшен белүе дә, документлар әзерләү һөнәре дә, өздереп гармун уйнавы да булышты. Ихтимал, Миңлеасия белән тату яшәүләре, гаиләдәге тырышлыклары да башкаларга үрнәк булгандыр. Йомыш белән килгән-киткән кешеләр Хафизны сөеп туя алмыйлар:

— Бу хәтле матур курчакны каян алдыгыз? — дип шаярталар иде.

...1952 елның октябрь урталарында Борһановны тагын беренче секретарь үз янына чакыртып алды.

— Тимерхан Борһанович, сине күрәсе килүемнең сәбәбе бер генә: без сине райкомның оештыру бүлеге мөдире итеп расларга булдык.

— Ә элекке мөдир кая китә, Кирилловны әйтәм?

— Аны, запастагы офицер булганлыктан, кабат хәрби хезмәткә алдылар.

Тимерхан инде бу юлы шактый кыюланган иде, җебеп-мәлҗерәп төшмәде, тәкъдим ителгән эштән баш тартты.

— Мин бит әле эшне башладым гына. Совхоз кешеләре мине үз күрәләр. Шул совхозда тагын бер биш ел эшләргә иде исәп, — диде ул.

— Тимерхан, син мине дә кызган, — диде Искәндәров. — Беләм, ишетеп торам, Комаров белән дә, совхоздагы белгечләр белән дә борчагың пешә икән. Сөйләшә дә беләсең, кеше хәленә керүеңне дә дан итеп сөйлиләр. Менә минем дә кабинет тузаннарын йотып утырасым килми, китәр идем берәр совхозга, саф һава сулап кына яшәр идем. Булмый бит алай. Без — барыбыз да партия солдатлары.

Теләмәсә дә, килешергә туры килде Тимерханга.

Башта аны раслату өчен Чистай өлкә комитетына, аннан Казанга — крайкомга җибәрделәр. Кулына бер конверт тоттырдылар.

И дөньялар, Тимерхан яшәгән чорда гына да сез кырык төрлегә төрләндегез бит! Татарстаннан ике өлкә, бер край ясаган заманнар бар иде бит әле. «Кызыл Татарстан» белән «Советская Татария» газитләрен бергә кушып, урыслаштырып маташтылар. Тик ул үзгәрешләрнең берсе дә озын гомерле булмады. Татарстандагы татарлар — татар булып, урыслар урыс булып калды.

Борһановны Чистай өлкә комитетында партия оештыру бүлеге мөдире Полющенков кабул итте. Шул атаклы Полющенков инде, азактан Социалистик Хезмәт Герое булган Григорий Григорьевич! Чистай шәһәр партия комитетының беренче секретаре булып та озак еллар эшләде. Полющенков Тимерханны икенче секретарь Бәдыйговка күрсәтте. Борһанов монда да үзенең райкомга күчүенә ризасызлыгын белдереп караган иде. Бәдыйгов эшне бик коры тотты:

— Йә риза буласың, йә партбилетсыз өеңә кайтып китәсең, — диде.

Борһанов, ризалык бирер-бирмәс көе, крайкомга адресланган пакетны алып, Казанга килде.

Крайкомда Тимерханны бүлек мөдире Харитоновка алып керделәр. Аңа да Тимерхан күңелендәгесен әйтеп бирде. Харитонов аны бик зур игътибар белән тыңлагач:

— Әйтегез әле, иптәш Борһанов, райком инструкторлары арасында белемле, әзерлекле кешеләр бармы? — дип сорау бирде.

— Бар, — диде Тимерхан, исемнәре белән ике иптәшне атады.

Крайкомның бүлек мөдире объектив кеше булса кирәк, Тимерхан исемнәрен атаган кешеләр турындагы сүзне дә дикъкать белән тыңлагач, әйтте:

— Ярый, иптәш Борһанов, бүгенгә кайтып торыгыз, мәсьәләне иртәгә хәл итәрбез, — диде. — Иртәгә Искәндәров пленумга киләсе, сез дә сәгать сигезгә бүлеккә килерсез.

Әйтелгән вакытка Тимерхан бүлеккә килде.

Озакламый бүлеккә Искәндәров та килеп керде. Тимерханны күргәч:

— Син монда нишләп утырасың? Эшең бетмәдемени әле? — дип кырыс кына сорап куйды.

Җавапны да көтмичә, Харитонов янына кереп китте.

Озак кына сөйләштеләр бугай, көтә-көтә арып бетте Тимерхан. Ниһаять, Искәндәров кабинеттан чыкты.

— Без мәсьәләне хәл иттек. Иртәгә крайком бюросына раслануга керерсең, — диде.

Крайком бюросын икенче секретарь Кузнецов алып барды.

Тимерханны чакырдылар.

Керде, кабинетта бюро әгъзалары гына булуын күрде.

Харитонов Тимерханны Мөслим райкомының партия-оештыру бүлегенә тәкъдим итте.

— Тиешле белеме юк. Ләкин Искәндәровның тәкъдиме бу иптәш турында ныклы, бик тә перспективалы егет, диде аны райком секретаре.

Тимерхан Борһановны бүлек мөдире итеп раслап, Мөслимгә кайтарып җибәрделәр. Совхозда, чын тормышта, халык белән бергә нибары бер ел эшләп калды Тимерхан. Үкенечле иде бу хәл, бик тә үкенечле иде. Инде менә тагын Мөслимгә күчеп кайтырга, тагын уңайсыз, шыксыз фатирга урнашырга, Миңлеасиягә кабат эш эзләргә кирәк.

Мөслимдә дә аларга гомуми торактан бер бүлмә бирделәр. Торак бик иске, бүрәнәләре череп бетә язган иде. Тугыз ямаулы җиз самавыр, ике чемодан белән алар шушы кысан бүлмәгә кайтып аудылар. Миңлеасия районның үзәк хастаханәсенә янә дә шәфкать туташы булып урнашты.

Биредә бер уңай ягы бар — райүзәктәге барлык кеше диярлек аларга таныш, ягъни танышуны өр-яңадан башлыйсы түгел.

Партия-оештыру эшләре Тимерханның барлык көчен, вакытын суырып алды. Райкомда эшләү ягыннан аның әле тәҗрибәсе бер дә юк иде шул. Аның каруы Салих Искәндәров артыгы белән тәҗрибәле. Үзенә дә, башкаларга да таләпчән. Берәүне бер кызганмый, үз вакытын да, башкаларның вакытын да тулысынча эшкә сарыф итә. Аның белән эшләве, бер яктан, гыйбрәтле: авыл хуҗалыгын ул әйбәт белә, озак еллар үз кулы белән иген иккән, икенче яктан, ул бик каты куллы, үз теләгең белән генә яшәргә ирек бирми.

Яңа эшкә керешер алдыннан Борһановны ул үз кабинетына чакырып, озаклап әңгәмә корды. Бу үзенә күрә бер инструкция иде. Тимерхан аны кәгазьгә яза барды, бу язу, әлбәттә, каралама иде, ул аны кабат күчереп, бик пөхтә итеп язды, тулы итеп, тутырып язды һәм өстәл өстендәге пыяла астына куйды. Әлеге киңәш, әлеге инструкция эшеннән киткәнче сакланачак, Тимерхан әле аны кат-кат кайтып карар, тәҗрибә туплаган саен ул аннан үзенә кирәклесен алыр, шул сөйләшүдә нихәтле мәгънә ятканын аңлар.

Искәндәров акыллы, зур шәхес иде. Күрәсең, аны РСФСР Верховный Советына депутат итеп ике мәртәбә юкка гына сайламаганнардыр. Партия эшенә барлык хирыслыгын салып эшләгән кебек, депутатлык вазифаларын да намус белән башкарды. Искәндәровны Мөслимдә генә түгел, тирә-юньдәге чиктәш район кешеләре дә яхшы беләләр, аны хөрмәт итәләр иде.

Тимерхан өчен Искәндәров үрнәк иде. Ул аның ашыкмыйча, һәр эшне җиренә җиткереп эшләү стилен үзенә күчерде. Кешеләр белән туктаусыз киңәште, районның нинди сулыш белән яшәвен белеп торды, белмәгәнне беләм димәс, лаф ормас, ялгышын яки кимчелеген таныргa оялмас, кешеләргә юк бәланы такмас, бюро утырышларында кирәклесен генә әйтер, документлар төзегәндә, эш-гамәлләргә бәя биргәндә, кеше куркытырлык җөмләләр кыстырмас иде. Ә бит ул еллар хәтергә нык сеңеп калды: боерык-фәләннәрне, эш кәгазьләрен укысаң, чәчең үрә торырлык кына түгел, йөрәгең ярылырдай җөмләләргә тап буласың. Озак еллар узгач, архив документлары белән танышкан чакта, Тимерхан исе китеп уйланып утырды. Ул күреп йөрде — җитәкчеләр арасында төрлесе бар иде: берәүләре гел дә явыз-усал, чамадан тыш аяусыз, кешеләрдән гел гаеп эзләп кенә йөри, икенчеләре кызгана белә, өченчеләре исә ваемсыз, битараф, кеше кайгысын бар дип тә белми, аның үзенеке — үзәктә, кешенеке — кештәктә. Андыйлар урыннарында озак сакланалар, үзләреннән өстәрәк утырганнарга яраша беләләр. Ә гади халык андыйларны бик тиз таный, «хәйләкәр төлке» дигән кушамат тага.

Илленче еллар башында колхоз уставын бозучыларга каршы кискен көрәш игълан ителде. Бәләкәй генә кимчелекне дә бик хәтәр күпертәләр, зурдан кубалар иде. Моны, бер уйласаң, акларга да буладыр. Халык бик фәкыйрь яшәгәнлектән, кайда ни күрә, шуны чәлдерә, колхоздан алган азык-төлеккә акча түләми, колхозныкын урлау гомумән дә урлауга саналмый башлаган иде инде.

Республикада колхоз уставын үтәүне тикшерү оешмасы төзелде. Бик хәтәр тотынды бу оешма. Райбашкармаларга җиде-сигез төрле күрсәтмә килеп төште. Райкомнарныкын әйткән дә юк инде. Күп еллар узган бит инде, әмма шул дәвернең кайбер кыйпылчыклары Тимерхан күңелендә әле дә булса саклана.

Сугыштан соң авылларга сабан туе үткәрү гадәте әйләнеп кайтты. Көрәштүдә, чабышларда, башка төр уеннарда катнашучыларга халыктан җыелган әйберләрне бирәләр иде. Чуптарлы сөлгедән дә зуррак бүләк юк та иде бугай. Ә көрәштүдә җиңеп чыккан, мәйдан тоткан батырга сөлге нәрсә ул!

Шулай Мөслимгә якын гына Катмыш дигән авылда сабан туе батыры булып районның финанс бүлеге мөдире Павел Демидов кала — керәшен егете. Нишләргә, беренче батырга нинди бүләк бирергә? Бирер әйбер юк. Картлардан төзелгән сабан туен үткәрү комиссиясе, уйлаша торгач, баш батырга фермадагы иң зур сарыкны бирергә дигән карарга килә. Авыл кешеләре барысы да «Якты юл» колхозыннан, барысы да Павел яклы, үз авылларын һич кенә дә кимсетәселәре килми. «Баш батырга нинди бүләк бирдегез?» — дигән чакта: «Киндер тастымал бирдек!» — дип торып булмый бит инде. Ичмасам, авыз тутырып: «Колхозның иң зур сарыгын сайлап бирдек!» — дисәң, әйтергә күңеллерәк ләбаса.

Мәйдан батыры Павел Демидов, тәкәне җилкәсенә салып, сабан туе мәйданын бер әйләнеп чыга да, шул күтәргән көе, өйләренә юнәлә.

Берничә көннән райкомга Демидов өстеннән шикаять керә. Имеш, Демидов, җитәкче булуыннан файдаланып, сабан туенда батыр кала, шул сәбәпле гади халыкка тиешле сугым малын эләктерә, бер гөнаһсыз ферма малын суеп ашый.

Шикаять райком бюросына куела. Бюро әлеге фактны колхоз милкенә кул сузу дип бәяли. Демидовны бик каты партия җәзасына тарту һәм эшеннән алып ташлау турындап ярсынып-ярсынып сөйлиләр. Искәндәров бюро әгъзаларын берничек тә уйлаган уйларыннан чигендерә алмый. Шул ук вакытта бюро әгъзаларына каршы япа-ялгызы гына калып та булмый бит инде. Демидовның язмышы аяусыз хәл ителә — чигенү юлы юк!

Демидов үзен аклау өчен әйтә:

— Хөрмәтле бюро членнары! Мин бит сарыкны урлап алмадым, хәләл көчем белән көрәшеп алдым. Хәзер инде гаебемне таныдым, көрәшкә керү кирәк булмаган икән миңа. Инде мин бик олы бер сарык сатып алып, фермага илтеп тапшырдым. Бәлки, шуларны искә алып, миңа булган каты җәзаны киметерсез.

Ул заманнарда ике төрле сөйләшү юк иде. Бюро әгъзалары кырт кисәләр: «Баштарак уйларга иде аны, Демидов. Астыңа су кергәч, инде үкенә башладыңмыни?»

Демидов, башын түбән иеп, бюродан чыгып китә.

Тимерхан күрде: Павелны бирәү дә кызганмады, гаделлекне табарга да тырышмады. Барысы да үзләрен эт койрыгыннан да тәзрәк дип санылар, барысы да гаделлек өчен көрәшәбез дип, күкрәк сугалар иде. Ярый әле Павелның бәхете — хатынының бер туганы кайсыдыр бер өлкәдә җитәкче эштә эшли икән. Ул, махсус самолет җибәртеп, Демидовны һәм аның гаиләсен үзләренә алдырта, эшкә урнаштыра.

Күкрәк суга-суга ярсынган бюро чаклы бюроны бер җитәкче шул рәвешле төп башына утыртты да куйды. Ярсыну шаукымына бирелгән райком бюросы финанс өлкәсен биш бармагы кебек белгән затлы бер хезмәткәреннән колак какты!

Тимерханга бу вакытта 27 яшь иде. Демидовның уттай кызарып өстәл буенда басып торганын күрде ул, кызганды егетне. Ләкин яклап сүз әйтә алмады. Әйтә дә алмас иде, ник дигәндә, ул бюро әгъзасы түгел...

## Дүртенче бүлек

Тимерханның армиядән кайтканына дүрт ел тулып килә иде инде. Солдат хезмәтендә ул җиде ел ярым булды. Аның бөтен яшьлеге сугыш чорына туры килеп, аннан соң да әле ничәмә еллар хезмәт итеп, армия сафларында узып китте.

Инде менә өйләнеп, бер баласы булгач, район хәрби комиссариаты аның кулына янә дә повестка тоттырды — аны тагын хәрби хезмәткә чакыралар. Илленче елларда хәрби хезмәттән баш тарту иң зур гаепләрдән санала, аның өчен хөкемгә тарталар иде. Шулай да Тимерхан хәрби комиссар Хәлиуллинга аңлатмакчы булды:

— Мин унҗиде яшемнән егерме бишкә тикле гади солдат булып хезмәт иттем. Белемем җитәрлек түгел. Хәрби хезмәттәге белгечлегем — эш башкаручы. Хәзер андый вазифаны гражданскийлар башкара. Мине хәрби хезмәткә кабат чакыруның нинди файдасы булыр икән?

— Иптәш Борһанов, син бит тәртипле, акыллы, уйлап кына эш итә торган кеше. Безгә элек хезмәт итеп кайткан солдатлардан офицерлар әзерләргә кирәк. Ә син нәкъ менә шуңа туры киләсең.

Тимерхан аңлады: Хәлиуллинны берни белән дә алдырып булмый. Шуңа күрә ул — гомерендә бер мәртәбә — хәйләгә кереште:

— Иптәш подполковник, — диде төче тавыш белән, — әллә сез мине законнарны белми дип уйлыйсызмы? Армия хезмәте турындагы законнар миңа, шөкер, күптән таныш. Военкомат белән мин һич кенә дә низагка керергә теләмим. Биредәге эшемнән дә арыдым инде: ни фатир юк, ни акчасы адәм рәтле түгел. Хәрби курсларга мин рәхәтләнеп барам, теләсә кайсы начальник белән, хет ул капитан, хет майор булсын, уртак тел таба алам, тик бит хикмәт минем теләктә генә түгел...

— Кемнең теләгендә соң?

— Мине бит райкомның бүлек мөдире итеп крайком билгеләде, крайком бюросы раслады. Мин бит военкомат чакыруы хакында крайком бюросына хәбәр итәргә тиеш. Сез шуңа ризамы?

Хәрби комиссар кызарып-бүртенеп урыныннан торды:

— Нәрсә, мин сине хәрби курсларга җибәрер өчен крайкомнан рөхсәт сорарга тиешме?

— Әлбәттә.

— На ..... нужен ты такой! — дип, хәрби комиссар урысчалатып бик хәтәр сүгенде.— Китер повестканы! — Кәгазьне алды, ертып, чүп савытына ыргытты.— Можешь быть свободным!

Тимерхан атна буе сөенеп йөрде — сөйләшә белеп сөйләшсәң, погонлы түрәне дә җиңеп була икән!

Тик иртәрәк сөенгән икән шул. Бер атнадан аны үз кабинетына Салих Искәндәров чакырып алды.

— Иптәш Борһанов, мин сине райком эшенә тәкъдим иткәндә, укырга җибәрергә дә булышырбыз, дигән идем. Исеңдәме?

— Бик исемдә, Салих Искәндәрович.

— Менә шулай. Әгәр райком бюросы сине партия мәктәбенә укырга тәкъдим итеп, өлкә комитеты безнең тәкъдимне хуп күрсә, син ни дияр идең?

— Рәхмәттән башка берни дә димәс идем, Салих Искәндәрович.

Бу сөйләшүне, өенә кайткач, Тимерхан хатынына җиткерде. Миңлеасия башта моңсуланды, аерылышу аның өчен ансат түгел иде бугай, ләкин үзен бик тиз кулга алып, ризалашты.

Озакламый Борһанов Тимерхан Борһанович исеменә Казаннан чакыру кәгазе килде: Республика партия мәктәбенә керү өчен ул әле имтихан тотарга тиеш икән.

1954 елның июль азаклары иде.

Армия хезмәтендә чакта урта мәктәпне тәмамлаганлыгына алган аттестатны бәләкәй чемоданга салып, Тимерхан Казанга килде. Медицина каравын узды, өлкә комитетында (ул чорда крайком бетерелгән иде инде) әңгәмәдә булды. Ниһаять, партия мәктәбенә имтиханнар тапшыру өчен тулай торакка урнашты.

Партия мәктәбенә 120 кеше алырга тиешләр икән. Ә чакырылганы — 167 кеше. Димәк, сайлап алачаклар. Тимерхан чамалады: укырга дип килүчеләр арасында белемлеләр байтак — укытучылар институты (ике еллык), партия мәктәбе (тугыз айлык), махсус урта мәктәпләр тәмамлаган җитди конкурентлар килгән. Тимерханның күңеленә шик төште: узып булырмы, әллә борынны салындырып, Миңлеасия янына кайтып егылырга калырмы?

Иң әүвәл ике йөз сүздән гыйбарәт диктант яздырдылар.

Иртәгесен аудиториягә партия мәктәбенең секретаре — Толмачева фамилияле, кырыс чырайлы, чәчен кыска итеп кистергән, урта яшьләрдәге хатын-кыз керде.

Беренче соравы:

— Борһанов кайсыгыз була?

Алгы рәттә үк утырган Борһанов торып басты, башкалар аңа төбәлделәр.

Секретарь хатын әйтте:

— Бер йөз дә алтмыш җиде кеше арасында барлык кагыйдәләрне дә җиренә җиткереп язган сез генә булдыгыз, иптәш Борһанов. «Бишле» сезгә! — Тимерханның аркасыннан кайнар ток узды.— Өч кешенеке — «дүртле», алты кешенеке — «өчле», калганнары — «икеле».

Башка фәннәрен дә Тимерхан «бишле»гә тапшырды, аны беренче көннәрдән үк партия мәктәбе кешеләре — педагоглар да, курсантлар да танып белде.

Тимерхан укуга бөтен күңелен салды. Җиде елдан артык армия хезмәтендә булу, хәрби боерыклар язу, документлар тутыру аның урысчасын бик тә бөтәйткән иде, урысчаны ул урысны сатып җибәрерлек дәрәҗәдә белә иде. Әмма шушы «урысчалык» аны беренче көннәрдән шөбһәгә дә салды. Партия мәктәбенә керүчеләр арасында кайбер районнардан мәгариф бүлеге мөдирләре дә килгән иде. Ике йөз сүзле диктант-

та алар илледән артык хата җибәргәннәр, азактан аларның кайберләрен урыннарыннан да алганнар.

«Ә ни өчен партия мәктәбенә кергән чакта татарлардан урысча диктант яздыралар? Татарча яздырсалар булмыймыни? — дип фикер йөртте Тимерхан, әмма шундук үз фикерләренә үзе каршы килде.— Районнардагы мәгариф бүлекләрендә бит барлык фәрманнар урысча языла, боерыклар урыс телендә бәян ителә, киңәшмәләр, бигрәк тә яңа уку елы алдыннан булган август киңәшмәләре урыс телендә алып барыла. Димәк, мәгариф бүлеге мөдире урысча белергә, грамоталы итеп сөйләргә һәм язарга тиеш. Ә ни өчен ул, тоташ татар ягы булган районда эшләүче мөдир урысча сөйләргә, урысча язарга тиеш? Аның үз туган теле юкмыни?»

Озын сүзнең кыскасы, Тимерхан бу урында буталып бетте, үзе куйган сорауларга тиз генә җавап таба алмады. Партия мәктәбе укучылары арасында йөргән бер имеш-мимеш аны бөтенләй дә чыгырдан чыгарып ташлады. Имеш, Татарстандагы педагогия училищеларында дәүләт имтиханы алганда, иң беренче имтихан урысча инша язу икән. Шул иншаны «өчле»гә яза алмасаң, син инде башка имтиханнарга кертелмисең, училище бетергәнгә аттестат ала алмыйсың, сиңа педучилищеда укуың хакында уч төбе чаклы белешмә генә биреп чыгаралар.

Сталин заманында булса, әйтер сүзең юк, авызың йозаклы. Тавыш чыгарып кара, тимер рәшәткә арасына кереп кенә утырырсың, инде бит ул вафат, бөтен ил аһлар орып, кайнар күз яше түкте дә, озак та тормый аның сакчы-палачын — Берияне аткач, Хрущев властьны үз кулына алды. Сталин үлгәч, инде нишләрбез, кемгә сыенырбыз, дип бер курыкканнар иде, егерменче партсъездда шәхес культын җимереп ташлагач, тагын бер курыктылар, ил берничә ай өнсез калып торды, аннары, язгы җылынулар башланды, тымызык яңгырлар сибәләп торды, туң боз эри башлады. Ниһаять, бөек ил, буржуйларга өстән генә карый торган ил, башкалардан үзен тимер пәрдә белән аерып куйган ил, аны-моны аңламыйча, гаҗизлектән интегә башлады. Хрущев язучыларны Кремльгәме, үзенең дачасынамы чакырды, ул аларга әйткән, имеш: «Будете шубаршить — сажать буду!»

Хрущев совнархозлар уйлап чыгарды, ил буйлап сәяхәткә чыкты. Хрущев Татарстанны, Башкортстанны, Куйбышевны бергә кушып, бер өлкә итеп калдырырга теләде. Калдырасы да икән, ике республиканың һәм Куйбышев өлкәсенең кыскартылган исемнәрен ялгагач, нииндер кötелмәгән оятсыз сүз килеп чыга икән, шуңа гына кушмый калдырган, имеш...

Ни булса булды, дөньяларның кай яккадыр үзгәрешен тоя Тимерхан. Мәктәпнең ике курсын тәмамлагач, Республика партия мәктәбе өч еллыктан дүрт еллыкка әйләнде. Исеме дә яңача яңгырый башлады: Казан Югары партия мәктәбе. Республика мәктәбен Казан мәктәбе итеп кенә тарайту күңелдә шатлык тойгылары уятмый иде, әлбәттә. Әмма... Югары партия мәктәбе дигәне ярап куйды. Димәк, Тимерхан хәзер югары белемле булачак. Программа да киңәйтелде: промышленность һәм авыл хуҗалыгы экономикасы, производство технологиясе, математика, статистика, хокук, төзелеш, сәүдә һәм финанс, бухгалтерия, механикалаштыру, электрлаштыру кебек конкрет фәннәр укытыла башлады.

Тимерхан Миңлеасиясенә хат язып тора. Лекцияләрне аларга Казанның атаклы укымышлылары сөйләгәнен, практик дәресләрнең шәһәр предприятиеләрендә яки лаборатория шартларында алып барылганлыгын хәбәр итә. Асия дә үз нәүбәтендә җавапсыз калмый. Ул әле һаман Мөслим хастаханәсендә эшли икән, озакламый икенче баласын — бу юлы һичшиксез кыз! — алып кайтып, Тимерханны сөендерәчәк икән. Уллары Хафиз бик тере, көйсезләнүне белми, тамагына ашый, шаян, кычкырып көлә, кычкырып җылый, кыскасы — дөнья түгәрәк, тик менә күңел-күбәләк кенә, Тимерхан дигән, Борһанов дигән «җилле җегетне» сагынып яши, ул сагынулар кайчанга тикле сузылыр, әйтүе кыен...

Ниһаять, бер көнне, февраль бураннары Казан урамнарын өермәләргә күмеп, дулый-дулый шашынган чакта, Асиядән телеграмма килеп төшә: әнис алма төсле чибәр кызлары туган!

Башка берәү булса, Казан урамнарын бетереп кычкырып йөрер иде, көтеп алган кадерле кызының тәпиен юарга дип, шешәләр әзерләр иде. Төптән уйлап эш итә торган Борһанов, урамнарга да чыкмый, шешәләр дә алмый, мыегына урап куя: әһә, әнис алма төсле кызыбыз, дигәнме? Бу бит — табыш, димәк, кызыбызның исеме Әнисә булыр: Әнисәм минем, Әнисәм...

Матур исем, ягымлы исем, бозып булмый торган исем! Тимерхан хатынын котлап, сәгате-минуты белән Мөслимгә телеграмм суга.

Аннары ул ике-өч көн үкенеп, уфтанып йөри. «Тиздән кайтырмын» дип әйтәсе булган, «сагындым» дип өстисе, тагын нindидер матур сүзләр әйтәсе калган. Тик инде телеграмм киткән, иясенә барып ирешкән, үкенүләрдән файда юк, хилафлык кемдә юк та, кайда юк! — ул тиз генә кайта да алмый, көннәр үтә, төннәр үтә, имтиханнар башлана — гомерләр уза бара, уза бара... Кышны яз, язны җәй, җәйне көз алмаштыра — ул чакларда барысы баш әйләнгеч тизлек белән эшләнә кебек иде. «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында практика узасы бар, Чистайның «Васелки» дигән авылында булып, «Чапаев» колхозының эшчәнлеге турында реферат язасы бар. Каләм сабын кимереп, азапланып язган хезмәтең өчен ут йотып йөрисе бар, азактан — әлеге рефератның үрнәк-өлге итеп студентлар күргәзмәсенә куелуын күргәч, шыпырт кына, тыйнак кына сөенәселәр бар. «Бар» нәрсә күп, «юк» нәрсә аннан да күбрәк. Кайчагында Тимерханыбыз Асия җанкисәгенә айлар буе хат язалмый,— моны «юк» графасына кертәбез, елына бер мәртәбә уку елының яртысында ун-унбиш көнлек ял бирелә, анда кайта алмаган чаклары да була — җәмәгать эшеннән баш тарта алмаган курсантка эш муеннан! Димәк, монысын да «юк»! графасына язабыз. Малае туганга җиде ел, кызы туганга өч ел, йә, ничә мәртәбә күрде ул аларны? Ничә мәртәбә кулына күтәреп, багалмаларын күкрәгенә кысты? «Шул да булдымы әти?» — ди торгандыр инде Миңлеасиясе. Ул хаклы, чамадан тыш хаклы, гаделлек аның ягында!

1958 елның апреле иде. Менә-менә дәүләт имтиханнары башланырга тора. Ничаклы гына тырыш булса да, дәүләт имтиханнарына башы-аягы белән күмелеп, көне-төне әзерләнсә дә, ул гел дә куркыбрак тора, җимерелеп төшмәгәем, кеше-кара алдында хур булмагаем, дип шикләнә иде.

Әнә шул борчулы-мәшәкатьле көннәрнең берсендә аны партия өлкә комитетына чакырып алдылар.

Кул кисәге хәтле генә имзасыз хат тоттырдылар.

**«Хөрмәтле өлкә комитеты!**

**Казан югары мәктәбенең дүртенче курсында Мөслим районы кешесе Борһанов Тимерхан укый. Аның әтисе Борһан исемле кеше Вәрәшбаш дигән авылда муллалык хезмәтен башкара. Сез безгә түбәндәге сорауга конкрет җавап бирегез: «Бер үк семьяда атасы мулла, малае партия пропагандисты була аламы? Капма-каршы ике идеология бер өйдә сыеша аламы?»**

**Тиз арада җавап бирүегезне көтәбез.**
**Җавап бирмәсәгез, Үзәк Комитетка язарбыз».**

Тимерхан агарынды.

Башына бер потлы гер белән китереп органдай булды!

Ләкин аңа югалып калырга ярамый иде. Тимерхан булган хәлне төп-төгәл сөйләп бирде:

— Сугыш елларында, авылда үлем-китем булганда яки балаларга исем кушканда, халыкның еллар буе сакланып килгән йолаларын башкаручы кирәк була. Авыл Советы председателе Вәлиев, җыелышта халыктан кул күтәртеп, әлеге эшкә минем әтине куйдырта. Бу хакта, кызыксынсагыз, беркетмә бар. Беркетмә язуында минем әти, ягъни Борһан,

авылның санитары дип күрсәтелә. «Борһан абзый гозере төшкән кешегә бара, авыл йолаларын риясыз башкара, моның өчен хәер алмый»,— дип авыл Советы башлыгының тәкъдименә кушыла. Минем этинең «Ярар Борһан» дигән кушаматы бар. Теләсә нинди гозердән баш тартмаганы өчен аны «Ярар Борһан» дип йөртәләр. Булганы менә шул, әти халык гозеренә каршы килми, халык йолаларын үти, әмма үзенең бер генә көн дә колхоз эшеннән калганы юк. Бу хәл минем үземне дә борчып килде. Заманалар бозылды, хәер, ул Сталин заманнарыннан ук бозылган иде инде, без бит кешеләрне бер-берсен чагарга өйрәттек. Булганны да, булмаганны да язарга! Әти — ярлы кеше баласы, чыгышы ягыннан сүз тидерерлек булмагач, мин боларга артык әһәмият бирми идем. Аннары бит аның указлы мулла булганы юк. Миңа үзебезнең районда да, авылларда да этинең кылган гамәлләрен ярамаган эш дип әйтмәделәр, әтием турында ни телдән, ни язмача кисәтү ясамадылар. Инде менә мин Югары партия мәктәбендә укыгач, үзебезнең районга кайтып, бүлек мөдире булып райкомда утырырга санаулы гына көннәр калгач, кемдер мине искә алган, җәмәгатьчелеккә, ялгышын төзәттерү өчен, «ярдәм итәргә булган».

Өлкә комитетында бүтән төпченмәделәр.

— Хатның язылу мотивы, болай булгач, безгә мәгълүм,— диделәр.— Бездә Мөслим райкомының хаты бар: сезне укып бетергәч, үзләренә кайтаруны сорыйлар. Райкомнан заявка да килде, шул ук көннәрдә анонимка да килеп җитте.

Тимерханның Миңлеасиядән берни дә яшергәне юк иде. Булган хәлне ул аңа җиткерде.

— Сиңа борчылырлык сәбәп юк. Имтиханнарыңа әзерлән, укуыңны тәмамла, юк-барны уйлап, башыңны катырма. Әгәр сиңа райкомыңда эш бирмиләр икән, өйдә бала карап утырырсың, ә мин хастаханәдә ике ставкага эшләрмен — көндезге смена гына түгел, төнге смена да бар бит әле. Без — нәфселе кешеләр түгел, ничек тә очын-очка ялгап барырбыз.

Миңлеасиянең сүзләре ышандыргыч, иң акыллы кешеләр әйткәнгә караганда да кадерлерәк иде.

1958 елның 1 июлендә Казанның Югары партия мәктәбе беренче чыгарылышын тәмамлады. Дүрт еллык авыр хезмәт, чамасыз тырышлык артта калды.

Чыгарылыш кичәсенә Семен Денисович Игнатьев үзе килде — өлкә комитетының беренче секретаре. Партия мәктәбен тәмамлаучыларның аны беренче мәртәбә күрүләре иде. Секретарь үзе дә, чыгышы да ошады. Беренчедән, ул — дөньяның барлык өлкәләрен күргән кеше, үзен, югарыдагы түрәләр кебек, һавалы тотмый, чыраенда да аның нәфис-зыялылык юк, ул менә хәзер генә колхоз тарантасыннан төшкән рәис төсле, кискен-кискен сүзләр әйтеп, дорфарак сөйләшә, сорауларга, уйлап-нитеп тормастан, туп-туры җавап бирә иде.

— Сезгә күңелне тырнап торган бер сорауны бирим әле, Семен Денисович,— диде арткы рәтләрдән аксыл чырайлы ябык бер адәм. Тимерхан аны белми, ул, мөгаен, гәзит хәбәрчеләреннән берсеедер.— Менә бу Югары партия мәктәбен тәмамлаучылар авылларга, районнарга, ягъни халык арасына эшкә китәләр бит инде. Аларга анда милли мәсьәлә белән дә очрашырга туры килер. Һәр милләтнең үз йөзе булырга тиешме-юкмы?

— Тиеш,— диде Игнатьев бер сүз белән генә.

Сорау бирүче җаваптан канәгать калмады булса кирәк, ул янә сүзен дәвам иттерде.

— Әйтегез әле, пожалысты, Семен Денисович, ник соң алай булгач, район гәзитләре татар телендә дубляж булып чыга? Казанда чыга торган урыс гәзите белән татар гәзитен берләштерделәр...

Игнатьев аз гына пауза ясап торды. Җавап бирү аңа уңайсызмы, әллә ул җавап бирергә теләмиме?

— Беләсезме, туганнар, мин Бурят-Монголиядә эшләдем, миннән монгол милләтчесе ясарга тырыштылар. Башкириядә эшләдем, миннән башкорт милләтчесе ясамакчы булдылар. Ышанырга рөхсәт итегез, сез миннән татар милләтчесе ясамассыздыр шәт?

Аксыл чырайлы интеллигентка инде төрле яктан ысылдап карасалар да, ул сорау бирүен туктатмады.

— Соңгы соравым, Семен Денисович. Университетта нигә татарлар аз? Моңа керү шартлары гаепләме, әллә хөкүмәтнең сәясәте шундыймы?

— Әйе,— дип бу сорауга пауза-мазар ясап тормыйча җавап бирде Игнатьев.— Мин белештем, Казан дәүләт университетында татарлар азрак. Ләкин бит Советлар Союзында бер Казан университеты гына түгел, башка вузлар да бар. Әгәр без, Казан университетында татарлар аз дигән сылтау белән, урысларны, башка милләт вәкилләрен куа башласак, яки кабул итү имтиханнарында башка милләтләр керүен тыйсак, илнең башка вузларында укучы татарларны да куып кайтармаслармы? Куярга мөмкинме сорауны шул рәвештә? Мөмкин. Чит илләрдә эшләргә теләүче дипломатларны укыта торган институт Казанда юк. Ә Ленинград белән Мәскәүдә генә бар. Укыйлармы анда татарлар? Укыйлар. Без башкаларны Казаннан кусак, ленинградлылар татарларны үзләреннән кусалар, без бер генә дипломат та җитештерә алмыйбыз булып чыга ич. Казан университетында татарлар азрак дигән сүзне мин йомып калдырырга теләмим. Чыннан да — азрак. Һәрхәлдә, без теләгәннән азрак. Казанда 13 югары уку йорты, 18 техникум бар. Казан инде ничә гасыр медиклар мәктәбе, химиклар мәктәбе белән дан тота. Дөньякүләм ачышлар геометриядән, химиядән Казанда ясалды. Безгә татар яшьләрен, әлбәттә, үз вузларыбызга күбрәк алырга кирәк. Бу мәсьәлә — көн тәртибендә. Тик мәсьәләнең икенче ягын да онытмавыгызны сорар идем. Мин Башкириядә эшләгәндә, Уфа вузларына башкортларны күбрәк алуны күтәрделәр. Башкорт далаларыннан без вузларга ысланган (бу сүзне ул урысча «копченый» дип әйтте) башкортларны куып китердек. Алар бер атнадан үз далаларына, үз тауларына китеп бардылар. Менә сез, сорау бирүче иптәш, матбугатта эшләүче булсагыз кирәк — бар нәрсәдән хәбәрдар булуыгыз әйтеп тора. Матбугатчылар, Югары партия мәктәбен тәмамлаучылар, сезнең барыгызга да мөрәҗәгать итеп әйтәм, гел, берөзлексез, яшьләрне колхозда калырга өндисез. Алай ярамый бит. Берәү җырчы булырга тели икән, китсен җырчылыкка — аңа ак юл! Очучы булырга, язучы булырга, рәссам булырга тели икән, рәхим итсен. Авылда калсын — авылны яратучылар, болын тугайларыннан, урман-сулардан башка яши алмаучылар. Мин хаклымы?

Зал аның уй-фикер сөрешенә бирелгән иде инде, барысы да дәррәү төстә:

— Хаклы! — дип кычкырдылар.

Шул мәлне алгы рәттә үк утырган, үзе карсак, үзе юантык бер абзый, кул күтәреп-нитеп тә тормастан, пылт итеп өскә калыкты. Аны күрү белән зал тын калды. Аның исемен берәү дә белми, дүрт ел уку дәверендә ул Тимерхан өчен «Калкавыч» дигән кушаматы һәм берәүнең дә башына килмәгән сораулар бирүе белән генә истә торып калды.

Бу юлы да ул сорауның көтелмәгәнен бирде:

— Семен Денисович, сезне Казан халкы, түрәләр өчен махсус ясалган мунчаларга йөрми, халык белән бергә гомуми мунчага йөри икән, дип сөйли. Шул сүз дөресме?

Зал шаулап көлде.

Игнатьев халыкның көлеп бетергәнен сабыр гына көтеп алды да ничектер юашланыбрак киткән тавыш белән сорады:

— Ә нигә көләсез? Сорау бик шәп һәм урынлы. Хикмәт менә нәрсәдә, иптәшләр: әгәр берәр шәһәргә барып чыксагыз, иң элек зиратына барыгыз, ул инде халыкның бирередә тәртипләме-түгелме икәнен әйтә дә тора. Аннары базарын карагыз: халыкның тырышмы-юкмы икәнен шун-

да күрерсез. Муллык бар икән, димәк, тырыш. Ә мунча мәсьәләсенә килгәндә, мин аерым бүлмәдә, бассейннары булган, финский сауналары куәтле пар бөркеп торган мунчаларда кемнәрдәндер үземне чаптырырга да, массаж ясатырга да яратмыйм. Мунча миңа халык белән бергә булсын. Мин анда шаян сүз ишетәм, тозлы-борычлы сүзләргә колак салам. Ә иң мөһиме — гомуми мунчада мин, кешеләрнең ялангач гәүдәсенә карап, халыкның ачмы-тукмы икәнен чамалый алам...

## Бишенче бүлек

Тимерханга эшкә билгеләнер алдыннан тагын Харитонов кабинетында булырга туры килде. Аноним хатны укыган чакта ук сабыр табигатьле бу кешегә игътибар итәргә өлгергән иде инде ул. «Йөзендә моның иман нуры бар, шикаять кәгазенә карап, сине алдан ук гаеплегә чыгармый, хөкем итеп куймый, димәк, ул гадел кеше»,— дип уйлаган иде.

Икенче очрашканнан соң, Борһановның ул чактагы фикере тагын да ныгый төште.

Харитонов бу юлы да әңгәмәне җай гына башлады:

— Теге чакта сезнең өстән язылган анонимканы без Мөслимгә җибәреп тикшерттек. Сез сөйләгәннәр дөрескә чыкты. Әтиегез мулла түгел, авылның сүз тыңлаучан бер карты гына икән. Аны миһербанлы бәндә дип бәяләү дөресрәк булыр. Без монда шулай килештек: аноним хат язган бәндәнең кулы җитмәслек булсын, сезне обкомга инструктор итеп алабыз. Минем кул астында эшләрсез. Хезмәт күрсәтү өчен биш район бирәбез сезгә. Көзгә табарак фатир ягын да җайларбыз дип өметләнәм, семьягызны да күчерербез.

Борһанов партоешмалар белән эш алып барырга тиеш булып чыга. Биш районда. Кадрларга аеруча игътибар итәсе, өлкә комитет белән райкомнарны бәйлисе, алар хакында мәгълүмат туплыйсы, тагын нәрсәләр, тагын нәрсәләр... Мондый чакта обком белән райкомнар арасында югалып калуың да бик мөмкин. Моны яхшы аңлый иде Тимерхан. Райкомда да бит шул ук эштә эшләде ул, азмы-күпме тәҗрибәсе дә бар иде. Әмма өлкә комитеты район комитеты түгел, үзең шунда туып-үскән, кешеләре белән өзлексез күрешеп-танышып, эч серләреңне бушатып яшәгән Мөслим түгел дә түгел.

Дүрт ай эчендә ул дүрт районны йөреп-өйрәнеп чыкты. Бишенчесенә барырга торганда, әтисенең үлем хәлендә булуы турында хатыныннан телеграмм алды. Әтисе, бичара, Тимерханны көтеп ятадыр инде, улын күреп, бәхилләшеп үләсе киләдер...

Бүлек мөдире Харитоновка керде.

Рөхсәт сорады.

— Иптәш Борһанов, Мөслимгә командировка яздыр. Райкомга, Хөсәенов янына кереп, эшләре белән дә кызыксынып чыгарсың,— диде Харитонов.— Мөслимдә яңа секретарь икәнен беләә идеңме әле?

— Беләм, Миңлеасия язган иде.

— Бик яхшы. Хөсәеновка миннән сәлам әйт. Кайткач, хәлләрне сөйләрсең, хәерле юл сиңа!

Тимерхан Вәрәшбашка юл тотты.

Ул кайтып кергәндә, өйдә кеше күплектән, басып торыр урын да юк иде. Аны әтисе янына уздырып җибәрделәр. Миңлеасия әтисе кырында, карават буенда басып тора, кайнатасына кашык белән су каптыра иде.

Тимерхан, кинәт күңеле тулып китеп:

— Әти, менә мин дә кайтып җиттем,— диде.

Ул арада Миңлеасия әтисенең авызына Тимерхан алып кайткан йөзем җимешен салды, әтисе, җимеш тәмен сизгәндәй, иреннәре һәм күзе белән ишарә ясап, ым кагып куйгандай булды.

Борһан карт улына күзләрен текәде, тик ул күзләрнең нуры сүнеп бара иде шул инде. Сүзен әйтерлек түгел иде карт. Тик шулай да ул Тимерханга: «Улым, мин синең кайтканыңны аңлап, күреп ятам, сүземне генә әйтә алмыйм»,— диядер кебек тоелды.

Миңлеасиянең кешеләр җан биргәнне күп мәртәбәләр күргәне бар иде. Ул, кайнатасының башы кыегаеп китүдән, аның җан биргәнен аңлады — үксеп җылап җибәрде. Тимерхан үзе дә бу минутларда күз яшьләрен чак кына тыеп тора иде.

Татар халкында мәетне үлгән көнне яисә икенче көнне үк җирләргә тырышалар. Озакка сузмыйлар. Өлгермибез дип куркасы юк — бөтен авыл булыша. Хәер, моның ул хәтле мәшәкате дә юк — мөселманнар мәрхүмне табутсыз күмәләр. Үзләре теләп юучылары да, кәфен кисүчеләре дә табылды, егермеләп егет шундук әйттеләр, каберне, Тимерхан абый, үзебез казыйбыз, хәзер кыш көне түгел, җирдә туң юк, без аны, алмаш-тилмәш, бер сәгатьтә казып бетерәбез, диделәр.

Кабер урынын билгеләгәндә, зиратта халык күп иде инде. Авылның яшьләре иде болар. Аларның беришесен Тимерхан күреп тә таный, укып йөргән чорында, җәйләрен авылга кайтканда, ул әтисен күрми китми, авыл яшьләре белән дә сөйләшеп алырга өлгерә иде.

Кабернең беренче көрәк балчыгын алганнан соң, кабер эргәсендә чират хасил булды. Егетләр барысы да кабер казуда катнашырга телиләр икән. Бераз казыгач, андагы егетләрне кулларыннан тартып чыгардылар, башкалары төште.

Борһан бабайның җәсәден зиратка тикле егетләр күтәреп алып килде. Күмү өлешен авылдагы шундый эшләрнең тәртибен яхшы белүче Салах абзый алып барды. (Укучыларга мәгълүм булсын: мәшһүр бораулау остасы, Минзәлә каласында яшәүче Мөҗәһит Әгъләмов — Салах абзыйның улы. Г. А.). Яшьләрнең Борһан бабайга ихтирамнары шуңа — ул аларның барысына да исем кушкан, өйләнгәннәренә никах укыган. Ә Салах абзый белән Борһан бабай ахирәт дуслар иде.

Салах абзый әйтте:

— Кабергә төшергәндә, Тимерхан энем, әтиеңнең баш очына син басарсың, йоласы шундый, син аның улы, аяк очына мин басармын, чөнки мин аның ахирәт дусты, уртасына күршеләрегездән берәрсе төшәр, «күрше хакы — алла хакы»,— ди халык.

Тимерхан әтисен соңгы юлга озату мәшәкатьләренә күмелгәнлектән, аның күңеле инде тәмам ныгып җиткән, ул аек акыл, саф баш белән уй-фикер йөртә иде, әтисенең кәфенгә төрелгән гәүдәсен җир куенына тапшырганда, ләхеткә куйган чакта, кинәт күңеле тетрәнде, җаны иңрәп китте: аңа бит әле җитмеш өч кенә яшь иде, аны инде Вәрәшбашлар күптән бабай дип йөриләр, аны ихтирам итеп күпме кеше соңгы юлга озатырга килгән, күпме егет аны зиратка чаклы күтәрешеп килде, күпме егет каберен казыды, киләчәктә безгә дә шундый ихтирам белән якты дөньядан китәргә насыйп булыр микән?..

Әтисен күмгәннән соң, Тимерхан төне буе йоклый алмады. Миңлеасиясен дә сагынган, балаларын да күрәсе килә, Харитонов әйткәннәрне дә җиренә җиткерергә кирәк иде. Тик ул Мөслимдә яңа секретарь Хөсәеновны күрә алмады, элекке танышлары, кордашлары белән күреп сөйләшкәннән соң, саубуллашып, Казанга китеп барды. Аның колак төбендә Миңлеасиясе әйткән сүзләр чыңлап тора иде әле: «Тимерхан, азапланма Казанда, кайт үзебезнең Мөслимебезгә, мин дә гел ялгызым, балалар да әтисез кебек, ятим үсәләр, адәм баласы бит якты дөньяга гомерлеккә килми, калган гомеребезне аерым-аерым түгел, бергәләп үткәрсәк иде». Бергәләп үткәрәсе иде, бергәләп!

Тимерхан әле әтисе үлгәнче үк, Мөслимгә кайтаруларын сорап, Харитоновка үтенеч белән мөрәҗәгать иткән иде. Бүлек мөдире гел суза килде.

— Без сине башка урынга җибәрербез — шәһәрле районга, ныклап эшкә өйрәнерсең, син бит перспективалы егет,— дип, аның үтенечен канәгатьләндермәде.
Ноябрь башларында Тимерхан, кат-кат уйлагач, өлкә комитетының икенче секретаре Салих Батыевка керде. Кулындагы гаризасын Салих Гыйлемханович алдына китереп салды.
Башкорт ягыннан килгән куе чәчле, кара күзле, чибәр кара татар исә кемнең нинди йомыш белән кергәнен бер күз сирпеп алуда белер дәрәҗәдә тәҗрибәле иде.
Батыев гаризага күз генә ташлады, шундук бүлек мөдире урынбасары Кузинны чакырды (бу вакытта Харитонов санаторийда иде).
— Менә сезгә Борһановның авылга җибәрүне сорап язган гаризасы. Хәзер үк, бер минут кичекми, хәл итегез. Һәртөрле формаль яклары бүген үк беткән булсын. Мин иптәш Борһановның кыю адымын яклыйм,— диде Тимерханга карамыйча гына.
Кузин бүлекне эшлексез итеп күрсәтәсе килмәдеме, Батыевка берничә сүз әйтүне кирәк тапты:
— Салих Гыйлемханович,— диде,— иптәш Борһанов безнең беренчеләр рәтендә резервта тора, бу инде расланган. Семен Денисович белә аны. Иптәш Харитонов, үзем кайткач, хәл итәрбез, дигән иде.
Батыев кинәт кызып китте:
— Карале, Кузин, бот кысып кына кайбер нәрсә тараймый. Энтузиастларны якларга өйрәник. Арадан берәрегезне авыл районына димли башласаң, каравыл кычкырасыз. Сезне бит Казанга терәлеп үк торган Югары Осланга җибәреп булмый, ә монда аңлы коммунист үзе сорап тора авылга! Хәзер үк, кабат әйтәм, бүген үк тиешле документлар әзер булсын, иптәш Борһановны эштән азат итегез.
Кузин икенче секретарь кабинетыннан Борһанов белән бергә чыкты. Санаторийда ял итүче Харитоновның телефонын алып, хәлне аңлатты. Тегеннән кире җавап бирделәр бугай, Кузин, кулларын җәеп җибәреп:
— Берни эшләр хәл юк. Сезгә, иптәш Борһанов, бераз сабыр итәргә кала,— диде.
Сабыр канатларының сынган чагы да була. Тимерханның үз туган районында, хатыны һәм балалары янында яшәргә теләге ни кадәрле көчле булмасын, сабыр итеп, Харитоновны көтеп алудан башка чарасы калмады. Тәртип каты — кая барасың. Партия өлкә комитетында оештыру бүлеге кайвакыт үзен секретарьларга буйсынмас дәрәҗәдә мөстәкыйль тота, чөнки кадрларның хәлен алардан да күбрәк белүче юк иде.
Әйе, Харитоновны көтеп алырга булды Тимерхан. Көтеп алырга... Бу хәл уйланырга мәҗбүр итте: туктале, ул соң Харитоновны узып йөри түгелме? Ике мәртәбә ул аның янында булды, ике мәртәбәсендә дә Харитонов аңа якты күз белән карады, аны яклады, шулай булгач...
Шулай булгач... бигрәкләр дә яшисе килми шул гаиләдән аерым. Харитонов — яхшы күңелле кеше, аңлар, аңламый калмас.
Харитонов аны, башка чактагы кебек, бигүк якты йөз белән каршы алмады. Озынча битендәге күләгәгә караганда, ул Борһановка үпкәләгән сыман иде. Шуңа күрә Тимерхан башлап сүз кузгатмады, Харитонов чакыруына буйсынып, аның кабинетына керде, ул ни әйтсә дә, шыпырт кына тыңларга булды.
— Иптәш Борһанов, дөресен әйтим, син минем күңелгә ятышлы кеше. Акыл иясе. Бәлки, шуңа күрәдер, мин сине шәһәр районына, бик тә тәҗрибәле кеше янына җибәрүне күздә тота идем. Инде эшләр болайга киткәч, эшне син Салих Гыйлемханович аркылы хәл кылырга уйлагач, тотмыйм. Сине җибәрергә, дөресрәге — тәкъдим итәргә уйлаган шәһәрнең исемен дә әйтеп тормыйм. Мөслимгә дисеңме? Ярар, Мөслимгә булсын, алга таба тагын күз күрер,— диде Харитонов.
Ул Мөслимгә кайтты — документы «Мөслим райкомы карамагына» дип язылган иде. Тимерханның күңеле бик күтәренке, ниһаять, ул гаиләсе

янына кайта, Мөслимдә аны хатыны Миңлеасия, улы Хафиз, нәни кызы Әнисә сагынып көтәләр иде.

Борһанов гаиләсе белән күрешкәннең икенче көнендә үк райкомга барды. Учетка керергә кирәк иде. Аның райком карамагына җибәрелүен, бәлки, өлкә комитетыннан беренче секретарьга хәбәр дә иткәннәрдер инде, әмма башкалар берни дә белми, таныш-белешләре аны югары мәктәптә укуын тәмамлавы, обкомда эшкә калдырулары белән генә котлыйлар иде.

Райкомның яңа секретаре Хөсәенов аны ул көнне кабул итмәде. Оештыру бүлегендә аңа өенә кайтып торырга куштылар.

«Тагын нәрсә уйлап чыгардылар икән? Әллә Харитоновка буйсынмаган өчен мине төнәтергә уйлыйлар микән?» — дип фикер йөртте Борһанов. Борчыла башлады. Борчылуы урынлы — берничә көннән Мөслимдә партконференция булачак, беренче секретарь аны кабул итәргә дә теләми, нүжәли ул корабтан ыргытылып калыр икән?

Мөслимгә, партконференция эшендә катнашу өчен, Волков килеп төште. Тимерхан аны якыннан белмәсә дә, хезмәт вазифасы буенча белә: Куприян Кузьмич — Татарстанның ашлык әзерләүләр идарәсе начальнигы, обком члены иде.

Иртәгә партконференция буласы көнне Борһановны беренче секретарь Хөсәенов янына чакырдылар. Мәгъсүм Шәйгазамович Хөсәенов — яңа кеше иде Тимерхан өчен. Бер мәртәбә дә күреп сөйләшмәгән кеше иде. Кабинет ишеген шакып килеп кергәч, Тимерхан анда бер кеше генә түгел, ике җитәкченең берьюлы утырганын күрде — Хөсәенов өстәле янында Волков та утыра иде. Казанда Волковны өлкә комитетында күргәләгән булганга, ул аны тазалыгыннан шундук таныды, ә ач яңаклы, ияк урыннары күгелҗемләнебрәк торган кара кешегә күз салып, Хөсәенов шул буладыр инде, дип исәп тотты.

Җитәкчеләрнең икесе дә аны өстәл янына килергә чакырдылар, урыннарыннан тормый гына, баш кагып исәнләштеләр, урындык тәкъдим иттеләр.

Волков беренче булып сүз башлады. Тимерхан аның үз эшендә тәҗрибәсе булган, шактый ук әрсез, кырыс, сәеррәк (үзенә артык ышанучан) кеше итеп бәяләде.

— Борһанов, белмәсәң белеп тор, мине Мөслимгә обком җибәрде: сине икенче секретарь итеп сайлатырга. Син моңа ничек карыйсың? — диде Волков.

— Югарыдан яхшырак күренә. Конференция ни әйтер бит әле. Бәлки, анда мине сайларга теләмәсләр...— диде Тимерхан.

— Сайлатырбыз! — диде Волков һәм, эшне беткәнгә санап, урыныннан кузгалды.

Тимерхан беренче секретарь кабинетында үзе генә торып калды. Хөсәенов үзе саубуллашмагач, ул китәргә ашыкмады, аның әле сөйләшәсе сүзе бар иде.

— Мәгъсүм Шәйгазамович, әгәр сезгә «Мәгъсүм абый» дип кенә дәшсәм, ачуланмыйсызмы? Сез миннән өлкәнрәк тә, аннары безнең татарлар арасында әтисенең исеме белән дәшү гадәте юк бит...

Хөсәенов, күренеп тора, гап-гади кеше, Волков кебек үзен әллә кем санаучы түгел икән.

— Без болай сөйләшик, Тимерхан, халык алдында бер-беребезгә йә «иптәш» дип дәшик, йә отчество белән авыз тутырып әйтик. Аңардан безнең укабыз коелмас. Үзара сөйләшкән чагында «абый-энем» булырбыз.

— Әйтегез әле, Мәгъсүм абый, Искәндәров үзе киттеме, әллә аны урыныннан алдыларммы?

— Искәндәров — акыллы һәм җайлы кеше. Сез минем белән килешәсезме?

— Һичшиксез.

— Менә шул, алайса. Аны районда да, өлкәдә дә яраталар, ихтирам итәләр иде. Ул үзе китте. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, пенсиягә чыкты. Гариза язып. Шулай да ул эшсез торырга күнекмәгән, Киров исемендәге колхозда парторг булып эшли. Ул инде район чаклы районны тарту түгел, бер генә колхозны тарту дигән сүз. Аңлыйсыңдыр?

— Аңлыйм. Үзем дә бит укырга киткәнче, «Мөслим» совхозында парторг булып эшләп карадым. Ул эш тә җиңел түгел.

— Әлбәттә. Ләкин ул инде район түгел.

Ул хактагы сүз озаккарак киткәнен, Хөсәеновның борчыла башлаганын күреп, Тимерхан сүзне туктатты. Юкса бу — Искәндәровны мактау, Хөсәеновны санга сукмау булыр иде.

— Мәгъсүм абый, әйтегез әле, конференциядә «чепе»ләр чыкмас микән?

— Ягъни?

— Оешкан төркемнәр юкмы?

— Юктыр дип беләм. Мөслимдә халык тәртипле бит. Җилгә каршы төкереп маташмас. Ә син үзеңне икенче итеп сайлауларына ничек карыйсың?

— Мөслимгә кайтаруны үзем сорадым бит. Халык әйтмешли, үзең тапкан карта, аша тарта-тарта.— Тимерхан көлеп җибәрде дә шып туктады.— Мин бит андый югары урын көтмәгән идем...

Конференция, нигездә, гаугасыз узды. Хөсәеновны беренче, Борһановны икенче, Әхмәтшинны өченче секретарь итеп сайладылар.

Алгарак узып булса да әйтик: Мәгъсүм Хөсәенов соңра Минзәләдә беренче секретарь булып эшләде, эшне бик көйле алып барды, энергияле, ял вакыты белән исәпләшми торган чын кеше иде. Күп төрле дәрәҗәле урыннарга сайланды, Социалистик Хезмәт Герое дигән затлы исем алуга иреште. Тимерхан абзый күреп йөри: кайчандыр партия органнарында ялагайланып йөргән кайбер бәндәләр йөзләрен 180 градуска бордылар, хәзер, перестройка заманында, пожардан соң шланг болгап йөргән пожарниклар төсле, партияне, коммунистларны сүгәләр, тиргиләр түгел, нәкъ менә ата-анасы белән сүгәләр. Имеш, дәрәҗә алучылар — алар ялагайлар, алар эшлексезләр, алар сәнәктән көрәк булучылар. Мәгъсүм Хөсәенов исә ялагайлануның ни икәнен дә белмәгән кеше, гап-гади кеше, булсынга йөргән, халыктан беркайчан да аерылмаган кеше. Күрделәр бит аны, зурладылар бит, якты дөньядан ул үзенең кем икәнен белеп китте, урыны җәннәттә булсын, дөнья бәясе кеше иде...

Ихтимал, җитәкчеләрнең затлылыгы яки затсызлыгы хатыннарыннан да киләдер. Малга табынган, үзен дөньяның кендеге дип санаган, комсыз табигатьле, тәкәббер хатыннарның ирләре хезмәт баскычыннан әлләни югары күтәрелә алмады, хатыннарының чүпрәгенә уралып, тормыштан төшеп калды. Мәгъсүм Хөсәеновның хатыны Сәрвәр апа үтә чыккан гади, тәрбияле, аралашучан ханым, электән укытучы иде. Беркайчан да иренең эшенә тыгылмый, ирен мактый башласалар, шундук туктата иде. Өч бала үстерде. Тимерхан белә, җитәкче урындагы кешеләрнең бала-чагага игътибарлары калмый, андый гаиләдә балаларны әни кеше үстерә. Балалары да, гаилә башлыкларына карап, тыйнак булып чыктылар, читтән әйбер ташымыйлар. Чөнки әтиләре гомер буе район җитәкчесе булып эшләсә дә, аларның фатирында гади генә бер шкаф, язу өстәле, әллә кайчан алган урындыклардан башка берни юк иде.

Тимерхан өченче секретарь булып сайланган Әкмал Әхмәтшинны бик яхшы белә, чөнки ул аның авылдашы диярлек. Иске Вәрәштән, ягъни Миңлеасияләр авылыннан. Фикергә бай, җор, үз эшен яхшы белә, намуслы адәм, практик эш остасы.

Менә шушы ике бик әйбәт кеше белән эшләргә тиеш иде Тимерхан. Эш бүлешкәндә аңа идеология дилбегәсен тоттырдылар. Мәктәпләр, уку

йортлары, медицина учреждениеләре, сәүдә, спорт, ирекле башка оешмалар — аның карамагында. Яшьләрне тәрбияләү дә аның ягына карый. Ул чагында коммунистик хезмәт бригадалары, шимбә һәм якшәмбе өмәләрен оештыру гадәткә кереп киткән иде.

Идеология ул — акыллы, тәрбияле булу турында сагыз чәйнәп утыру түгел. Анда авыл хуҗалыгы белән дә бәйләнешкә керергә, авылдан төгәл бер йомыш белән килгән колхозчы яшьләрне кабул итәргә, алар теләгәнне җитәкчеләрдән үтәтергә кирәк. Юллар төзү, район хастаханәсен булдыру, авылларга электр кертү — барысы-барысы сиңа, идеология секретарена да кагыла. Кеше сәламәт булмаса, аңарда сәламәт акыл була алмый, димәк, хастаханәнең төгәл эшләве дә сиңа кагыла. Авылда ут юк икән, яшьләр китап укый алмый, газит укый алмый, электрны авылларда булдыру шуның өчен дә кирәк. Юллар төзек булса, яшьләр шыңшып йөрми, шәһәр культурасы белән аралаша.

Ул елларны районда нефть разведкасы эшли иде. Бораулаучы егетләр белән дә Тимерхан бәйләнешкә керми кала алмый иде. Районда үткәрелә торган массакүләм чаралар — барысы да аның карамагында.

Мөслимдә эшләгән 1959 ел Борһановның аеруча исендә калды. Ел башыннан һәр көн диярлек кар явып торды. Бураннар уйнады. Колхозларда натуралата түләү буенча гарантия керде.

Адәм баласы икмәк ашый башлады.

Терлек асрап, базарга ит-май чыгару, тамагы туя башлагач, кунакка йөрешү, туйлар ясау кебек имин еллардагы матур гадәтләр әйләнеп кайтты.

Яз иртә килде. Җылы, дымлы көннәр, шифалы яңгырлар игеннәрнең матур һәм тигез тишелеп, бик тиз үсеп китүенә булыштылар. Мөслим игенчеләре — үз тарихларында беренче мәртәбә — иң югары уңыш алдылар — УНСИГЕЗ центнер чамасы. Сугышка кадәр алынган алты центнер белән чагыштырганда бу бик күп иде. Ләкин кырдагысы унсигез иде. Аны әле амбарларга кайтарып салганчы җитмеш җиде кат тир түгәргә туры килде. Ник дигәндә — яңгырлар коеп-коеп яуды. Уракка төшүдән башланган иде яңгыр, карга килеп тоташты. Мул уңышны кырда калдырмас өчен бөтен халык күтәрелде. Башта комбайннар эшләде, басуларга комбайн керә алмаслык булгач, тәгәрмәч тиңентен бата башлагач, кырларда уракчы хатыннар, көлтә бәйләүче җиңгиләр, чүмәлә һәм эскерт куючы абзыйлар, үсмерләр пәйда булды. Инде онытыла башлаган гамәлләр кире кайтты.

Халыкны үгетләү, аның күңелен сүрелдермәү Борһанов өстендә иде. Юл кожанын салганын хәтерләми. Яңгырлар аз гына туктап, аз гына аязып алган сәгатьләрдә ындыр табакларына арыштан, бодайдан көшелләр өелә, җилгәргеч машиналар гүли, өстәмә итеп ясалган сушилкаларда — ашлык киптерү урыннарында көне-төне эш кайный. Өемнәрдәге ашлык җылынып кызып китмәсен өчен, аны җиңнәрен сызганып куйган җиңгиләр зур агач көрәк белән һавага чөеп, гел җилләтеп торалар.

Болар барысы Тимерханга фронтны хәтерләтә, биредә һөҗүмнең кайнар сулышы сизелә иде.

Урак өстендә халыкның күңелен сүрелдермәү аеруча мөһим. Мондый чакта җитәкчеләр йоклап ята алмый. Уракның иң кызган бер чорында партия өлкә комитетының беренче секретаре Игнатьевның Мөслимгә килеп җитүе эшләрне тизләтергә ярдәм итте.

Семен Денисович Мөслимдә игеннәрнең шаулап уңганын белеп, Мәгъсүм Хөсәенов белән килешеп килгән иде. Район авылларында ашлыкның тулып ятуын, урыны-урыны белән инде бозыла да башлавын күрде зур җитәкче, колхозларда транспорт җитмәвен, шул сәбәпле элеваторларга ашлык чыгарып булмавын аңлады. Боларны ул райком секретаре авызыннан ишетеп түгел, колхозларда булып, барысын да үз күзе белән күргән иде.

Вахитов колхозына барды. Ындыр табагы тулы ашлык. Авылның яше-карты, хәтта бала-чагасы икмәк эшкәртүдә. Төрле киптерү җайланмалары эшли, терлек торакларына тикле ашлык белән тулган. Күршедәге «Кызыл Октябрь» колхозына киләләр. Биредә председатель булып Вәли Хәлиуллин эшли, сугышны узган кеше, чын мәгънәсендә дипломат, сүзнең кирәген генә әйтер, әйтә белеп әйтер.

— Килеп бик яхшы иткәнсез, иптәш Семен Денисович. Икмәк күп, икмәкне кая куярга белгән юк. Быел без дәүләткә ике план күләмендә тапшыра алабыз ипекәйне.

— Нәрсә тоткарлый соң?— ди Игнатьев.

— Транспорт юк. Шул үзәккә үтә.

Алар колхозларга өчәү чыкканнар иде: Игнатьев, Хөсәенов, Борһанов. Тимерхан күрде: Хөсәенов тоташтан борчыла, Игнатьев әле яктыра, әле борчыла. Колхоз рәисенең сүзләреннән соң, ул Мәгъсүм абзыйга өзеп кенә әйтте:

— Киттек райкомга, шунда сөйләшербез!

Райкомда ул өлкә комитетының транспорт бүлегенә шалтыратты.

— Кемнәр транспорт бирергә тиеш иде Мөслимгә?

— Чаллы белән Ютазы,— дип җавап бирәләр Казаннан,— ләкин алар безгә буйсынырга теләмиләр.

Чаллы белән тоташа, Ютазы белән тоташа Игнатьев. Автоколонна начальнигы Садриевны доклад белән чакырта. Кичке сәгать уннар житә, офыкның алсулана башлавын карап тора Семен Денисович, аннары борыла, ишекле-түрле йөренә башлый. Ул утырмый, гел шулай йөреп тора, ул утырмагач, Хөсәенов белән Борһанов та утыра алмый, әмма аларга ишекле-түрле йөрергә дә ярамый, чөнки бу хәл беренчене мыскыл итү төсле була.

Ниһаять, ишек шакыйлар. Нервылары кыл кебек тартылган Хөсәенов ишекне үзе барып ача.

Кирза итекле, брезент киемле егет керә.

Исәнләшә.

— Семен Денисович, сезнең чакырту буенча Ютазы автоколоннасы начальнигы Садриев килде.

— Яхшы,— ди Игнатьев.— Мөслимгә билгеләнгән машиналар ник Мөслимдә түгел?

— Мин ике ут арасында, Семен Денисович. Бер яктан — обком белән Совмин кыса — 20 машина таләп итә, икенче яктан, Ютазы райкомы секретаре Һадиев: «Син, Садриев, безнең райкомда учетта торганыңны оныτма»,— ди. Нишләргә инде миңа?

Семен Денисович шул мәлдә Хөсәеновтан бер бит кәгазь сорап алды, язды: «Ип. Һадиевкә. Әгәр иртәгә сәгать 6 га 20 машина Мөслим райкомы каршысына килеп туктамый икән, алдан ук белеп торыгыз: Сез партиядән чыгарылган булырсыз. С. Игнатьев».

Иртәнге сәгать биштә егерме машина инде райком бинасы каршында тезелеп тора иде. Төштән соң Чаллы машиналары да килеп житте. Әмма аның соңга калуы автоколонна башлыгына кыйбатка төште, аны шул ук көнне эшеннән бушаттылар.

Семен Денисович Игнатьев — әйткән сүзен җилгә очыручылардан түгел иде.

## Алтынчы бүлек

**1960** елның язы да матур килде.

Сабан ашлык күкрәп үсте, болыннарда печән ерып йөргесез булды.

Мондый чакта авыл кешеләренең күңеле күр була һәм алар сабан туе бәйрәменә бик теләп әзерләнәләр.

Мөслимдә сабан туен үткәрүгә җаваплы итеп Борһановны билгеләделәр. Бу аның өчен, халык белән аралашу, кешеләрнең уй-теләкләрен белү ягыннан бик тә мөһим бер эш иде.

Мөслим райүзәге — табигатьнең иң гүзәл урынында. Болыннар күп монда, мул сулы Ык елгасы ага биредә. Очраклы гына килеп чыккан кеше дә Ыкның биек ярына басып, авылларга, Урал тауларының итәге булган күгелҗем тауларга озак, бик озак сокланып карап тора.

Ул елларны Әлмәт, Бөгелмә, Азнакай нефтьчеләре ял көннәрендә хатыннары, бала-чагалары белән автобусларга төялеп киләләр, ял итеп, коенып, монда рәхәтлек табалар иде.

Ял булгач ял инде: күңел ачулар да була, куна-төнә ятулар да: соңга табарак ял итүчеләр болыннарны таптап, кара җиргә калдыра башладылар.

Шундый бер гыйбрәтле дә, сәер дә хәл Тимерханның исендә торып калган. «Кызыл Октябрь» колхозы председателе Хәлиуллин шундый тәртипсез кыланган машиналар янына бик хәтәр усалланып килә. Мәлләтамак авылының болынына килгән берничә машина болынны эштән чыгарган. Председатель Вәли Хәлиуллин җиңел машина янына килеп, шоферның документларын сорап ала, чибәр яшь таза егеткә каш астыннан бер томырылып карагач, документларны Мөслимгә — милиция идарәсенә җибәрә.

Шуннан соң Ыкта су коенып яткан нефтьчеләр янына килә:

— Бу машиналар кемнеке? Болынны таптарга кем рөхсәт итте сезгә? — дип кычкыра.

Яр читендәрәк су коенучы берәү председательгә бик текәлеп карый, аннары кинәт кычкырып җибәрә:

— Халиуллин! Боже мой!

— Денисов! Йа алла, ты жив?! Дружище Николай Петрович!

Карап торган кешеләр гаҗәпләнәләр — бу нинди көтелмәгән очрашу? Болар кемнәр?

Ул арада Денисов коры җиргә чыга, өстеннән шыбырдап су ага, Хәлиуллин аны шул юеш килеш чатырдатып кочаклый. Алар — әле берсе, әле икенчесе — алмаш-тилмәш бер-берсен күтәреп, болында ду киләләр.

Унбиш ел буе бер-берсенең исәнлеген белмәгән ике фронтовикның очрашуы икән бу! Хәлиуллин белән Денисов аяусыз бер бәрелештә бер-берсен югалтканнар, Денисов моңарчы фронтовик дусты Вәли өчен хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөргән. Менә бу очрашу дисәң дә очрашу!

Вәли аңлап ала — документлары милициягә озатылган шофер Денисовныкы икән. Милициягә кәгазь язып, гафу үтенеп, документларны кайтарта Хәлиуллин, фронтташ дустын, гаиләсе белән, үзләренә кунакка алып китә.

Фронт дуслыгы — утта сыналган дуслык. Тапталган болыннарны, тәртипсезлекләрне дә оныттыра ул. Юк, Денисов аның тапталган болыннарын онытмый, колхоз фермасына су кертү өчен торбалар бирә, ул торбаларны сузучы һөнәр ияләрен бирә Хәлиуллинга. Әнә шундый танышлыклар аркылы «законлы» шефлыклар туа, бер «Кызыл Октябрь»гә генә түгел, тирә-юньдәге башка колхозларга да булыша нефтьчеләр.

Тимерхан Борһанов җитәкчелек иткән сабан туена Әлмәт, Бөгелмә, Азнакай, Баулыдан, Башкортстанның Бакалы районыннан (Мөслим белән Бакалы ярышучы районнар иде) халык күп җыелды. Нефтьчеләр — таза, гаярь, эштә чыныккан кешеләр. Алар арасында Әсгать Абдуллин кебек инде исеме тирә-якта шаулаган батырлар бар. Минзәләдән бик таза егетләр килде.

Элекке елларда көрәш кагыйдәләрен куллану булмый иде. Бигрәк тә үлчәү алып барылмый иде. Хәтта чиратка да язылмыйлар, кемгә ничек

кулай, җаен гына күтәп утыра да, көрәшә-көрәшә хәлдән тайган көрәшчене әйләндереп кенә сала!

Борһанов, шәһәрдәге кебек, спортның барлык кагыйдәләрен саклап үткәрергә булды милли көрәшне. Кулланучылар җәмгыятеннән үлчәү китертте, көрәш кагыйдәләрен белүче һәм ул кагыйдәләрне күз карасыдай саклаучы биш карттан комиссия төзеттерде. Казаннан махсус чакыртылган спорт мастерын да шунда куште. Көрәшчеләрне үлчәүләре буенча категорияләргә бүлеп чыктылар, кемнең кем белән көрәшәчәгенә шобага салдылар. Авыр үлчәүдә 109 килограммга җиткән көрәш батырлары бар булып чыкты. Минзәләдән килгән бер урыс малае үлчәнде, Виталий Кузнецов исемле бу үсмер егеткә уналты яшь, авырлыгы 69 килограмм икән. Бу егет Минзәлә автоколоннасының тимерчелек мастерскоенда чүкеч сугучы — ярдәмче тимерче булып эшләвен әйтте. Исеме җисеменә туры килгән менә шул егет барлык үлчәү категорияләрендәге көрәшчеләрне җиңә барып, авыр үлчәүдәгеләр белән көрәшкә чыкты. Иң азактан ул Бөгелмәдән килгән шофер, 109 килограмм авырлыгындагы баһадир белән алыша башлады. Картлар аны кызганып, үзеннән ике мәртәбә диярлек авырлыктагы Алып батыр белән бил алыштырмаска да теләгәннәр иде, әмма егет сүзендә нык торды, көрәшәм, диде.

Бил алышу башланды. Шагыйрь әйтмешли, «йөрәкләр мәйдан кебек кысылды». Баһадирның япь-яшь үсмердән җиңеләсе килми, эш кыенлашсын дип, ул майкасын салмаган. Бер-ике тапкыр алышкач, Кузнецов аңардан ефәк майкасын салуны таләп итте. Баһадирның майканы салмый хәле булмады. Шуннан соң тагын бер-ике мәртәбә алыштылар. Кузнецов кинәт «у-ух!» — дип кычкырып җибәрде, 109 килограммлы баһадирны күз ачып йомганчы югары күтәрде һәм җилкәсе аша чөеп, җиргә сылады.

Ул сабан туеннан соң вакыт күп узды, соңрак белдек: Кузнецов көрәш буенча өч тапкыр дөнья чемпионы, биш тапкыр Европа чемпионы, унбер тапкыр СССР чемпионы, 1972 елны олимпиадада икенче урынны алып, көмеш медаль белән бүләкләнде. Атказанган спорт мастеры, атказанган тренер булды.

Алтмышынчы елларның тагын бер хикмәтле ягы бар иде. Илдә ит, сөт җитештерү, терлек продуктларын күбәйтү өчен яңа бер хәрәкәт җәелдерелде. Сыер һәм дуңгыз фермаларында баш санын арттыру бурыч итеп куелды. Куян фермалары, каз-үрдәк фермалары, тавык фермалары оештыру да алга килеп басты. Шулар белән бергә халыктан сөт җыю, йомырка сатып алу, колхоз-совхозларда бозау һәм сарык сатып алу башланды. «Контрактация» дигән әкәмәт сәер сүз җыелыш саен кабатланып йөрде. Әлеге эшнең башында Мөслим районы барды. Районның колхозлары бу эш белән шулкадәр дә мавыктылар, чама хисен бөтенләй онытып җибәрделәр. Аерым вәкилләр күрше Башкортстаннан үгез бозау, дуңгыз, сарык сатып алып, машиналар белән колхозларга өзлексез ташып тордылар.

Малны берәр ай симерткәч, заготскотка тапшыралар иде.

Шулай бер елны өлкә партконференциясенә Мөслим районының дәүләткә ит тапшыру буенча өч еллык планны үтәве турында рапорт бирелде. Боларның берсе дә тырыш хезмәттән башка була алмый, Башкортстанга чыгып, машина-машина терлек төяп кайту өчен дә тырышлык, булдыклылык кирәк, әмма болар артында күз буяу дигән эчке бер ямьсез нәрсә дә яшерелгән иде.

Дөньяда баш әйләнгеч яңалыклар булып тора. Хрущев «Американы куып җитү һәм узып китү», «озакламый коммунизмда яшәү» идеяләрен республикаларга сибеп ташлады. Китте ярыша-ярыша план үтәүләр, китте чирәм җир ачулар, «капитализмның бугазыннан алулар», социалистик дәүләтнең космоска беренче булып Гагаринны очыртуы белән мактанулар!

Ярыш — мавыктыргыч нәрсә. Мөслимнең ирешкән уңышларын әлерәк кенә Куйбышевтан килеп өйрәнеп йөргәннәр иде, Идел буеның башка өлкәләренә дә ярыш шаукымы күчеп өлгергән иде, шул эшләрнең нәтиҗәсе булып Идел буе өлкәләренең берсендә — Рязаньда мылтык шартлады һәм өлкәнең барлык мал-туарын суйдырып бетереп, өч еллык планны үтәтеп, дан алган Ларионов атылып үлде.

Уйлый белгән кешегә уйларлык эшләр бар иде дөньяда!

## Җиденче бүлек

**1961** елның апрелендә Мөслимгә Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеев килде.

Укучының уйга калуы мөмкин: туктале, каян килеп чыкты әле бу Табеев? Татарстан өлкә комитетында беренче секретарь Игнатьев иде бит?

Әйе, 1960 елның октябренә тикле Игнатьев Семен Денисович иде. Ул үз теләге белән ялга чыкты һәм урынына Табеевны калдырды. Бу көтелмәгән хәл иде. Салих Батыев секретарь булыр дип көтелә иде. Яше дә, тәҗрибәсе дә, белеме дә, партия таләп иткәнчә, ныклыгы да җитәрлек иде. Ә менә Игнатьев беренче секретарьга откан да утыз ике яшьлек Табеевны тәкъдим иткән.

Моңа Татарстанда байтак кеше гаҗәпләнде.

Салих Гыйлемханович инде секретарьлыкка әзер булып тора иде. Үзәк Комитетка Батыевны да, Табеевны да чакырдылар. Икесе белән дә аерым-аерым әңгәмә үткәрделәр. Әмма Батыевка: «Беренче секретарь син буласың, диміделәр, кемне тәкъдим итәсең?» — диделәр.

Салих Гыйлемханович — җилнең каян искәнен бик тиз тоеп ала торган кеше — үзен куймаячакларын шундук аңлады, ул чагында Министрлар Советында эшләгән Абдразяков булуын да теләмәде.

— Табеев Фикрәт Әхмәтҗановичны тәкъдим итәм,— диде.

— Биографиясе? — диделәр Үзәк Комитетта. Табеевның биографиясен алар күптән белә иде инде, әмма Батыев беләме икән, үзе тәкъдим иткән кандидатураны өйрәнгәнме икәнен чамалау өчен сорадылар.

— Озын итеп сөйлимме, кыскачамы? — дип сорады Батыев.

— Мөһимен сөйләгез.

— Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев 1928 елны туган, татар, 1951 елдан КПСС әгъзасы, югары белемле, Казан дәүләт университетын тәмамлады. Экономика фәннәре кандидаты. Тормыш юлы нык — 1945 елдан колхозчы. Университеттан соң шунда укытырга калды, ассистент булды, политэкономия кафедрасының доценты. Җәмәгать эшләрен бик теләп башкара. Университетта чакта ук шул югары уку йортының профком председателе иде. Хезмәт баскычы бик текә күтәрелде. Татарстанның өлкә комитетында бүлек мөдире, пропаганда секретаре булып эшләде, хәзер дә эшли. Тәртипле, марксизм-ленинизмга турылыклы, озын сүзнең кыскасы — партия солдаты.

— Татарлыгы ничек?

— Тумышы белән ул Рязань ягыннан. Мишәр. Ә мишәрләр, дөресен әйткәндә, сөйләргә дә, эшләргә дә маһир. Теге якка да, бу якка да егыла торган кеше түгел Табеев, тормышка ныклы үз карашы бар, тәртип бозучыларны акылга утыртыр дәрәҗәдә каты куллы.

Батыевтан соң Табеевның үзен чакырып әңгәмә үткәрделәр. Анда алар ни турында сөйләшкәннәрдер — билгеле түгел, шунысы мәгълүм: 1960 елның октябрендә өлкә комитеты пленумында Фикрәт Әхмәтҗан улы Табеевны беренче секретарь итеп сайлап куйдылар. Бәлки, революциянең беренче елларында өлкә комитетында беренче скрипкәне яшь революционерлар уйнагандыр, әмма соңгы елларда, бигрәк тә сугыштан соң 32 яшендәге беренче секретарь булганы юк иде әле.

Сайлаганнан соң озак та үтми, Фикрәт Әхмәтҗанович Мөслимгә килеп, район хәлләре белән танышты. Озын буйлы, яшь, сүзен өзеп сөйләшә торган секретарьның беренчеләрдән булып Мөслимгә килүе, әлбәттә, бирседәгеләр өчен абруйлы иде. Ул колхозларда булды, председательләр белән әңгәмә корды.

Киткән чакта райком секретаре Хөсәеновка әйтте:

— Элеккерәк елларны бөтен гаепне, барлык чүпне колхоз председательләре өстенә өяләр иде, аларны җәзага тарталар иде. Без моны дөрес түгел дип саныйбыз. Әгәр председатель ул эшкә сәләтле түгел икән, авырып-нитеп китә икән, аны ул эштән алырга, ләкин юк гаепне бар итеп аңа такмаска, җәзаламаска кирәк. Нахакка күпме кешенең гомере өзелде, Сталин ГУЛАГлары тоткыннар белән тулы иде бит. Инде без дә өстебезгә гөнаһ алмыйк, Мәгъсүм агай, мөмкин кадәр гадел булыйк. Председательләр корпусы күктән төшми, аларны урыннарда әзерлиләр. Барлык колхоз җитәкчеләренә Татарстан өлкә комитетының сәламен тапшырыгыз. Шикләнеп-куркып эшләмәсеннәр, хуҗалык җитәкчеләре батыр һәм кыю булырга тиеш. Сез дә, Сезнең кул астында эшләүче башка җитәкчеләр дә бездән яклау табарсыз. Мин моны ышанып әйтәм, буш вәгъдәләр чәчеп йөрү миңа файдалы түгел, буш вәгъдә белән ничәмәничә җитәкче янды бит инде. Язгы чәчүне оешкан төстә үткәрә алырсыз дип ышанам, урыннардагы әзерлекне күрү миңа шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Ихтимал, бер атнадан чәчү башланыр. Уңышлар сезгә! Игеннәр буынга утыргач, бәлки, сабан туе чорында тагын бер килермен.

Бу 1961 елның апрелендә булды.

Ә өч атнадан, 1961 елның 9 маенда Тимерхан Борһановны район Советы сессиясендә райбашкарма председателе итеп сайладылар. Район таныш булса да, райбашкармадагы эш үзенчәрәк иде шул. Партия райкомында кул астындагы кечерәк җитәкчеләрне эшләтү, ягъни сүз тыңлату өчен райкомның бер «звоногы» җитә иде, ә хәзер әле синең абруйлы булуың, игенче крестьянның эшен биш бармагыңдай белүең кирәк. Тимерхан — авылда үскән, иген-таруның да, мал-туар үрчетүнең дә нәрсә икәнен, шөкер, үз җилкәсендә татыган кеше, әмма син бит хуҗалыкны үзең алып бармыйсың, синә ышанган җитәкче кадрлар — колхоз рәисләре, аларны тыңлый белгән урта буын тармак җитәкчеләре алып бара. Өстәвенә, син үзең баш, үзең түш түгел, синең өстән райком бар әле, синең фикерең, синең ниятең алар фикере һәм нияте белән туры килсә, бик хуп та бит...

Тимерхан тагын башы-аягы белән эшкә чумды — аңар иң элек райбашкармадагы бүлекләрнең вазифаларын һәм Мөслим райбашкармасындагы кадрларның нәрсәгә сәләтле булуларын белеп бетерергә кирәк иде. Кеше — катлаулы җан, син аны еллар буе өйрәнеп тә белеп бетерә алмаска мөмкин, ә төгәл бер очрак, ситуация аны ача да сала синә. Бүлекләрдә эшләгән дистәләгән кешенең нинди дер хәл-әхвәлгә очраганын көтеп утыра торган заман да түгел шул. Бүлек мөдирләре белән аерым-аерым әңгәмә корырга, алар белән бергә авылларга чыгарга, авыл кешесенең кәефе ничегрәк икәнне, аның сулышы нинди икәнне белергә туры килде.

Кешеләр белән сөйләшә торгач, аларның зарларына колак сала торгач, төп юнәлеш ачыкланды: район юлсызлыктан интегә. Мөслим — Бөгелмә юнәлешендә Тымытык белән Азнакай юлларына дамба күтәртеп, чуерташ салып чыгарга кирәк.

Борһанов шул ният белән Азнакай җитәкчесе Хәмидуллин янына барды.

— Һидият туган, юлларыбыз бик начар бит. Әллә бергәләп тырышып карыйкмы? — диде һәм күңелендә туган уйларын Азнакай секретарена сөйләп бирде.

Аның нияте Хәмидуллинга ошады. Ул район колхозларын Азнакайдан Тымытыкка, Тымытыктан Урсай авылына кадәр дамба күтәртү, таш

төшәп чыгу эшенә тартырга вәгъдә итте. Ә Мөслим колхозлары Урсай авылы белән тоташалар иде.

Утыз чакрым озынлыгындагы юл колхозларга бүлеп бирелде. Башланган эш — беткән эш, диләрме? Ике ай эчендә юл салынып бетте, берничә урында ермакларга вак күперләр саласы гына калды.

...Еллар узар, чәчләргә чал кунар, Борһанов министр урынбасары булыр, Тимерханны өлкә комитеты Азнакайга эш белән җибәрер. Районның авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Борһановны Урсайга алып килер. Алар Ыктан көне-төне ташып, дамбага җәйгән вак ташны искә төшерерләр, юлга күзләрен мөлдерәтеп карап торырлар. Хәзер ул юлдан йөрмиләр, чөнки нефтьчеләр Чалпы авылыннан Мөслимгә таба асфальт юл салдылар...

Ә нинди дәртләнеп салганнар иде ул юлны! Хөсәенов Мәгъсүм абыйлары да Тимерханның идеясен хуплаган иде. Шул юлдан машиналар чаба башлагач, нинди куанганнар иде...

Борһанов райбашкарма председателе булгач, күп эшне үзенә алды. Монысы — аның эше, монысы — минем эш, дип, вакланып тормады. Райкомның беренче секретаре әйтеп куя иде кайчакта:

— Ей богу, миңа Борһанов белән эшләве рәхәт. Эшне ул үзе белеп эшли, этеп-төртеп кушканны көтеп тормый.

Мәгъсүм абыйларында кешелекле сыйфатлар күп. Булсынга эшләүчене күрә белә, кирәк чагында җылы сүзен кызганмый. Әмма үз эшен вакытында алып бармаганнарны да кызганмый шул инде. Үз вазифасын үтәмәгәннәрне ул урынына утырта белә. Шулай бер вакытны, район сабантуйлары узгач, терлек азыгы әзерләүне көчәйтә торган чакта, чабылган печәнне җыеп алуны озакка сузганнары билгеле булды. Моны «Беренче Май» колхозы шулай сузган. Үлән кипкән, әмма эскертләнмәгән. Председательләр киңәшмәсендә «Беренче Май» җитәкчесе Александр Кондратьевның исәп-хисабы тыңланды. Терлек азыгы әзерләү ул колхозда өзелгән. Залда утыручылар Кондратьевның хәленә керергә теләп:

— Иптәш Хөсәенов, ул өченче көн сабантуйда батыр калды. Байтак көрәшчене баш аркылы чөйде, ыргытып кына бәрде,— диделәр.— Кызганыйк инде без аны, бик күп көч түкте бит.

Хөсәенов башта утырып сөйләшкән иде, эшләр болайга киткәч, торып басты. Өстәл яныннан трибунага чыкты — моны ул юри, игътибар иттерер өчен эшләде, чөнки әйтәсе сүзе бик тә мөһим иде.

— Аңладым мин сезне, иптәшләр. Әле сез шуңа исегез китеп утырасыз икән. Кондратьев ыргытып кына бәрде, дисез. Ул ыргыту — ыргытумыни? Менә райком ыргытса, сөякләреңне җыя алмассың!

Кемдер пырхылдап көлеп җибәрде. Башкалар тыелып калды. Терлек азыгы әзерләү — уен эш түгел. Хөсәенов та сүзен көлдерү өчен әйтмәде, җаны ачытып әйтте.

Ул заманнар искә төшкәндә, Тимерхан әле бүген дә аңлап булмастай хәлләргә аптырый. Җитәкчегә күңел ачулар, гармун уйнаулар, җырлаулар тыела иде ул заманда. Кечкенәдән җаны гармунга кушылып үскән Тимерхан өчен болар бик тә, бик тә сәер иде.

Әле дә хәтерендә: Мөслим райбашкармасында эшләгәндә, Казаннан килгән бер кечерәк кенә түрәне Тимерханнар кунакка чакырганнар иде. Ризыктан авыз итеп, чәй-мәен дә тоткалап, бераз күңел ачып утырганнан соң, Тимерхан кулына баян алды. Әкрен генә, талгын гына, җанны эретерлек итеп кенә «Минзәлә» көен уйнады. Күрә: әлеге түрәнең музыкага исе дә китми. Тимерхан тырышканнан-тырыша, күңелендәге бар моңын гармун телләренә сала,— кунакның бер кылы да селкенми, әллә бар аңа музыка, әллә юк.

Тимерхан, ниһаять, аңлады, баянын җилкәсеннән салып, идәнгә куйды. Шуннан соң кунак бик тә җитди чырай белән, мәчет мөнбәренә чыккан мулла кебек, үтемле вәгазь әйтте:

— Егет, син гармунны начар уйнамыйсың. Артист булсаң, сәхнәдән уйнап, халыкны кул да чаптырыр идең. Әйтүләренә караганда, эшеңне дә әйбәт алып барасың икән. Син бу гармун кычкыртуларыңны ташла. Җитәкче кешегә килешми!

Тимерхан рәнжеде, әмма дәшмәде...

Ә хәзер әнә җитәкчелеккә таза, энергияле, һәр яктан сәләтле кешеләрне куялар. Алар мәктәп эскәмиясеннән музыкага, спортка, көрәшкә күнегеп үскән. Югары уку йортларында әлеге талантлы егетләр бу һөнәрләрен камилләштерәләр. Укып чыгып, колхоз председательләре, совхоз директорлары булгач та спортны да, музыканы да ташламыйлар. Халык моны яратып кабул итә. Гадилек дип, ихласлык дип, аралашу, уртак тел таба белү дип атала ул. Бүгенге Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Фатих Сибагатуллин — сабантуйларында мәйдан тоткан көрәшче. Арча районының хакимият башлыгы Вәгыйз Минһаҗев та — батыр булып сыналган кеше, өстәвенә, көмеш телле тальянда өздереп халык көйләрен уйный.

Дөньяның һәм үз илебезнең атаклы педагоглары Ян Амос Каменский, Антон Макаренко һәм тагын башкалар адәм баласының һәм физик, һәм эстетик тәрәккыятен (үсешен) яклыйлар. Шуларны уйлаганда, Мөслимдә, райком бюросы әгъзаларының ярсый-ярсый Демидовны (бары тик җитәкче булганы өчен генә!) сабан туенда көрәшеп батыр калганга, колхозның тәкәсен алды, дип партиядән чыгаруларын ахмаклыктан башка берни дә дип әйтеп булмый.

Да-ааа, бар иде тинтәк заманнар! Бар иде тинтәк җитәкчеләр. Әмма алар арасында Харитонов кебек, Хөсәенов кебек акыллы һәм намуслы җитәкчеләр дә бар иде.

Бар иде, әмма сирәк иде.

Күбесе мин-минлек чире белән агуланганнар иде.

Пенсиядәге Тимерхан абзый бүген шуларны күңеленнән үткәреп, таң калып утыра.

## Сигезенче бүлек

Райбашкарма рәисе булып эшли башлавына өч ай тулдымы икән, Борһановны өлкә комитетына җибәрергә кушып, Казаннан шалтыраталар. Хөсәенов моңа борчыла, телефоннан ике мәртәбә Табеевка чыга.

— Фикрәт Әхмәтҗанович, зинһар, Борһановка тимәгез. Ул әле эшли генә башлады бит.

Табеев сүзне ике сөйләшүчеләрдән түгел.

— Иптәш Хөсәенов,— ди ул кискен итеп,— белеп торыгыз, бу мәсьәләдә тагын бер мәртәбә шалтыратсагыз, телефоныгызны өздертәм!

Мәгъсүм абыйлары Тимерханны үз кабинетына чакырды, туганнарча үз итеп әйтте:

— Нишләргә инде, малай, телефонымны өздертәм, ди шеф. Мин үз ягымнан фактически барысын да эшләдем инде, күндереп булмый бит теге мишәрне. Җибәрәсе бер дә килми сине үземнән.

Алар үзара зарланышып утырганда өлкә комитетыннан Фарух Садыйков шалтыратты. Монысы — партия-оештыру бүлегеннән.

— Миңа Борһановны бирегез.

— Баш өсте,— диде Хөсәенов.— Ул минем янда утыра.

Борһанов трубканы алды, исәнләштеләр.

— Беләсеңме, Тимерхан Борһанович, синең үзеңә мөстәкыйль камыт кияр вакыт җитте. Юкса син моңарчы башкалар кигән камытка ышанып, мичәүдәге ат булып кына бардың. Так што, төпкә җигелеп тарта

башларга вакыт. Ике пар күлмәк-ыштан сал чемоданыңа, иртәгә үк обкомга килеп җит.

Ул заманнарда кирле-мырлы сөйләшү гадәттә түгел иде.

Тимерхан өйгә кайтты, Миңлеасиясенә хәлне сөйләп бирде. Хәлләр үзгәрәчәген аңлады Миңлеасия, авыр итеп бер көрсенде. Ни хәл итмәк кирәк, үзе дә, ире дә партия солдаты, партия кая куя — шунда барасың. Миңлеасия — Мөслимнең үзәк хастаханәсендә шәфкать туташы һәм башлангыч партоешма секретаре. Ике бала үстерәләр. Олы уллары Хафиз инде өченче сыйныфта укый, кечкенәләре Әнисәгә җиде яшь, укырга керергә әзерләнә. Миңлеасиянең әти-әниләре Мөслимнән ике генә чакрым ары Иске Вәрәштә яшиләр. Әти-әнисе якын булгач, Миңлеасиягә рәхәт иде, ул үзен гүя аларның канаты астында кебек сизә иде. Балалар җәйләрен дә, кышкы ял вакытларында да әбиләрендә була алырлар иде. Гомер кичергән карт белән карчык оныкларын өзелеп яраталар, алар килгәнне көтеп алалар, сөеп туймыйлар иде.

Инде менә китәләр.

Кала таулар, кала болыннар, кала инеш, кала күз күреме җитмәс киңлектә — Мөслимнән Иске Вәрәшкә тикле — болыннарны тутырып үскән әрәмәләр...

Барысы да кала. Хастаханәдә инде ияләшкән, якын күргән иптәшләре, хезмәттәшләре кала. Миңлеасия тормышта чәчрәп торган булдыклы хатын, җор телле, шаян табигатьле җиңгәчәй булу белән бергә, тормышта кыен килгән чакларда сабыр да була белә, сызлануларын тышка чыгармый, үзе генә кичерә. Аның бер дә башка урынга күчеп китәсе килми. Җитмәсә әле ул өченче балага йөкле, менә-менә дөньяга яңа бер сабыйны бүләк итәргә тора, соңгы аен йөри... Инде менә бүген иртәнге сәгать биштә Тимерханга шалтыраталар:

— Әти кеше, котлыйбыз, малаегыз туды!

Тимерхан ничек кирәк алай чәчәк әмәлләп, бала табу йортына ашыга, Миңлеасиясен ерактан гына торып котлый (бала тапкан ана янына бит кертмиләр!), борчылмаска куша һәм туп-туры аэропортка юнәлә.

Обкомда аны Садыйков кабул итте.

— Иптәш Борһанов, сезне Тукай районына, халыкча әйтсәк, Әтнәгә беренче секретарь итеп сайларга тәкъдим керде. Ул — халыкның матур йолаларын саклый белгән культуралы район. Анда сезнең эше татарчаны чатнатып сөйләшә торган чын татар кирәк. Обкомда сезне иң кулай кеше дигән фикергә килдек.

Садыйков — тәмле телле, җайлы кеше,— Тимерханны сүзе белән эретеп, беренче секретарь кабинетына алып керде. Анда Табеевтан башка Верховный Совет рәисе Салих Батыев, Министрлар Советы рәисе Габделхак Абдразяков бар иде.

Борһанов аларның барысы белән дә күрешеп-исәнләшеп чыкты.

— Ну, нихәл? — дип сүз башлады Табеев.— Менә сине, Тимерхан Борһанович, Әтнәгә — Тукай районына беренче секретарь итеп җибәрергә карар кылдык. Менә биредә без өчәү, шаһитлар алдында ризалыгыңны ишетик.

— Хөрмәтле җитәкчеләр, мин бит әле Мөслим райбашкармасында өч кенә ай эшлим. Авызга тәме генә йөгереп килә әле ул эшнең. Аннары бит Мөслим — үз ягым, кешеләрен бәләкәйдән беләм. Өстәвенә, әле кичә өченче балам дөньяга килде...

— Бәрәкалла! — диде Батыев.

— Котлыйбыз! — диде Абдразяков.

— Малаймы? — дип сорады Табеев.

— Әлбәттә! — диде авызы колак артына җиткән Борһанов.

Табеев телефон номерын җыеп, тиз генә шалтыратты.

Тал чыбыгы кебек зифа гәүдәле кыз өстен тастымал белән каплап, бер шешә коньяк, ризыклар, салфеткалар кертте.

Табеев янындагы шкафның түреннән рюмкалар алды, рюмкалар бәләкәй түгел иде, шуларны тутырып, Табеев коньяк салган чакта шикләнүчәнрәк табигатьле Тимерхан куркуга калды: нужәли шуны эчәргә туры килер?

Җитәкчеләр аяк өсте бастылар, рюмкаларын кулга тоттылар.

— Тимерхан, сине улың туу белән, яңа эшкә билгеләнүең белән котлыйбыз. Сау-сәламәт бул! — дип, Табеев рюмкасын ялт кына аударып куйды, башкалар да шуны ук кабатладылар.

Тимерханга да алар эшләгән гамәлне кабатлаудан башка әмәл калмады.

Әтнәгә Тимерханны Батыев алып барды. Дөбъяздан чыккач та, Әтнә ягы басулары башлана. Игеннәре күкрәп утырган кара туфраклы Мөслимнән соң Әтнә Тимерхан өчен җан көеге иде. Ул уйга калган, баласы туганны әйткәненә дә, тиз генә килешүенә дә үкенә иде инде.

Батыев моны сизде булса кирәк.

— Ник сөмсерләрең коелды, Тимерхан? — диде. — Бу, әлбәттә, Мөслим кырлары түгел. Ләкин халык монда да Мөслимнән ким эшләми. Әнә авылларын кара — нинди төзекләр, кала суккан кебек бит. Кайгырма, ияләшеп җиткәнеңне сизми дә калырсың әле.

Конференция сәгате сукты.

— Сайламасалар ярар иде. — Тимерхан моны үкенмичә, ихлас әйтте.

— Сайлатырбыз! — диде Батыев җитди чырай белән.

Конференциягә җыелган делегатларның күбесе Борһановны таныйлар, янына килеп, кул биреп күрешәләр, өлкә комитетында инструктор булып эшләгәндә, Борһановка беркетелгән биш районның берсе Әтнә иде. Ул вакытта, 1958 елны, ярты ай чамасы Әтнә (Тукай районы) колхозларында булып, ул инде байтак кеше белән танышып өлгергән иде. Күз ахырларында йөргән иде Әтнә якларында Тимерхан. Игеннәр ярыйсы ук әйбәт үскәннәр иде ул елны, ә менә быел республиканың төньяк районнарында шундый көчле корылык, игеннәр тишелеп чыкканнан алып август урталарына тикле яңгырның әсәре дә юк. Менә шушы корылыктан интеккән районга аны башлык итеп куймакчылар. Сайламасалар гына ярар иде. Алтмыш беренче елның 17 августы аның хәтерендә калыр иде.

Юк, сайладылар.

Салих Батыев, җиңел сулап, Казанга кайтып китте. Аның белән бергә обком инструкторы Мостаев та Әтнәдә калмады. Әтнәдә эшләп интеккән элекке секретарьга Казанда фатир бирделәр, ул да койрык тайдырды. Аның фатиры исә Борһановка калды. Инде гаиләне алып килергә кирәк иде.

Ул Әтнәгә җыенган көнне Мөслим райкомында бюро утырышы бара иде. Хөсәенов, утырышны бүлеп, иптәш Борһановны озатырга кирәк, дигәч, аэропорт тирәсенә кеше агыла башлады. Моны күреп тору Тимерханга рәхәт тә, уңайсыз да иде. 36 яшенә җитеп, аның мондый хөрмәтне күргәне юк иде әле.

Миңлеасияне дә хезмәттәшләре озата килде. Алар, хатын-кызларга хас булганча, кочаклашып җыладылар.

Борһанов эшне, һәр җитәкче кебек, кул астында эшләргә тиешле кешеләр белән танышудан башлады. Усман Шаһи улы Җиһаншин — икенче секретарь, азактан Татарстанның Авыл хуҗалыгы министры булачак кеше. Фатих Хәлил улы Минушев — райбашкарма председателе, Арча — Әтнә якларын химияләштергән галим. Нәкыйп Сафа улы Сафин — Советлар Союзы Герое, «Северный» совхозы директоры, райком бюросына сайланды. Тормышта җитәкче дә, чын кеше дә булып калуны аңа Ходай тәгалә тумыштан ук биргән. Ул шундый да тыйнак, шундый да эшлекле, Тимерхан аны унҗиде ел үгетләп тә бер генә мәртәбә дә Алтын йолдызын тактыра алмады. Бар әле бездә олы йөрәкле кешеләр, бар!

Сугышта, хезмәт фронтында ул — каһарман, шәхси тормышында беркемнән дә аерылмый торган гап-гади кеше. Шайтан белсен, ул хәтле дә тыйнаклыкның кирәге бар микән?!

Тимерхан аңлады һәм күңеленә беркетте: мондагы халык Казанга якын яши, аңлы-белемле, мәдәниятле халык. Монда үзеңне итәгатьле тотарга, эчкерсез ихлас сөйләшергә кирәк. Туп-туры! Болар дипломатлыкны, хәйләкәрлекне, алардан акыллырак булып кыланганны яратмыйлар гына түгел, күралмыйлар, гафу итмиләр.

Җиһаншин белән Минушев авыл хуҗалыгын биш бармаклары кебек беләләр, алар — югары дәрәҗәдәге белгечләр, җир белән эш итү гыйльмен бик тирән үзләштергәннәр, төньяк районнардагы уңдырышсыз көлсу туфрактан уңыш алу серләрен төшенгәннәр, корылык елына, бик авыр чакка туры килсә дә, Борһанов күңелен төшермәде. Табигать үз җаена кайтыр, яңгырлар булса, мондый кадрлар белән җир җимертеп эшләргә була, дип уйлады.

Әтнәне берничә ел рәттән корылыклар көйдереп, иген уңышы начар булганлыктан, колхозларның экономикасы да шәп түгел, колхозчылар үз хуҗалыкларында булдырган табыш бәрабәренә яшиләр, колхозларда эшче көчләр җитми, ныклап эшләрдәйләре күрше Мари республикасына — урман эшенә китеп барган, андагы комбинатларга күчкән, Казанга китеп, заводларга эшкә кергән иде.

Борһанов күчеп килгән елны район дүрт центнер тирәсе уңыш җыеп алды, ул бит чистартканнан соң чәчүлеккә дә җитми, симәнәне башка урыннан табарга туры киләчәк. Колхозчыларга бирергә — икмәк, терлекләргә фураж юк.

Август урталарында, ниһаять, халык зарыгып көткән яңгыр явып алды. Моның бәрәңгегә шифасы тиде, симәнәгә салып куйгач, малтуарга ашату өчен бераз бәрәңге калды. Колхоз амбарыннан өмет итә алмагач, халык тулаем Казаннан ипи ташып ашауга күчте.

Тимерхан беренче нәүбәттә районның «Искра» колхозына килде. Анда председатель булып алыштыргысыз җитәкчелек иткән кеше — даны республикага таралган Фәйзи Галиев эшли иде. Хуҗалык зур, җиде авылны берләштерә, авылларны карап-барлап чыкканнан соң, икәүләп әңгәмә кордылар. Бу сөйләшүдән Борһанов күп нәрсәне аңлады. Фәйзи, аның кебек үк фронтовик, хуҗалык белән озак еллар тоташтан җитәкчелек иткәнгә, ул һәр нәрсәгә үз чынлыгы белән бәя бирә, муллыкның каян барлыкка килүе Фәйзи Галиевкә көн кебек ачык. Ул саннарны санга куша, саннарны саннан аера, ул төп байлык чыганагы итеп җирне һәм анда бил бөгүче игенчене генә таный. Мал-туарга фуражны җитәрлек калдыра алмаса да, аның чәчеп үстергән үләннәрдән өеп куелган эскертләре бар, табигый болыннардан чабып алган печән кибәннәре бар, булган саламны ул, әрәм-шәрәм итмичә, көздән үк терлек абзарлары янына кайтарып өйдергән, бәрәңгене дә, башкаларга караганда, күбрәк калдырган.

Ул чакта ук инде колхозны унсигез ел җитәкләгән Фәйзи, олылап әйткәндә, Фәйзи Әхмәтович, колхозда эшче көчләре дә, механизаторлар да җитәрлек икәнен әйтте. Зур һөнәр алырга — артист, язучы, рәссам, инженер, очучы, галим булырга теләгәннәрне Фәйзи Галиев тотмый, аларга булыша, тик бер генә үтенеч белдерә: зур кешеләр булгачыннан да алар туган-үскән ояларын онытып бетермәсеннәр, кайтып күренсеннәр иде...

Фәйзидән соң Тимерхан икенче фронтовикка — Нәкыйп Сафинга барды. Сугыш герое хезмәт фронтында ниләр майтара, янәсе.

Сафин совхозы — элеккеге Кызыл юл районының үзәге булган Кенәр янындагы авыллардан тора, Кенәр үзе дә совхозга бер бүлекчә булып керә иде. Кешеләре тырыш, тәртипле, әмма, соңгы елларда иген уңмау сәбәпле, экономика шулай ук түбән, халыкның ашар икмәге юк.

Совхозлар ул вакытта ук дәүләт тарафыннан финанслану аркасында, алардагы хәл колхозлардагыга караганда өстенрәк, акрын булса да, төзелеш тә бара, машина-техника да кайта, эшчеләр дә адым саен зарланышып йөрмиләр. Бу хәл Тимерханны бераз булса да тынычландырды.

Башка хуҗалыклар белән дә берәм-берәм танышып чыккач, Борһанов, кул кушырып утырырга ярамый, эзләргә, бу авырлыкларны җиңүнең чарасын табарга кирәк, дигән фикергә килде. Беренче чиратта үрчемне сакларга, терлекләрнең кырылуына юл куймаска! Колхозчы үз хуҗалыгында бәрәңгене үстерә белә, мул уңыш ала. Көзен артыгы белән кайтарып алырга килешеп, алар беркадәр бәрәңге бирделәр — терлекләргә ярап куйды анысы. Алар спирт заводыннан сыерларга һәм сарыкларга ашату өчен бәрәңге калдыкларын алырга килештеләр. Казанның «Кызыл Шәрекъ» сыра заводы арпа калдыкларын колхозларга бирергә, шуның бәрабәренә ашлык ташу һәм заводтагы әзер сыраны сәүдә оешмаларына илтү өчен колхозлардан машина алырга булды.

Әтнәнең райбашкарма председателе Фатих Минушевның абыйсы Салих Минушев Казан шәһәр комитетының административ бүлек мөдире икән. Фатих абыйсы янына барып сөйләште: Казан ресторанnарындагы азык калдыкларын Әтнә колхозларына гына бирсеннәр иде. «Кызыл таң» колхозы (Ключий Сап авылы) шушы нигездә дуңгыз симертүне оештырды. Ярты еллап вакыт узгач, колхозда семинар-күргәзмә оештырылды. Дуңгыз күп, дуңгызлар симез, үз авырлыкларын күтәреп, аякларына да басып тора алмыйлар. Семинарда катнашучы зоотехниклар күрә: дуңгыз абзарлары тирәсендә шампан бөкеләре, этикеткалар аунап ята.

Зоотехникларның берсе семинарны мактый, шаяртып әйтә:

— Иптәш председатель, дуңгызларыгыз аягына да басып тора алмый. Әллә сез аларны шампан шәрабе белән сыйлыйсызмы?

Рестораннар, завод калдыклары белән генә мал-туар асрап булмаганны һәркем белә. Югарыда да моны аңлыйлар, республика ресурсыннан ара-тирә фураж да биреп куйгалыйлар. Ләкин үз хуҗалыгыңда булмаса, андый ярдәм белән генә ерак китеп булмый.

Кышлату чоры узды. Терлекләрне язга алып чыктылар. Кояшка сыртларын куйган ябык сыерлар капка төпләрендә, ферма ихаталарында басып тора, каргалар алар тиресендәге украларга куна.

Борһанов та язга чыкты. Ул хәзер колхозлардан кайтып керми, мал-туарның күпләп үлү очраклары булмауга шыпырт кына шатлана. Аның хәзер барлык вакыты райком белән колхозлар арасында йөреп уза, өйләренә сирәк эләгә. Колхозларны бер Борһанов кына кайгыртмый, алар бюро әгъзаларына бүлеп бирелгән, хуҗалыктагы хәл өчен бюро әгъзасы колхоз председателе белән тигез җавап бирә.

Иртә килгән язның чәчү мәшәкатьләре дә иртә башланды.

1962 елның 17 апрелендә инде чәчүгә чыктылар. Әтнә районының «Үрнәк» колхозында бодайны кипшенеп өлгергән беренче мәйданда хәтта 12 апрельдә үк чәчтеләр. Туфрак эшкәртү анда барлык кагыйдәләренә туры китереп эшләнде. «Үрнәк»не, аның председателе Бариевны райком секретаре өлге итеп куйды, аның белән тигезләшергә чакырды.

Сабан ашлык әйбәт тишелде. Орлыклар борынлап чыкканчы көннәр җылы торды, бу исә көлсу туфрак өчен мөһим шартларның берсе иде. Тимерхан елларның, һава шартларының җайлы килүен бик теләи, аның яңгыр теләмәгән бер генә көне дә юк иде.

Бу уңайдан ул Сталин белән Черчилльнең сөйләшүен исенә төшерде.

Черчилль әйткән, имеш: мин совет халкына бәхет телим, дигән. Сталин әйткән: әгәр син, Черчилль әфәнде, совет халкына бәхетне чынлап торып телисең икән, майда һәм июнь аенда СССРда берәр яңгыр булсын, дип телә, дигән.

Тимерхан Борһановның да күзе хәзер күктә, болытларда. Теләп тә карый иде соң ул яңгырны!

## Тугызынчы бүлек!

Чәчү эшләре бетеп, сабан ашлык тишелеп чыккач, Борһановны Казанга — киңәшмәгә чакырдылар.

Әтнәне чыгу белән «Үрнәк» колхозы кырлары башлана. Анн—Бәрәскә басулары. Тимерханның Мөслим ягында үскән игеннәрне күргәне бар. Хәтфәдәй басулар күзләрне иркәли иде анда. Әтнә басуларын ул күзен дә алмый карап барды: ямь-яшел кырлар нәкъ менә Мөслимдәге төсле сөендерә иде аны.

Узган елгы корылыктан соң, нибары дүрт центнер чамасы ашлык җыеп алганнан соң, быел инде игеннәр күкрәп үссен, уңыш мул булсын, дигән өметле уй җанда саклана иде.

Өлкә комитетының яңа бинасына килеп кергәч, бүлек мөдире Александр Петрович Бушнев та аңа шатлык өстәде. Имән кискәседәй нык вә юантык, чыраенда беркайчан да күләгә-мазар булмый торган бу кеше, бите-башы белән елмаеп каршылады Тимерханны.

— Әйдәгез әле, иптәш Борһанов, яңа бинаның актлар залын күрсәтим әле сезгә,— диде.

Зал бик иркен, биек түшәмле, кызыл хәтфә белән тышланган урындыклар, тәрәзәләрне япкан яшел шторлар, президиум өчен биегәя барган баскычлар итеп ясалган урындыклар һәм сәхнәнең нәкъ уртасына куелган постау япмалы озын өстәл, имәннән кырлы-кырлы итеп ясалган биек трибуна, аның фронтонына куелган СССР гербы — барысы да күңелне кинәндерерлек дәрәҗәдә матур, зәвыклы һәм затлы иде.

Җиде йөз кешелек шушы залда киңәшмә башланып китте.

Министрлар Советы башлыгының докладын — шәһәр халкын терлек продуктлары белән тәэмин итү мәсьәләсен тыңлаганнан соң, кыска вакытлы тәнәфес игълан иттеләр. Киңәшмәне өлкә комитетының икенче секретаре Виктор Петрович Никонов алып бара, беренче секретарь Табеев ялда икән.

Тәнәфестән соң эшләр барышын хәбәр итәр өчен сүз Борһановка бирелде.

Икенче секретарьның кулында — барлык районнар турында тулы мәгълүмат. Борһанов авыз ачып әле бер сүз дә әйтергә өлгермәгән иде, секретарь аңа шундук сорау бирде:

— Сез иптәш Борһанов, ни өчен колхозчылардан бозау контрактовать итмисез?

«Тора торгач торжагун» дигәндәй, һич тә көтмәгәндә, кинәт, маңгайга бәреп, тактсыз рәвештә бирелгән әлеге сорау Борһанов кебек һичкайчан каушамый торган нык адәмне дә каушатып җибәрде. Чебен очкан тавыш та ишетелерлек тынлыкта ул бер-ике генә сүз әйтерлек көч тапты үзендә:

— Без бу эшне башладык, иптәш Никонов. Көчәйтербез.

Никонов, аңа ачулы караш ташлап, өздереп әйтте:

— Нәрсә, без сине, иптәш Борһанов, Әтнәгә безне тыңламаска дип җибәрдекмени?

— Мин куелган мәсьәләнең җитдилеген аңлыйм. Эшне төзәтербез.

— Күрербез, ничек төзәтерсең икән? Утыр. Уйла, кайтканчы уйлап бетергән бул!

Киңәшмәдә Абдразяков сүз алды.

— Менә, иптәшләр, без монда Борһановның белдерүен тыңладык. Без нәрсә аңладык? Без шуны аңладык: районда колхозчылардан бозау контрактовать итү начар куелган. Мин әйтер идем, хәтта бик начар. Әтнә

халкы, бозауларны колхозга сатасы урында, аларны өч яшенә җиткәнче үстереп, симертеп, Казанның колхоз базарына алып килә, өчләтә кыйбат бәягә сатып, шәһәр халкын талый, эшчеләр сыйныфының соңгы тиенен суырып ала. Моннан нинди нәтиҗә чыгарабыз? Моннан, иптәшләр, шундый нәтиҗә чыгарабыз: Борһановны кисәтеп, аның шәхси җаваплылыгын исенә төшерергә, инде шуннан соң да эшне төзәтмәсә, партия җәзасына тартырга кирәк, каты җәзага.

Борһанов сәхнәдән төшеп, алгы рәткә утырды. Әтнә басуларында игеннәрнең тигез тишелүен күреп хозурланудан берни дә калмаган, Әтнәгә райком секретаре булып барырга риза булуыннан ул үкенә үк башлаган иде инде. Хикмәти хода, син әле районга күчеп, колхозлар белән, райкомдагы кадрлар белән танышып кына чыктың, син әле ничек кирәк алай терлекләрне кырдырмый кышлатып чыгардың, сине инде республика алдында хур итәләр. Ичмасам, ул терлекләрне ничек саклап алып кала алдыгыз, дип сорасалар иде. Аның тәне авырайды, фикерләре чуалды, гарьләнүе, тимгел-тимгел булып, битенә бәреп чыкты. Ул бит Мөслимдә икенче секретарь чагында бер елда өч еллык ит тапшыру планын үтәү хакындагы рапортка үзе кул куйган иде. Алары төш кенә булдымыни соң? Нигә аларны бер дә искә алмыйлар?

Шулай да Борһанов киңәшмә барышында әкренләп тынычланды, үзен кулга алырга өлгерде.

Ул Әтнәгә кайтты. Бюроны җыйды, хәлне аңлатты.

Иртәгесен колхоз-совхоз җитәкчеләрен җыйдылар, сөйләштеләр. Алар риза булды. Нәкыйп Сафин тәкъдим кертте:

— Безнең якларда моңарчы колхозчыдан бозаудыр, сарыктыр ише мал-туар җыю булмады. Контракт димәгәең, әллә нәрсә диген, барыбер талау инде ул. Шул эшкә обком тотынган икән инде, Министрлар Советы теше-тырнагы белән ябышкан икән, бездән генә алмый калмаслар. Сез риза булсагыз, мин мондый тәкъдим кертәм: колхоз башлыкларына, совхоз директорларына бу эшне үзләре генә башкарып чыгу авыр булыр, аңа вакыт та күп китәр. Райком секретаре Тимерхан Борһанович радио аша чыгыш ясап, шуны бөтен районга җиткерсә, әйбәт булыр иде. Ни дисәң дә председатель — председатель инде ул, райком — райком.

Бу фикерне хупладылар.

Борһанов радиодан сөйләде. Колхозларга вәкилләр китте. Колхозчылардан сатып алына торган бозауларның һәм сарыкларның тере үлчәвенә бер сум акчалата түләргә карар кылынды. Өч көн эчендә хуҗалыклардан өч меңнән артык бозау, ике меңнән артык сарык сатып алынды.

Соңга таба беленде: кайбер районнарда терлек контрактацияләүдә тупаслыклар да булган.

Тукай районының Шурабаш авылыннан да Мәскәүгә шикаять киткән. Хатны тикшерергә Әтнәгә Үзәк Комитет инструкторы килде. Үзе белән ул Усман Җиһаншинны алды.

Тикшерделәр, белделәр. Хатны җәйге каникулга кайткан студент язган. Бозау хуҗасы малын көчләп алу турындагы фактны расламады.

— Минем уем, әлбәттә, бозауны олы мал итеп суеп сатарга иде. Әмма райком секретаре радио аша бик үтенеп сорагач, риза булдым — бердәнбер бозавым үзем теләп саттым колхозга.

Ризалык белән саткан булса да, Тимерхан мондый хәлләрнең дөрес түгеллеген ул чакта ук аңлый иде. Әмма өстән кушкач — үтәми кара. Азактан нәрсә буласы билгеле бит. Тик бер генә нәрсә Борһановны юата, өстә утыручылар да моны начар ниятттән чыгып эшләми, халыкка ит булсын дип эшли, шәһәр кешесе, завод-фабрика эшчеләре авылга кайтып бозау үстереп йөри алмый бит.

...Бәла ялгызы гына йөрми, диләр. Хак сүз. Моның шулай икәненә Тимерхан шул ук алтмыш икенче елны тагын бер кат ышанды.

Май урталарында җылы яңгырлар явып торды. Игеннәр күзгә күренеп үсте. Әтнә халкы шатланып яшәде, уңыш алырбыз, дип чынлап торып ышанды. Алар белән бергә Тимерхан да шатланып туя алмый, Мөслимдәге төсле уңыш алуга өмет итә иде.

Яңгырлар дәвамлы булып чыкты — былтыр яумаганны быел куып житәргә теләгәндәй, яуды да яуды. Иртән дә яуды, кичтән дә яуды, көндезен дә, төнлә дә туктап тормады.

Минераль ашламаларны күп кулланмагангадыр, ул елларны игеннәр иртә өлгерә, уракка да июль урталарында инде төшәләр иде. Әтнәдә 18—20 июльләрдә аеры уру башланды. Ул чорда бер комбайнга 550—600 гектар игенне урып-сугу йөкләтелә иде. Белгечләр, колхоз-совхоз башлыклары белән киңәшкәннән соң, уйлаган уйны радио аша барлык колхозчыларга, механизаторларга җиткерергә булдылар. 21 июль көнне кичен «радиоперекличка» дигән нәрсә үткәрелде. Нәкъ шул сәгатьләрдә яңгыр сибәли башлады. Бер-ике сәгатьтән ул бик көчәйде, чиләкләп коярга тотынды. Урамга чыгарлык түгел, яңгыр өермәсе аяктан егарлык иде.

Иртәнге дүртләрдә яңгыр тагын да көчәйде. Телефончы кызлар райкомга яңадан-яңа хәбәрләрне ирештереп тордылар. Яңгыр бөтен районда ява, су ярлардан чыккан, чокыр-чакырларны тутырган, тигез җирләргә, барлык болыннарга җәелгән, хәтта дамбаларны баскан.

Район су эчендә утыра.

Район үзәге Әтнәдән беркая да чыгарлык түгел.

Яңгыр тудырган хәвеф белән көрәшү өчен штаб төзелде, ул эшне Фатих Минушевка тапшырдылар.

Борһанов Ашыт суы буендагы Бәрәскә авылына барырга ният кылып, район юллар бүлеге башлыгы Фәизовка шалтыратты.

Фәизов хәбәр итте:

— Әтнәдән Дөбъязга тикле юл су астында. Күпер итеп салынган икешәр метр калынлыгындагы тимер-бетон торбаларны су агызып алып киткән.

Тимерхан юл бүлегенә:

— Көймә бирегез,— диде.

— Көймә бездә гомумән дә юк.

— Ни өчен юк?

— Суы булмагач, көймәсе ничек булсын?!

22 июль көнне яңгыр туктамады, көчәйде генә. Әтнә метереологиясендә эшләүчеләр яңгырның бер тәүлек эчендә 143 миллиметр яуганлыгын хәбәр иттеләр. Бу — райондагы еллык уртача явым-төшемнең яртысы дигән сүз иде.

Тимерхан Казанга — Никоновка телефоннан хәбәр итте. Ярдәм сорады. Амфибия машиналары белән хәрбиләр генә бу бәладән коткара алачаклар иде.

— Буада да көчле яңгырлар. Анда бер тәүлеккә 70 миллиметр яуган инде. Беренче чиратта аларга ярдәм оештырабыз,— диде Виктор Петрович.

— Аңлашылды, иптәш Никонов. Бездә бер тәүлеккә 143 миллим: э яуды инде. Дамбаларны су басты, күперләрне агызды.

Виктор Петрович бик тә борчылган тавыш белән:

— Ярар, сезгә ашыгыч ярдәм оештырырбыз,— диде.

23 июль көнне яңгыр тагын чиләкләп орды — 35 миллиметрга артты явым, барлыгы 178 миллиметр булды.

Шул көнне Казаннан солдатлар белән ике амфибия килде. Аларның эшен оештыру өчен Финанс министры Хәмит Әюпов җибәрелгән иде. Бу машиналар сыер савучыларны төяп берәр рейс ясагач, болындагы түмгәкләргә эләгеп, су эчендә торып калдылар. Аларны көчле тракторлар белән тарттырып чыгарырга туры килде.

Яңгыр өермәсен Әтнә халкы туфан калыкты дип бәяләде. Ике тәүлектән ары чиләкләп койган яңгыр субтропик урманнарындагы яңгырларга тиң иде. Һиндстанда субтропик яңгырлары машиналарны йөрүдән туктата, кешеләрне аяктан егып, агызып алып китә, шуңа күрә Һиндстан кешеләре субтропик яңгырлары вакытында урамга чыкмыйлар, шәһәрләрдә хәрәкәт туктап кала. Субтропик яңгыры җир өстенә койма булып ишелеп төшә.

Әтнәдәгесе дә субтропик яңгырыннан ким булмады. Печән кибәннәре суда йөзеп йөри, бүрәнәләр чайкала, төбе-тамыры белән купкан карт өянкеләр еракларга агып киткән.

Дусым авылының тау башыннан караганда болыннарны, уйсулыкларны баскан, чокырларны тигезләгән, дамбаларны күмгән су зур бер диңгезне хәтерләтә иде.

Ферма терлекләре лагерьларда иде. Яңгыр өермәсенең кинәт башлануы сәбәпле, хуҗалыклар зыян күрде. Ленин исемендәге колхозның 1200 баш сарыгы Иделгә агып китте. «Северный» совхозының дистәләгән дуңгызы Шушма елгасы буйлап Нократка китеп барды. Су тегермәннәре, җәйге лагерьдагы күчмә вагоннар, сыерларны ясалма каплату пунктлары да ишле суда агып китте. «Искра» колхозының печән кибәннәре болынны басып алган су белән Иделгә «сәяхәт»кә чыкты. Дөбъяз урта мәктәбенең кышка әзерләп куйган 400 кубометр утыны агып киткән — ташкын суы хәтта балаларны да кызганмаган.

Тимерханны шатландырганы һәм таң калдырганы шул: халык куркуга төшмәде, кул кушырып утырмады. Су белән бүленеп калган кешеләрне, мал-туарны коткару чараларын күрде.

Бәрәскә авылының комбайнчысы Галләм Фәйзерахманов үзе эшли торган комбайн белән ике рейс ясап, савымчы кызларны һәм җиңгиләрне су эченнән алып чыга. Колач җитмәс болын өсте су белән капланса да, комбайнчы ориентирны белә, чөнки ул анда уйнап үскән, печән чапкан, һәр түмгәк, һәр коры елга аңа билгеле.

Шул ук Бәрәскә авылыннан флотта хезмәт итеп кайткан диңгезче Гарифулла Хәмидуллин берүзе 200 баш сыерны котырынып аккан елганың бер ягыннан икенче ягына алып чыга. Ул моның әмәлен таба һәм шуны бик оста файдалана. Ул башта нәсел үгезенең ике мөгезенә бик ныгытып дилбегә урап бәйли, дилбегәнең икенче очын элмәкләп, ике иңсәсе аркылы үткәрә һәм, үгезне сөйрәп, суга кереп китә. Үгез артыннан ике йөз баш сыер да суга керә, йөзеп китә, барысы да исән кала. Бу бит, уйлап баксаң, киноларга төшерерлек манзара!

«Үрнәк» колхозы көтүчесе Галимхан, куаклы болынны су баскач, симертүдәге 100 баш үгезне бер урынга, куаклык янына туплап куя да үзе агач башына менеп, чыбыркы белән биленнән бәйләп куя, ике тәүлек буена малларны үз яныннан җибәрмичә, суга батып үлүдән коткарып кала.

— Ник йөзеп чыкмадың? — диләр аңа авылдашлары.

— Партбилетымны чылатудан курыктым, билетны коры килеш, алып кайтасым килде.

«Северный» совхозы директоры, солдатларына Днепрны кичүне оештырган Нәкыйп Сафин — Советлар Союзы Герое — кичке савымга килгән кызларның су эчендә калуларын белеп ала. Йөгерә елга буена — трусиктан гына калып, елганың аръягына йөзеп чыга. Кызларны берәмберәм елга аркылы чыгара башлый. Аркасына салып, йөзеп алып чыга ул аларны. Батыр йөрәкле кеше сугышта да, тынычта да батыр инде ул, курку белмәс, тәвәккәл батыр!

Табигатьнең гаҗәп сәер гадәтләре бар. Ул кеше законнарына буйсынмый. Безне озак еллар Мичурин — табигать сихерчесе — болай, дип әйткән, тегеләй дип әйткән дип алдап йөрттеләр. Имеш, табигатьтән мәрхәмәт көтәргә ярамый, без аңардан үзебезгә кирәкне көч белән алырга тиешбез, дигән Мичурин. Баксаң-күрсәң, бөтенләй дә алай түгел икән. **Табигатьне шулкадәр азаплагач, без аңардан мәрхәмәт көтә алмыйбыз,** дигән икән Мичурин бабай.

«Табигатьне азаплагач, миһербан көтә алмыйбыз»,— дигән шул. Табигатьтән талап алырга димәгән бабаң.

1961 ел Әтнәгә һәр гектардан 4 центнер чамасы икмәк алырга мөмкинлек биргән иде, икенче елны ук Әтнәләр гектарыннан уртача 18-әр центнер җыеп алдылар. «Искра», «Үрнәк», Жданов исемендәге колхозларда гектарыннан 25 әр центнер да чыкты. Ул еллар өчен бу могҗиза иде.

Утыз елдан артык вакыт узгач, 1994 елны Әтнә белән Буа җирләреннән тагын өермәле-давыллы яңгырлар узды. Сәгать ярым эчендә Әтнәдә 53 миллиметр яңгыр яуды. Хуҗалык һәм терлек каралтыларына зур зыян килде. Исәпләүләр буенча, Әтнә районына килгән зыян ике миллиард ярым тәшкил иткән. Әмма Әтнә районы хуҗалыклары җиргә давыл сылап, ябыштырып бетергән игеннәрне бөтен халык тырышлыгы белән аякка бастыралар, гектарыннан 40 ар центнер уңыш җыеп алдылар. Бу — республикада уңыш алу ягыннан икенче урын.

Хәзерге хуҗалыклар көчле, хәвефкә очраганны бик тиз тергезәләр. Ә теге чакта, 1962 елны, терлекләрнең җәйге лагерьларын тәртипкә кертү, савымчыларның эшен җайга салу, терлекләр санын давылга, туфан булганчы дәрәҗәгә җиткерү өчен күпме көч түгелгәнен Тимерхан үзе генә белә. Урып ташлаган арыш тезмәләрен өермәле яңгыр җиргә сылаган, аларның күбесе агып киткән иде. Аларны инде коткару мөмкин түгел, игеннәрнең калганын югалтуларсыз җыеп алу бурычы тора иде алда.

Шул эшне әтнәлеләр башкарып чыктылар. Мөслимнән Симонов конструкцияле җилгәргечнең сызымын алып кайтты Фатих Минушев. Электрга көйләнгән бу җилгәргеч кешеләргә — бигрәк тә аның эшләвен күреп кайткан делегациягә бик ошый иде. Аны һәр колхозга ясадылар — Фатих ясатты, ул үтә чыккан эшлекле, ихлас күңелле кеше гел менә булсынга гына йөри, җилгәргеч ясау белән ул үзе җитәкчелек итте, бу эшне урыннарда күрсәтеп, аңлатып бирә иде. Аның тырышлыгы белән зуррак колхозларда икешәр җилгәргеч булдырылды, һәм шулар эшне бик нык тизләттеләр.

Фатих боерыгы белән, кырлардан кайткан ашлык ындыр табагына бушатылмый, махсус ясалган бункерларга салына, бункерлардан исә җилгәргечкә механик рәвештә, үзеннән-үзе агып тора. Җилгәргеч электр көче белән, тәүлек буе, туктаусыз эшли. Дәүләткә ашлык тапшыруны көн саен эшләргә мөмкинлек тудыра җилгәргеч. Колхозларның икмәкне күп сатасылары килә,— акча кирәк. Икмәк халыкка бирергә дә, терлекләргә калдырырга да җитә. Казаннан килгән шоферларга шартлар тудырылган, ындыр табагында өзеклек юк, машиналар җилгәргән ашлыкны мөшкәдән генә агызып ала. Тимерхан боларны күреп тора, эшләрнең җайга салынуыннан канәгатьлек таба. Болар бит моннан бер-ике ел элек Мөслимдә булган хәлләрнең кабатлануы. Үзалдына уйлап та куя: бу бит бәхет, эшкә килгәннең икенче елында ук икмәгең уңсын әле!..

**1962** елның декабрендә районнарны эреләндерү башланды. Арча, Балтач, Тукай районнары зур бер районга әйләнде. Гигантомания кузгалды җитәкчеләр күңелендә. Боларның барысын Арчага туплап, райүзәкне Арчада ясадылар. 56 колхоз, 250 мең гектар җир, 200 дән артык авыл! Йә, моны кем гигант димәс?! Татарстандагы байтак район юкка чыккач, аларның райүзәкләре гади авыллар булып калды — аларда төзелеш туктатылды, административ биналар салу бетте. Ул районнарның бик күп җитәкчеләре эшсез интекте — аларның язмышы урындагы колхоз-совхозларга, авыл советларына, ә нигездә аларда яшәүчеләрнең мөстәкыйль рәвештә, үзбаш көн итүләренә бәйле булып чыкты.

Элек республикада 51 авыл районы бар иде, шулар хәзер 17 район булып оешты. Ул вакыттагы эшсез калган кешеләрнең, гаиләләренең нинди авырлык кичергәннәрен, йөрәк әрнүләрен Тимерхан бүгенгедәй хәтерли, берсе дә онытылмаган.

1962 елның 12 декабрендә Арчада Балтач, Арча, Тукай район Советы депутатларының берләштерелгән сессиясе булды. Сессия Тимерхан Борһановны район Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлап куйды. Элекке райкомнар урынына производство идарәләренең партия комитетлары төзелде — Арчада шуның секретаре итеп күп еллар төрле районнарда райкомның беренче секретаре булып эшләгән Мөхәммәт Закиров сайланды. Производство идарәсе начальнигы итеп Лев Шәрифуллин билгеләнде.

«Ярар, күченә торгач, Арчага да килеп җиттек, бәлки, монда төпләнеп, тамыр җибәрербез инде»,— дип уйлады Тимерхан.

Алай уйларга аның нигезе дә бар, 37 яшенә ул нинди генә урыннарда булмады да, кем генә булып эшләмәде!

Инде безнең Тимерханыбыз өр-яңа баштан Арчаны өйрәнә башларга тиеш булып чыкты. Районның җитәкче эшләренә һәм бүлекләргә, нигездә, Әтнә — Балтач кешеләре куелды. Күрде Тимерхан: Арча кешеләренең фатирлары бар — эшләре юк, Әтнә белән Балтачтан килгәннәрнең эшләре бар — фатирлары юк. Бу, әлбәттә, нормаль хәл түгел. Яңа хезмәткәрләрне тораклы итү — Тимерхан җилкәсендә. Ә фатир юк. Барысы да ерактан килеп эшли, төрле кешеләрдә куна, кайда туры килсә, шунда тамак ялгый.

Ул елны кыш буе буран булды, юлларны, урамнарны күмде, чана таккан тракторлар да үтә алмаслык урыннар күп иде. Балтач белән Арча арасында юл юк. Әтнә белән дә шулай.

Элек Арчадан җибәрелгән бер кешедән агач йорт торып калган. Ул хәзер — кунакханә. Шунда бер йөзгә якын «җаваплы эшче» өелеп ята. Район үзәгенә йомыш белән килеп чыккан кешеләр, бер килүдә йомышларын йомышлый алмагач, райбашкарма коридорында куна-төнә яталар. Юри уйлап чыгарсаң да, алай эшләп булмас иде кебек тоела Тимерханга. Эт баш, сыер аяк!

Дөрес булмаган түрәләрнең кылган гамәлләре, дөрес булмаган, валлаһи! Юкса сүтелгән, кителгән, кимсетелгән-таратылган районнарны утыз елдан соң кире кайтарырлар идемени?!

Гаделсезлекнең башы фатир кытлыгында сизелде. Торак йортлар салу өчен югарыдан акча бирмиләр, районның үз мөмкинлеге юк. Зарлануны берәү дә яратмый, бәхәсләшә башласаң — беттең! Эшсез калуыңны көт тә тор. Казанга барып, өлкә җитәкчеләре белән ипле генә сөйләшеп карый Борһанов — тыңлыйлар, ачуланмый гына әйтәләр: «Эзлә, тап, син шуның өчен куелган. Төшенденме, төшенмәсәң — төшендерербез!»

Арчадан чыгып качасы, Мөслименә әйләнеп кайтасы килгән көннәре күп булды Тимерханның!

Районда фатир алу озакка сузылу сәбәпле, Борһановка һәм поселок Советы председателе Гаффаровка җаваплы хезмәткәрләр үпкәләрен

ачыктан-ачык әйтә башладылар. Үз карамакларында булган чараларны да хутка җибәрделәр. Ул вакыттагы хәрби комиссар, поселок Советы председателен үзенә чакырып, Гаффаровтан йортын киңәйтер өчен бура буратуны таләп итә. Гаффаров әйтә, акча юк, ди. Икенче көнне үк хәрби комиссар Гаффаровка повестка җибәрә. 53 яшендәге кеше ике айлык хәрби сборга барырга тиеш. Гаффаров, нык рәнҗеп, Борһановка килде. Тимерханның Мөслимдә чакта андый повестка белән эш иткәне бар бит инде. Ул чакта әле ул яшьрәк тә, тәҗрибәсезрәк тә иде, шулай да әрсез комиссарны җиңә алды. Хәзер аның тәҗрибәсе дә күбрәк, хокукы да зуррак. Өстәвенә, ул үзен кайгыртмый, районның бер җитәкчесен кайгырта.

Борһанов хәрби комиссарны үз кабинетына чакырып, сәгате-минуты белән килеп җитәргә боера. Теге килә, килми хәле юк.

Бик тыныч, хәтта артык тыныч тавыш белән башлый сүзне райбашкарма председателе:

— Иптәш военком,— ди,— хәрби комиссариатны сезнең үз шәхси мәнфәгатегез өчен файдаланырга ни хакыгыз бар? Йә Гаффаровтан, илле өч яшендәге кешедән, повестканы хәзер үк аласыз, йә мин сезне партконтрольгә бирәм.

Хәрби комиссар повестканы алуы һәм Гаффаровтан гафу үтенүе хакында райбашкармага — Борһановка хәбәр итә.

Райүзәк — Казан каласы түгел, анда яңа хәбәр сәгате-минуты белән тарала. Борһановның гаделлеге турындагы сүз шул ук көнне Арча халкына барып ирешә. Бу — аз да түгел, күп тә түгел — абруй дигән сүз.

Тимерхан үзе дә фатирсыз иде. Ул Арча кунакханәсенә урнашты. Анда йокларга да урын юк. Әтнәгә кайтыр иде, вакыт юк, юлы да ташкүлчим! Буш вакытларында, кабинетында кеше-мазар булмаганда, Әтнәдә бергә эшләгән коллегаларын уйлап утыра. Фатих Минушевны Авыл хуҗалыгы министрлыгына алдылар, аның эш көйле булырга тиеш, ни дисәң дә Казанда фатир табу ансатрак. Усман Җиһаншинны Куйбышев районына җибәрделәр, производство идарәсе начальнигы итеп, аның эшләре кай тирәдәрәк икән?

Борһанов берәр колхозга барырга дип кузгала. Кабинетыннан коридорга чыкса, халык, халык, баш тыгарлык та түгел. Элекке өч районнан җыелганнар бит. Райбашкарма коридоры Казанның тимер юл вокзалын хәтерләтә. Кешеләр килә тора, китә тора, районым бетте дип өендә генә ята алмый бит инде адәм баласы. Аның йорт саласы бар, укырга китәсе бар, тагын әллә нәрсәләр эшлисе бар. Шуның өстенә Казаннан командировка белән киләләр, урнаштыруны үтенәләр. Балтачка яки Әтнәгә трактор белән илттереп куй аларны, кайтуына юл арчылган булсын...

Хәзер Тимерхан Борһанов уйлый: ул чагында өстән оештырылган бу мәхшәрләр кемгә кирәк булды икән? Күпме кеше салкын тидереп, авырып ятты, йөрәк җәрәхәте алды, бу эшләргә рәнҗеде.

Арчаның бер түрәсе булып сайланса да, Тимерхан үзе дә ул чактагы хәленнән риза түгел иде. Тик аның хәлен аңлаучылар, аңа булышучылар булу гына төшенкелеккә бирелмәскә ярдәм иткәндер. Аның хәлен иң нык аңлаучы, ихтимал, Гайнуллина Мәрьям, райбашкарма секретаре булгандыр. Тимерханга кадәр ул бүлек мөдире, райбашкарма председателенең урынбасары, райкомда секретарь булып эшләгән, белеме ягыннан педагог — Арча педагогия училищесын тәмамлаган, табигате белән көләч, якты йөзле, татлы сүзле, бер күрүдә кешеләрнең күңел түрендә урын ала торган кеше. Өч баласы бар. Менә шушы ханым үзе кыю, үзе ягымлы, вәгъдәсен беркайчан да вак тараканга ашатмас, әйткән сүзен ул егылып үлсә дә үти, эшне оештыра белә, һич кенә дә иренми, үзенә дә, башкаларга да таләпчән. Аны бер генә җөмлә белән «изге күңелле акыл иясе» дип бәяләргә булыр иде. Тимерхан белән эшләгәндә, ул үзенең вазифасын Арча буенча «җаваплы оештыручы» яки зур бер хәрби берләшмәнең оператив штаб начальнигы кебек башкарды. Гайнуллина белән унбиш ел

бергә эшләде Борһанов, алар гаилә дуслары булып калдылар. Мәрьям ханымның ире Рифкат Гайнуллин, «гомерлек балыкчы», озак еллар әзерләүләр оешмасында эшләде, сугыш инвалиды булса да, җәмәгать эшләреннән баш тартмый, башка ветераннардан алда йөри. Әгәр әнә шул ике дусты, гаилә дуслары булмаса, беренче елларны Тимерханга Арчада бик кыен булыр иде, ул, бәлки, шундый да авыр һәм мәшәкатьле йөкне тарта да алмаган булыр иде.

Акрынлап Арча үзәгендә дә фатирлар була башлады. Башта җитәкче хезмәткәрләр тәэмин ителде. Бер-ике елдан ике катлы, уналты фатирлы йорт төзелеп бетте. Тимерхан үзе дә кайсыдыр авылдан сатып алып кайткан агач йортны әмәлләп, шул йортка Әтнәдән гаиләсен күчерде.

## Уникенче бүлек

**1966** елның май ахырлары иде. Шулай бер көнне райбашкарманың чираттагы утырышы барган вакытта Казаннан шалтыраттылар:

— Иптәш Борһанов, Арчага Министрлар Советы председателе Гомәр Исмәгыйлевич килә. Сез аны Арчаның Биектау белән чиктәге «Заветы Ильича» колхозы җирендә каршы алыгыз.

Борһанов утырышны урынбасарына калдырып, әйтелгән урынга китте. Күңеле тыныч иде Тимерханның. Язгы кыр эшләре җиренә җиткереп башкарылган, инде тишелеп чыккан игеннәр басу туфрагын күмеп, хәтфәдәй яшәреп утыралар.

Усмановның Арчага беренче генә килүе түгел иде. Теге килүләрендә аны район җитәкчеләре бергәләп каршыладылар. Ә менә хәзер... бу юлы Борһанов иске «газигы» янында ялгызы гына басып тора. Машина шулкадәр дә иске, бәрелмәгән-сугылмаган урыны юк. Заводтан чыккан буяулары инде уңып беткән. Кеше күзе төшмәстәй машинасына карап, Тимерхан гарьләнеп куйды. Нигә яңа машина бирмиләр? Казанга терәлеп торган Арчаның райбашкарма җитәкчеләренә яңа машина хәрам мәллә?

Юлның калкурак урыныннан кара «Волга» килеп чыкты. Машина иске «газик» янына килеп туктады. Аңардан җиңел сөякле, ыспай гәүдәле Усманов чыгып, Тимерхан белән исәнләште. Башка бер сүз дә әйтмәстән, акрын гына «газик»ны әйләнеп чыкты, бер сорау ташлады:

— Кем машинасы бу?

— Үзебезнеке дип беләбез.

— Шаяртмый әйткәндә?

— Райбашкарма председателе йөри торган машина бу, Гомәр Исмәгыйлевич.

— Әйдә, минем машинага, шофер белән янәшә утыр.

Арча юлы белән киттеләр...

Ике атна чамасы узгандыр, Министрлар Советыннан шалтыраталар:

— Тимерхан Борһанович, сезнең райбашкармага Усмановның «Волга» машинасы бирергә дигән боерыгы бар. Хәзер үк шоферыгызны җибәрегез, машинаны алып китсен, шофер кайткач та миңа хәбәр итәрсез.

Бу — Совминның Эшләр бүлегеннән Янкин иде. Халык исемен яттан белә торган Григорий Иванович Янкин.

Бу вакыйгадан соң байтак еллар узса да, Борһанов моны чираттагы гади нәрсә итеп карамый. Гомәр Усмановның сүзен сүз итә торган, эшен эш итә торган кеше икәнен исенә төшерә. Югыйсә соңгы елларда, журналистлар, язучылар да хәтта, республика җитәкчеләренә гел кара буяу гына сылап куя башладылар. Әйтерсең, алар гел үзләрен генә кайгыртып яшәгәннәр, халык өчен, республика өчен берни дә эшләмәгәннәр.

Бөек Тукаебызга Кырлайдагы мәһабәт музей кайчан салынды? Табеев белән Усманов эшләгәндә. Ул музейны булдыру өчен кем кара тир түкте? Министрлар Советы председателенең беренче урынбасары Мансур Хәсәнов. Моны оныту, боларга күз йому — гаделсезлек булыр иде.

Борһанов унике ел Усманов җитәкчелегендә эшләде. Тимерхан аны эшлекле, принципиаль җитәкче итеп хәтерендә саклый. Юкка-барга исе китмәс, шарлатанлыкны яратмый, мактауга һәм мактануга кискен рәвештә каршы, «махсус әзерләгән обедларга» кермәс, «Башка вакытта, башка вакытта»,— дип кенә котылыр. Көннең көн буе йөрсә дә, район хуҗалыкларын карап, эт булып арыса да, ул Казанга кайтып китә, район җитәкчеләренә:

— Сез дә өегезгә кайтып, кичке ашыгызны хатыннарыгыз белән ашагыз,— ди иде.

Усмановның «башка вакытта» дигән сүзе Тимерханның күңеленә уелып калды. Арчада унбиш ел эшләү дәверендә Тимерханның райүзәккә кәефләнеп кайтканы булмады. Авыл җитәкчеләре «махсус әзерләгән обедларга» чакырган чакта, ул Усманов сүзе белән: «Башка вакытта»,— дип җавап бирә иде.

Казанга күчеп китәргә булгач, колхозлардан аны озатырга дип килгәннәр иде.

— Әйдәгез, сезне бер булса да адәм рәтле итеп озатыйк инде, теге чакта, без сезнең кул астында эшләгәндә, «башка вакытта» дип китеп бара идегез, ә хәзер нишлибез? — диделәр.

Тимерхан әйтте:

— Менә минем адрес. Өйгә кунак булып килсәгез, ничек тә рәтен табарбыз. Ә хәзергә, юл кешесенең юлда булганы яхшы, диләр, мин гаиләм белән кузгалыйм...

## Унөченче бүлек

Тимерхан Борһанов — зур язмыш кешесе. Дөнья җилләре, заман давыллары аны ил буйлап та, республика буйлап та күп йөретте. Ятим бала булып үсте. Анысы «Тимерханның яшьлеге» дигән повестемда тәфсилләп сурәтләнде. Япон самурайларына каршы сугышты, сигез елга якын армия хезмәтендә бил бөкте. Югары партия мәктәбендә укыды. Мөслимдә, Әтнәдә партия эшендә, Арчада райбашкармага килде — иң күп утырып эшләгәне биредә булды. Мөслим сабакларын, Әтнә тәҗрибәләрен, партия өлкә комитетындагы өлкәннәрдән отып алганнарын Арчада тормышка ашырырга тиеш дип тапты. Кадрларны өйрәнү мәктәбен дә, колхоз председательләре корпусы белән эшләүне дә, бозау контрактациясен дә, табигать афәтләрен дә, дәүләткә икмәк тапшыру мәшәкатьләрен дә — барысын да күрде Тимерхан. Арчада фатирсызлыктан, кешеләрне урнаштырудан интекте. Эшләмәгән эше калмады Тимерханның. Әмма Арчада бер эшләмәгән өлкәсе, дөресрәге — җиң сызганып, бөтен күңелен салып эшләмәгән өлкәсе калган икән әле.

Арчада ул культурага аеруча игътибар итәргә тиеш булып чыкты. Ник дигәндә, Арча — Казан арты, Арча — Тукай ватаны.

...1975 елның сентябрь азакларында Татарстан хөкүмәте Тукайның 90 еллыгын уздыру турында карар кабул итте. Шул уңайдан Министрлар Советына чакырып алдылар Борһановны. Чакыручы кеше Министрлар Советы председателенең урынбасары Мансур Хәсәнов иде. Озынча ыспай гәүдәле, такыр башлы булганга зур маңгайлы, сүзен өзеп кенә сөйләшә, бәхәсләшүченең ике сүздән авызын каплый ала торган Хәсәнов аны үз кабинетында, ике тумбалы массив өстәл яныннан чыгып, рәсми

рәвештә каршылады. Кабинетта Хәсәновтан тыш, мәшһүр рәссам Бакый агай Урманче бар иде. Кулына ике катлы агач йортның эскизын тоткан Бакый агай башлады сүзне:

— Тимерхан туган, менә бу рәсемдәге ике катлы йорт Тукайның төп музее булып Кырлайда салынырга тиеш,— диде ул һәм эскизны өстәл уртасына бастырып куйды.

— Йортны салуның срогы бик кыска,— дип Хәсәнов рәссам сүзенә ялгап алып китте.— Бина 1976 елның 26 апреленә төзелеп бетәргә генә түгел, тулысынча музей итеп җиһазланган да булырга тиеш.

— Йортның проекты юк, төзүчесе билгеләнмәгән, акчасы да бүленмәгән, нибарысы ярты ел вакыт калган, без аны ничек төзеп бетерәбез инде?

— Тимерхан Борһанович! — диде Хәсәнов, калку күзләре белән Борһановка төбәлеп.— Хәзерге заманда, төзелеш бик тиз кирәк булса, проект-мазар көтеп тормыйлар, эшне башлыйлар да, аннан рабочий чертежлар сызып, төзелешне дәвам итәләр. Проекты булыр, исәп-хисап эшләрен башкарыр өчен сметасы төзелгән булсын.

Борһанов белә, Хәсәнов сүзне кабатларга яратмый, аның фикере төгәл була, димәк, эшне кичекмәстән башларга кирәк.

Иң әүвәл Тимерхан госпланга керде. Председатель урынбасары Мөхәммәтҗановка хәлләрне сөйләп бирде, музей бинасына иң яхшы нарат бүрәнәләр кирәк булуын әйтте.

— Иң яхшы наратлар электрлаштыруга гына рөхсәт ителә,— дип кырт кисте Камил Мөхәммәтҗанов.

— Ә мин нәрсәгә сорыйм? Электрлаштыруга түгелмени? Кырлайдагы искергән электр баганаларын алыштырырга кирәкме? Яз нарәтне менә шуларга дип!

— Бу — идея! — диде Мөхәммәтҗанов.

Икенче эш итеп Тимерхан Тукай-Кырлайга барды, председатель Ленар Вәлиуллинны эзләп тапты. Мари белән чиктәш Шурабаш авылы янындагы нарат урманына килделәр. Борһановның кулында госплан нарәте иде инде, төзелешкә кирәкле нарат диләнкесе сайладылар.

Урман һавасы тынга кабар дәрәҗәдә саф иде, нарат ябалдашлары арасыннан кыеклап кояш нурлары сузылган иде.

Диләнкене барлап йөри торгач, аларның күңеле күтәрелде. Алар башта утырып киңәштеләр, аннары кулларын баш астына куеп, коелган ылыслар өстенә сузылып яттылар. Урман һавасы үпкәләрне чайкап, җанны рәхәтлек белән тутыра иде.

Наратлар барысы да зәңгәр күккә сузылалар. Егерме бишәр метрлы наратларның югары очындагы ябалдашлары арасыннан зәңгәр күк күренә, наратлар бер урында әйләнәләр сыман иде. Шуларга карап озак яттылар, ниһаять, Тимерхан түзмәде:

— Тукай гомер буе кеше бусагасында йөргән. Аның Казандагы Болгар номеры да сигез метрдан артмаган. Беләсеңме, Ленар, без синең белән бөек шагыйрьгә ике катлы, әллә ничә бүлмәле, бер мең ярым квадрат метрлы йорт салып бирик әле, ә? Шул эшебез өчен, бәлки, тарих безне дә онытмас,— диде.

Тик бу эш алда иде әле. Чамасыз күп тырышлык, булдыклылык, оештыру сәләте таләп итә иде Тукай йорты. Балта осталары, столярлар, пыяла куючылар, слесарьлар, калайчылар, буяучы-малярлар табарга кирәк. Аларны бөтен районны бетереп эзлисе бар.

Шулай да иң әүвәл урман кисүчеләр кирәк — алары Кырлайдан табылды. Октябрь-ноябрь айларында урман киселде — Тукай йортына кирәкле бүрәнә әзерләп куелды. Тик аны Кырлайга ташып булмады әле. Урманга кәрә торган төштә зур сазламык бар иде, көннәр суытканны, кыш җиткәнне көтәргә булдылар. Җитмеш алтынчы елның кышы салкын һәм буранлы булды. Шулай да «Сельхозтехника»ның Кенәр бүлекчәсе, тракторлар һәм кешеләр биреп, бүрәнәләрне кайтартты.

Арча районындагы балта осталарының иң маһирлары Хәсәншәех белән Апазда икәнен белә иде Арча халкы. Борһановка шуны җиткезделәр. Алар белән сөйләшүе җиңел булмаячак. Осталар үз базарын белә — бәяне югары тота. Шулай да «Ватан» совхозы дирекциясе район җитәкчеләренең сүзен тыңлады — кирәк кадәрле останы бүлеп бирде. Райбашкарма, райком белән килешеп, алар куйган эш бәяләрен кабул итте. Эшне башлап җибәрәсе иде дә — проект юк. Арча райбашкарма председателенең урынбасары булып Казанның инженер-төзүчеләр институтын тәмамлаган Калуева эшли иде. Тәҗрибәле инженер Тукай йортының проектын төзүне дә, сызымнарын ясауны да, сметаларын булдыруны да үз өстенә алды. Балта осталары беренче күрсәтмәне аңардан алып, эшкә керештеләр.

Кырлай авылы тормышында тарихи чор башланды. Пычкылар чыжлаган, балталар тукылдаган тавыш иртә таңнан караңгы төшкәнче авыл урамнарын яңгыратып торды, якын-тирәдәге урманнарга бәрелеп, шаңдау булып кире кайтты.

«Ватан» совхозыннан алты кешелек бригада килгән иде. Кара исәп белән чутлаганда да, әлеге бәләкәй бригада көне-төне, тәүлекләр буе ялсыз-нисез эшләгәндә дә, Тукай йорты өлгермәячәк. Шурабаш авылыннан тагын алты кешелек бригада китерелде. Ишек-тәрәзә рамнарын, кәрниз орнаментларын ясау кебек столярлык эше Яңа Кенәр промкомбинатына тапшырылды, музей йортының әйләнә-тирәсен бизәү-җиһазлау, рәшәткә кору, буяу-матурлау эшләрен Әтнәдәге төзелеш оешмасына йөкләделәр. Әйләнмәле түгәрәк тимер баскычларны ясау белән Арчалар шөгыльләнде. Дөньяда «Сельхозтехника» дигән тешеңне сындырырлык сүз бар, әнә шул оешманың Арча бүлекчәсе ажурлы баскычлар ясауны үз өстенә алды. Музей йорты алдына аның хуҗасы Тукай куелырга тиеш. Ул һәйкәлне, Тукай шүрәлеләрен агачтан кисеп, Бакый Урманче әзерләде.

Тукай йорты кешеләрне кузгатты. Борһанов үзе Казанга атна саен диярлек барып торды. Мансур Хәсәнов, культура министрын яки Язучылар союзы председателен үзе белән алып, ак «Волга»сында Арчага кайтып төшә, райкомга керә, райбашкармадан Борһановны таптыра, эшләрнең барышы белән иркенләп таныша иде. Кырлайга да ничәмәничә тапкыр барганы булды аның. Бәләкәй Апушны асраган Сәгъди йорты да, мәктәп янының пөхтәлеге дә, авылның үзенең төзек һәм чиста булуы да аның өчен бик мөһим. Әмма барыннан да бигрәк ул Тукай йортының матур булуын, Җир шарының теләсә кайсы почмагыннан килеп чыккан кешегә дә ошавын тели иде. Чөнки Тукайның 90 еллыгына Мәскәүдә Бөтенсоюз комиссиясе төзелеп, комиссиянең җитәкчесе итеп атаклы шагыйрь Михаил Луконин билгеләнгән иде. Тукай бәйрәменә СССРның һәр республикасыннан кунаклар киләчәк, алар кимендә 30 язучы булачак. Финляндиядәге Тукай җәмгыятеннән дә мәртәбәле галимнәр бәйрәмдә катнашырга теләк белдерделәр[1].

— Әгәр башка берәр республикада Тукай кебек үзе бөек, үзе егерме җиде яшендә һәлак булган, нибары җиде еллык иҗат дәверендә даһи шигырьләр, публицистика, сатира, балалар өчен әкиятләр калдырган икенче берәү булса, аңа триумфаль музей салган булырлар иде,— дип ярсынып сөйләде Евгений Александрович Евтушенко.— Аның «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп иҗат ителгән татар балеты Европаны урап, Канадага тикле барып җитте бит инде. Хөрмәтле Табеев, сезнең Мәскәүгә ләббәйкә дип миллионлаган тонна нефтьне магистральләр буйлап кудыртуыгыз да, дәүләт амбарларына ел саен ике миллион тоннага якын

---

[1] Бу повестьның авторы ул хәлләрне инәсеннән җебенә тикле белә, Мәскәүдә Бөтенсоюз комиссиясен төзетүче дә, Кырлайдагы бәләкәй музейны күрсәтеп, Евгений Евтушенконы дулкынландыручы, азактан Тукайга атаклы музей төзетер өчен тынгысыз шагыйрьне Фикрәт Табеев янына кертүче дә ул иде.

югары сыйфатлы ашлык салдыртуыгыз да — берсе дә тарихта калмаячак. Салдырыгыз Тукайга музей — сезнең исемегез мәңгелек булыр!

Менә каян башланды ул Тукай Йорты! Менә нәрсәдән килеп чыкты Татарстанның Хөкүмәт карарлары!

Инде төзелешнең үзенә әйләнеп кайтыйк.

Тукай Йортын салу гыйнварда башланган иде, май башында төгәлләнде. Димәк, 26 апрельгә өлгертеп булмады, дигән сүз. Ләкин Тимерхан да, бу эшкә җаваплы Мансур Хәсәнов та борчылмадылар. Тукай бәйрәмен үткәрү төп-төгәл 26 апрельгә түгел, суык җилләр искән, яз яңгыры җирдән әле узмаган чакта түгел, җылы май аенда дип билгеләнде.

Бина үзе төзелеп бетсә дә, музей эчендә эш күп иде әле. Экспонатларны әзерләү, аларны урнаштыру Казанның сынлы сәнгать музеена, аның директоры Петровка тапшырылды. Бу эштә Казан рәссамнары һәм музей хезмәткәрләре армый-талмый эшләде.

Музей бинасы япа-ялгызы гына тырпаеп утыра алмый, музейның комплексы да була. Кырлайда урта мәктәп бинасын салу, мәдәният йортын булдыру, кибет фронтоннарын яңарту, колхоз терлекләре өчен яңа тип тораклар төзү, авыл уртасыннан ага торган инешне Тукай Йорты янында буа итеп кору, Арча белән Кырлай арасына 22 километр озынлыгындагы асфальт юл уздыру, авылны яшелләндерү, Арча белән Кырлай арасындагы юлның ике ягына буй урман утырту — болар барысы бер ел алдан эшләнделәр.

Авылны яңарту, аны төзекләндерү, экскурсиягә килүчеләрнең игътибарын җәлеп итәрлек итү — Тукайның 80 еллыгында ук эшләнә башлаган иде инде. Ә менә Тукай йортын салу, агач утырту 90 еллыкка гына эшләнә алды.

Арча — Кырлай юлындагы агачлар — буй урман — 1975 елны эшләнде. Заманында, Арчага бер килүендә, аны өлкән язучы, Гомәр ага Бәширов киңәш иткән иде. Борһанов ул хакта «Якты истәлек» дигән мәкалә дә язды, ул мәкалә «Ватаным Татарстан» да басылганнан соң, академик, Татарстан Фәннәр академиясенең Президенты Мансур Хәсән улы Хәсәнов үпкә белдерде. Гәзиткә язып түгел, халыкка кычкырып түгел, үзара сөйләшкән чакта, иптәшләрчә.

Һәм ул хаклы иде.

Киңәш бирү — бер нәрсә, шул эшне тормышка ашыру — бөтенләй икенче нәрсә бит. Тукай узган юлларга агач утырту өчен Мансур Хәсәновка күпме чабарга туры килгәнен мин бик яхшы беләм. Минем ул чактагы эшем — Тукайның 90 еллыгы белән турыдан-туры бәйле иде. Һич ялгышмый әйтә алам — җитәкчелек Мансур Хәсәнов кебек нык куллы, аз сүзле, әйткәнен үтәтми калмый торган җитәкче кулында иде.

Боерыкны бирүчеләр бар, шуны гамәлгә ашыручылар бар. Менә монда инде таякның юан башы Тимерхан Борһанов өстенә төште.

Министрлар Советының авыл хуҗалыгы эшләрен алып баручы Борис Мартынов янына керде. Кырлай юлына, асфальтның ике ягына буй урман утыртырга кирәклеген сөйләп бирде. Рөхсәт итегез, диде.

Борис Павлович — болай йомшак табигатьле кеше, усал итеп дәшмәс, тавышын күтәрмәс, чыраенда да аның беркайчан да ягымлылык китми. Бу юлы да ул усал сөйләшмәде, йомшак кына итеп:

— Ничә балаң бар? — дип сорады.

— Өчәү, — диде Тимерхан.

— Сөрү җирләренә агач утырту җитәкчелек күрсәтмәсе белән катгый рәвештә тыела. Күрсәтмәне боздыңмы — партбилетыңнан колак кагасың! Балаларыңны ач калдырасың килмәсә, баш катырып йөрмә, Тимерхан Борһанович.

Уйланып-газапланып берничә көн үткәргәч, янә Казанга — бу юлы Усмановның үзе янына ук юнәлде Тимерхан.

— Нигә килдең? — дип туп-туры сорады Усманов.

Тимерхан Кырлай юлын сөйләде, буй урманның хыялдагы образын сурәтләде, әмма Мартынов янында булуын дәшми калдырды.

Усманов авыл хуҗалыгы бүлегеннән Лидия Таркаеваны чакырды. Сүзне ерактан китереп, дипломатларча башлады:

— Хөрмәтле Лидия Васильевна, безнең алда бик зур, бик мәшәкатьле эш тора бит әле. Республика җәмәгатьчелеге бөек Тукаебызның 90 еллык юбилеена әзерләнә. Шундый чараларның берсе — Арча белән Кырлай арасына асфальт юл җәю бара. Шул ике арадагы юлны тагын да матурлау, күз явыңны алырлык чибәр итү өчен юлның ике ягына агач утырту кирәк. Бу — халыкка истәлек, бөек шагыйрьгә хөрмәтебез булыр иде. Сезгә мәгълүм, юл буйларына агач утырту, сөрүлек җирләрне киметү кебек зарарлы практиканы без тыйган идек. Шулай да менә минем фикергә ничек карыйсыз? Мин моны фәкать сезнең карамакка калдырам.

Мондый ысул йомшак җәеп катыга салу дип атала. Түрә кеше «синең карамакка» ди икән, бу инде боерык дигән сүз. Тәҗрибәле, күпне күргән Лидия Таркаева эшнең кая таба тәгәрәгәнен шундук аңлап алды.

— Дөрес әйтәсез, Гомәр Исмәгыйлевич, чәчүлек җирләрен саклауны мин яклыйм. Моңа минем мөнәсәбәтем тәгәл һәм ачык: Тукай хакына сөрүлек җире бүлеп бирү ялгыш булмас.

«Дипломатлыкта болар берсеннән-берсе уздыра»,— дип елмаеп уйлады Тимерхан.

Арча урман хуҗалыгы юл буена агач утыртуга бик теләп тотынды. Директор Борис Абрамов әлеге эшне үзе күзәтеп торды. Җәй коры килгәнлектән, су сиптерүче машиналар белән агач үсентеләрен дымландыруны Борһановка ул кинәш итте. Арча — Кырлай юлындагы буй урманга ул елны дүрт-биш мәртәбә су сибеп чыктылар. Үсентеләрнең берсе дә үлмәде, корымады, күзләрне иркәләп, вак яфраклары белән лепердәшеп утырдылар.

Тукай бәйрәме буласы язны районга Табеев килде. Кырлайны карап, булачак музей йорты, башка биналар белән танышканнан соң, кайтырга чыктылар.

Табеев машинаны туктатып, буй урманны карарга төште.

— Фикрәт Әхмәтҗанович,— диде Борһанов,— без Кырлай юлына агач утыртып чыктык. Берүк безне ачуланмагыз инде...

— Күреп торам,— диде Табеев, иренен кысып.— Башка урында булса, моны эшләгән кешеләр җәзаның иң катысын алырлар иде. Сез дөрес эшләгәнсез, Тукайга истәлек булсын!

## Ундүртенче бүлек

Тукай бәйрәмен Татарстан, гадәттә, 26 апрельдә уздырып килә иде. Быел, Тукайның 90 еллыгы булгач, Татарстан җитәкчелеге һәм Язучылар оешмасы Кырлайдагы бәйрәмне җылы май аенда үткәрергә булдылар.

Бу повестьның авторы ул заманда Язучылар оешмасының җитәкчесе булып эшли иде. Бәйрәмнең май аенда үткәрелечәгенә ул сөенде. Ник дисәң — Советлар Союзының төрле почмакларыннан килгән кунакларга язучылар — Тукай оныклары — туган ягыбызның чәчәкле-гөлле аен күрсәтергә теләделәр. Кырлай урманнары яшел яфракларына төренеп, шаулап утырган чакта, менә шушы урманнарда булган инде Тукайның Шүрәлесе, дип сөйләп-аңлатып йөрү нинди күңелле! Кояш нурларына тулып торган ямьле май аенда иксез-чиксез илебезнең төрле якларыннан җыелган кунакларга «Тукай» теплоходын, Тукай исемендәге районны, авылларны, мәктәпләрне, культура йортларын күрсәтәсебез килә иде. Тагын бер мөһим нәрсәне онытырга ярамый, без Тукайның 90 еллыгын бөтен дөньяга чыгару — ЮНЕСКО аша үткәрүне юллап бетергән идек.

Мансур Хәсәнов тырышлыгы белән бәйрәмне үткәрергә Мәскәүдән — РСФСР Министрлар Советыннан 70 мең сум акча алуга ирештек. Хәзерге акча белән исәпләгәндә, ул 350 миллион сумнан артык. «Булгач-булгач булсын инде, булдыраек булмаса»,— дип тотынылды. Бәйрәмнең иң зур өлеше Арча районында булганга күрә, акчаның да байтак өлеше, Язучылар союзы бухгалтериясе аркылы, Арчага күчерелде.

Ни хикмәттер, Тукайга дөнья гомер буе рәхимсез булган. Тукай җылыга туймаган. Бәйрәмне кояшлы май аенда үткәрәбез дип кенә торганда көннәре кинәт суытып җибәрде. Майның инде икенче яртысы, ә урамда нибарысы өч градус җылы. Җитмәсә — җиле ачы, үзәкләргә үтә. Бәйрәм буласы көнне, бәлки, әле җылытып та җибәрер, дип көтсәк тә, булмады. Шул ук — өч градус җылы. Кунаклар инде җыелган, бәйрәмне үзгәртеп булмый.

«Акбүз атлар кузгалдылар авылга таба туры...»— дигән заман шагыйре. Тукай бәйрәменә авылга кузгалдылар машиналар: «Волга»лар, «Жигули»лар, «Москвич»лар. Иллешәр кешене төягән ике зур автобус кузгалды. Мәскәүдән һәм Ленинградтан, Урта Азиядән һәм Идел буе республикаларыннан, Уралдан һәм Себердән, Финляндиянең «Тукай» җәмгыятеннән килгән иде кунаклар...

Өлкән әдипләребез — Нәкый ага Исәнбәт, Гомәр ага Бәширов, Хәсән ага Туфан кышкы киемнәрдән — алар өстендә мех якалы кыска тун, башларында җылы бүрек.

Бернинди суыкка да, ачы җилгә дә карамый, Тукай бәйрәменә, Арчага, Тукай-Кырлайга барырга теләүченең исәбе-хисабы юк. Машиналар да, автобуслар да аларны сыйдырып бетерә алмады. Алар поездларга утырып, юлаучы машиналарны туктатып, үз җайлары белән китеп бардылар.

Урманнар, яшел болыннар, игене чайкала башлаган басулар аркылы узыла. Арчага килеп җитәргә ун чакрымнар кала, кунакларны Арча җитәкчеләре каршы ала. Җыр, бию, гармуннар, чәчәкләр, милли киемнәрдәге кызлар, чуптарлы сөлгегә куеп, күтәреп килгән табак чаклы зур чәкчәк... Йә, моның кай ягы Урта Азия республикаларындагы кунак каршылаудан ким?!

Суыктан туңган йөзләр языла, чырайларга елмаю нуры куна. Уен-көлке, бию-җыр, тәмле сулар җаннарны җылытып җибәрә.

— Йә, туганнар, хәлләрегез ничек? Бик туңмадыгызмы? — ди райком секретаре, кунаклар белән аралашкач.

— Хәлләр безнең ал да гөл, көннең суык икәнен үзең бел! — ди бернинди суыкка да бирешми торган тубал чәчле Туфан.— Кунакларның кәтгәләрен алып килдек. Үзегез әзерме?

— Әзер. Бөтен район кузгалды.

— Район гына түгел, бөтен республика кузгалды, иптәш секретарь,— ди райбашкарма рәисе Тимерхан Борһанов.

Мәскәү кунагы, Тукай бәйрәмен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе рәисе Михаил Луконин янә дә төзәтмә кертүне кирәк таба:

— Татарстан гына түгел, дөнья кузгалды. Мин әле ике көн генә элек Австралиядә идем. Егерме бер сәгать буе очып, аннан кайтып җиттем...

Машиналар кәрваны, Арчаны узып, Тукай-Кырлай юлыннан тезелеп бара. Юлның ике ягында урман полосасы, татарчалап әйткәндә — буй урман. Ул ун елдан, Тукайның 100 еллыгына күкрәп утырыр. Җиләс җилләр аның яфракларын лепердәтер. Ул чагында Тукай бәйрәменә килүчеләрне зифа буйлы яшь каеннар, мәңге яшь чыршылар, миләшләр каршы алып, озата барырлар.

Тукайның 100 еллыгына Рәис Беляев — заманында Чаллы каласын салдырган булдыклы зат — Кырлайның Тукай мәйданнарына плитәләр түшәтеп чыгар, яңа һәйкәлләр ясатыр...

Машиналар кәрваны Тукай-Кырлайга килеп керә. Шыңгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган ТУКАЙ ЙОРТЫ әллә каян күзгә ташлана.

Аның күгәрми торган калай белән ябылган түбәләре кояшта ялык-йолык килә.

Тимерхан күреп тора — йорт алдына җыелган кунаклар таң калалар. Бу йортны салуда үзенең дә өлеше булганга Тимерхан гаҗәеп бер горурлык хисләре кичереп йөри.

Чыннан да, Тукай Йорты зур булып, иркен булып җитешкән. Халыкның мең еллык күңел байлыгы — орнаментлары кәрнизләргә килеп кунган.

Йортның эченә керә кунаклар. Музейда тарих бар, Тукай язмышы бар, ятимлек-кимсенүләр, мәдрәсәләр, Тукай булган барлык урын бар.

Йортының нәкъ каршысында утырып тора иде Тукай, әмма кергән чакта бер Тукай иде, музейдан чыкканда, ул инде башка Тукай, «халыкның мең еллык тарихыннан, күңел газапларыннан» үсеп чыккан Тукай иде.

Менә нинди көннәрең килде синең, ШАГЫЙРЬ!

Борһанов кунакларны Кырлайның культура сарае каршысына, туптуры урамга ясалган сәхнәгә чакырды. Бөтен илдән килгән утыз җиде кунак бина буена тезелделәр.

Михаил Луконин, Бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы секретаре, күңеленә тулышкан кайнар хисләрен белдерде:

— Кулымны йөрәгемә куеп әйтәм: татар халкының ике һәйкәле бар: берсе — батырлыкка, икенчесе — шигъриятькә. Шундый һәйкәлләрнең хуҗасы булган халыкны олы бәйрәме белән котлыйм! Тукае һәм Җәлиле булган халык — бәхетле халык ул.

Трибунага шагыйрьләр күтәрелә. Тукай якташлары иксез-чиксез Ватаныбызның данлы улларын тыңлый. Язмышы һәм иҗаты ачы күз яшьләре, каһкаһәле көлү белән тулган, табигатьнең кайнар сулышын һәр адымында тоеп торган ТУРЫ ТУКАЙ турындагы олы сүзне, хакыйкать сүзен тыңлый.

Аннары кунаклар, Татарстан әдипләре Шүрәле урманына юл тоталар. Монда зур табын әзерләнгән.

Дөньяның суыклары онытыла. Күңелдә ятим Тукай, шәкерт Тукай, гомере буе явызлыкка каршы көрәшкән туры Тукай яңара.

Мостай Кәримне самавырның түренә үк утырталар.

— Йәле, кодачалар, ясап җибәрегез әле татар чәен. Татар Тукай, татар Такташ, татар Туфан барында татар халкы яшәр! — ди ул.

Табын шаулый, табын гөрли.

Тимерхан Борһанов табынчыларга әмер биреп йөри.

Аның тамагыннан аш үтми бүген. Ул ашамыйча да тук. Шушы триумфаль бәйрәмне әзерләүдә үзенең дә өлеше барлыгын тоеп тору — аның җанын горурлык хисе белән тутыра.

*Казан.*
*1994—95 еллар.*

**Автордан:**

**Кеше гомере нинди генә вакыйгаларны сыйдырмый! Без менә Тимерхан Борһановның ятимлектә үсүен дә, авыр сугыш юлларын узуын да, җитәкчелектәге һәм гаиләсендәге тормышын да ике повестьта — «Тимерханның яшьлеге», «Тимерханның авыл юллары» әсәрләрендә сөйләп бирдек. Укучыларга вәгъдә итәм: аның хакында тагын өченче повесть «Тимерханның атылган наркомнарны эзләве» әсәре булачак. Бу чорда ул Татарстан Тәэминат министрының урынбасары булып эшләде, пенсиягә чыкканнан соң, музей төзеде. Беренче повестем укучылар күңеленә хуш килде, бу — миңа шатлык. Монысын да яратсын иде укучы. Бар теләгем шул.**



# ОЛУГ БАКЧАДАН БЕР БӘЙЛӘМ

**Гасыр башында, бөек Тукайлар чорында тугандаш төрек шагыйрьләрен иркен укып, татарчага күчерү, йә нәзыйрә сурәтендә шигырьдә файдалану, осталыкка өйрәнү, иҗади аралашу күренеше табигый булган — бу, әлбәттә, әдәбиятларны якынайткан, баеткан: Тукай, Дәрдемәндләрнең чын төрки йә төрек рухлы шигырьләрен генә хәтерлик!.. Бүген инде без, ниһаять, үзебезнең ныклы, тарихи җирлегебезгә кайтабыз, чын нигезне, уртак чишмә башын эзлибез. Төрек шигъриятеннән өр-яңа тәрҗемәләрдән бу бәйләм дә укучыларыбызга шул сәфәрдә рухи бер азык булса икән: анда бу олуг әдәбиятның горурлыгы, 13—14 гасырларда яшәгән Юныс Әмрә (журналыбызда аның иҗатыннан зур сәхифә — Равил Фәйзуллин тәрҗемәсендә — басылган иде инде!), егерменче йөз шагыйрьләре Фәтхуллаһ Гөлән, Гашыйк Вәйсәл, Ф. Кысакөрәк һәм Н. Асъялар иҗатыннан лирик-фәлсәфи, халыкчан, классик һәм яңа шигырь үрнәкләре сайланып, тәрҗемә ителде.**

## Юныс Әмрә

### Үлгәннәр дәшми — әйтмиләр берни

Битараф бу дөньяга килеп, киткән
Адәмнәр ник дәшми, бер хәбәр бирми?
Кабер өсләрендә үләннәр үскән,
Үлгәннәр өнсез шул — әйтмәсләр берни.

Кылган уйный берәүнең баш өстендә,
Сәрви күләгәсе — икенчесендә...
Монда кем: бер сабыймы? Асыл ирме, йә? —
Үлгәннәр өнсез шул — әйтмәсләр берни.

Туфракка әверелгән күптән тәннәре,
Юк сөйләргә авыз, ирен, телләре...
Догадан без ташламыйк мәрхүмнәрне!
Үлгәннәр өнсез шул — әйтмәсләр берни.

Юныс сөйли:— Күр, тәкъдир нинди ачы:
Кайда гүзәл ярның күз, керфек, кашы?
Кабере — ташландык, кайда караучы? —
Үлгәннәр өнсез шул — әйтмәсләр берни.

* * *

Үлем — хәбәрен салганчы,
Әҗәл якадан алганчы,
Газраил кулы органчы —
Бар, сыен Аллаһка, Күңел!

Дөньяң тик фани булмасын,
Күзең ач, җаның уянсын...
Бул Дуска чын юлдаш, яр син —
Бар, сыен Аллаһка, Күңел!

## Фәтхуллаһ Гөлән

### Без дә тереләчәкбез

Бу ил шәһит-газилардан калгандыр;
Безгә тиңсез бүләк — бабайлардандыр,
Җәннәткә тиң монда баглар-бакчалар,
Зөбәрҗәт төсле үзән, кыр-япаннар
Аларның бөек гомереннән ядкярдер.

Фирүзә гөмбәз, якут баганалар,
Дүрт ягында сакчыдай манаралар;
Һич искермәс бер васыять белән яна
Изге язу тәндә — йолдыздан анда;
Сүнмәгән хыял — тере дастан алар!

Шәрыкътән Әсфәндияр, Гарептән — Искәндәр
Мондый җирне хыял да итмәгәннәр.
Без хыялны чын итеп, төннәр кичтек.
Һәм ирештек — бу ил, дөньяга күчтек...
Ят дөньядан, көнләп, күзәткәннәр бар!

Хәзер көзге җил — лаләле бакчада...
Рәнҗү катыш хис кисә безне анда.

Хыялларда ләкин һаман таң балкый,
Һәркөн безнең уйда — чын айдын-якты:
Ихтимал, без терелачәкбез — алда!

### Башка дөнья җилләре

Сизәм: гомер ахырына баруым...
Чатнаган хәятта хыял бәллүрем.
Нинди нур ул иркәли керфекләрем? —
Нинди төсләр китерәчәк картлыгым?

Яшьлек дәрте — ул да инде үткәндә...
Күзләрдә томан: мәңгелекнең эзе...
Рухка байрак иде бит теләк үзе! —
Хәзер — төсе уңган пәрдә хисләрдә...

Хәзер юк нә шәфәкъ, нә кич кайгысы,
Уйда фани дөньяга юк урыным,
Шулдыр башка дөньяга ашу юлым:
Сәба җиле, туфан-давыл агышы...

Кызыктырмый йортлар да — күккә ашкан,
Кырда — лалә, төнбоек, ак чәчәкләр.
Юклык ачысы, барлыктан — рәхәтләр,
Үткәннәр моңы, хатирә, җыр-дастан.

Миңа алар сөйләми берни инде,
Күк гөмбәзе — теләк касәсеннән зур.
Һәм касәмдә дә хәзер тәкбир шулдыр:
«Аллам үз янына тиз алсын мине!»

Төн вә көндезне кушкан нур — Мәңгелек,
Миңа язган еллар шунда җыелыр...
Көткән йортка бу гомер фида булыр —
Бу шул йорт ки, гел якты... караңгы юк.

Әлвидагъ, җырлар ханлыгы-гомерем, хуш!
Ярканатлар калсын төн оясында.
Яктыга таба йөзсен нурда дөнья —
Төрки моңга илаһи сөюне куш!

## Гашыйк Вәйсәл

### Гүзәллегең нуры

Гүзәллегеңне кем белер —
Миндә балкышы булмаса?
Күңелем сарае дөм булыр
Гыйшкың яктысы булмаса!

Серемне фашлый каләм дә,
Дәртемә юк бит дәрман да,
Исемең таралмас галәмгә,
Гашыйгың шашкын булмаса!

Кем укыр да кемнәр язар,
Сер төенен чишәр кем, яр?
Бәрән бүре белән уйнар —
Уйда башкалык булмаса!

Гүзәл бу йөзең күренмәс,
Гыйшкым чире китә белмәс,
Гөлнең дә кадере беленмәс —
Миндәй бер мәгъшук булмаса!

Синнән алдым бу фөрьядны:
Шул — дөньяның чын тәм-таты,
Ил танырмы Вәйсәл атын —
Ул шулай гашыйк булмаса?!

## Нәҗип Фазыл Кысакөрәк

### Нәкъ утыз ел

Нәкъ утыз ел — тик сәгатем
      йөргән, ә үзем туктап торганмын,
Күктән хәбәр алмый, кәгазь
      очырткыч тик очырганмын.

### Сәнгать

Аңладым шуны: Сәнгать ул —
      Аллаһны аңлау юлы...
Чын хезмәт — шул, ә калганы —
      уен, кузна уены.

### Лөгать

Сүзлек китабы биргәннәр
      кул-әлемә,
Белсеннәр: Аллаһтан гайре
      сүз белмәм — бер кәлимә.

### Матурлык

Үлем дә — матурлыкка юл:
      серле пәрдә артыннан хәбәр.

Юкса үлеп, Мәңгелеккә
ашыр идеме Пәйгамбәр!

### Калмады

Бу кайгы-гамь дөньясында
һични юк омтылганым:
Калмады — намаз вакытыннан
башка көтеп алганым...

## А. Ниһат Асья

### Дога

Моң яңгырап торыр манараларны,
Берүк, азансыз калдырма, Илаһым!

Килсен һаман изге бал кортлары, син
Умарта-йортсыз калдырма, Илаһым!

Шул манараларны күккә әйләгән
Изге язусыз калдырма, Илаһым!

Чын мөселман йортын, халкымның рухын
Син рамазансыз калдырма, Илаһым!

Кузгат һаман — көтү күк калган илне —
Әмма чабансыз калдырма, Илаһым!

Һәм безне сөенечсез, су-һавасыз,—
Ягъни ватансыз калдырма, Илаһым!

Чын мөселман йорты булган Ватанны,
Аһ, мөселмансыз калдырма, Илаһым!

*Рәдиф ГАТАШ тәрҗемәләре.*

# ПУБЛИЦИСТИКА



# КАЯ БАРА БУ РОССИЯ?



**Татарстан телевидениесе аша язучы Әхәт Мушинский урыс телендә алып бара торган «У зеленого камина» («Яшел камин янында») дигән телевизион тапшыруларда республикабызның бик күп күренекле шәхесләре катнашып килә. 1993 елның декабрь аенда башланып киткән бу тапшыруларда без Минтимер Шәймиев, Фәрит Мөхәммәтшин, Василий Лихачев, Туфан Миңнуллин, Фуат Мансуров, Миргазиян Юныс, Разил Вәлиев, Илдар Зарипов, Зилә Сөнгатуллина, мөфти шәех Равил Гайнетдин, Вил Мирзаянов, Равил Бохараев һәм башкалар белән очраштык. Алар — халкыбызның йөзек кашлары булырдай зыялылар: сәяси эшлеклеләр, иҗат әһелләре, галимнәр, дин әһелләре һ. б.**

**Журналыбызның бу санында без укучыларга Әхәт Мушинскийның «Яшел камин янында» профессор Әгъдәс Борһанов белән булган әңгәмәсен иректе язма рәвешендә тәкъдим итәбез.**

**Әүвәл — әңгәмәдәшләр хакында кыскача белешмә.**

**Әхәт Мушинский 1951 елда Казанда татар артистлары гаиләсендә туган. Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Ул — урыс телендә иҗат итүче татар язучысы. 1984 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Дистәләгән повесть һәм романнар авторы. «Кайту», «Ак бүре» исемле повестьлары «Казан утлары» журналында да басылды. 1992 елда «Русско-татарско-турецко-английский разговорнию» дигән сүзлек-белешмә төзеп бастырды. Ә. Мушинский Бөтендөнья язучылары ассоциациясе — ПЕН-клуб составында татар язучыларының ПЕН-клубын оештыручыларның берсе, аның җаваплы сәркатибе. Ул шулай ук Татарстан Милли китапханәсенең өлкән фәнни хезмәткәре.**

**Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов 1920 елда туган. Казан дәүләт университетын тәмамлаган, шунда ук укыткан. Октябрь революциясе көннәрендә меньшевиклар һәм эсерларның эшчәнлегенә багышланган докторлык диссертациясен 1966 елда ук уңышлы якласа да, аның тарих фәннәре докторы дигән фәнни дәрәҗәсен рәсми рәвештә егерме өч елдан соң гына — 1989 елда раслыйлар. Тоталитар режим, Бөек Октябрь революциясе — бары тик большевиклар казанышы, дип раслап килгән заманнарда башка төрле фикер йөртүче галимнәрнең кирәге булмаган, әлбәттә.**

**Бүгенге көндә Ә. Х. Борһанов — күренекле тарихчы, Россия дәүләт университеты профессоры, Россия Федерациясенең Дәүләт Думасында азчылык милләтләргә кагылышлы законнарны эшләүчеләрнең берсе, белгеч-консультант.**

**Әгъдәс Борһановны Мәскәүдә, зурлап, татар Сократы дип йөртәләр.**

**Ул бик мөлаем, ягымлы әңгәмәдәш.**

* * *

Әхәт Мушинский. *Әгъдәс ага, Сез докторлык диссертациягезне 1966 елда ук яклаган булгансыз, ә тарих фәннәре докторы дигән рәсми дәрәҗә Сезгә 1990 елда гына бирелә. Ничек алай килеп чыкты соң ул? Аңлатып үтегез әле шуны.*

Әгъдәс Борһанов. Моның сәбәбе бик гади. Мин үземнең диссертациямдә Октябрь революциясе тарихына Сталин һәм аның иярченнәре биргән бәяне, аларның үзләренчә шәрехләү-сукалауларын сүтеп ташлап, башкачарак яктылыкта карарга, Ленин фикерләренә кайтып төшәргә тырышкан идем. Билгеле ки, үзем аңлаган кадәр дәрәҗәдә. Минем карашларым ул чорда хөкем сөргән карашларга һич тә туры килми иде. Шулай итеп, каршылык килеп чыкты. Революциянең характеры нинди булган? Большевикларның башка демократик партияләр белән үзара мөнәсәбәтләре ниндиерәк? Кыскасы, миңа кадәр тикшеренүче галимнәр Октябрь революциясенең социалистик йөзен генә күреп, һәрвакыт шуны ассызыклап килгән булсалар, мин исә Октябрьнең демократик йөзенә күбрәк игътибар итәргә тырыштым. Җыеп кына әйткәндә, менә шулай.

Ә. М. *Без, галим, галим, дип сөйлибез. Галим заман кешесе булырга тиеш, дибез, фикерләрендә чоры-заманыннан артта калмаска тиеш, дибез. Үзегез галим кеше буларак, Сез моны ничек аңлыйсыз?*

Ә. Б. Галимлекне мин болай аңлыйм: ул, ягъни тикшеренүче-эзләнүче галим, үткәннәргә анализ ясап, аны тикшереп-өйрәнеп, шуның мисалында бүгенгене аңлатып бирергә һәм, шуннан чыгып, киләчәкне алдан күрә белергә тиеш. Әмма, ни кызганыч, андый галимнәр артык күп түгел һәм ул табигый дә. Язучы, рәссам һөнәрләре шикелле үк, галим һөнәре дә сәләткә бәйләнгән. Аларның аермалары шунда: язучы яки рәссам сурәтләп күрсәтү сәләтенә ия булса, галим тикшеренү, аналитик фикерләү сәләтенә ия була. Хәзер нәкъ менә шундый галимнәр үсеп чыгар дип өметләнергә кирәк. Мин моны, нигездә, җәмгыять законнарын өйрәнүче галимнәрне — иҗтимагый фәннәр белгечләрен күздә тотып әйтәм, алар — бүгенге чынбарлыгыбызны анализлап өйрәнүчеләр. Мин аларны — тарихчыларны, философларны, социологларны һ. б. — физиклардан, химиклардан аерып куям. Соңгылары теләсә кайсы чорда ни-нәрсә бар — шуны өйрәнеп тикшерергә мәҗбүрләр һәм, мин әйтер идем, хәтта бурычлылар. Алар физик яки химик күренешләрне өйрәнгәндә һәрвакыт объектив дөреслекне алга сөрергә тиешләр, бернинди өстәп-арттырып җибәрүләрсез. Тегe яки бу җисемне идеалистик яисә материалистик караштан нигезләгәндә, бәлки, кайбер фәлсәфи уйланулар характерындагы фикерләр өстәлергә дә мөмкиндер. Әмма шуннан арысы — юк. Ә инде иҗтимагый фәннәргә килгәндә, иҗтимагый фән белгечләренең эше-гамәле сәясәт белән, бүгенге көн белән, бүгенге чынбарлык белән бик тыгыз бәйләнгән. Менә шулардан чыгып, иҗтимагый фән галименең максатлары да, бурычлары да бер нәрсәгә кайтып кала: чынлап та, бу галим бүгенге чынбарлыкны өйрәнеп-тикшереп, шундый тәңгәл нәтиҗәләр чыгарырга тиеш ки, шул чынбарлыкны сәясәтчеләр дә, социологлар да, политологлар да һ. б. кабул итеп алырга тиешләр, аны күз уңында тотып эш йөртергә тиешләр.

Ә. М. *Катлаулы! Бик катлаулы! Әле мин Сезнең тагын башка сүзләрегезне дә хәтерлим: хәзерге галимнәр арасында, күп булса, ике процент чамасы гына чын галим бардыр, дигән идегез. Бу хикмәтле сүзләрегезгә әйләнеп кайтуым менә ни өчен: Сез, галим ул — ачышлар ясаучы кеше, аның үз концепциясе, ягъни тегe яки бу мәсьәләгә карата анык карашлары була, дип сөйләгән идегез.*

Ә. Б. Әйе, нәкъ шулай. Әле генә әйтеп узган фикерләребез дә шул юнәлештә иде бит. Галим кешенең үз мәктәбе, үз тәгълиматы булырга тиеш. Фәннең үзе тикшерә торган тармагын ул аерым бер яссылыкта — аерым яктылыкта алып, шуны чынбарлыкка бәйләп, үз сүзен әйтергә бурычлы. Ә инде башкалар әйткәнне кабатлап, шуны кайта-кайта чәйнәп йөрүчеләр — алар галимнәр түгел. Кызганычка, тарих фәнендә аның әнә шундыйлары байтак шул әле. Ә үз карашлары, үз концепциясе булган галимнәр юк дәрәҗәсендә аз, бик аз!

Ә. М. *Сезнең ике китабыгыз барын беләм. Һәр икесе дә фәнни ачышка торырлык хезмәтләр. Шулар хакында берничә сүз әйтсәгез иде, Әгъдәс ага!*

Ә. Б. Беренчесе... Шәкертләремнән кайсыдыр берсе әйтмешли, тарих фәнендәге беренче битем... Дөресен әйтим, үзең турында сөйләнеп утыру ничектер мактану булып кабул ителмәсен иде... Сезнең «беренче ачыш» дигәнегез, ул һаман да шул минем диссертациям белән бәйле. Мин анда үз карашларымны бик фәнни итеп расларга тырышкан идем. Һәм аларның дөреслеге, соңлап булса да, танылды. Мин хаклы булып чыктым. Октябрь революциясе тарихын мин большевиклар һәм башка демократик партияләрнең үзара мөнәсәбәтләре күзлегеннән карап бәяләдем. Ул революциядә крестьяннарның, эшче пролетариатның нинди роль уйнаганын, арттырмый-бизәми генә, ачып бирә алдым.

Тарих фәнендә беренче сүзем — беренче битем әнә шул булды.

Икенче бите исә... Анысы да Октябрь революциясе һәм аннан соңгы чорлар белән бәйле, революцион үсештә социализм төзү чоры белән бәйле. Мин, хәзерге үзгәртеп кору чорына кадәр булган тарихи араны җентекләп өйрәнгән-тикшергәннән соң, янә дә үз концепциямне — үз карашларымны әйтеп бирә алдым. Җитмеш ел дәверендә социализм төзи-төзи, Россия нинди хәлдә калды? Бүгенге ачы чынбарлыгыбызның очы-башы кайда? Мин, әнә шуларны өйрәнеп тикшеренүләрем нәтиҗәсендә, кризистан ничек чыгу концепциясен формалаштырдым. Большевистик тоталитар режим алып кереп батырган сазлыктан, тупиктан илне алып чыгу концепциясе ул. Икенче хезмәтем әнә шул.

Ә. М. *Алтмышынчы еллар башында Сез КПССның Татарстан өлкә комитетында фән бүлеге мөдире булып эшләгәнсез. Ул бүлектә Сезгә кадәр Ф. Ә. Табеев эшләгән булган, ул идеология секретаре дәрәҗәсенә күтәрелгәч, Сез аны алыштыргансыз икән. Әмма озакламый,— тарихта булмаган гайре табигый хәл! — Сез, андагы шартларга ризасызлык белдереп, эштән китәргә гариза биргәнсез. Шундый җылы урыннан ни өчен китәргә булдыгыз? Аңлатып бирсәгез икән шуны.*

Ә. Б. Беләсезме, күрәсең, минем табигатем шундыйдыр инде. Ул берничек тә партия органнарындагы казарма шартларына яраклаштырылган эш мөхитенә сыеша алмагандыр. Армиядә дәрәҗәгә карап берсүзсез буйсыну тәртибе, командир сүзе — закон, дигән кагыйдә яшн бит. Мин үзем — отставкадагы майор, яшьлегемнең иң матур сигез елы армия сафларында үтте. Менә шул, армиядәге тәртип, казармачылык, үзеңнән өстен дәрәҗәлеләргә берсүзсез буйсыну кагыйдәләре партия аппаратында урнаштырылган кырыс тәртипләр янында бөтенләй бер башка түбәнәеп кала. Бу — кемнәргәдер сәер тоелырга да мөмкин, әмма дөресе шулай. Партия аппаратында һәммәсе шундый кысаларга куелган, иерархик баскыч шулкадәр нык сизелә — әйтерең дә юк! Әйтик, инструктордан башлап һәркемнең хокуклары һәм бурычлары ачык билгеләнгән-чикләнгән. Синең кем белән аралашырга, ә кем белән аралашмаска тиешлегең дә, хәтта буфетта кайсы залда ашарга тиешлегең дә өстәлеңә кадәр билгеләнеп куелган. Бүлек мөдиренең вәкаләтләре бер төрле, ә инде өлкә комитеты секретарьларыныкы — бөтенләй башкача. Хокуклары һәм вазифалары да төрле, әлбәттә. Ашаган азыгыңа, алган паегыңа кадәр аерылып тора. Партия күзәнәгендәге чин-дәрәҗәләр турында сөйләп торасы да юк, алар арасындагы мөнәсәбәтләр әллә нәрсә ул. Анда иҗади эшләү, уйлану-эзләнү, нәрсәгә булса да үз карашыңны белдерү, нәрсәнедер үзеңчә планлаштыру турында хыялланырга да мөмкин түгел. Анда бөтенесе дә алдан, катгый рәвештә партия уставы, партия программасы һәм югары инстанцияләрнең директивалары, «кыйммәтле күрсәтмәләре» белән билгеләнә һәм тормышка ашырыла. Син шул күрсәтмәләрне тайпылышсыз үтәп барырга тиешсең. Менә шул тимер кыршау мине бик нык кыса, тәртипләре изә-сыта, сулыш алырга да ирек бирми иде. Алай да мин ике ел чамасы түздем әле. Әмма эшли башлавымның беренче айларыннан ук мин үземнең ризасызлыгымны сиздерә килдем, иң яхшысы — китим мин бу эштән, дип әйтә килдем. Әмма анда бер кереп кысылгач, тиз генә чыгып китеп тә булмый икән. Бары тик ике елдан соң гына җай чыкты да, тизрәк гариза биреп, китеп тә бардым. Шулай, сыеша алмадым мин анда. Аннары, тагын шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: власть, хакимият — ул шундый бер категория... Ул шулкадәр үз баткагына суыра башлый... Баткак кынамы соң, куркыныч, төпсез сазлык ул... Кеше түрәлеккә, хакимлек итәргә бик тиз күнегә, аның өстенлекләрен, тәмен бик тиз тоеп ала. Хакимлек, түрәлек — иң тәмле икмәктән дә тәмле, иң татлы ризыклардан да татлырак! Кешеләрне үзеңә буйсындыру, аларга боеру, аларны үз кубызыңа биетү... Яшермим, эшләвемнең икенче елы тулып килгәндә, әнә шул төпсез сазлык мине дә суыра башлаган иде инде. Зур түрә булып, түшеңне киереп йөрү... Читтән караганда, җирәнгеч бер

нәрсә ул! Менә шуларның барысы да минем партия өлкә комитетыннан китүемне тизләтте.

Ә. М. *Анысы табигый, әлбәттә. Анысы аңлашыла. Еш кына Сезгә Фикрәт Табеев: «Сез уйламагыз, сез эшләгез!» — дип әйтә торган булган икән. Шулай сөйлиләр. Чынлап та әйтә идеме шулай?*

Ә. Б. *(Көлә.)* Әй-е-е-е... Беләсезме, без Табеев белән бик еш бәхәсләшә идек. Ул яшь ягыннан миннән яшьрәк, билгән урыннарыбыз-дәрәҗәләребез бер чама-да — шунлыктан, без бик тиз үзара «син» дип сөйләшүгә күчеп киттек. Аннары, минем гадәтем шундый: һәр нәрсәгә үз фикерем булырга тиеш. Нәрсә турында булса да фикер алыша башласак, мин сикереп торам да: «Минемчә, бу мәсьәлә менә шулай-шулай...» — дип тезеп китәм. Көлешәләр. Күрәсең, минем бу чыгышларым тора-бара Табеевны туйдыра башлагандыр. Шундый фикерләшүләрнең берсендә ул миңа әйтә: «Беләсеңме, Әгъдәс Хәсәенович, син уйлама, ә кушканны үтә, син эшләвеңне бел! Биредә синнән башка да уйлаучылар җитәрлек!» — ди.

Ә. М. *Шулай ук дидеме?*

Ә. Б. Мин аңа: «Мондый шартларда эшли алмыйм», — дидем. Ә ул: «Әйдә, әйдә... Акыл сатма!» — дип сүзне бетерергә ашыкты. Шулай аерылыштык.

Ә. М. *Мәскәүдә Сезнең «Откуда и куда идешь, Россия?» дигән китабыгыз чыгып килә икән. Шулай итеп, кайдан һәм кая таба бара инде бу Рәсәй?*

Ә. Б. Китабымның исеменә мин гомумиләштерелгән эчтәлек-мәгънә салырга тырышмадым, чикләнгәнрәк мәгънә салдым. Бу хакта кереш сүземдә дә искәртеп уздым. Димәк, тарихи яктылыкта, татарчалап әйтсәк, хан заманнарыннан башлап Россия кайдан килеп чыккан да, хәзер кая таба бара? дигән сорау куелмый. Сүз Россиянең бүгенге хәлендә кая таба баруы хакында. Ни өчен ул бүген шушындый авыр социаль-икътисади упкынга тәгәрәде? Мин менә шул хакта фикер йөртәм. Сүземне крепостное право бетерелгәннән соңгы заманнан, төгәлрәге, Столыпин реформалары чорыннан башлап җибәрәм дә, Октябрь революциясе аша бу якка килеп чыгам. Илнең бүгенге хәтәр хәле турыдан-туры Октябрь революциясе белән бәйләнгән икәнен исбатларга тырышам. Октябрь илдә социализм төзү күрсәтмәсен бирде, социализмны төзи дә башладык, төзедек-төзедек — нәтиҗәдә, үзебезгә бөтенләй кирәкмәгән шыксыз-кыяфәтсез бер нәмәрсә төзеп ташладык...

Илдәге бүгенге хәерчелекнең башы яманаты чыккан пролетариат диктатурасына, дәүләтнең тулы хакимлеккә омтылышына барып тоташа. Бөтен нәрсә дәүләтләштерелде, асылда җәмгыять тулаем дәүләтнең ялчысы булып калды. Һәм нәкъ менә шул вакытта илнең цивилизациядән, тәрәккыяттән читләшү процессы башланды, ул алга киткән илләр атлый торган олы юлдан тайпылып, салулап бер читкә кереп китте. Кыскасы, ил юлыннан язды. Кайда килеп төртелгәнебезне менә хәзер күрәбез дә инде.

Ә. М. *Ә кая бара бу ил?*

Ә. Б. Кая бара, дисезме? Әгәр дә илнең эчке сәясәте тамырыннан үзгәрмәсә, аның тоткан юлы һаман начарлана гына барачак. Киләчәгебез бер дә якты түгел. Бу хәл, минем карашымча, ил халкы өчен хәерлегә булмас. Халыкның бай ачы тәҗрибәсе бар. Пугачевчылык, разинчылык, егерменче гасыр башында тулы булмаган ике дистә ел эчендә — өч революция... Болары тарихи тәҗрибә. Ә бүгенге оешкан җинаятьчелекнең үсеше, масса-күләм урлашу, масса-күләм эчкечелек, җәмгыятьнең рухи череп таркала баруы — без боларны күреп торабыз ич. Билгеле ки, моның ахыры яхшы булмас. Халык, әлбәттә, бик түзем, әмма, кызганычы шул, түземлек артында тагын бер сыйфат яшеренеп ята — урысчалап әйтсәк: долго запрягает, да быстро ездит. Озак җиксә дә, тиз җилдерә, булып чыгамы? Шуңа күрә хакимиятнең ялгыш сәясәтеннән яхшылык көтеп булмый! Гомумән, социаль шартлаулар алар бит халык тарафыннан әзерләнми, андый шартлаулар большевиклар яки необольшевиклар, янсә башка төрле экстремистлар тарафыннан әзерләнә. Юньсез хөкүмәтнең юньсез сәясәте әзерли аны. Ахырда халык бу «эт — баш, сыер — аяк» хәлләрдән туя, гарык була һәм... «шартлый».

Ә. М. *Ни өчен шулай килеп чыкты соң? Хосусый милек дәүләтләштерелеп беткәнгә күрәме?*

Ә. Б. Россия дәүләте күп гасырлар буена күпчелек халык өчен хосусый милекчелек принципларын инкяр итеп, хосусый милек бары тик элитар даирәләр өчен генә, җәмгыятьнең бик кечкенә өлеше өчен генә дип, раслап килде. Моның нәтиҗәсе шул булды: халыкта хосусый милек ияләренә — байларга нәфрәт хисе тәрбияләнде, аның белән генә дә калмады — милек-мөлкәтнең үзенә карата да нәфрәт хисе тудырылды. «Әтәй малы — катай!»

Шул уңайдан бер гыйбрәтле вакыйга турында сөйләп узыйк әле. Инде Октябрь революциясе җиңгән көннәр. Петроград янындагы Петергофта крестьян депутатларының бер корылтае — съезды үткәрелә. Андагы биналарның барысы да җимерек тә ватык, таланган да тапталган. Бары тик бер зиннәтле сарай бинасы гына төзек, канализациясе дә эшли икән үзенең. Корылтайны шул бинада үткәрергә булалар. Димәк, шулай итеп, сарай бинасында канализация эшли, ә депутатлар — крестьяннарның иң аңлы, иң алдынгы вәкилләре! — туалетлардан файдаланмыйлар. Алар нишли? Сарайдагы бәһасез кыйммәтле амфораларны, зиннәтле борынгы юнан вазаларын төнге чүлмәкләр итеп файдаланалар: шуларга пес итәләр, кәкәй итәләр. Ватып-кырып, пычратып-буяп та бетерәләр, билгеле. Хикмәт крестьяннарның дөм томаналыгында, мәдәнисезмәнсезлегендә түгел, хикмәт шунда — урыс мужигы ул бәһасез амфора-вазаларның үзенеке түгеллеген белә, беркайчан да үзенеке булмаячагын аңлый, бу матурлык белән байлар гына соклана, биредәге зиннәтле җиһазлар — байларныкы. Шуңа күрә дә аларны пыран-заран китереп, буяп-пычратып бетерүдән мужик тәм таба, рәхәтлек кичерә. Андый матурлыкка, андый зиннәтләргә мужикның мөнәсәбәте әнә шундый була. Ә инде байлык-муллыкта яшәгән алпавытларга, буржуйларга ул ярлы-ябагайның нәфрәте гасырлар буе тәрбияләнеп, канына сеңеп килгән. Унсигезенче гасыр язучысы, философ публицист Панинның гаҗәп төгәл әйтелгән гыйбарәсе бар: хосусый милек — ул җәмгыять тормышының җаны. Ягъни болай: милек булса, ул кешеләрнең милеккә булган мөнәсәбәтләрен дә, үзара мөнәсәбәтләрен дә калыплаштыра. Әгәр дә инде хосусый милек булмаса, күпләрдә булмаса, аларда милке-мөлкәте булган «соры корт»ларга карата нәфрәт хисе тәрбияләнә. Һәм алар һәрвакыт Ленинның атаклы өндәве белән рухланып эш итәргә әзер торалар: «Талап җыелган байлыкны тала!»

Ә. М. *Бу күренеш хәзер дә күзәтелә бит. Эшмәкәрләрне, банкирларны үтерәләр. Күптән түгел бер сөйләшүдә Сез, ул үтерелгән эшмәкәр, банкир кебекләрне гади халык кызганмый, дигәнрәк фикер әйткән идегез.*

Ә. Б. Алай гына да түгел. Аерым катлам кешеләрдә, бөтенләй бернәрсәсез калган, йортсыз-җирсез адәмнәрдә ул үтерешләр хәтта шатлык хисе дә уятадыр, бәлки, гади халык ничек сөйли? Халык, берәр үтерү турында ишетсә: «Ә, караклар, жуликлар бер-берсеннән үч алалар, алар шулай үзара «аңлашалар». Безнең анда эшебез юк»,— дип кенә нәтиҗә ясап куя. Шулай итеп, җәмгыятьтә үтерешләргә битарафлык туа. Юкса, бу бит үтереш, кан коела бит, кешене үтерәләр бит... Ничек инде кемне дә булса үтергәнгә шатланырга мөмкин? Элек мондый нәрсәләр, мондый мөнәсәбәт юк иде. Ә, нигездә, кемнәрне үтерәләр? Мин җинаятьчел шәхесләрне әйтмим. Алары — башка. Бүген милек-мөлкәт бүлешүчеләрне, иртәгә милек хуҗасы булырга теләүчеләрне кыралар.

Ә. М. *Алар арасында бик хуҗалыклы, башлы кешеләр дә бардыр дип беләм. Илне күтәрердәй кешеләр...*

Ә. Б. Әлбәттә. Хәтта начар кеше булса да — үтерергә ярамый. Бик эре сәүдәгәрләрне, үз эшләренең осталары булган кешеләрне үтерәләр. Ә бит алар, ахыр чиктә, җәмгыять файдасына эш йөртүчеләр. Ләкин өлешсез-милексез калган гади халык аны аңламый. Гади халык үзен таладылар дип уйлый. Ул эшли, ә теге эшкуарлар җиңел кулдан гына халык байлыгын үзләштерә бара, янәсе. Ә бит ул үзенчә хаклы. Хосусыйлаштыруда хөкүмәт ясаган хаталар нәтиҗәсе бу. Бөтен хикмәт тә менә шунда.

Ә. М. *Халык Лев Толстойның бер хикмәтле сүзен әллә белми, әллә оныта: әгәр кеше үзе өчен яхшы эшли икән — димәк, ул җәмгыять өчен дә эшли.*

*Минем Сезгә бер сәеррәк соравым бар. Ничегрәк әйтим икән? Сез университетта милек-мөлкәт фәлсәфәсен укытасыз. Мондый фән башка бер уку йортында да өйрәнелми, минемчә. Сез милек-мөлкәт буенча зур белгеч-галим, ә үзегез, фәнни итеп әйткәндә, мал-мөлкәткә стоикларча, ягъни бик исегез китмичә, түземлелек белән карыйсыз, тыныч карыйсыз. Хәтта түбәнсетеп үк карыйсыз түгелме?*

Ә. Б. Юк ла! Түбәнсетеп түгел. Болай бит: мине байлык-мөлкәт үзе кызыксындырмый. Мин, әлбәттә, байлыкка каршы түгел. Кыйммәтле акцияләрем-кәгазьләрем, акчам, коттедж-йортым, машинам булса — бик риза булыр идем. Әмма алар юк, булмавы, бәлки, хәерледер дә. Мине мәсьәләнең гамәли тормыш-көнкүрешкә кагылган ягы кызыксындырмый. Мине, галим буларак, мал-мөлкәтле кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре күбрәк кызыксындыра. Аларның үзара тәңгәллеге, яраклашуы, дип әйтимме соң? Бу — тикшеренү, нәтиҗәләр ясау өчен бик кызыклы күренеш. Әйтик, язучы яки рәссам теге йә бу мәсьәләне, теманы лирик пландамы, әллә романтик яктылыктаракмы хәл иткән шикеллерәк. Иҗатчылар да бит үзләре алынган теманың төбенә төшәргә телиләр. Менә мин дә, галим буларак, мал-мөлкәтне үземдә булдырырга ашкынудан битәр, аны тикшерүдән күбрәк тәм табам. Аннары шунысы да бар: фәлсәфи фикерле тикшеренүче-галимме ул, язучымы, рәссаммы — алар, кагыйдә буларак, чын мәгънәсендә эре мөлкәтчеләр була алмыйлар, чөнки аларның уй-фикерләре байлык туплау ягына юнәлтелмәгән, алар мал-мөлкәткә исләре китеп карамыйлар. Әлбәттә, артык килере булганда, әйтик, Рудольф Нуриев шикелле иҗатчы берәр вилла-фәлән сатып алырга мөмкин, картиналар яки башка зиннәтле коллекцияләр тупларга мөмкин. Әмма бу — һич тә байыйсы килгәннән түгел.

Мал-мөлкәтле булу, аны арттыру-ишәйтү — бу шулай ук бик азларга гына бирелә торган иҗади сәләт, иҗади һөнәр. Мин, бу мәсьәләне өйрәнә торгач, шундый фикергә килдем: милекче булудан да иҗадирак һөнәр юктыр шикелле. Әйтик, менә сез — язучылар — нәрсәдер язасыз, ди...

Ә. М. *Сез интеллектуаль милек, акыл байлыгы турында әйтәсезме?*

Ә. Б. Юк, юк! Эш анда түгел. Менә сез бу очракта — журналист, мин — галим, кемдер — язучы. Без теләсә кайчан, теләсә нинди шартларда иҗат итә алабызмы? Минемчә, юк, итә алмыйбыз!

Ә. М. *Акыл белән уйлап караганда...*

Ә. Б. Юк, юк! Сез дә, мин дә илһам килгәндә генә иҗат итә алабыз. Сез, әйтик, бер мавыктыргыч темага килеп юлыгасыз да, сездә илһам уяна, хыялыгыз-фикерегез шул юнәлештә эшли башлый. Ә кайчакта шундый вакытлар була: килми генә илһам! Бер юл да яза алмыйсың. Янә Лев Толстойның хикмәтле сүзләре искә төшә: язмый тора алмас дәрәҗәгә җиткәч кенә язарга кирәк, дигән ул. Галим кеше дә шулай. Бер эшкә тотындымы, ул аны көнен дә, төнен дә уйлаудан туктамый. Йоклаганда да шул мәсьәләне чишеп ята, уянуга язу өстәле янына ашыга, онытканчы тизрәк язып куярга кирәк бит. Димәк, иҗат кешеләре илһам килгәндә генә эшли ала. Ә милек иясе, мал-мөлкәте булган кеше нишли? Ул бит: «Бүген илһам килде — мал-мөлкәтем турында кайгыртыйм әле»,— дип, яки: «Бүген илһамым юк, мал-мөлкәт көтеп тә торыр...» — дип, кул кушырып утыра алмый. Аның мөлкәте нишләргә тиеш? Ул бозыла, чери, аны урлыйлар, ул эшләми, юкка чыга бара. Менә шуңа күрә дә милек-мөлкәтле кеше мөлкәте турында уйламыйча, аны кайгыртмыйча тора алмый. Язучы Зоя Богуславскаяның «Новый мир» журналында (№ 8, 1995) «Окна на юг» («Көньякка караган тәрәзәләр») дигән кызыклы хикәясе басылган. Хикәя хәзерге урыс байлары турында. Хатын ире турында уйлана: «Булганы җитеп ашкан бит, нигә кирәк аңа артык акча, байлык, хакимлек? Һаман-һаман хәтәр тәвәккәллек, үзенне куркыныч астына кую нигә кирәк? Нигә ул шундый? Аны аңлап та булмый. Һаман байлыгын арттыруга комарлана, тыелгысыз мавыга, азарт...— һич аңламассың. Күрәсең, ул шунсыз яши дә алмыйдыр инде,» — ди. Шунсыз яши алмый — хикмәт менә шунда шул. Милекче һөнәрен мин иң иҗади һөнәр дип әйтер идем. Бик булдыклы кешеләр һөнәре ул. Кешене бар булганы белән суырып ала торган һөнәр. Чөнки мөлкәт — яшәү чыганагы. Ә инде галим бүген үз тикшеренүләренә тотынмый тора икән — нәрсәсе бар моның? Яки язучы уйланган берәр әсәрен

язмый калса, шуннан дөнья җимереләме? Милекче алай итә алмый. Мал-мөлкәте юкка чыга икән, ул аны кайтарып ала алмый. Мәсьәләнең фәлсәфи асылы да менә шунда.

*Ә. М. Әйтик, Тукайның «Кисекбаш»ы язылмый калса, Чеховның «Өч кыз туган» әсәре иҗат ителмәсә, кешелек нәрсә югалта? — димәкчеме Сез? Ярар... Ә бер байның мал-мөлкәте, хәтта дәүләт күләмендә юкка чыкты, ди. Шуннан кешелек нәрсә югалта?*

Ә. Б. Югалтуын югалтмыйдыр да... Әгәр дә мал-мөлкәт күп булып, байлык ташып торса, аңар милекчеләрнең дә мөнәсәбәте тиешенчә булса, илдә бүгенге хәл дә килеп чыкмаган булыр иде, шәт. Без үзебезне кайгыртуны тулысынча дәүләт карамагына тапшырдык та,— чөнки безне шуңа өйрәттеләр! — авыз ачып көтеп утырабыз. Ә дәүләт ул иҗади оешма түгел! Анда бюрократ түрәләр утыра, алар бер генә мәсьәләне дә иҗади хәл итә алмый. Алар безне шушы көнгә китереп җиткерделәр дә инде. Без хәзер дөнья стандартларыннан (үрнәкләреннән) ике башка, ике гасырга диярлек түбәнрәк дәрәҗәдә калдык. Син, әйтик, рәссам буларак, бүген бер әсәреңне ясамый каласың икән, аннан кемгәдер зыян булырга мөмкин, әлбәттә. Әгәр дә милекче,— крестьянмы ул, сәүдәгәрме, башка берәр төрле эшмәкәрме,— үз һөнәренә шулай бармак аша карый башласа, без барыбыз да хәер сораныргa калачакбыз. Әле бүгенге көндә ил-дәүләт кенә сoранып яши, ә инде без барыбыз да — 150 миллион халык! — сораныргa калсак... Аллам сакласын!

*Ә. М. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: Сез бит үзегезнең китабыгызда, мәсьәләләрнең мәсьәләсе — дәүләт белән зыялылар арасындагы мөнәсәбәт, шул исәптән, иҗади зыялылар белән мөнәсәбәт, дип язасыз. Бер дә милекчеләрне телгә алмыйсыз. Ни өчен соң Сез китабыгызда матди байлыклар тудырмаган, көн-төн мал-мөлкәт артыннан кумаган зыялылар өчен борчылып язасыз?*

Ә. Б. Сез, минемчә, бу мәсьәләгә бер яклы гына киләсез. Мин дәүләт белән зыялылар арасындагы мөнәсәбәтләр турында язам икән — ул мөнәсәбәтләрнең нинди булырга тиешлеге турында язам. Һәм, Россия тарихы мисалында тикшереп-өйрәнеп, менә шундый фикергә килдем: Россиядә һәрвакыт зыялыларны эзәрлекләп торганнар, аларны бәяли белмәгәннәр. Урыс дәүләте һәрвакыт үзе акыллы булып кыланган, аңа укымышлы галимнәрнең кирәге булмаган. Фәнгә караш та шундый булган һәм бүген дә шулай булып кала бирә. Шунлыктан безнең бүгенге фәнебез дә кызганыч бер хәлдә, хәерче хәлендә. Фән шундый булгач, бөтен хуҗалыгыбыз да шул хәлдә.

Мин китабымда зыялылар, интеллигенция мәсьәләсендә нинди караштан чыгып фикер йөртәм? Интеллигенция — экстремистлар оясы, ул халыкны дәүләткә каршы рухта тәрбияли, имеш. Әйтик, большевиклар кемнәр булган? Интеллигентлар, зыялылар... Эсерлар — шулай ук интеллигентлар. Рәсәй халкын революциягә кем алып килде? Шул ук интеллигентлар. Күрәсезме, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, барысы да интеллигентлар, зыялылар коткысы икән. Ә мин үземнең китабымда халыкның өметләрен, хыялларын, уй-хисләрен, психологиясен сүзләргә-фикерләргә әвереелдереп яңгыратучы инструмент — интеллигенция, зыялылар, дип язам. Бары тик интеллигенция генә халыкның иң изге, иң мөкатдәс уй-хисләрен үз йөрәге аша үткәреп тиешле рәвештә чагылдыра ала. Интеллигенция — ул шундый социаль катлам: ул һәрвакыт хакимияткә тәнкыйди фикердә, оппозициядә булырга тиеш. Чөнки хакимият бер вакытта да безнеке, халыкныкы була алмый. Кемнәрдер үзләрен, менә яңа хакимият килде, дип юата. Юк, хакимиятнең, дәүләтнең һәрвакытта да үз мәнфәгатьләре бар. Дәүләт мәнфәгате — бер төрле, халык мәнфәгате — икенче төрле. Асылда дәүләт җәмгыятькә, халыкка хезмәт итәргә тиеш. Әмма дәүләт милли байлыкларга хуҗа булмаган очракта гына халыкка хезмәт итә ала. Ә инде бар байлык дәүләт кулында булып, халык аның ялчысы сыйфатында калса... Сталин гына ул, депутатлар — халык хезмәтчеләре, алар эшче-крестьяннарга хезмәт итә, дигән уйдырма чыгарган иде. Чеп-чи ялган! Менә шуңа күрә дә мин интеллигенция һәрвакытта да хакимияткә оппозициядә, тәнкыйди караштa булырга тиеш дип язам. Гомумән, теләсә нинди хөкүмәт аңа карата тәнкыйди фикерле катлам булганда гына нормаль яши һәм эшли ала. Физикада бик гади закон бар: каршылык күрсәткән әйбергә генә таянырга мөмкин. Каз-үрдәк мамыгына таянып буламы? Ә кем каршылык

күрсәтә? Җәмгыятьнең аек акыллы катламы, уйларга сәләтле катламы. Болай караганда, һәр кешегә уйлау сәләте бирелгән, һәркемнең акылы бар кебек. Әмма җәмгыять һәрвакыт уйланучы һәм уйланып, баш ватып тормаучы ике катламга бүленә. Уйланучы, фикер йөртүче катлам гадәттә азчылык була. Ул — интеллигенция, зыялылар. Аны беркем дә хакимияткә каршы булсын әле болар, дип тәрбияләми, ул телиме-теләмиме — уйлана, фикер йөртә һәм объектив рәвештә, гадел рәвештә, дип әйтик, хакимияткә оппозициядә булып чыга. Чөнки зыялылар барысын да күреп-аңлап тора, алар илнең үткән тарихын белә, бүгенгесенә бәя бирә һәм киләчәге турында нәтиҗә чыгара ала. Шуңа күрә дә интеллигенция хакыйкатьне, чын дөреслекне сөйләргә мәҗбүр була. Ә ачы хакыйкать хакимияткә ошамый. Әмма хакимият тиешенчә үсештә булсын өчен интеллигенция белән һәр даим яхшы мөнәсәбәттә калырга, үзен тынгысызлап торучы зыялыларның булуына шатланып яшәргә тиеш. Әгәр инде интеллигенцияне, совет чорындагыча, хакимияткә тәлинкә тотучы ялагай итеп калдырсалар — бетте... Ул чорда чын зыялыларның бер өлеше чит илләргә чыгып качты, калганнарын — күпчелеген! — ГУЛАГларда, Колыма, Магадан, Воркуталарда череттеләр. Инде чит илләргә чыгып китәргә өлгермәгәннәре, Колымаларда башын саласы килмәгәннәре большевиклар хакимиятенә тәлинкә тотарга мәҗбүр булды. Нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты? Без коллык рухында тәрбияләнгән халык белән утырып калдык. Коллык рухында тәрбияләнгән халык тулы мәгънәсендә илнең гражданы түгел, ул инде — кол! Ә җәмгыятьнең таза-сәламәт үсеше өчен гражданнар кирәк. Фикерләүче, каршы тора алучы, үз дәрәҗәсен белүче шәхесләр кирәк, тәлинкә тотучы ялагайлар кирәкми. Ялагай — ул һәрвакыт чит кеше ихтыярына буйсынучы кол. Ә җәмгыять үсештә булсын өчен миллионнарның ихтыяры, миллионнарның иҗади фикерләве кирәк. Шул вакытта гына тиешенчә үсеш-тәрәккыять була ала. Бу мәсьәләдә зыялыларны беркем дә алыштыра алмый. Җәмгыятьнең бары тик буыннан-буынга тәрбияләнеп килгән, чын мәгънәсендә асыл укымышлылары гына моңа сәләтле. Чөнки алар каршы торырга, һәрнәрсәгә тәнкыйть күзе белән карарга өйрәнеп үскәннәр. Тәнкыйтьтән башка исә бер генә җәмгыять тә тәрәккый була алмый, тиешенчә үсә алмый.

Ә. М. *Россия Федерациясе кысаларында суверен Татарстан? Сез бу формулировканы ничегрәк кабул итәсез?*

Ә. Б. Әлбәттә, бу формулировка әлләникадәр каршылыкларны үз эченә ала. Бу — тел үзенчәлекләреннән килеп чыга, күрәсең. Кешеләрнең теле, ул кайсы гына милләт теле булмасын, теге яки бу төшенчәләрнең асыл сыйфатларын бервакытта да тулысынча ачып бетерә алмыйдыр. Әмма шулай да һәрнәрсәне чагыштырып карарга кирәктер. Чагыштырып алып караганда барысы да аңлашыла. Әгәр дә без Татарстанның бүгенге хәлен большевиклар хакимияте чоры белән чагыштырып карасак? Аерма бармы? Бар! Ул чорда суверенитет бар идеме? Юк иде. Хәзер бармы? Әйе, бар. Әлбәттә, бу суверенлык чикләнгән, ул хакта шик булмаска тиеш. Бу мәсьәләгә безнең ничәмә-ничә гасырлар буена Россия составында, Россия белән бергә гомер кичерүебездән чыгып карарга кирәк. Габдулла Тукай ничек дигән әле?

Рус белән гомер кичердек сайрашып,
Тел, легать, гадәт вә әхлак алмашып,—

дигәнме?

Татар халкының чирек өлеше генә үзенең тарихи Ватанында яши. Без бар тарафтан урыслар белән чолганып алынганбыз, дип әйтү генә аз булыр. Без бит шәһәрләребездә дә һәм, хәзер инде, күп кенә авылларыбызда да урыслар яки башка милләт халыклары белән аралашып яшибез: бер татарга — бер урыс яки чувашмы-башка халыкмы. Шулай булгач, нинди дер тулы суверенлык турында сөйләнеп йөрү — җитди эш түгел. Әмма шулай да бүгенгә эшләнгән эшләребез, Татарстан Конституциясенә салынган маддәләр әле тулысынча ачылып бетмәгән. Бу юнәлештә бик күп көч түгәргә, күп хәрәкәт итәргә кирәк әле. Бары шулай булганда гына бүгенге суверенлык формуласын нәкъ менә чын суверенлык сыйфатлары белән тулыландырырга мөмкин булыр. Иң беренче чиратта, Үзәккә — Мәскәүгә һәр мәсьәләдә бәйле булуны бетерергә кирәк. Кызганыч ки, бүген Үзәккә бәйлелек, Үзәккә буйсынганлык бер Татарстан башына гына төшкән бәла түгел. Теләсә кайсы төбәк, теләсә кайсы урыс өлкәсе дә шундый буйсыну хәлендә яши — урыс дәүләтенең үзәкләштерелүе бу, телдә генә федераль булып, асылда

унитар дәүләт булуы. Нәрсә килеп чыга? Үзәк бөтенесенә дә хуҗа, ә җавапны җирле урыннардагы хакимият тотарга тиеш. Анда бит халыкны ашатырга-эчертергә, йорт-җирен булдырырга, эш урыннары белән тәэмин итәргә кирәк. Азык-төлек, транспорт, элемтә һ. б. һ. б. бихисап күп мәсьәләләрне хәл итәсе бар. Үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең халык тормышына яраклаштырылмаган булуы — бу борынгыдан килә торган урыс традициясе. Шуңа тагын большевиклар уйлап чыгарган демократик централизм идеясен дә өстәргә кирәк. Демократик үзәкләштерү, имеш! Бу сүзләр үзләре үк бер-берсен юкка чыгара торган сүзләр бит. Бу принцип шуңа китерде ки, төбәкләрнең хокуклары бөтенләй кысылып бетте. Кем әйтмешли, алар шөреп сорап та Мәскәүгә йөгерә башладылар. Бигрәк тә элекке милли автономияләр үрнәгендә ачык чагыла бу, аларның милли мәдәнияте изелеп-сытылып юкка чыгу дәрәҗәсенә килеп җитте. Хәзер инде алар бу хәлдән чыгарга тырышалар. Шулай да мин, экстремистик фикерле кайбер милләтчеләр шикелле, бернинди суверенитет та юк, бернинди мөстәкыйльлек-бәйсезлек юк, дигән фикерләрдән ерак торам. Ул милләтчеләр барысын да каралтып күрсәтергә яраталар. Юк, нәрсәләрдер эшләнде, эшләнә һәм эшләнәчәк. Бу нисбәттән Татарстан аерым тырышлык күрсәтте. Бөтен Россиядә суверенлык-бәйсезлек хәрәкәтенең башында ул торды, дип әйтергә була. Аннары Башкортстан кушылды, аннары башкалар... Бирсен генә Ходай! Татарстанга башка автономияләр генә үрнәк итеп карыйлар дисәк, аз булыр. Урыс төбәкләре дә татарларга сокланып, көнләшеп карыйлар. Бигрәк тә Россия белән Татарстан арасында Шартнамә төзелгәч, өлкәләр-крайлар: әнә, татар әфәнделәр үзләренә нинди хокуклар яулап алдылар, без дә үзебезгә ни-нәрсә булса да эләктереп калсак иде, диделәр. Һәм бу хәрәкәт өлкәләргә дә тарала башлады. Инде хәзер, Россия белән Татарстан арасында төзелгән Шартнамә һәм аерым килешүләрдә әйтелгәннәрдән чыгып, шуларны гамәли эшләр белән тормышка ашырасы һәм Татарстан Республикасы законнары белән ныгыта барасы иде. Мин болай дип әйтер идем: Шартнамәдәге тиешле маддәләрнең мәгънәләренә дөрес аңлатмалар биреп, шуларны кабаттан килешүләрсез генә Татарстанда эшкә ашырырга һәм тиешле законнар белән ныгытырга кирәк.

Мин милли мәсьәләләрне хәл иткәндә экстремизм куллануны кабул итә алмыйм. Без инде төрле чуалышлар, революция-контрреволюцияләр һәм большевистик геноцидтан болай да гарык. Кан коюга булган лимит — соңгы чик норма күптән инде арттырып үтәлгән. Бигрәк тә хәзер, бик үк демократик булмаган Конституциядән файдаланып та, әле хакимият башында утыручыларны — әгәр дә без аларга ошамыйбыз икән — бездән ераграктан үзләренә ошаган халыкны эзләргә озатырлык демократик мөмкинлекләр бар, минемчә. Бүгенге хакимиятнең үзенең дә лимиты чыгып бара шикелле...

Ә. М. *Фикерләү рәвешегез белән Сез, минемчә, көнбатышка йөз тотучы галим. Мин хаклымы-юкмы?*

Ә. Б. Әйе, нигездә мин, фән теле белән әйткәндә, көнбатышчы (западник) — Көнбатыш европа мәдәнияте һәм көнбатышча яшәү формалары яклы кеше. Мин, әлбәттә, Шәрек сыйфатларын да кире какмыйм, аларның да күпмедер өлешен кабул итәм. Ләкин шуны әйтергә кирәк: бу хәл тарихи шартлар аркасында шулай килеп чыккан — Көнбатыш Европа кешелек дөньясының алгы сафына баскан. Көнбатыш бар халыкларга да яраклы, һәркемгә дә тук тормыш тәэмин итә ала торган бердәнбер юлны тапкан. Хәзер үзләренең тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре, фикерләүләре, тарих вә мәдәниятләре белән Көнбатыштан шактый нык аерылып тора торган Көнчыгыш илләре дә,— әйтик, Япония, Корея, Вьетнам, Сингапур, Малайзия кебек илләр дә,— икътисади үсешләрендә, дәүләт төзелешендә асылда көнбатышча яшәү юлына бастылар. Ә инде Көнбатыш илләренең үзләре хакында — алар кечкенәме-зурмы — сөйләп тә торасы юк.

Ә. М. *Татарстан китап нәшриятында Сезнең тагын бер китабыгыз чыгып килә икән. Исеме — «Россия сама по себе или в координатах Запада и Востока?» Бик катлаулы исем, шулай түгелме?*

Ә. Б. Әйе, шулай. Чыгып килә. Зур түгел ул, ни бары дүрт табаклы китапчык. Мин ул хезмәтемдә дә нәкъ шул Көнбатыш-Көнчыгыш мәсьәләсен күтәрәм, Россиянең кайсы якка таба юл тотарга тиешлеген гоманлыйм. Эш шунда ки, Россиядә бик күптәннән — 18-19 гасырлардан ук тулы бер агым-караш барлыкка

килә: славянофиллык карашы. Фән теле белән әйтсәк, янәсе, славян халыклары аерым үзенчәлеккә ия, иң зур славян иле булган Россия исә шулкадәр үзенчәлекле ил, имеш — аны гомуми аршин белән үлчәп, акыл белән аңлап бетерерлек түгел. Соң, акыл белән дә аңлап бетереп булмагач, аны ничек аңлап бетерергә кирәк икән? Белмим инде, әгәр баш белән, ми белән аңлап бетереп булмаса, ул Россияне кеше тагын кайсы җире белән аңлатырга тиеш икән соң? Мәсьәлә бит нәкъ менә шунда!

Славянофиллык карашы, минемчә, бик реакцион караш. Ул Россиягә күп зыяннар китерде. Сүз уңаеннан, чыгышы белән безнең борынгы татар токымыннан — чыгытайлардан булган философ Чаадаев Петр Яковлевич турында әйтеп үтәсем килә. Ул, әлбәттә, урыслашкан, христиан динен кабул иткән морза. Менә шул Чаадаев — саф көнбатышчы философ, зур галим. Үз фикерләрен бик матур итеп әйтеп бирә ала торган, яхшы каләмле шәхес. Миндә аның байтак әсәрләре бар, бертомлыгы да, икетомлыгы да. Мин аны рәхәтләнеп кат-кат укыйм, укып туя алмыйм. Аның фикерләренә таянып, күптән түгел генә «Исторические науки» журналында күләмле генә бер мәкалә дә бастырдым. Чаадаев та үз заманында, Көнбатышка никадәр якынрак булсак, Россия кереп баткан сазлыктан шулкадәр тизрәк чыгачакбыз, дип язган. Димәк, Россия инде шул заманнарда ук сазлыкта булган... Көнбатыш! Көнбатышта югары цивилизация, тәрәккыят, мәдәният, анда тормыш дәрәҗәсе дә бик югары. Көнбатыш — ул Европа гына түгел, ул Төньяк Америка да. Нишләтәсең, тарихта менә шулай килеп чыккан инде. Аның объектив та, субъектив та сәбәпләре күп. Иң әһәмиятлесе шул: Көнбатыш илләрендә дәүләт системасы җәмгыятькә буйсындырылган. Аларда гражданлык җәмгыяте барлыкка килгән. Ә бездә әле андый җәмгыять һаман да юк, оешып житмәгән. Бездә хәтта халык аны бөтенләй аңламый да әле: нәрсә ул гражданлык җәмгыяте? Менә шунда шул бөтен хикмәт тә! Теләсә кемнән сора, ул сиңа: безнең дәүләтебез бар, дип җавап бирәчәк. Шулай итеп, дәүләт төшенчәсенә без җәмгыятьне дә, илне дә кертәбез булып чыга. Асылда исә нәрсә соң ул дәүләт? Дәүләт ул — идарә итү органнары. Ул — җәзалау органнары, ул — төрмәләр, ул — армия! Дәүләт ул — бюрократия...

Ә. М. *Милиция, полиция...*

Ә. Б. Әйе, милиция, полиция һәм чиновник түрәләр. Фәнни яктан килеп караганда, менә шул ул дәүләт! Ә Россиядә шулай килеп чыккан: дәүләт бар, җәмгыять юк. Юк! Теләсә нәрсә әйтегез, юк кына җәмгыятебез!

Ә. М. *Җәмгыять дәүләттән өстен булырга тиешмени?*

Ә. Б. Әлбәттә! Дәүләт җәмгыятьнең хезмәтчесе булырга, җәмгыять өчен эшләргә тиеш. Ләкин моның өчен җәмгыятьне гражданнар тәшкил итү шарт, ә гражданнар үз чиратында д е м о с н ы тәшкил итә. Ә нәрсә ул д е м о с? Ул бөтен халык дигән сүз түгел, демос ул — мал-мөлкәте, милке булган гражданнар дигән сүз. Бүген без кирәксә-кирәкмәсә дә авыз чайкый торган «демократия» сүзе дә шуннан килеп чыккан. Борынгы Грециядә, Рим дәүләтендә — д е м о с — г р а ж д а н н а р дигән сүз ул. Алар яулап алынган яки тирә-якта яшәүче бар халыклар да түгел, алар — милекчеләр. Хәлле кешеләр, хуҗалар.

Ә. М. *Сез — татар, тумышыгыз белән дә Татарстанның татар авылыннан...*

Ә. Б. Сарабикколдан.

Ә. М. *Районыгыз?*

Ә. Б. Элеккеге Шөгер, хәзерге Лениногорск районы.

Ә. М. *Әйдәгез, татарлар хакында да бераз гәп корып алыйк әле. Минем беләсем килә: татар халкының нинди сыйфатлары Сезгә ошый, ә нинди сыйфатларын сызып ташлар идегез?*

Ә. Б. Беләсезме, бу сорауга мин тулысынча канәгатьләндерерлек итеп җавап бирә алмам шикелле. Мин урыс халкының уңай һәм тискәре сыйфатларын бармак бөгеп санап бирә алыр идем, аларны шактый яхшы беләм. Ә менә

татарларның тискәре сыйфатларын бик белеп бетермим. Мөгаен, мин үз халкымны җитәрлек белмимдер. Бәлки, бәлки... Авылдан, татар җирлегеннән мин бик күптән аерылган, ә шәһәрдә — бигрәк тә Мәскәүдә төрле милләт кешеләре белән аралашасың, күбрәк урысча сөйләшәсең. Дөрес, мин туган телемдә сөйләшәмүкыйм да, гади генә нәрсәләрне яза да алам.

Уңай сыйфатлар... Алар турында мин үз мәкаләләремдә язгаладым да шикелле инде. Мине тискәре сыйфатлар күбрәк кызыксындыра, шуларның асылын аңлыйсым, төбенә төшәсем килә. Мин болай уйлыйм: борынгы заманнарда зур булган һәм бүген дә кечкенә булмаган татар халкының бер бик кызыклы сыйфаты сакланып калган. Барлык бөек халыклар өчен хас бер сыйфат ул. Безнең халык чын мәгънәсендә бер-беренә ярдәм итү, булышу дигән сыйфатларны санлап бетерми, минемчә. Шул җитенкерәми. Аз санлы халыклар бер-берләренә ярдәм итешеп, булышып яшиләр. Аларда бу сыйфатлар гасырлар буена бик нык үскән-ныгыган. Ә бездә — юк. Югыйсә, татар халкы өчен бүгенге шартларда бигрәк тә кирәк сыйфат бу, халык шуңа мохтаҗ.

Ә. М. *Яһүдләр? Алар аз санлы халыкмы?*

Ә. Б. Алар аз санлы халык. Менә алар бер-берсенә ярдәмләшә дә ярдәмләшә инде! Шулай булмаса, яһүдләр тарих мәйданыннан күптән төшеп калган булыр, юкка чыгар иделәр. Аннары, безгә шуны да истә тотарга кирәк: дәүләтчелеге бетерелгән татарларга гасырлардан-гасырларга бер яман сыйфат йоккан: ул сыйфат түрәләргә дә, зыялыларның бер өлешенә дә, ярлы-ябагайга да хас. Бу — ялагайлык, тәлинкә тоту, ярарга тырышу. Шунысы кызык: югарырак үрлисе килә, ул шуның өчен өстәгеләргә ярарга тырыша; ярлы-ябагай исә бөтенләй хәерчелеккә төшмәгәем дип курка, шуңа күрә түрәләргә ялагайлана. Ә менә урта катлам, уртача муллыкта яшәүчеләр, кагыйдә буларак, үз дәрәҗәләрен белеп яшиләр. Бөтен дөньяда демократиянең таянычы да — урта сыйныф, урта катлам. Алар, гадәттә, вөҗданлы, намуслы булалар. Җигелеп эшли дә беләләр, тормышлары да җитеш.

Ә. М. *Шул исәптән, зыялылар да...*

Ә. Б. Зыялылар да, әлбәттә! Ләкин шунысы бар: зыялылар барысы да бер төрле түгел бит. Аларның түрә булганнары, хакимияткә якын торганнары шулай ук ялагайлана белә.

Ә. М. *Ә түбәндәгеләргә алар бариннар тәкәбберлеге белән карый. Шулай түгелме?*

Ә. Б. Әлбәттә шулай!
Әгәр дә инде татар халкының уңай сыйфатларына килсәк, алары да җитәрлек. Мин иң әүвәл ике сыйфатны аерып күрсәтер идем. Аның беренчесе — үҗәт тырышлык, максатчанлык. Бу сыйфат бигрәк тә иленнән аерылып, читтә яшәргә мәҗбүр булган татарларга хас. Мин, мәсәлән, Мәскәүдә татарлардан бик затлы, зур шәхесләрне беләм: академиклар, галимнәр, хәрби начальниклар, иҗат әһелләре ... Шулкадәр күп алар Мәскәүдә, минем исем-акылларым китә! Менә бу бит үҗәт тырышлык, максатчанлык нәтиҗәсе. Хәрбиләр дә татарларны мактап бетерә алмый: татар белән разведкага барырга була — сатмаячак, хыянәт итмәячәк, диләр. Икенче сыйфат — дуслыкка омтылу. Дуслык — ул бит бик авыр сынау. Чынлап карасаң, аны һәркем дә күтәрә алмый. Татарның дуслыгы шул кадәр зур, шул кадәр көчле була, чын дуслык икән — ул гомерлек! Мин үзем интернационалист кеше, төрле милләт халыкларының төрле катламнары белән аралашып яшим. Әмма әлеге ике уңай сыйфатның татарлардагы кебек көчле булганын башка халыкларда таба алмыйм.

Ә. М. *Ә космополитизм — миллилекнең иң югары дәрәҗәсе түгелме ул? Кешелекнең киләчәге түгелме?*

Ә. Б. Юк! Мин мондый карашны һич кабул итә алмыйм. Әгәр дә син үзеңне берәр милләт вәкиле итеп тоймыйсың икән, димәк, синең өчен барлык милләтләр дә бер төрле, тигез, имеш... Юк, юк! Кайберәүләргә шулай тоела гына ул. Бу нисбәттән мин байтак чыгышлар ясадым инде. Үз мәкаләләремдә милли аерым-

лыкларның, үзенне бер милләтнең вәкиле итеп тоюның биологик мохтаҗлык икәнен раслап килəм.

Кешелек дөньясы барлык яктан караганда да үзенең күптөрлелеге белән кызыклы, ул шул күптөрлелектә генә тулы чагылыш табып яши. Милләтләрне бетерү, юк итүне ишәйтә барсаң, ахырзаманга кадәр барып чыгарга мөмкин ич. Болай һич тә ярамый. Юкка чыга бара торган милләт-халыкларны теркәү өчен «Кызыл китап» булдырыр вакыт та житкәндер, шәт. Кешелек генофондына янаган куркынычны искәртеп тору өчен кирәк булыр иде андый китап. Аерым состав өлешләре юкка чыккан очракта, кешелекнең биологик, социаль, мәдәни сәламәтлегенә ясалган зыян дәрәжәсен билгеләү максатыннан чыгып, даими тикшеренү-өйрәнүләр алып бару да комачауламас иде. Теге яки бу халыкны югалтуның табигатьтә, җинаятьчел саксыз хуҗалык итүдән яисә башка эшчәнлеккә бәйле рәвештә, үсемлекләр яки хайваннар дөньясындагы теге яки бу төрне югалтудан күпкә куркынычрак хәл икәнлеген аңларга вакыт. Бөек дәүләтчелек шовинистлары арасында америкалылар уйлап чыгарган «эретү казаны» дигән теория бик модада хәзер. Янәсе, вак милләтләр шул «казанда» эреп юкка чыга барырга тиешләр. Әмма, шул ук вакытта, Америка психологларының кайберләре, этник охшашлык һәм тәңгәллек югалтуны — психик авырулар килеп чыгуның, сексуаль мәсьәләләрдән кала, икенче урында торган сәбәбе итеп исәплиләр. Аннары: берәр милләт-халык бетсә — кешелекнең бер мәдәни чыганагы да юкка чыга, дигән сүз. Дөнья мәдәниятының хәзинәсе ярлыланып калачак. Әгәр дә: «Ничә тел белсәң, син шул мәртәбә кеше,» — дигән тәгъбиргә таянсак, болай дип тә әйтә алабыз: «Бер милләт ничә төрле башка милләт мәдәниятын үзләштерсә, шул кадәр милләтләр белән бергә, бертигез бәхеткә һәм иминлеккә муллыкка килачәк.» Бу фәнни-логик рәвештәге фикер йөртүләргә дини яктан килеп гомаплауларны да өстәргә кирәктер, мөгаен. Дини карашларга таянып, кешелек Илаһи бөек зат тарафыннан ничек булса шулай яратылган, шулай тәрәккый итә, дигән тәгълимат бәхәссез дип уйлыйм. Әгәр дә шулай икән, зур милләтләрнең аз санлы халыкларны «эретеп бетерергә» омтылышы безне бар иткән Илаһи зат гамәлләренә каршы килә түгелме соң? Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясы юбилей сессиясендә (октябрь, 1995 ел) Рим Папасы Иоан Павел II, ахыргы бөтендөнья сугышыннан соңгы тарихка күзәтү ясаганнан соң, милләтләрнең хокукларын яклау ихтыяҗының кичектергесезлегенә басым ясады һәм, Кеше хокукларының гомуми декларациясе үрнәгендә, милләтләрнең хокуклары буенча да шундый бер халыкара документ эшләргә кирәк, дигән тәкъдим белән чыкты. «Беркем дә — дәүләт тә, башка берәр милләт тә, берәр халыкара оешма да — аерым бер милләтнең яшәүгә хакы бармы-юкмы икәнлеген билгели алмый, андый хокук беркемгә дә бирелмәгән,» — диде ул үзенең чыгышында.

Ә. М. *Татар диаспорасының, ягъни читтә яшәүче татарларның киләчәген Сез ничек күзаллыйсыз?*

Ә. Б. Мин бу мәсьәләне өч өлешкә бүлеп карар идем: беренчесе — тел, икенчесе — мәдәният, өченчесе — базар мөнәсәбәтләре.

Иң мөһиме — татар диаспорасының, читтә яшәүче татарларның Татарстан халкы белән үзара тыгыз мөнәсәбәт-бәйләнешләрын урнаштыру. Иң әүвәл мәдәни мәсьәләләр буенча кирәкле эш бу. Ырудашлары белән мондый элемтә тарихи Ватаныннан читтә яшәүче татарлар өчен генә әһәмиятле, дигән сүз түгел. Мондый элемтә һәр ике як өчен дә файдалы, чөнки татар диаспорасында бик танылган зыялылар, сәнгать әһелләре, эшмәкәрләр һ. б. байтак. Шуңа күрә, үзара элемтәләр ныгыган саен, Татарстан Республ.касының потенциаль мөмкинлекләре, җегәре дә арта гына барачак. Һәм икътисади, һәм мәдәни, һәм сәяси җегәре дип әйтик. Шулай итеп, большевикларның җәмгыятьне аерым вак кисәкчәләргә таркату юнәлешендәге иң кабахәт эшләренең ачы нәтиҗәләре дә юкка чыгарылыр иде, бәлки. Күпмилләтле гражданнар җәмгыятенең иң мөһим сыйфатлары булып, ул җәмгыятьтә сәяси структуралар гына түгел, ә, бәлки, милли-демократик структуралар, аерым алганда, диаспоралар өчен милли-мәдәни автономияләр формасындагы структаралар барлыкка килү дә шарт.

Россиянең башка барлык милләтләре кебек, безгә — татарларга да икътисади базар мөнәсәбәтләренә керергә туры киләчәк. Әмма, шул ук вакытта, үзебезнең татарлыгыбызны югалтмаска, урыслар тарафыннан «эретеп» йота бару, манкортлаштыруга юл куймаска, үзебез булып калырга кирәк. Бу мәсьәлә, югары тәрәккыятьле, күпмилләтле чит илләрдә дәүләт ярдәме белән нәтиҗәле

тормышка ашырылса, бездә дә бары тик күп төрле матди һәм рухи-мәдәни чаралар белән генә хәл итәлә алачак. Әмма бездә хәлләр башкачарак тора шул. Россия дәүләте белән мөнәсәбәтләребез дә башкачарак. Аңардан безгә махсус ярдәм көтеп утырырга һич ярамый. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, ул дәүләт үзенең бөек урыс милләтенә дә беркайчан да ярдәм итмәде, ул аның җелеген суырды, шулай итеп, инде бүгенге хәленә — үлеп бара торган милләт хәленә китереп җиткерде. (Безнең илдә кешеләр Япония, Америка, Европадагыга караганда 15—20 елга азрак яшиләр, үлем-китем күптән инде тууга караганда күпкә артыграк, мәрхүм философ Мамардашвилиның безнең өскә ябырылып килә торган антропологик һәлакәт хакындагы күрәзәчелегераслана бара шикелле.)

Базар икътисадын тормышка ашыру шартларында Россия халыклары өчен беренче кичектергесез бурыч — урта сыйныф, урта катлам булган гражданнар җәмгыяте төзү. Безнең бурыч исә — ялланып хезмәт итүче (Марксча әйтсәк — «ялланган коллар») татар милләтеннән булган гражданнарны милекчеләр итү, мал-мөлкәт иясе итү. Моны башлыча акционерлык җәмгыятьләре, кооперативлар, җитештерү һәм сәүдә оешмалары, һәртөрле компанияләр оештыру аша, шуңа өстәп, шәхси яисә гаилә эшчәнлегенә нигезләнгән фирмалар аша гамәлгә ашырырга мөмкин булачак. Ә инде моның өчен татар гражданнарының һәм эшмәкәрләренең байлыгын туплап, татар милли капиталын, ягъни маясын булдырырга кирәк. Мин үз халкыма әнә шул юлда уңышлар теләр идем...

* * *

Әхәт Мушинский. Профессор Әгъдәс ага Борһанов белән әңгәмәбез әле тагын берничә сәгать дәвам итте. Без ярты төннән соң гына аерылыштык. Машинабыз төнге Мәскәү урамнары буйлап җилдерә. Ә мин уйланып кайтам: халкыбызның нинди затлы шәхесләре бар бит, гаҗәеп рухи бай, әхлакый ныксаф, искиткеч укымышлы, галәмнәрне айкарлык тирән фикерле шәхесләр. Аларны кадерлисе иде, аларга ягымлырак буласы иде, кайгыртучанлык күрсәтәсе иде...

## ӘДӘБИ МИРАС

# Утыз елдан соң да соң түгел...

Олуг шагыйребез Хәсән Туфанның без бу санда укучыларыбызга тәкъдим итә торган, моңа кадәр матбугатта басылмаган мәкаләсенең язылу тарихы да бик кызыклы вә гыйбрәтле дип беләм... Әйе, 1965 елның җәе. Язучылар, тәнкыйтьчеләр даирәсендә яшьләр поэзиясе һәм яңа, ирекле шигырь тирәсендә бәхәсләр куера башлаган чак. Хәер, әлегә бу — тик телләрдә генә (Нурихан Фәттахның яшьләр газетасында «Шигырьме, әллә башваткычмы?» исемле мәкалә бастыруын исәпкә алмаганда), алар — соңрак, көз көне башланачак... Әле безнең — Равил Фәйзуллин (һәм ошбу бәндәгезнең дә!) шигырьләре журналда, газеталарда басылып, макталган, әле генә (май аенда) узган Татарстан Язучылар съездында да хуплап телгә алынган көннәр. Шулай ук Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Ренат Харис исемнәре дә матбугатта еш күренә. Әмма безнең шигырьнең киләчәге — «ирекле шигырьдә» дип, беренче тәҗрибәләре белән үк күпләрне үзенә «буйсындырган башчы»быз Равил Фәйзуллин турында инде үзәк матбугатта да бер-бер артлы Рөстәм Кутуй, Фатих Хөсни, Рафаэль Мостафин, Әнвәр Бикчәнтәев мәкаләләре басыла башлады, һәммәбезне диярлек хуплап, Казанда Сибгат ага Хәким җитди сүзен әйтте — кыскасы, 1965 елның җәе нәкъ шагыйрьләрчә кызу, яшенле яңгыр көтелгән бер халәттә иде кебек... Менә шул вакытта мәйданга Равилнең «Нюанслар иле» исемле зур шәлкеме чыкты — ул «Казан утлары»ның август санында дөнья күрде (хәтердә калган ай — чөнки бу санда яшь шагыйрь Зөлфәтнең шушы язда үзем тәкъдим итеп редакциягә юллаган шигырьләре дә басылды). 300 юлдан артык «нюанс»лар — кыска шигырьләр, өч, дүрт, биш юллыклар, япон, кытай шигыренә охшаш яңа форма, иң мөһиме, сурәтле өр-яңа фикер дөньясы! Без, яшьләр, бу шәлкемне дәррәү хуплап, алкышлап каршыладык.

Менә шушы «Нюанслар иле»н Хәсән ага әллә кульязмадан, әллә корректурасыннан укыган да... әле журнал чыкканчы ук, зур мәкалә язып, «Социалистик Татарстан» газетасына китергән. Анда әллә — «бу бит әле басылмаган да шигырьләр турында» дип, әллә — яшь шагыйрьнең киләчәген чамалап, мәкалә белән ризалашмыйлар. Аксакал, бераз көткәч, аны кире алып китә... Һәм кабат бастыру өчен беркая да бирми булса кирәк. Әмма яшьләргә, очрашканда, укыта торды, фикерләре белән кызыксынды. Мин дә, мәсәлән, мәкаләне остазның үз янында укып, фикеремне ачык итеп әйттем (мәрхүм Рәшит Әхмәтҗан белән барган идек, минем Язучылар берлегенә рекомендация алып йөргән көннәр иде. Хәсән ага рекомендациясендә дә бу төр шигырьгә үз карашын белдереп үтә!) Әйе, ул елларда без, яшь шагыйрьләр, (күбебез егермедән генә узган!) бер-беребез өчен дә, яңа шигырь өчен дә үләргә әзер идек! Беркатлы, садә, бәхетле чаклар, чынлап шагыйрьләрчә аралашкан, дәрәҗәләр аермаган тигез вакытлар! Ә «Нюанслар иле»н без яшь иҗат көчләре белән бергә — артистлар, композиторлар, рәссамнар һ. б. җыелып ясап, шаулап-гөрләп якладык (шунда М. Шабаевның, булачак әдипләр А. Хәлим, Ә. Гаделләрнең, композитор Ренат Еникеевның бик кызыклы чыгышлары истә калган). Һәм тиздән башланачак «шигырь турында бәхәс»ләргә шул кәеф, рух белән бергә килдек, бердәм атладык... Бер елдан артык барган бу шигырь турындагы сөйләшүгә (әмма нигәдер күбрәк шәкел — яңа, ирекле форма турында гына сүз булды... без китергән әчтәлек, яңа фикер, сурәтләр исә читтәрәк калды кебек) Хәсән ага инде «Барны үстерергә, юкны эзләмәскә» исемле мәкалә белән килде... Әмма без, яшьләр үз карашыбызда калдык...

Мәкаләне кабаттан укыганда күңелдә әнә шул истәлекләр яңарды.

**Уйлыйм: кайсы хаклы соң? Остазмы, әллә нәкъ Такташның яшь чагын хәтерләтеп, шигърияттә яңа бер давыл кузгаткан яшь талантмы? Икесе дә үзенчә хаклы (гәрчә, остазның бу мәкаләсендә Гали Рәхимнең «Нәләтләр шагыйре»ндәгечә аңлау, хуплау юк, әлбәттә!): күпне күргән, кичергән, шәкли һәм фикри үзгәрешләрне үз башыннан үткәргән аксакал — шигырьне нәкъ үзе иманганча күрергә тели, классик традицияләргә таяна, яшьләр аларны онытыр дип борчыла; ә яшь шагыйрь — җанын биздергән, әдәбиятта күбәеп киткән «фикерсез, сурәтсез, буш, такмак-шакмак шигырь»дән качарга тели, кануннарны җимереп, яңа шигырь, яңа форма, жанрлар тудырырга омтыла... Һәм моңа ирешә дә. Аның бу «нюанс»лары соңыннан татар шигыренең, шиксез, яңалыгы һәм уңышы саналып, шагыйрь бу жанрда һаман үсә, эзләнә, яңара барды — нәтиҗәдә «Кыска шигырьләр» кебек мәгълүм китабы да мәйданга килде. Күп телләргә тәрҗемә ителеп, рус телендә аерым басма булып та дөнья күрде. Шунсын да искәртеп узыйк: моннан 30 ел элек Х. Туфан күрергә теләгән классик формадагы шигырьләрне дә байтак язды шагыйрь. Әле күптән түгел генә дөнья күргән 3 томлыгында да бихисап андый шигырьләр. Кызык, аларны аксакал шагыйрь хәзер укыса, нәрсә әйтер иде икән?**

**Редакциягә Х. Туфан иҗатын өйрәнүче тынгысыз галимебез Мәсгуд Гайнетдинов китергән (аңа рәхмәтлебез!) бу мәкалә — әнә шул елларның бер кызыклы истәлеге, шигърияттә төрле шагыйрьләр, шәхесләрнең үзара мөнәсәбәтен, бәхәстә аңлашуын, кыскасы, татар шигыренең үсеш юлларын күрсәтүче җитди бер әдәби ядкяр.**

**Рәдиф ГАТАШ.**

# Хәсән Туфан

## «НЮАНСЛАР ИЛЕ»НДӘГЕ ШИГЫРЬЛӘР ТУРЫНДА

Яшь шагыйребез Равил Фәйзуллинның яңа тәҗрибәләре,— поэзиябездә зур табыш булачак вакыйга рәвешендә олыраклар каравына тәкъдим ителгән яңа шигырьләре,— җитди уйланулар тудыра. Әле соң түгел чагында, вакыйга дигәнебез күңелсез фактка гына әверелүдән элек, үз карашымны әйтеп китүне вөҗдан эше итеп саныйм.

Равилнең бу яңа шигырьләренең «Нюанслар иле» дип аталуы да, бүлекләргә бирелгән («Этюдлар, фәлсәфи эскизлар», «Күңел калейдоскобыннан» кебек) гаҗәп исемнәр дә, нииндидер кызыксыну, өметләнү хисе тудыра.

«Нюанслар иле»ндәге шигырьләрнең һәрберсен җентекләп, берничә кат укып, күздән кичереп чыктым да,— нигә укыдым икән дип,— кайгырып утырам менә: укымаган, танышмаган булсам, өметләрем элекке хәлдә калган булыр иде.

Равил, асылда, буш егет түгел. Аңарда шагыйрьлек потенциясе барлыгына ышануымда ялгышмыйм бугай. Формаль новаторлык белән («яңалык өчен яңалык» диелә торган шөһрәтчелек белән) никадәр генә мавыкса да, барыбер үзенең табигый тавышын табар, барыбер «боз өстендә янган учак» кына булмас ул, дип ышана идем. Хәтта әле дә, шул иманымны югалтканым юк. Иҗаты, шигъри учагы турында Равил үзе нинди фикердә икән соң дисәк, «Нюанслар иле»ндә шуңа җавап булырлык шигырьләр бар.

*Язганда*

Шатлык эчкә сыймый:
күңел локаторы
ике сүз тапты!

* * *

Олы уйлар төртеп уята да
кәрлә эшемне кочаклап
йокыга китәм.

* * *

Мин учак яктым.
Җир яктырганын
башка планеталар да,
бәлки, сизгәннәрдер.

(Шактый кыю ишарә бу: «Минем яктыны башка планеталар да күрергә тиеш, янәсе. Үзеңне инде пьедесталда дип сизә башлауны хәтерләтә бу).

Бу шигырьләр шагыйрьлек дигән бөек эшкә җитди мөнәсәбәтне, ихтирамны түгел әле, ә бары кызык сүзләр әйтү белән мавыгуны гына, шигырь белән шаяруны гына чагылдыралар.

Равилнең менә шул төстәге, шигырь белән шаяру төсендәге тыйнаксызлыклары аны, совет әдәбиятына ихтирамсыз булуга гына түгел, хәтта әдәби әдәпсезлеккә этәргән. Шуның мисалына күз салып үтешли, тагы бер кат искә алыйк:

Равил безне — олырак буынны — «моңардан яхшы шагыйрь чыгачак» дигән фикергә китергән, өметләндергән егет. Менә безнең шул Равилебез шау-шу тудырып шөһрәт таба торган «яңалыкка» гына батып калмасын өчен, «Олы уйлар төртеп уятса да, кәрлә эшемне кочаклап йокыга китәм» дип кенә ятмасын өчен, уйласын, уянсын өчен — кискенрәк итеп, тавышны күтәребрәк әйтергә телим.

Равилнең характерлы ягы — «локаторына» каяндыр килеп кергән кыштырдауны «тота алуны» да яңача иҗат методы дип каравында һәм пьедесталга басып уйларга тырышуында гына түгел бит. Мәсьәләнең күңелсез ягы — Равилнең шактый «сабыйлыгында», — үзен инде камилләшеп җиткән итеп, татар совет поэзиясенең сыйфаты турында яңа хөкем карары чыгарырга тиеш булган «трибунал» тройкасының рәисе дип санауында.

Менә шуның бәхәссез бер мисалы:

*С. Хәкимне укыганда*

Идел уртасында
тездән урыннар бар.

Нәрсә бу? Татар совет поэзиясенең алтын фондына керәчәк кадерле иҗатка, «Фәрхинур»лар, «Рамазан»нар, «Ибраһим Юсфи»ләр, «Ленин фәрманнарына» һәм башкаларга карата кощунство бу. Әгәр «судья» — Равил — «карарына» үзе генә сокланып, аны үз бүлмәсе диварына гына элеп тотса, «сукырга суд юк» дип кенә калырга да мөмкин булыр иде. Ләкин, ул бит аны «Казан утлары» аша ил мәйданына ябыштырып куярга тырыша:

«Судья судта карар укый,

Ә чебен...
тәрәзәдән ярык эзли —

янәсе. Чебенне күрә Равилебез, ә филне күрмәсәң дә ярый, күрәсең. Идел, — теләсәң генә ни әйт — Идел ул. Мунча сулары да коела торган, — «ап-ак күбекле» сулар да коела торган, — Болак түгел.

Бу яңа шигырьләрен «Нюанслар иле» дип атауларында (шактый абстракт төшенчә астында бирелүендә) реаль дөреслек ята: Равилнең бу язмалары әле, чынлап та, үз «тауышын», поэзиядә аяк терәп басарлык җирлеген эзләүнең, чын шагыйрьлекне табуның очраклы төсмерләре, очраклы нюанслары гына; болар әле үзендәге потенциал мөмкинлекләр яңгырашының түгел, ә еракта, бүтән чыганаклардан чыккан яңгышларның очраклы рәвештә «локатор»га килеп эләккән нюанслары гына.

«Нюанслар иле» үзенең очраклы нюанс, очраклы яңгыраш икәнен кычкырып раслап тора. Шуның кайбер фактларына күз салыйк:

Әгәр дә без бөтендөнья әдәбияты белән һичбертөрле бәйләнеше булмаган ил, ниндидер аерым бер утрауда яши торган ил генә булсак, Равилнең «Нюанслары»

поэзиябездә яңалык алып килә дип уйларга мөмкин булыр иде. Ләкин, дөнья әдәбиятында, төп үзенчәлекләре белән, башкалардан бөтенләй аерылып торган, мең яшькә җиткән формалар, япон һәм кытай шигыре диелгән формалар бар бит. Гасыр агышы эчендә исемнәр үзгәрсә дә («танка» дан «рэнга»га, «рэнга»дан «хокку»га күчсәләр дә) күпчелеклеге өч юллы, рифмасыз һәм ритмсыз кыска (кечкенә) шигырь «һәйкәлләре» булып торалар алар. Равилнең «Нюанслар иле»ндәге шигырьләре исә — әнә шул борынгы һәйкәлләрдәге үзенчәлекләрнең татар компиляциясе икәнлекләрен раслыйлар.

Бу хәл татар поэзиясе йөзенә нур өстәми, ә киресенчә, аны оялтырлык хәлгә, уңайсыз хәлгә куя.

«Нюанслар иле»ндәге шигырьләрнең зур күпчелеге, формасы белән генә (100 дән артыграк шигырьнең 72се өчәр юллы булуы белән генә) түгел,— эчтәлекнең тотрыксызлыгы белән дә,— японнарның «рэнга»сын, урта гасырлардагы ясалма шигырьләрен хәтерләтә. Татар телендәге бу «рэнга»ларның кайберләре табышмакны, ә кайберләре җаваплы табышмакны искә төшерә:

* * *

Хет бер алмам
кеше кулына эләксә иде!

Карурмандагы карт алмагач.

* * *

Пенсияләр артты.

Ә — айда
бер сөенүче дә табылмады.
*(Бусының җавабы куелмаган).*

*Соңгы лəгънəт*

Табутны шулай куйганнар,—
аяк табаннары
кояшка терәлеп тора.

Барыннан да битәр «Нюанслар»ның типик эчтәлеге — «фәлсәфә»се гаҗәпләндерә. Иске дөнья белән яңа дөнья арасында, идеология мәйданнарында кангакан, җанга-җан диярлек кискен көрәш барган заманда, давыллардан-өермәләрдән бер читтә, ерак тылның кырыйдагы тын, аулак бүлмәсендә калейдоскоптагы кызык күренешләрне күзәтеп утыруны чамалап, дөньяны шаккатырачак яңалыклар эзләп ятуны чагылдыра бу шигырьләрдәге фәлсәфә, нафталин исе сеңгән бүлмә «әсире» бу фәлсәфә:

*Әсир*

Вазада җикән-камыш.

Ханым көлмәк салгандагы җил
ул бик аз шул.

(Бу — өчәр юллы шигырьләр моннан соңгы мисалларда юлларга бүленмичә алына):

«Инде апрель. / Елка булган чыршы кәүсәсендә / кисәк мамык һаман тора»

«Ой, быел кыш озын булды!/ Тәрәзә арасындагы мамыкны да/ эретер идем». *(Җавабы «Көткәндә»).*

«Улыма тешләр чыкты./ Үз яңагымнан/ куркып киттем»
*(Җавабы — «Картлык»).*

«Кесә тишегеннән җилләр исә,/ маңгайга тотыныр өчен/ куллар өскәрәк шуды» *(«Ярлылык»).*

«Диңгез аша/ очар кош канаты/ кабартма майлый».
*(Җавабы әйтелмәгән. Кабартманы тавык канаты белән генә түгел, а сыерчык, тургай яки сандугач канаты белән майлаучылар да бар, күрәсең!).*

«Пристаньне алып киттеләр./ Дулкындагы карбыз кабыгына/ балыкчы карт карап тора». Нәрсә бу? «Нюанслар иле»ндәге «күз» бу! Тормышны, табигатьне

калейдоскоптагы күренешләрдә генә тәсмерләп ятсаң, Илнең меридианнары арасында гөрелдәп торган көзне, төннәрдә дә эштән тынмаган көзне, фаралар яктысындагы киеренке, чиксез киеренке көзне — карбыз кабыгы образында гына күрергә дә мөмкиндер шул...

Ә яз! Офыкларга тоташкан кыр массивлары өстендә чәчү машиналары гөрелтесе белән күкрәп торган тере, реаль язны ничек күрсәтә соң «калейдоскоп»? Былтыргы яздан калган «карга оясына килеп эләккән пароход тавышы» белән!

«Нюанслар иле»ндәге шигырьләр чынбарлыкның, тормышның, табигать күренешләренең үзләреннән түгел, аларны бары форточка аша гына күрергә омтылучы кешенең язу өстәле «иленнән», бүлмә «пленыннан» гына алган ясалмалары булып тоелалар. Әйтерсең лә алар бары шуны раслар өчен генә язылганнар:

*Омтылыш*

Комета атылды.

Сабый бала форточкадан
кулын сузды.

Чынбарлыкка нинди бәйләнеше бар соң моның? Җир шарыннан чиксез ерактагы орбиталарының (меңәр миллион километрга сузылган җәенке орбиталарының) — кояш тирәсеннән үтә торган борылышларында гына «койрыклы йолдыз» булып (комета булып) күренгән җисемнәр дә (вак планеталар дип аталган җисемнәр дә) атыла ала, янәсе!

Шигырьне алдан хәзерләп куелган өр-яңа формаларга мисаллар табу рәвешендә генә язасың икән, мондый «иҗат»тан ясалма шигырь генә туа ала. Чын яңалык — дөньяны яңартучы алдынгы замандашларың күңеленнән җыеп алган уйларны-тойгыларны аларның үзләренә тапшыру процессында (әсәр хәленә китерү процессында) гына туа ала. Ә «локатор» ярдәме белән генә тудырылган яңалыкның бәхетсез бала гына булуы мөмкин. Мәсәлән:

«Ерак кыр чишмәсеннән кыз — су ташый да, су ташый... өйгә тамчы су кирәкми».

Шигырьдәге кызның исеме күрсәтелмәгән булса да, Ф. Хөснинең «Тәрәзәләрем»ендәге Мәрфугасы бит бу.

«Маяклар, күрдегезме яңа ак дулкынны!/ Чуер ташлар арасында туфлиләре». *(Җавабы — шигырьнең исеме итеп «Иделдә син йөзгәндә» дип куелган. Ләкин Вознесенскийның «Оза»сын Иделгә китердем» дип әйтү чынлыкка туры килгән булыр иде).*

«Кырмыска саламны сөйрәп
түмгәгенең түбәсенә менде.

Кояшка тәки якынайды.

Мостай Кәримнең барыбызга да таныш кырмыскасыннан соң, аркасына йөк күтәреп Европадан Азиягә чыгып барган кырмыскадан соң, Равилнең һәм аның кырмыскасының эше — яңалык та, егетлек тә түгел...

Күңелендәге калейдоскоптан гына алынган шигырьләрне чынбарлык җирлегенә китереп бастырдың исә, ятышсыз яклары ачыграк күренә башлый: Дөньяда, мәсәлән, җир астында метролар бар. «Кояш балалары» — дип йөртелгән таш күмерен җир өстенә чыгаручы шахтерлар, шахталар һәм башкалар (оборонага хәзерлек урыннары) бар... һәм, Равилнең әйтүенә карaганда:

«Җир астында да шәһәрләр бар./ Битләрдә кояшсыз күз яше» — бу шигырьнең аңгырашы шәптән булмаса да, «яңа» фәлсәфәсе шәп бит, янәсе.

Кулны артка куеп йөрү мәҗбүри булган урыннар була. Атарга алып барылганда ветеран коммунистлар да, Җәлилләр дә шулай барганнардыр. Ә хәзер — Лиссабондагылар, Мадридтагылар... Араларында бөкреләре дә бардыр бәлки... һәм шундый күренешләр «истәлек»ләр фонында ха-ха-ха-лап авыз җырып торучы... шигырь дә бар:

«Бөкресе нәни генә күмелсен дип,/ кулын артка куйды./ Дөнья аз гына камилләнде».

Ә поэзиянең хәтерендәге дөнья нишләде? Тоже камилләште?!

Равилнең бу әсәрендә нюанс кына, табышмак кына булмаган шигырьләр дә бар бераз. Аларда фикер нормаль хәлдәге кешечә, аңлашылырлык рәвештә әйтелгән. Алар, бәлки, яңачалык белән мавыгуны онытып торган арада язылганнардыр:

«Өметемнең күзе шундый зур!/ Керфекләре генә ябылмасын».

«Үземнән канәгать булсам,/ сез җирәнегез миннән» — мондый ачык итеп әйтелгән гади фикерләр аңлашыла, әлбәттә. Ләкин, авторның бу соңгы сүзен жест кына, тамак кырып кую гына дип аңлап, аның соравын үтәмәү яхшырак булыр. Котәргә, котәргә, сабырлык белән котәргә кирәк әле.

«Нюанслар иле»ндәге шигырьләрнең 75ләбен — бу әсәргә ялгыш кына кергән дип әйтергә мөмкин: ул шигырьләргә «яңачалык» җене рәтләп кагыла алмаган күрәсең. Аларда — бүлмәдән чыгарга теләү, халык көнеле иленә килергә омтылу, илнең шатлыгы, кайгысы белән дулкынлана башлау күренешләре чагыла. Менә берничә мисалы:

«Хыял агачлары корымаган,/ өмет куаклары киселмәгән,/ ышаныч бөреләре кипмәгән.../ уенчыклар гына җитми».

Бу шигырьгә «Балалар» дигән исем куймасаң да, аңлашыладыр, балаларга карап дулкынлана алу бу.

«Салават күперендәге төсләргә кысан түгел./ Җирдә нинди генә халык юк!»

«Ярлар бик тар булса — ул инеш,/ ярлар ерак булса — ул диңгез,/ ярлар чиксез булса — океан.../ Һәр тамчының дулкын өстендә булырга хакы бар».

*(«Һәр тамчы» дигәне аерым кеше турында түгел, «һәрбер халык» мәгънәсендә алынган).*

Сүзнең сөземтәсен Равилгә һәм аның «стилдәш»ләренә генә түгел, ә барлык яшьләребезгә адреслап әйтү файдалырак булырдыр: кайбер яшь дебютантларның бераз өметле әсәрен күрү белән «талант бу!» дип, чаң кага башлыйбыз без. Ашыкмаска, язучы буларак кына түгел, ә кеше буларак,— яңа кешелекнең бер члены буларак та,— кем икәнен, кая табарак барачагын да чамаларга тиешбездер бит!..

«Талант» дигән сүзне шактый арзанайттык. «Булдыклы» диясе урында да кулланыла хәзер ул бездә.

Ә талант — чын талант — әдип яки шагыйрь буларак, халык күңеленең ышанычлы вәкиле, алдынгы сафларындагы байракчыларның берсе дигән сүз ул. Чын талант — бүлмәгә генә сыя алмый ул. Аның «бүлмәсе» — илнең иҗтимагый мәйданы. Мәйданга чыгуларының беренче елларында ук, алдынгы замандашларының мәхәббәтен казанган Тукайлар, Такташлар, «Моабит дәфтәрләре» биеклегендәге Җәлилләр дигән сүз ул — чын талант.

Акыллырак, таләпчәнрәк булыгыз, яшьләр. «Талант» сүзен саксыз куллануыбызны гафу итмәгез.

Бу мәкаләгә нокта куйганда да, баштагы сүземдә әйтелгән хәлдә мин: әгәр дә Равилнең бу шигырьләрен укымаган булсам, борчылырга туры килмәгән булыр иде. Укыдым. Димәк, үзем дөрес дип ышанган фикерләремне, вөҗдан эше, иман эше булган сүземне әйтми кала алмыйм.

1965.

# ИКЕ ДӘВЕР КЕШЕСЕ



Күренекле әдип Афзал Шамов.

Афзал абый Шамовка быел туксан биш яшь тулыр иде. Ул сиксән тугыз яшенә якынлашкан көннәрдә арабыздан китте. Олырак яшьтәге әдип вә шагыйрьләр аны искә алганда кайчак: «Афзал Шамов ике дәвер кешесе иде»,— дип әйткәлиләр. Бер карасаң — ул чынлап та шулай икән: Афзал абый патша заманында туган һәм шул дәвердә балигъ булган, ягъни кешегә хас сыйфатларны туплап калыплашкан. 1917 елдан соң килгән яңарышны, яңа туачак дәверне инде ул буй җиткән егет буларак каршылый. Аның яшьтәгеләр бүген, әнә, Әфганстан яисә Ичкерия ише «кайнар нокталар»да кан коюлы сугыш афәтенең әчесен татып, «тормыш мәктәбе» узалар.

Хәер, ул җәһәттән Афзал Шамовлар чорындагылар өлешсез калмаган: башта бөек түнтәрелеш көннәренең канлы вакыйгаларына шаһит булган алар. Аннан соң ил халкын хак вә хаксызларга бүлеп, кулга утлы корал тотып, тиңдәше булмаган аяусыз сугыш кырына барып кергәннәр. Унтугыз яше тулган көннәрне инде Афзал абый туган-үскән җиреннән бик еракта — көньяк Украина далаларында — Врангель һәм Махно җитәкчелек иткән, башлыча тәҗрибәле, башкисәр офицерлар корпусына каршы аяусыз көрәшүче кызыл гаскәриләр арасында каршылый. Бу вакыйгалар соңыннан аның яза башлап та төгәлләнмичә калган «Перекоп» романы битләрендә һәм күпсанлы хикәя вә повестьларында чагылыш табачак.

Әмма Афзал абыйның унсигез яше тулганчы ук иңенә утлы корал асып, яу кырына ташлануын күп кеше белми әле. Чөнки үзе аны беркайда да тасвир итеп, язып калдырмаган, биографик белешмәләргә дә теркәмәгән. Заманы шундыйрак булган. Ә бит дөреслектә ул — 1917 ел вакыйгаларыннан соң Казанда башланып киткән чуалышларда ук кулына корал тотып катнашкан, ягъни, «бик иртә өлгергән» сирәк шәхесләребезнең берсе. Тик ул вакытта элеккеге шәкерт Афзал Шамов кызыллар ягында торып сугышмаган һәм шул сәбәпле соңыннан бу хәлләрне рәсми белешмәләргә теркәүне дә кирәк санамаган. Алда әйткәнемчә, заманасы андый булмаган. Дөрес, ул буржуйлар ягында торып, ярлы-ябагага каршы да сугышмаган. Ул өченче фронт, өченче бер көч сугышчысы — яшел әләм күтәреп, аклар белән кызыллар арасында торып көрәшүче Вәисов «гаскәрләре» сафында булган.

Афзал абый бу хакта бервакыт безгә бик тәфсилләп сөйләгән иде. Бу хәл 1979 елның декабрь урталарында, Казан — Мәскәү поездында булды. Без, бер төркем язучылар, СССР Язучылар берлеге белән СССР Әдәби фондының бергәләп уздырылган зур бер утырышына бара идек. Дистәгә якын язучы утырган

вагонның «картлар купесы»нда без дүртәү — Афзал Шамов, Сибгат Хәким, Атилла Расих һәм мин. Күрше купеларда, табын корып, шау-гөр килешәләр. Ә без, картлар, чәй эчеп, сабыр гына әңгәмә куертып барабыз. Шулчак үз биографиясе дә, мулла улы вә ишан оныгы булуы сәбәпле, ак таплардан азат булмаган Атилла ага итагатьле генә итеп сорау бирде:

— Афзал Шиһабетдинович, сезне Вәисовчылар идеясен яклап, сугышып йөргән дип сөйли кайбер Казан картлары. Шул хәл дөресме соң? — диде.

Афзал абый тартынмыйча гына булган вакыйгаларны сөйләп бирде.

Баксаң-күрсәң, аның бабасы Нәҗметдин шул хәрәкәтне башлап җибәргән өлкән Вәисовның иң якын мөритләреннән берсе саналган икән. Тик соңрак, башлы-күзле булып, мөстәкыйль тормыш көтә башлагач кына, яшь кәләшенең үгетләвенә буйсынып, ул хәрәкәттән бераз читләшә төшкән. Һәм, бәлки шул сәбәпледер, тиздән сөргенгә җибәрелгән Баһаветдин Вәисов язмышына дучар ителмәгән. Ә бит ул елларда Зөя өязе авылларыннан бик күп кешене фирка башлыгына ияртеп сөргенгә, яисә Зөя, Казан калаларының төрмәләренә озаткан булганнар.

Әйе, хәлле генә игенче һәм һөнәрче улы Нәҗметдин, үз вакытында фирка башлыгыннан беркадәр читләшеп, аның аянычлы язмышын кабатламый. Әмма ләкин ул яңа дини агым йогынтысыннан ваз кичми, бу идея аның күңел түрендә пыскып яшәвен дәвам итә. Соңыннан шул рухи омтылышны ул улы Шиһабетдин күңеленә дә сеңдерә ала. Гасыр башларында, 1905 ел хөрриятеннән соң, яңадан дөрләп кабынып киткән «вәисовчылар хәрәкәте» Казанда, Апанаев байларның «Касыймия» мәдрәсәсендә укып йөргүче шәкерт Афзалетдинны да үз өермәсенә ияртеп ала...

Күп еллар узгач поездда безгә сөйләгәннәре шул булды. Укымышлы, зиһенле шәкерт буларак аны ешрак Вәисовның хәзерге Тукай исемен йөртүче урамда урнашкан төп йорты, «штаб» тирәсендәрәк тоталар. «Яшел әләм җилфердәгән ишек төбен саклаучыларның берсе мин идем. Без, сакчылар, мылтык тотып, биек болдырда басып торабыз. Ә иптәшләребезнең күпчелеге Казан урамнарында барган бәрелешләрдә катнашалар», — дип искә алганы хәтеремдә Афзал абыйның. Чөнки бу хакта без әлеге сәфәр тәмамлангач та берме, икеме тапкыр сөйләшкән идек. Дөресрәге, мин, төпченеп, аңа сораулар бирдем. Ул исә җавапсыз калмады. Сиксәненче еллар башында әле Вәисовчылар хәрәкәте хакында мәгълүмат бик аз иде. Хәзер дә ул хакта күп язмыйлар. Һәрхәлдә, ул хәрәкәтнең патша чоры Россиясендә хөкем сөргән милли изүгә каршы оештырылган бер чара булганлыгы бәхәссез. 1917 елгы вакыйгаларда да ул хәрәкәт милли мөстәкыйльлек өчен көрәшүче көчләргә якынрак торган булса кирәк. Һәрхәлдә, ул дәвердә аңа ышанган яшьләр һәм шәкертләр үзләрен халкыбызның борынгы дәүләтчелеген торгызырга йөрүчеләр итеп хис кылганнар дигәнрәк фикердә калганмын мин.

* * *

Афзал абый Шамовның әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлавы да шул ук унсигез-унтугызынчы еллар чигенә туры килә. 1918 елның көзендә ул туган якларына кайта, үзләреннән ерак булмаган Татар Исламы авылында балалар укытырга керешә. Шул кышта аның хәбәр һәм мәкаләләре татар газеталарында күренгәли башлый. Беренче дөнья күргән һәм укучылар күңелен җәлеп иткән «Очрашу», «Кызыл корбан» (1919) хикәяләренә оеткы салына. Менә аның «Эш» газетасының 1919 елгы 3 октябрь санында басылган, байлар белән ярлылар тормышын капма-каршы куеп тасвирлаган шигыреннән дүрт юл:

Анда тыныч, анда рәхәт,
Шат яшиләр «җан» өчен.
Әмма монда башка тормыш...
Җан бирәләр ил өчен.

Бу юлларны ул инде, әлбәттә, Казанда курсларда укып йөргән, яисә иңенә кызылармеец шинелен кигән көннәрендә язган булса кирәк. Озаклямыйча ул авыл мөгаллимнәре әзерләүче курсын калдырып, үз теләге белән «ил өчен җан бирү»челәр сафына барып баса. Һәм гражданнар сугышы беткәнче яу кырыннан чыкмый. Афзал абыйның ут эчендә йөргән шул елларда рус классик әдәбияты белән бик кызыксынып танышa башлавы һәм көндәлек язарга карар биргәнлеге хакында сөйләгәне хәтеремдә.

Бервакыт, җитмешенче еллар урталарында, язучы Госман ага Бакир белән икәү, сырхаулап торучы Афзал абыйның хәлен белергә бардык. Сүз иярә сүз чыгып, гражданнар сугышы көннәре дә искә алынды. Афзал абый шунда:

— Ул чор көндәлекләрем исән әле. Вакыт-вакыт аларны кулыма алгалыйм. Бик сирәк вакыйгаларны гына терки алганмын дип үкенеп тә куйгалыйм,— диде.

Госман ага аның сүзен дәвам итте:

— Ул вакытта мин бөтенләй дә яза алмадым. Фәкать егерме өченче елдан, синең белән ятимнәр мәктәбендә бергә эшләгән көннәрдән башлап кына көндәлек алып бара башладым...

Әйе, яу кырында җиңеп кайткач та аларның бергәләп яңа тормыш кору фронтында эшләгәнлекләре миңа да мәгълүм иде. Ул елларда Афзал Шамов, университет каршында оештырылган рабфакта уку белән бер үк вакытта, төрле курсларда укыта. Ә 1923 елда элекке Казанның читендәрәк хәзерге Гагарин һәм Короленко урамнары тоташкан урындагы бер ялгыз бина-утарда ятимнәр өчен Г. Тукай исемен йөрткән балалар йорты оеша. Аны оештыручылар балалар язучылары Гасыйм Лотфи белән Госман Бакиров булалар. Укытучы-тәрбияче итеп, ярдәмгә Афзал абыйны да чакыралар. Тагын бер очрашу вакытында, дөресрәге, Афзал абый белән Гасыйм Лотфи, яшьлекләрен искә төшереп, элеккеге балалар йорты урнашкан тирәләрдә йөргәндә һәм шунда уздырылган әдәби кичәләрне искә алганда, Афзал абый:

— Ул кичәләрнең барлык афишалары да, программалары да миндә саклана әле,— дип әйткән иде.

Җае чыкканда әйтеп калыйм: Афзал абый Шамовның ул ике-өч дәвернең вакыйгаларын берләштергән истәлек-көндәлекләрен дә, бик бай башка тупламаларын да һич кенә дә югалтмыйсы, киләсе буыннар өчен дә саклыйсы иде. Дөрес, алар әлегә нык кулда, аның балаларында калганнар. Ә киләчәктә аларны бер урынга, берәр гыйльми үзәккә алу зарурдыр, шәт. Алда әйтелгәнчә, көндәлекләрне ул 1919 елдан яза башлый. Шулай булгач, анда егерменче, утызынчы еллар вакыйгалары да беркадәр чагылыш тапмый калмагандыр. Үзе сөйләгәннәргә караганда, Мәскәү дәүләт университетында укыган елларында ул чордашы Шамил Усманов белән бик якыннан аралашкан. «Казаннан Мәскәүгә эш белән барганда да еш кына Шамил белән Асияларга төшә идем»,— дип әйткәннәре һәм күренекле артистка Измайлова белән мәшһүр комиссар тормышына бәйле мәзәкләр сөйләве хәтеремдә.



Афзал Шамов һәм Госман Бакиров 1924 елда

Афзал Шамов татар әдипләре, татар зыялылары дистә еллар буе хыялланган һәм омтылган биек үргә — университет белеме алуга ирешкән беренче язучыбыз булса кирәк. Заманында университетка кереп уку турында Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һ. б. күренекле шәхесләребез дә байтак хыялланган. Әмма патша Россиясендә андый мөмкинлек бик-бик аз кешеләргә, анда да башлыча морза һәм түрә балаларына гына тудырылган булуын һичничек тә инкарь итә алмыйбыз. Ә инде җәйнең-җәй буе буразнада, кышын исә шәм яктысында аяк киемнәре тегеп яки кысан мунчада киез әвәләп көн күргән Шиһабетдин улына, элекке заман булса, мөгаен, андый бәхет тәтемәс тә иде.

Дөрес, яңа заманда да аны, соңгы курста укырга тиеш бер вакытта, «кулак баласы» дип, чак кына университеттан куып чыгармыйлар. Бу хәл 1929 белән 1930 еллар вакыйгаларына, колхозлашу вакыйгаларына бәйле рәвештә килеп туа. Колхозлашу шаукымы кузгалгач кына икеләтә-өчләтә көч куеп эшләп, таза тормыш корган бертуган Шиһабетдин белән Галәветдиннең «советча»

яшәмәгәнлекләре ачыклана. Аларны кулга алалар һәм озакламыйча юк итүгә хөкем чыгарыла. Шул шаукым татар дөньясында инде язучылык хезмәте белән шактый дан-шөһрәткә ирешкән Мәскәү студенты Афзал Шамовка да кара кулларын суза. Аны тизрәк әдәбият мәйданыннан сызып ташларга һәм югары белем алганлык турындагы таныклыгыннан мәхрүм итәргә теләүчеләр табыла. Бу афәттән Афзал абый авыр тетрәнүләр, зур югалтулар бәрабәренә генә котылып кала ала. Ләкин ул афәт күләгәсе аны шушы утызынчы елдан соң гомере буе эзәрлекләп килә. Үз эшләре арасында да кайберәүләр, бик ачулары килгәндә, «Совет тарафыннан атыласы кулак баласы» дип искә төшергәләп торалар.

Ләкин шундый авыр сынаулар да Афзал ага Шамовның башкаларга карата булган итагатьлелек, кешелеклелек сыйфатларын сызып ташлый алмый. Афзал абыйның һәркемгә карата ярдәмчел кеше булуын бик күпләрдән ишетеп белгән булсам да, ике очрак мине тәмам хәйран калдырды. Башта үземә бәйле бер шундый очракны искә төшереп үтим. Укый-яза белә башлаган көнемнән язучыларны илаһи бер изге затлар итеп күрергә күнеккән, бигрәк тә татар язучыларына чын табыну белән табынган кеше икәнлегемне белгәч, 1967 елда мине Татарстан Язучылар берлегенә эшкә чакырганнар иде. Килдем, хуҗалык эшендә эшли дә башладым. Ләкин бер ел үтмәстән бик каты авырып та киттем. Элекке елларда дүрт мең чамасы кешене берләштергән, авыр хезмәт үтәүче бер коллективта башта зур бер бүлекне, аннары партия оешмасын җитәкләү минем саулыкка зыян китергән, нервыларны бик какшаткан иде булса кирәк. Авыр хәлдә больницага эләктем. Тәнемә чит кеше каннарын өстәп, хәл керткәч, янымга баш врач килеп утырды. (Аның ике-өч ел Алжирда да эшләп кайткан бик тәҗрибәле табиб булганлыгын соңрак белдем.)

— Энем, чирең катлаулы,— диде.— Андый катлаулы чирләр белән көрәшүче врач тимерюлчылар хастаханәсендә генә бар. Тик анда сирәк кешене алалар...

Мин, бер сүз дә әйтә алмыйча, авыр уйларга чумып ятып калдым. Шул ук сүзләрне ул, мөгаен, эштән хәл белергә килүчеләрнең берсенә дә әйткән булгандыр. Бу хәбәр тиздән Афзал абыйга да барып ирешкән. Ә аның улы Альфред тимерюлчылар хастаханәсендә эшли икән. Афзал абый анда барган, сөйләшкән, үгетләгән, ялварган дигәндәй. Озакламый мине шунда күчерделәр, аллы-артлы ике-өч авыр операция ясады миңа республикабызның танылган хирургы Михаил Семенович Сигал. Шулай итеп мине җәһәннәм базыннан кире шушы якты дөньяга тартып чыгардылар. Бүген дә исән-имин йөреп торуым белән мин шул шифалы, җылы куллы мәрхүм хирург белән Афзал абыйга һәм аның улы Әлфәриткә (Афзал абыйча әйтү) гомерем буе бурычлымын. Күңелемдә булган рәхмәт хисләремне дә бәлки вакытында әйтеп җиткереп бетерә алмаганмындыр. Шулар өчен өчесеннән дә бүген тагын бер кат гафу үтенәм.



Афзал Шамов 1927 елда.

Мине тетрәндергән икенче бер вакыйга Афзал абыйның хатынын җирләгән бер вакытта булды. Гадилә апаның бик сабыр табигатьле, итагатьле кеше икәнлеген, Казан кызы булганлыгын, революция алды елларында башкалабызның мәшһүр Фатиха Аитова гимназиясендә белем алганлыгын белә идем. Менә бервакыт аның җеназасы өстенә чал чәчле бер абзый килеп башын куйды:

— Рәхмәт, җиңги,— диде ул күз яшьләре аралаш.— Абый кебек син дә киң күңелле, ярдәмчел булдың, без ятимнәрне үз канатың астына алып үстердең...

Казанда галим-голәмә арасында күренгәләп, борынгылар тарихына бәйле кызыклы гына хикәятләр сөйләргә һәвәс Сәлих Нәҗмиев дигән кеше иде ул. Сорашып белдем: ул Вәисовның мөрите булган Нәҗметдин картның тугызынчы ир баласының улы икән ләбаса! Аталары Галәветдин «дошман сыйныф» буларак кулга алынгач,

алар ятим калганнар. Мәскәүдән кайтып, китап нәшриятына эшкә урнашкач та Афзал абый аларны үз гаиләсенә алган, үз балалары белән бергә тәрбияләгән, укыткан икән. Гадилә апа да моңа һич карышмаган, авыр язмышны ире белән бергә кичергән, кимлек-кыенлыкларны бергә күргән. Мондый олы җанлылыкны һәркем дә булдыра алмый бит. Ә алар аны булдырган. Менә шул сыйфатлары өчен дә бик кадерле шул безгә Афзал абый һәм аның тиң, тату гаиләсе!

* * *

Безнең әти-әниләр буыны Афзал Шамов һәм аның белән бер чорда иҗат иткән Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Шамил Усманов, Һади Такташ әсәрләрен укып буй җиткән һәм тәрбияләнгәннәр. Егерменче елларда Афзал Шамов — иң актив иҗат иткән әдипләрнең берсе. Бу елларда ул киң җәмәгатьчелек тарафыннан уңай кабул ителгән хикәя һәм повестьларны бер-бер артлы яза һәм бастырып та чыгара. 1926—27 елларда ике хикәя җыентыгы дөнья күрә, шул ук елларда атаклы «Рәүфә» повесте, «Днепр буенда» исемле озын хикәясе языла, революциянең ун еллык юбилеена багышланып «Перекоп» романыннан өзекләр басылып чыга. Шулар артыннан ук диярлек «Бер мәхәббәт турында», «Ана» кебек киң офыклы әсәрләр языла, бераз соңрак мәгълүм «Госпитальдә» хикәясе туа. Әйе, ул чорда А. Шамов үзен оста хикәяләүче итеп таныта.

Шушы әсәрләре белән А. Шамов яраткан остазлары Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимовлар тиңенә барып баса. Ул елларда А. Шамов иҗаты һәм иҗади активлыгы белән яшьтәш каләм тибрәтүчеләрен бер адымга артта калдырып бара диярлек. Тормыштагы активлыкларын да бергә кушсаң, проза өлкәсендә аннан фәкать Шамил Усманов белән Кави Нәҗми генә калышмаска тырышалар сымак.

Менә шушы шәхесләр һәм алар иҗат иткән әсәрләр тәрбиясен күреп, алар рухын тоеп тормыш юлына баскан буын безне — авыр броньлы танклар сугышы заманында парта араларына утырган утызынчы ел балаларын укытты һәм үстерде. Аталарыбызны кан коюлы, дәһшәтле сугыш афәте меңәрләп-меңәрләп үз тегермәнендә тарткан көннәрдә без Афзал Шамовның «Днепр буенда», «Госпитальдә» ләрен, Гомәр Разинның «Сиваш»ын, Габдрахман Әпсәләмовның сугыш хикәяләрен укып, ятим күңелләребезне юаттык. Көчле рухлы әсәр геройларыннан үрнәк алып, алдыбызда торган авырлыклар алдында җебеп төшмәскә күнектек. Ул елларда без яратып, күмәкләп укыган әсәрләр арасында Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты»сы, Александр Фадеевның «Тар-мар» романы да бар. Латинча хәрефләр белән басылган бу ике роман да Афзал абый тәрҗемәсендә чыкканнар иде. Аларга соңрак шул ук тәрҗемәдәге «Хаҗи Морат» — Лев Толстойның иң кешелекле әсәрләреннән берсе өстәлде. Сүз уңаенда гына әйтеп китим, «Хаҗи Морат» романын, Язучылар берлеге каршындагы тәрҗемәчеләр берләшмәсе җитәкчесе буларак, кабат чыгарырга дип ике-өч мәртәбә нәшриятка тәкъдим иткән идем. Яңадан дөнья күрәсе булса, Афзал абый аны тагын бер мәртәбә күздән кичереп, эшкәртеп тә чыгасы иде. Ләкин нәшриятта миңа, ул әсәрне кабат чыгаруны партия өлкә комитетында да, үзәктә дә хупламыйлар, дип аңлаттылар. Кавказда кабат «Шамил бандалары»н «җиңәселәр» буласын күздә тотып шулай эшләгәннәрдер, күрәсең. Чөнки җитмешенче, сиксәненче елларда ук Кавказда тыныч түгел, әле анда, әле монда дигәндәй, ел саен төрле «бандалар»га каршы гаскәр, танклар куллану очраклары булгалап тора иде бит. «Хаҗи Морат» әсәре исә андый гамәлләргә каршы язылганнарның да иң үтемлесе санала.

Хәтеремдә: кырыгынчы елларда безнең авылда ике китапханә иде. Кечерәге — мәктәпнеке: анда булмаган китапларны эзләп еш кына авыл советы каршындагы китапханәгә дә барып чыккалый идек. Иң гаҗәбе шулдыр, бүгенге заман белән чагыштырганда йөз мәртәбә начаррак тормыш иткән авыр сугыш заманында Татарстаннан читтәге, бик алай зур да булмаган татар авылының ике китапханәсе дә өзелмичә Казаннан һәр яңа чыккан китапны гына түгел, «Совет әдәбияты» журналын да, татарча һәм русча басылган «Әдәби альманах»ны да, яңадан-яңа дәреслекләрне дә даими алып торалар иде! Барлык фәннәрне дә без үз ана телебездә язылган дәреслекләрдән укыдык. Шуңа өстәп әле астрономия, физикадан өстәмә китапчыклар, гади радиоалгычларны ясарга өйрәткән татарча белешмәлекләр дә бар иде.



**Чуваш язучысы А. Колган, татар әдипләре Г. Әпсәләмов, А. Шамов, чуваш шагыйре П. Хузангай, татар шагыйрьләре Зәки Нури, Хәсән Туфан** ***(сулдан уңга).***

Шундый ук күренеш күрше авылның мәктәп-китапханәләренә да хас иде бугай — аларга да яңадан-яңа татар китаплары килеп тора, үзара очрашкан саен без кемнең нәрсәләр укуы белән дә кызыксынабыз. Хәзер исеме яңадан илгә кайтарылган «ак эмигрант» язучы Габделбари Баттал туган Яңавыл егет-кызлары еш кына әдәбият укуда безгә үрнәк булалар иде. Берзаман алар кулында күрелгән Һади Такташ «Әсәрләре»н үзебезнең зур китапханәбездән эзләп табуымны һәм мавыгып укыганлыгымны, Такташча итеп, сүз тезмәләре тезеп маташканлыгымны беләм. Хәтерем ялгышмаса, кызгылт коленкор тышлы ул китап та авыр сугыш елларында басылып, безнең ерак авылны да эзләп тапкан иде. Шул елларда кулдан төшмичә укылган китапларымның берсе — Афзал абыйның бик калын хикәяләр тупламасы иде. Өченче шундый китап — Шәриф Камалның бик калын — озынчарак форматлы иде бугай — шактый тулы бер җыентыгы булды. Мирсәй абый Әмирнең «Агыйдел»ен исә без, Артыкбикә, Күчәрбайлар рәвешенә керергә тырышып, мәктәп сәхнәсендә шуларны җанландырырга маташып йөргән идек. Ул елларда мәктәптә һәм авыл клубларында театр уены уйнау үзенә күрә бер күркәм традиция иде. Яшьләр күңеле шул эшкә, шул һәвәслеккә тартылып торыр иде.

Димәк ки, болар барысы да ерак Казанда торып иҗат итүче Камал, Әмир, Шамовларның уңай бер йогынтысы нәтиҗәсе булган инде. Шул рәвешле алар безне тәрбия кылуда үзләреннән өлеш керткәннәр.

Казанга килгән беренче елларда мин әнә шул үрнәк шәхесләрне күрү хыялында яшәдем. Беренче очрашып сөйләшүдән соң ук миңа Афзал абыйның тыйнаклыгы күзгә чалынган иде. Ул елларда аның «Миннур карт» хикәясе телдән төшми мактала иде. Сугыш хикәяләре һәм истәлекләре көндәлек матбугат битләрендә еш күзгә чалына иде. Ләкин мин алар хакында иркенләп сораша алмадым, Афзал абый күбрәк үземне сөйләтте.

Язучылар оешмасында эшләү дәверендә миңа ике дистә ел чамасы аның белән якыннан аралашып, киңәшеп эшләргә туры килде. Ул елларда Афзал абый Татарстан әдәби фонды идарәсенең бик таләпчән рәисе булды. Каләмдәшләренә, бигрәк тә яшь буын язучыларына карата кайбер мәсьәләләрдә артык таләпчәнлеге ошап бетмәгән очраклар да булгалый иде, әлбәттә. Ул бигрәк тә яшьләр арасында киң тарала башлаган «күңел ачу» гадәтләрен, гаилә тәртипсезлекләрен яратмады. «Каләм иясе һәрчак башкаларга үрнәк буласы кеше», — дип әйткәләр иде. Үзе ул җәһәттән дә артык тыйнак вә тәртипле булды, билгеле.

Хәер, аның тыйнаклыгы кеше арасында үз-үзен тотышында гына түгел, иҗатка карашында да чагыла иде. Кайберәүләр кебек бер үк әсәрне, бер үк китапны элекке дан-шөһрәткә таянып еш чыгаручыларны ул өнәмәде. Шул сәбәпле үз әсәрләренең дә еш кабатланып чыгуын теләми иде. Фәкать аның шул тыйнаклыгы, башкалардан алдарак булырга тырышмавы нәтиҗәсендәдер инде, бүгенге заман китап укучыларына аның сайланма әсәрләр тупланмасы да тапшырылмыйча калды. Бүгенге көндә аның варислары кулында элек дөнья күргән әсәрләренең алты зур томга сыешлы тупланмасы һәм әле беркайда да басылмаган (кызганычка, тәмамланмаган да) өч йөз битле кулъязмасы һәм сайлап бастырган очракта да зур-зур томнар тәшкил итәрдәй кызыклы вә гыйбрәтле көндәлек язмалары бар.

Афзал абый вафатыннан соң берәр ел чамасы үткәч, кызы Әлфия аның әдәби мирасын нәшриятка китереп биргән иде. Нәшриятта шул әсәрләрнең калынрак бер-ике томлыгын әзерләү турында да сүзләр булды. Ләкин нәшрият җитәкчелегенең һаман алмашынып торуы һәм тора-бара китап бастырып чыгаруның зур бер проблемага әйләнеп баруы нәтиҗәсендә ул хыял әле дә тормышка ашырылмаган килеш кала. Татарстан китап нәшриятында Афзал абыйның соңгы елларда үз кулы белән тапшырган ике әсәре чыкты. «Язны көткәндә» дип исемләнгән бик тә матур, гыйбрәтле хикәясе «Көзге ачы җилләрдә» (1988) җыентыгында һәм «Соры мәче» хикәясе балалар өчен дип аерым китап итеп басылды.

Афзал ага Шамовның үз-үзенә карата бик тә таләпчән һәм үз ишләре арасында аеруча да тыйнак булуына тагын бер генә мисал китереп китәсем килә. Шул ук вакытта бу мисал милли әдәбият вә сәнгать өлкәсендә эшләүче башка бик күпләр өчен дә гадәти бер хәл, чарасызлык күренеше буларак та гыйбрәтле, минемчә. Вакыты-вакыты белән партия взносларын да җыйган кеше буларак тәгаен беләм — аның РСФСР күләмендәге персональ пенсиясе йөз дә бер сум иде. 1961 елда аңа зурдан кубып билгеләнгән пенсия бу. Еллар үтә барган саен эш хаклары әз-әзләп кенә булса да арттырылды, шуңа карап кирәк-ярак хакы да арта барды. Шуларга нигезләнеп үз пенсияләренең «түшәмен» беркадәр күтәрүгә ирешүчеләр, шуның артыннан йөрүчеләр дә булгалады. Әмма ләкин Афзал ага Шамовның шул «мәшәкать» белән йөргәнлеген хәтерләмим. Үзе өчен кемгәдер үтенеп, ялынып йөрүләрне ул бервакытта да өнәмәде. Андый киңәшләрне дә алмас иде. Кайберәүләр уйлавынча, бу очракта да ул «артык тыйнак» булды. Миңа калса, аның шул тыйнаклыгы, кешегә ялынмаска тырышуы — үз дәрәҗәсен, үз абруен саклавының бер чарасы иде. Яңа җөмһүрият оешуның беренче көннәреннән үк шул җөмһүрият даны өчен аттай җигелеп эшләгән, күп хезмәтләр куйган, аерым кимсенүләр кичергән бер шәхес буларак, аның үзенә карата башкачарак мөнәсәбәтне көтүе бик аклана иде.

Ләкин еллар дөбердәп үтә торды, буыннар алмашына барды, әдәбият мәйданында кайчандыр төпкә җигелеп тарткан атның егәрен җуеп артка тайпыла башлавын күрүчеләр яисә күрергә тырышучылар гына табылмады.(Хәер, мондый хәл бер Афзал ага язмышына гына кагылмый. Моңа мисаллар безнең тормышта җитәрлек. Әйтик, дистә еллар буе халкыбыз мәдәнияте күгендә былбыл булып сайраган Фатих ага Хөсни мирасы бүген ни хәлдә? Аңа игътибар итүче бармы?) Әйе, еллар уза тора, элекке остазлар, йодрык төйнәп бүгенге тәртипләргә каршы чыга алмаучылар читкә тибәрелә бара. Узып барышлый гына алар өстенә юл чаңнарын (тузанын) кагып киткәләүчеләр дә очраштыргалый.

Ни үкенеч, тормыш шулайрактыр шул инде ул... Бигрәк тә безнең дәвердә ул үткәннәргә карата кырыс булмакчы. Элеккерәк дәверләрдә кешеләр бер-берләренә карата мәрхәмәтлерәк булган дип сөйлиләр. Бәлки, шулай да булгандыр. Миңа калса, Афзал ага Шамов менә шундый шәхес — элекке бәрәкәтле дәвердән, патриархаль тәртип белән яшәгән бабаларыбыз дәвереннән килгән холык-фигыльле олпат бер шәхес иде. Иҗат белән дә ул әнә шул онытылып баручы гадәт һәм йолаларны безнең көнелләрдә яңартырга теләде сыман. Аның шул изге ниятләрен истә тотып, мирас үрнәкләрен бүгенге буын яшьләренә дә җиткерәсе, сайлап алынган әсәрләреннән һич югы бер-ике калын китап чыгарасы иде. Һәрхәлдә, мин шундый өметтә калам. Чөнки ул мирас инде хәзер бер Афзал Шамовныкы гына түгел, бөтен халкыбыз мирасы булырга хаклы.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН.**

# ТАВЫШСЫЗ ҖЫР

Минем өчен, әйтик, АКШ вице-президенты, йә булмаса Венгрия президенты, Франция, Төрки премьер-министрлары турында истәлек язу артык авыр булмас иде, чөнки аларны гомеремдә бер генә тапкыр күрдем. Бер күргән берегебрәк кала икән ул! Дөрес, күргәнең күренекле булганда... Ә менә тарихтагы, кеше күңелендәге эзләре премьер-министрларныкыннан кимрәк булмаган язучылар, галимнәр, рәссамнәр, композиторлар, башка һөнәр ияләре белән, еллар үткәч бөек дип бәһаләнәчәк кешеләр белән, көн саен очрашып яшәгәндә эш башкачарак: сөйләшкән сүзләр дә, кигән киемнәр дә, бергә ашаган ризык та, көннәр-айлар-сәгатьләр дә хәтергә тоныкбулып сеңеп кала. Көндәлек хәлләргә игътибар җитми шул, җитми...

Без Мөхәммәт абый Мәһдиев белән шактый гомер аралашып яшәдек. Ничә еллар дәвамында һәр яз саен Тукай-Кырлайга барулар, төрле мәҗлесләрдә табындаш булулар, җыелышларда, Мәскәүдә узган язучылар съездларында катнашулар, «Казан утлары», «Татарстан хәбәрләре», «Яшь ленинчы» редакцияләрендә очрашулар, аның йә минем басылып чыккан әсәрләребез турында фикер уртаклашулар, нефть якларына, Чаллыга, Түбән Камага, илнең ераграк төбәкләренә бергә сәяхәт кылулар... болар барысы да булган хәлләр. Әмма алардан хәтергә уелып калган эзләрне истәлек итеп тергезү, алда әйткән сәбәпләр аркасында, бик үк җиңел эш түгел...

Мөхәммәт абыйның хәтере әйбәт иде, һәм ул ике-өч елга бер җаен китереп Әлмәт якларында булган бер сөйләшүне искә төшерә иде. Ул нефть суыртa торган «торнаның», ягъни насосның, уннарча еллар бертуктамый эшләгәнен күреп, бу безнең әниләр кебек икән, дигән иде. Мин аңа: сат бу табышыңны, мин, шул күзәтүне кулланып, әниләр турында шигырь язармын, дигәнмен. Ул миңа: яз гына, бушлай бирәм, дигән булган. Мөхәммәт абый миннән егерме еллар әнә шул шигырьне көтеп йөргән, ә мин, вәгъдәсез, язмаганмын...

Дөрес, булган хәл. Шул күзәтүдән файдаланып шигырь язмавым өчен Мөхәммәт абыйның рухы алдында гафу үтенергә генә кала. Нишлисең бит, минем дә үз принципларым бар — нинди генә сокландыргыч, кызыктыргыч булмасын, башка язучылар тапкан, тотып алган шигъри детальләрне, күзәтүләрне, чагыштыруларны үземнең әсәрләремә үземнеке итеп кертмәскә. Әлбәттә, эпиграф итеп алырга, йә булмаса авторын күрсәтеп файдаланырга бик мөмкин.

Мөхәммәт абыйның кунакчыл, тыйнак өендә дә берничә тапкыр булырга туры килде. Ул Казан университетында укытканда алган Галиев урамындагы квартирасында бик озак яшәде. Тукай премиясе лауреаты, халык язучысы дигән исемнәргә лаек булгач кына Чехов урамындагы «түрәләрский» (үзе шулай дип әйтә торган иде) өйгә күчте. Ләкин анда озак яши алмады...

Алар өенә беренче тапкыр керүем бер егерме биш, егерме җиде еллар элек булгандыр. Шунысы ныграк истә калган. Беренче тапкыр булгангадыр инде... Мин ул вакытларда Язучылар союзы идарәсендә җаваплы сәркатип идем. Язучылар союзы Бауман урамындагы Матбугат йортының икенче этажында иде әле. Проза секциясеме, шигырь секциясеме утырышыннан соң без, бер төркем яшьрәкләр, күрәсең богема йогынтысына бирелепме, бәхәсләрне «суыныбрак» дәвам итәр өченме, Матбугат йорты каршындагы «Елочка» дигән мороженое кафесына кереп киттек. Арабызда Мөхәммәт абый да бар иде. Кафеда, билгеле, мороженое ашап салкын тидертмәс өчен ликер, коньяк, коры шәраб кебек төрле җылыткычлар да саталар иде. Шагыйрь Нәби ага Дәүлинең, минемчә, матбугатта күренмәгән бер эпиграммасы бу ханәгә бик төгәл бәя бирә:

Матбугат йорты каршында
«Елочка» дигән йорт бар.
Үзе кечкенә булса да,
Матбугат йортын йоткан...

Менә шул кафеда бераз «йотылып» утырганнан соң безне Мөхәммәт абый үзләренә алып китте. Сәбәп: ул үз сүзләрен дәлилләр өчен ниндидер кулъязмалар, ниндидер китаплар күрсәтергә теләде. Һәм без аның өенә ике таксида барып төштек. Без дигәннән, хәтерем ялгышмаса, Фәрваз Миннуллин, Рәдиф Гатауллин, Рөстәм Мингалимов һәм тагын кемнәрдер бар иде. Ул торгынлык елларында, ни өчендер, таксилар күп һәм таксофоннар да пассажирга карата шактый ихтирамлы, мәрхәмәтле иде.

Фәнни бәхәсне без ул көнне бик тиз тоттык. Эштән Мөхәммәт абыйның хатыны Лилия апа кайтты. Кунакларга рәтле өстәл дә әзерләмәгәнсең, дип ирен битәрли-битәрли, ул тиз генә табын корып җибәрде... Кыскасы, мәҗлес башланып китте. Һәм мин шунда беренче тапкыр Мөхәммәт абыйның җырлавын ишеттем. Без гармунсыз-нисез генә берничә халык җыры җырлаганнан соң, Фәрваз бугай, әйдә, Мәһди, үзеңнең теге Гайнавалыңны сузып җибәр әле, диде. Мөхәммәт абый, артык кыстатып тормастан, тамагын кыргалап куйды.

— Дөрес, егетләр, бу җыр «Ташкыннар» драмасыннан Гайнавал җыры, ну аның сүзләре Таҗи Гыйззәтнеке булмаска тиеш. Әнә карагыз Батырҗан ариясен, йә булмаса теге «Өмә җырын», башка җырларын исегезгә төшерегез... Сәйдәш язганын да, башка композиторларныкын да... Гайнавал җыры халыкчанлыгы белән аерылып тора. Менә, игътибар итегез әле,— дип ул җырлап җибәрде:

Телеграмм баганасын
Саныйсым калган икән.
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән...

— Сиздегезме?— ул халык җыры. Аның исеме — «Телеграмм баганасы» булырга тиеш.

Мөхәммәт абыйның тавышы ул вакытта да, соңгы елларда да көр иде. Баска якын баритон белән ул салмак итеп, җырлаган һәр сүзен мәгънәви хис белән сугарып, тамагы авазын җаны белән тыңлап җырлый иде. Аһ, шушы сәләт кайбер профессиональ артистларда да булса икән!... Башкаручылар бик күп, ә җырчылар — бармак белән генә санарлык. Башкаручы булыр өчен көчле тавыш (хәзер исә — яхшы микрофон) һәм махсус белем дә җитә, ә Җырчы өчен болар гына аз. Чын мәгънәсендә Җырчы булыр өчен башкару осталыгына күңел байлыгы, югары культура, кешелеклелек сәләте дә өстәргә кирәк. Ә Мөхәммәт абый, сәхнәләргә чыкмаса да, җырчы иде... Ул җырның нечкә күңел белән генә тоеп була торган әчкәреге серләрен яхшы белә иде һәм шул серләрдән үзенең роман, повестьларын, хәтта публицистик йә тәнкыйть мәкаләләрен язганда да бик оста файдалана иде. Аның әсәрләренең укучы күңеленә нык тәэсир итү көчен кайберәүләр оста тотып алынган тормыш детальләре, бизәкле, җор телле булуы белән аңлаталар. Алар да хаклы, әлбәттә. Әмма Мәһдиев әсәрләренең төп үзенчәлекләреннән берсе булган җылы, бераз моңсу лиризм — җырлардан. Повесть, хикәяләрендәге кайбер абзацлар, хәтта бүлекләр дә, гаҗәеп рәвештә кинәйтелгән җыр куплетларын хәтерләтәләр. Аларның хәтта үз көйләре дә бар кебек. Ишетә белергә генә кирәк. Мөхәммәт абыйның китапларын яңадан укый башлау белән миңа әллә кайдан ерактан төрле көйләр ишетелә башлый. Еш кына шуның берсе башкаларын басып китә, үзенең тибрәнүенә мине дә суырып кертә. Үзем аның китабын укыйм, үзем әкрен генә, эчтән генә, тавышсыз гына җырлап җибәрәм:

...Сагынасыңмы дип сорыйсың,
Сагынмаган кая ул...

**Ренат ХАРИС.**

8—9 март, 1996 ел.

# ӘХМӘТ ФӘЙЗИ ХАТЛАРЫ



Күренекле әдип Әхмәт Фәйзи.

Ниндидер язучы мирасы турында сүз алып барганда, гадәттә, аның басылып чыккан яки тәмамланмаган, яисә төрле сәбәпләр аркасында дөнья күрми калган әсәрләрен генә күз алдында тоталар иде. Әдипнең эчке дөньясын, аның фикерләрен бөтен тулылыгы белән аңлау өчен бу гына аз, әлбәттә. Язучының шәхси архивы исә тәмамланган әсәрләрдән тыш тәмамланмаганнарын да, әсәрнең төрле вариантларын һәм әсәрне язу өчен тупланган материалларны, көндәлек һәм куен дәфтәрен, фоторәсемнәрен, язышкан хатларын һәм очраклы рәвештә язучы кулына кергән башка әдипләрнең кульъязма әсәрләрен дә һәм башка документларны да үз эченә ала. Шәхси архивлар безгә әдәбиятның барышын конкретрак күзәтергә, чор каршылыкларын ныграк аңларга, язучыларның үзара мөнәсәбәтләрен ачыкларга һәм шәхсән язучының үзен аңларга да булыша.

Моннан өч ел элек миңа язучы Әхмәт Фәйзинең шәхси архивы белән эш итәргә туры килде. Кызыклы материалларга бай булган бу архив фәнни яктан эшкәртелеп, билгеле бер системага китерелде һәм аның тасвирламасы төзелде. Хатлар исә әнә шул тасвирламаның зур өлешен алып тора. Бу мәкалә шул хатларга нигезләнеп, аларны өйрәнү, күзәтү нәтиҗәсендә туган кайбер фикерләрдән чыгып язылды.

Әдип Әхмәт Фәйзинең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты кульъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсендә саклаучы 101 нче санлы шәхси архивында барлыгы — 880 хат бар. Алар 207 эшне тәшкил итә. Шуларның тугызы (216 хат) — язучының иҗтимагый-иҗади эшчәнлеген һәм биографиясен чагылдырган II тасвирга кертелде. Хатларының күпчелеге дөньяга чыкмаган. 48 хаты Ә. Фәйзи әсәрләре биштомлыгының 5 нче томында басылды (5 том.— Казан, ТКН.— 1987, 366—411 б).

Хатлар белән танышканнан соң аның киң карашлы, эрудицияле галим, татар әдәбияты, мәдәнияты үсеше өчен көрәшүче, аны халыкара мәйданга чыгарырга омтылучы фидаи икәнен күрәсең. Аның алдан күрә белүчәнлеге, без бүген хәл итә торган проблемаларны беренчеләрдән булып, үз вакытында ук, дәүләт җитәкчеләре алдына куюы, кыюлыгы сокландыра. Мәсәлән, архивта аның 1955 елда КПСС Өлкә Комитеты секретаре С. Г. Батыевка язган хатының караламасы (Ф — 101, тасв.— 3., 4 нче эш) һәм КПССның Татарстан Өлкә Комитетына язган тулырак вариантлы хаты саклана (Ф — 101, тасв.— 3, 63 нче эш). Ә. Фәйзи бу хатында язучылар белән 19 январьда Өлкә Комитетында булган очрашудан бик үк канәгать калмавын, очрашуга хәзерлексез килгәнгә һәм аз

вакыт бирелгәнгә күрә үз фикерен аңлатып житкерә алмавын әйтә. Очрашуда әйтеп бетермәгән фикерләрен язмача белдерә. Ул республикадагы иҗат оешмалары бер-берсеннән аерым яшәмәсеннәр иде, Тел, әдәбият институты татар әдәбияты тарихын булдыруны, татарча бер томлы энциклопедия чыгаруны, имля, орфография эшләрен төгәлләүне көн тәртибенең үзәгенә куярга тиеш, ди. «Хәзергә кадәр әдәбият фәнендә һәм югары житәкче органнарда татар мәгърифәтчелегенә һәм җәдитчелеккә карата булган ялгыш карашның үзгәргәне юк. Фәннәр арасында тарих өлкәсе безнең ни өчендер иң артта калган фән һәм моның өчен без барыбыз да җаваплы», ди. Фикерләр дөрес һәм бик урынлы булса да, партия җитәкчеләре аларны тормышка ашырырга бик атлыгып тормый, каршы чыгучылар да була. Мәсәлән, аның Мәскәүдән шагыйрь Әнәс Каринның хатыны Рәшидә Хәмитовага язган хаты (1958 ел 21 апрель) кызыклы. Ул шул еллардагы сәяси хәлләр, реабилитацияләнгән язучылар турында язгач, өлкә комитетына беренче секретарь булып эшкә килгән яңа кеше — С. Д. Игнатьев турында җылы гына сүзләр әйтә: «Менә аңа татар культурасын белүче яхшы ярдәмчеләр кирәк иде. Батыев та, Фасеев та йомшаклар. Фасеевны әйтеп тормыйм, аңардан төплерәк Батыев шактый ляпсуслар ясаштыра. Мәсәлән, декада вакытында Москва газеталарында «революциягә кадәр татарның әдәбияты юк иде» — дип язып чыкты. Просветительство мәсьәләләрендә элекке буталчыклык һаман хөкем сөрә. Тарихны искажать итү бездә берни дә түгел, Фасеевлар да, Хәйриләр дә шуны белә торып, үз сүзләрен әйтүдән куркалар. Милли мәсьәләдә Ленин нормаларына кайту буенча бездә бик күп эшлисе бар әле», — ди. Сүз уңаеннан, фондта Камил Фасеевның халкыбызның рухи мирасы үсешен тоткарлаудагы «яхшылыкларын» күрсәткән, тагы ике хат саклануы турында да әйтеп үтәргә кирәк. Болар — 1958 елның 16 апрелендә Хәмитова Рәшидәнең һәм 1956 елның 18 февралендә Н. Җиһановның Ә. Фәйзигә язган хатлары. Ә. Фәйзинең «Литературная газета»да (1956 ел, 18 октябрь) «Әдипнең эрудициясе» исемле мәкаләсе басыла. Мәкалә басылу уңаеннан укучылардан күп санлы хатлар килү язучының киң карашлы, эрудицияле галим икәнен күрсәтеп тора.

Ә. Фәйзигә үзенең гомере буе табынган шагыйре Г. Тукай турында тарихи-биографик роман язу өчен күп көч куярга туры килә. Монда да язучыдан киң белем, эрудиция таләп итегә. Ул шагыйрь йөргән эзләрдән йөреп чыга, бик күп төрле архивларда, фәнни китапханәләрдә эзләнә, шул чор әдәбияты, матбугаты белән таныша. Тукайның замандашлары, якташлары, аның турында истәлек сөйләрдәй кешеләр белән хат алыша. Фондта «Тукай» романын язу белән бәйле 59 хат бар. Аларның барысына да тукталу мөмкин булмаганлыктан, кайберләре хакында кыскача гына әйтеп үтү белән чикләнәбез.

1952 ел 8 февральдә сеңлесе Зәйнәпкә язган хатының ахырында ул түбәндәгечә хәбәр итә: «Романның икенче китабы өчен библиотекада көн-төн материал укыйм һәм кайбер бүлекләрне яза барам. Уральскига җәен барам. Уральски егете Нафигов Зеленодольскидан миңа язып тора һәм Уральскийның фотоларын җибәрә. Шәп егет булып чыкты, миңа бик кирәк егет». Чыннан да, Тукайның Уральскийдагы тормышы турында иң күп белешмә материал җибәрүче шул елларда аспирантурада укучы, хәзер академик Нафигов Рафик Измайлович була. Фондта аның бу уңайдан Ә. Фәйзигә 1951—56 елларда язган 22 хаты теркәлгән. Ә. Фәйзи Тукай белән бергә Уральскида типографиядә эшләгән хәреф җыючы Гладышев Александр Кузьмич белән дә языпшып торган. А. К. Гладышевның 1952—56 елларда аңа язган 18 хаты саклана. Хатлар фактик материалларга байлыгы белән шул чорны күз алдына китереп бастырырга ярдәм итәләр. Ә. Фәйзи К. Мотыйгыйның энесе, Уральскидагы пенсионер Гариф Төхфәтуллинга 1953 елның 9 октябрендә язган хатында Камил Мотыйгый, Тукай турында үзе белгәннәрне яза да: «...инде шулар турында Сезнең өстисе сүзләрегез булса, Сез миңа, романны язучыга, зур бер ярдәм иткән булыр идегез», — ди.

Романда телгә алынган Бәдри абзый малае — Хисаметдинов Камали Тукай турында үзенең белгәннәрен әйтеп Кыргызстанның Җәләлабад өлкәсе «Кок-янгак шәһәреннән 4 хат җибәргән, М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге китапханәнең бүлек мөдире А. Абрамишвили 1957 елның 28 августында язган җавап хатында: «Китапханәнең СССР халыклары әдәбияты бүлегендә Сезне кызыксындырган «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналлары һәм «Фикер» газетасы юк», — дип белдерә. Тукай турында нидидер белешмә бирү характерындагы менә шундый ха-

тлар тагы Абдулла Гомәров (1953, 23 сентябрь), Салих Вәлиди (1952, 8 апрель), Зәкәрия Әхмеров (1953, 12 март), Рәхмәтуллин, Габделбари, Агафонов Б. С. (1955, 20 январь), Зәйнәп Хәйруллина (1952, 19 июль), Гази Кашшаф (1953, 6 февраль), Габдрахман Кәлтиев (1953, 5 ноябрь), Мостафа Ногман (1953, 12 февраль) кебек зыялылардан.



Әхмәт Фәйзи, хатыны Елизавета Степановна Сверчкова һәм уллары Рөстәм.

Ә. Фәйзинең хатлары белән танышa барган саен, аның тагы бер ягы ачыла. Ул югары культуралы, кешеләргә игътибарлы, мәрхәмәтле, чын интеллигент булган. 1957 елның 7 июлендә Әмирхан Еникигә язган хатында: Г. Тукай һәм Фатих Әмирханның якын дусты, «Әльислах» газетасының редакторы Вафа Бәхтияровка бүләк алыр өчен Казанда чагымда 700 сум чамасы акча җыйган идем, шуны мең сумга тутырып бирәр бүләк алып биргәгез иде, дип үтенә. Бүләк өчен акчаның күп өлешен Тел, әдәбият, тарих институты галимнәре биргән була. Йомыш гәрчә язучы Абдулла Әхмәткә тапшырылган булса да, ул аны вакытында үтәмәгән икән. Ә. Фәйзи шуңа бик нык уңайсызланып: «Вакытында аның (Вафа Бәхтияров) 75 еллыгын билгеләп үтәргә безнең күз җитмәде. Соңга калып булса да аңа кечкенә генә бүләк оештырсак, без бу тыйнак җәмәгать эшчесенә карата үз бурычыбызны беркадәр үтәгән булыр идек»,— ди.

Ә. Еники аңа җавап хатында (1957, 22 июль) аның гозерен үтәүләре турында яза. Аның әйтүе буенча, бу вакыйга Вафа абзыйга бик нык тәэсир иткән: «Ул бизгәк тоткан шикелле калтыранып, озак кына сүзен әйтә алмыйча утырды. Дөресен генә әйткәндә, мин аны бу кадәр нечкәреп сөенер дип көтмәгән идем. Кешене онытмау нинди зур эш! Ә без, каткан йөрәкләр, шуны уйлый да белмибез. Ярый әле синең кебек тынгысыз бер абыебыз бар. Картның күз яше белән әйткән рәхмәтләре тулысынча сиңа булырга тиеш»,— ди.

Ә. Фәйзи ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә кулыннан килгән кадәр ярдәм күрсәтергә тырышкан. Татар халкының сөекле композиторы С. Сәйдәшев вафат булгач, аның хатыны Асия ханым авыру хәлендә, яшәү өчен уңайлыклары булмаган салкын бер бүлмәдә кала. Шул уңайдан Ә. Фәйзинең аңа квартира белән ярдәм итүләрен сорап, КПССның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре С. Д. Игнатьевка язган хатының караламасында: «После похорон Сайдашева, когда еще была свежа память о нем, в административных сферах поговаривали об использовании квартиры Сайдашева под музей его имени, предоставив семье другую жилплощадь. Теперь об этом забыли вовсе. Мы должны иметь уважение к учреждаемому самими же институту народных артистов и сохранить чуткость к памяти их. Этого требуют самые элементарные правила советской морали»,— дигән юллар бар. Аның 1953 елның 8 августында Зәйнәп Хәйруллинага композитор Фәрит Яруллин әтисенең — Заһидулла Яруллинның улы мирасына варислыгын раслауны оештыруны сорап язган хаты да, 1956 елның 27 апрелендә Татарстан Язучылар союзы идарәсенә Тукайның исән апалары Газизә һәм Сажидәгә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә мөрәҗәгать итүе дә, яки 1945 елда СССР совет рәссамнары союзы рәисенә Мәскәүдә каты авыру хәлендә яшәүче рәссам М. М. Абдуллинга һәм аның гаиләсенә ярдәм күрсәтүне үтенеп язган хатлары да аның олы йөрәкле шәфкатьле а[illegible] булуын раслап торалар. Фронттан 19[illegible]3 елның 31 июлендә Татар академия театры режиссеры Ширъяздан Сарымсаковка язылган хат сәнгать кешеләренең вакытыннан элек дөньядан китүләренә җаны әрнү, борчылу белән тулы: «Артистларыбызның үлүендә без үзебез гаепле түгелме? Ягъни, алар тере чакта без үзебезнең дуслык, дуслыктан да югарырак рәвештә үз талантларыбызга карата иҗтимагый, тарихи миссиябезне онытып җибәрмибезме? Сарымсак, егет

дус! Нидер эшләргә кирәк! Күбрәк ялкын! Калганнарны, тереләрне сакларга кирәк! Тиешле югарылыкка менеп, хөкүмәт трибунасына җитеп! Тиешле шартлар тудырып! Үзгәчә мөмкин түгел. Сугыштан соң сафларны барлаганда бу бездән соралыр. Моның өчен без һичшиксез җавап бирергә тиеш булырбыз. Бәлки мин моннан кайталмый калырмын. Ул хәлдә бу минем васыять булып калсын».

Ә. Фәйзинең шушыңа аваздаш фикерләре Салих Батталга шигырь белән язылган (1945, 11 июль) хатында да урын алган. Сугышта югалган дуслары Муса Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуйларны сагынып искә ала да: «Син бик кирәк монда, тизрәк кайт әле»,— ди. Салих Батталның бу хат уңаеннан 1950 елның 15 февралендә язган аңлатмасы бар. Ул: «Әхмәт Фәйзи бары үз иҗатының язмышы өчен генә түгел, ә бәлки бөтен татар совет әдәбияты язмышы өчен гомер буена янып-көеп яши. Бу чын мәгънәсендә дәүләтчә кайгыртуның ни дәрәҗәдә тирән булуы, андагы югалтулар өчен аның ни кадәр әрнүе бу шигырь-хатта ачык чагылган.

Шуның белән бергә бу хат авторга хас булган чиктән тыш тыйнаклыкны да чагылдырган: иҗат гомеренең бер минутын да әрәм итми, армый-талмый эшләгән язучы әле һаман үз эшеннән риза түгел. Ул эшне «бар» дип әйтергә дә йөрәге базмый...

Димәк автор без — язучыларның өстенә ни кадәр зур бурычлар йөкләгәнен бик ачык сизә һәм шул бурычны үтәр өчен әдәби көчләрен исән калганнарын тупларга омтыла»,— дип дөрес нәтиҗә ясап куя.

Хатлардан Ә. Фәйзинең Н. Исәнбәт, Ә. Еники кебек чордашлары белән дусларча җылы мөнәсәбәтләрдә булуын күрү белән бергә, шагыйрь Әхмәт Ерикәй белән булган каршылыкларны һәм аңа карата булган антипатиясен дә ачык күрергә мөмкин. Аңа булган кире мөнәсәбәте сигез хатта искә алына.

«Сафа» пьесасын китап итеп бастырудан нигезсез рәвештә төшерелеп калдырылуы уңаеннан КПСС Үзәк Комитеты секретаре П. Н. Поспеловка язган хат та шактый гыйбрәтле. Хатта хәсрәт тәнкыйтьчеләрнең мәсьәләнең асылын аңламыйча үз вакытында һ. Такташны, М. Җәлилне, Ш. Маннурны, С. Батталны «батырулары», бигрәк тә Н. Исәнбәткә һөҗүм итүләре бәян ителә. Анда шулай ук Ә. Ерикәй кебек аерым шәхесләрнең М. Җәлил иҗатын юри яшереп, халыкка чыгартмыйча яткырулары да әйтелә.

«Безнең Татарстанда чын иҗади атмосфера юк, ярдәм итәсе урында административ идарә итү белән шөгыльләнәләр. Без аңлатма кәгазьләре, жалобалар язарга түгел, ә романнар, пьесалар, поэмалар язарга тиеш,— ди. Шушы ук мәсьәләләр аның КПССның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре З. И. Моратовка язган хатында да яктыртыла.

Ә. Фәйзи үзе язганнарга бик тә җаваплы караган. Басылган материалда төгәлсезлек, гаделсезлек күрсә шунда ук гаделлекне торгызу өчен көрәш башлаган. Бу җәһәттән аның «Качкын» операсы турында «Правда» газетасына (1952), типография гаебе белән аның «Фининспектор белән сөйләшү» шигыре тәрҗемәсендә киткән хата турында «Совет әдәбияты» журналына, редакция хезмәткәрләре гаебе белән Ф. Әмирхан турындагы мәкаләдә Әмирханга дөрес булмаган бәяләмә бирү уңаеннан «Дружба народов» журналына (1950) язган хатларын китерергә мөмкин. «Литературная энциклопедия» редакциясенә язган хатында энциклопедиядәге мәкаләләрдә татар язучыларына карата бирелгән бәяләрнең гафу ителмәслек ялгышлыклар белән тулы икәнен хәбәр итә. Яшь, талантлы татар язучыларының энциклопедиягә бөтенләй кертелмичә төшерелеп калдырылуларын да искәртә. «Известия» газетасы редакциясенә язган хатында (1955 ел, 2 апрель) «Шүрәле» балетының сюжеты Г. Тукай язган «Шүрәле» әкиятенә нигезләнүен, әмма ни өчендер аның исеме беркайда да телгә алынмавын тәнкыйть итә. Хатлардан Ә. Фәйзинең иҗат эшен туктарлаган, кирәксезгә рухи һәм физик көчен түктергән, озак еллар буе нерв киеренкелеге белән яшәргә мәҗбүр иткән кешеләр белән низагта булуы һәм алар белән көрәш алып баруы да ачыла. Аның танылган балетмейстер Л. В. Якобсон белән «Шүрәле» балеты либреттосының авторлыгы хакында судлашып йөрүе 1941 елдан 1957 елга кадәр сузыла. Бу уңайдан — 68 хат һәм Ленинград язучысы Ю. И. Слонимский тарафыннан 1953—54 елларда язылган 4 хат бар. Ул да Л. В. Якобсон тарафыннан алдануы, суд өчен материаллар җыюы турында әйтә.

Ә. Фәйзине татар сәхнәсе культурасы, зәвыксыз эшләнгән спектакльләр дә борчый. Бу уңайдан 1952 елның 29 декабрендә ТАССРның сәнгать эшләре идарәсе начальнигы Закировка язган хаты кызыклы: «Опера һәм балет театрында «Качкын» спектакле тиешле сәнгать югарылыгында эшләнмәгән... Ар-

тистлар белән эшләү начар, йомшак... Хор яңгырамый, мизансценалар фикерне ачмыйлар... «Шүрәле» балетының репетициясен дә карадым,— начар. Режиссер үзе яшь булса да тәнкыйтьне кабул итәргә теләми, үзсүзле. Менә болар да татар спектакльләренең чиле-пешле, сәнгатьчә дәрәҗәсе түбән булып чыгуын тәэмин итә дә инде»,— дигән фикерләрне әйтә.

Сөйләгәннәрдән чыгып шуны әйтергә мөмкин: без карап үткән хатлар Әхмәт Фәйзинең тормышын, иҗатын тагы да тулырак күзалларга ярдәм итәләр. Бу хатлар — әдипнең киң эрудицияле, кешелекле, нечкә зәвыклы, тәрбияле, гаделлек өчен көрәшүче олы җанлы шәхес икәнен дәлилли торган тарихи документлар.

Сүз ахырында укучыларга Ә. Фәйзинең шәхси архивыннан берничә хат тәкъдим итәбез.

**Заһир ИСЛАМ,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре.

*8 август, 1953.*
*Мәскәү*
***Зәйнәп Хәйруллинага.***

Зәйнәп күрше, әйбәт күрше!

Үзеңне Казан белән бергә сагынып бик күп сәлам. Бөтен өй эче җәмәгатенә — шулай ук. Казанны чыннап та сагындым, һаман барып чыгарга чират тими. Сентябрьдә дип торам инде, алла боерса! Әле мине бер нәрсә борчый, Зәйнәп! Миңа билгеле булуынча Фәрит Яруллинның атасы биредәге творческий, правовой оешмаларда улының наследнигы булып исәпләнми икән. Следовательно, «Шүрәле» өчен ул акча да алмый булып чыга. Бу ничек инде? Әле суд уңае белән Ленинград юристы миңа обращаться итә: сез Ф. Яруллинның бердәнбер наследницасы Сачекның Украинадагы адресын беләсезме, дип. Мин аңа бүген язып җибәрдем: андый кешене, тем более Ф. Яруллинның андый наследнигын белмим, ә менә аның төп наследнигы — атасын беләм, дидем. Ләкин ул гына җитми бит. Фәритнең атасы срочно, нотариус аша, үзенең Фәритнең туган атасы икәнен оформить итеп, Москва литфондына, йә минем исемгә җибәрергә тиеш бит! Кайда ул карт? Точный исем, фамилиясе һәм адресы ничек? Мин бу хатны Союз композиторовка язмакчы идем. Ләкин алар җәйгә таралып беткәннәрдер, дип уйлыйм. Ярдәм итик әле шул картка, Зәйнәп! Син бу мәсьәләдә нишли аласың, эшлә, калганын мин монда Москвада тәгәлләрмен. Җавап көтәм.

Үзең нихәл, кайчан отпуск? Әниләр, апалар исәнме? Чулпан[1] ни эшләр бетерә? Аңа минем сәламне тапшыр!

Сәлам һәм хөрмәт белән **Әхмәт Фәйзи.**

Минем җәйге адрес конвертта. 25/VIIIка хәтле.

***Әмирхан Еникигә***
*1957 ел, 7 июль.*

Әмирхан дус!

Сиңа йомыш, авырсынма! Син бер тапкыр Ясная Поляна әманәтен Казанга бик зур һәм мактаулы төгәллек белән алып кайтып тапшырган идең. Инде икенче изге бер йомыш тора. Мин Казанда чагында Тукай һәм Ф. Әмирханның дусты, карт җәмәгать эшчесе Вафа абзый Бәхтияровка аның 70 еллыгы һәм декада уңае белән бүләк алып бирер өчен 700 сум чамасы акча җыеп, шуны 1000 сумга тутырыр өчен Абдул Әхмәткә (Ф. Хөсни киңәше белән) тапшырган идем. Костюммы, нәрсә алып бирмәкче булып калганнар иде. Шул әманәт А. Әхмәтнең битсезлеге аркасында шушы көнгә кадәр тапшырылмаган икән! Хурлык һәм оят! Ул карт бит үлем алдында тора, үлсә, ичмасам, кадеремне белделәр дип куанып үлсен иде! Ә бу оятсызлар аның үлгәнен көтеп торалар. Мин ул кеңәгә күтәреп

[1] 1. Чулпан — Чулпан Бәхтиярова музыка белгече, профессор.

йөрүче ага-энедә бу кадәр оят качкан дип белми идем. Алар синең һәр изге ниятеңне бер комедиягә әйләндерергә, мыскыл итәргә һәм, әгәр мөмкин булса, шуны синең гөнаһыңа әйләндереп йөзеңә сугарга торалар. Бер караклары Тукай рукописен урлый, шуны минем өскә аударырга тырышалар бит!

Синең белән без аз-маз иске (ягъни благородныйрак) тәрбия күргән кешеләр өчен А. Әхмәтнең бу поступогы әлбәттә гафу итәрлек түгел. Ал зинһар шуның кулыннан акчаны һәм илтеп тапшыр шуны (акча рәвешендәме, бүләк рәвешендәме) шул һәйбәт һәм бәхетсез картка! Акчаның күп өлешен мин филиалдан[1] җыйганга күрә, аннан бер кеше белән икәүләп эшләсәгез тагы да яхшы. Мәсәлән яшь галим Мөхәммәдьяров белән (ул нәкъ Вафа Бәхтияровның күршесе).

Абдул Әхмәткә мөрәҗәгатне шушында терким (доверенность урынына). Акчаны расписка биреп ал. Сәлам белән кулыңны кысып Әхмәт.

P. S. Җәйге планнарыңны язып җибәр. Планнар туры килмәсме? Өфе ягы тартмыймы сине?

**Ә. Ф.**

Без халыкка хезмәте белән танылган кешеләребезне хөрмәт итәбез, аларның юбилейларын уздырабыз. Вафа абзый Бәхтияров шундый карт эшчеләрдән берсе. Ул Тукай һәм Фатыйх Әмирханның якын дусты, аларның ярдәмчесе, «Әльислах» газетасының (укучылар органы) редакторы. Совет елларында ул совет укытучысы һәм чын мәгънәсе белән совет кешесе. Карт һәм авыру булуына карамастан (76 яшь) ул шушы көнгә кадәр безнең тарих, әдәбият, музыка оешмаларына үзенең тарихи белешмәләре белән ярдәм күрсәтеп килә. Вакытында аның 75 еллыгын билгеләп үтәргә безнең кул җитмәде. Соңга калып булса да аңа кечкенә генә бүләк оештырсак, без бу тыйнак җәмәгать эшчесенә карата үз бурычыбызны беркадәр үтәгән булыр идек.

*Первому секретарю Татар. Обкома КПСС*
*тов.* ***Игнатьеву.***

После смерти татарского народного артиста, композитора С. Сайдашева осталось его больная жена А. Сайдашева в большой, но совершенно не приспособленной к зиме квартире (по ул. Горького, 13). В зимние месяцы в этой квартире поддавалось утеплению только одна маленькая комната, где хозяйка спасалась от холода. Неоднократные ее обращения к учреждениям и лицам ведающим жилищными делами, о замене ее большой квартиры двумя комнатами, пригодными для жилья остались безрезультатными. Безответными остались так же ходатайства отдельных лиц, друзей покойного композитора. Мало того, дирекция Татар. Акад. театра, кому принадлежит помещение, в последнее время выселила ее из маленькой утепленной комнаты в холодный зал и поместила там свою работницу. Бездушно поступила дирекция по отношению к памяти работника, отдавшего всю свою творческую силу этому театру.

После похорон Сайдашева когда еще была свежа помять о нем, в административных сферах поговаривали об использовании квартиры Сайдашева под музей его имени, предоставив семье другую жилплощать. Теперь об этом забыли вовсе. Мы должны иметь уважение к учреждаемому самими же институту народных артистов и сохранить чуткость к памяти их. Этого требуют самые элементарные правила советской морали.

Дорогой товарищ Игнатьев, мы очень просим вмешаться в это дело и положить конец мытарствам семьи Сайдашева.

*Хатның караламасы.*
*(датасы куелмаган).*

*20 август, 1956.*
*Москва.*
*Укытучысы* ***В. А. Кондаковка***

Дорогой Вадим Александрович.

Перечитал еще раз Ваше письмо и решил написать, хотя я в сентябре буду в Казани и намереваюсь зайти к Вам специально поговорить на тему, поднятую

[1] филиал — хәзерге көндә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институты.

Вами. Вы совершенно правы в том, что официальное «отсутствие вежливости» компенсирует благодарная чуткость (неофициальная, а потому ценная!) общественности и друзей. А представьте себе обратное: официально вас чествуют, а общественность и друзья холодны к вашим заслугам. Хуже ничего нельзя придумать. Вам довелось ли прочесть в «Советской России» от 26. VII довольно-таки злую и едкую, но вполне справедливую статью о Казанских делах? Наше Казанское руководство засыпалось с одним своим питомцем — любимчиком, выпестованном как раз в духе угодного ему кадра. Оно решило возвысить его, перевести, из районного воротилы в областное с наиотличнейшей характеристикой. И что ж? Любимчик-то подвел: оказался подлецом и пройдохой! Общественность запротестовала против такого «выдвиженца», официально-признанного и центральная печать одобрила ее суд. Вот еще как бывает в жизни, Вадим Александрович! Я сам проработал для Казани, для татарского народа более 35 лет честно, не покладая рук. Я являюсь пионером в ряде областей искусства: нашей с Жигановым оперой открылся первый в истории татарского искусства оперный театр, по моей инициативе и по моему либретто был поставлен первый татарский балет («Шурале»), нашедший всесоюзное звучание, первые исторические пьесы о Тукае и роман о нем, около 20 названий книг и т. п. Не только орденом, но даже медалью не удостоили мой литературно-общественный труд официальные руководители. Но признали меня общественность, полюбил, как мне кажется, мои книги народ, свидетельством чего являются письма, телеграммы, личные засвидетельства, ваши признательности,— и мне больше ничего не нужно. Выше этой оценки я ничего не представляю. Скорбно лишь то, что в некоторых случаях получается расхождение оценок — официальной и общественной. Но от этого проигрывает не чествуемое лицо, а официальное руководство. Но все же радостно констатировать, что это расхождение, видимо было временного характера, связанного с периодом «культа личности», и теперь мы возвращаемся постепенно к Ленинским нормам руководства и связи общественностью. Это очень хорошо! Обо всем остальном — при встрече. Желаю вам здоровья и бодрости, дорогой учитель!

Ваш **Ахмед Файзи.**

Фаине Аполлинариевне большой поклон!

*Казан, 22 дек. 1954.*
***Сеңлесе Зәйнәптән.***

Абый, кичә 21 декабрьдә Сәйдәшне озаттык. 19 ында сәгать көндезге 3 тән, төнге 10 га кадәр халык урамнан, бер квартал чират торып, күрергә халык агылды. Ә кичә 21 ендә иртәнге 9 00 дан көндезге 12 00 гә кадәр шулай бертуктаусыз аны күрер өчен бөтен Казан халкы агылып торды. Кемнәр генә килмәгән анда: карт бабайлар, әбиләр, руслар — барысы да килгәннәр. Ә инде аның гәүдәсен чыгарганда, шулай ук озатканда халык урамга сыймады, бөтен транспортлар туктады. Алып киттеләр машина белән, биек итеп, бөтен кешегә күренерлек итеп куйганнар, веноклар хисапсыз күп. Ике духовой оркестр. Тат. акад. театрыннан татар зиратына алып киттеләр. Мин дә Куйбышев мәйданына кадәр озаттым. Минем эшкә барасым бар иде. Радиодан аның турында сөйләгәндә, үзенең «Күзләр»дәге музыкасын уйнаганда, чыннан да аның халык белән саубуллашкан теге гәүдәсе күз алдына баса. Монда, Москвада вакытта синең аның янына еш кына баруыңны һәм аны Казанга озатканда зур тырышлык күрсәтүең турында сөйлиләр.

Ярый инде абый, рәхмәт, үкенечкә калырлык булмаган инде.

Зиратта речь белән Җ. Фәйзи, филиалдан Гыймади һәм тагын кемдер речь сөйләгән.

*Язучы Нәкый Исәнбәтнең Әхмәт Фәйзигә язган хаты*
*7/VI—33 ел.*

Хатыңны алдым, фәез!

Бераз мине кызарткансың. Но, иптәшләрчә. Күп сүзең туры. Алай да син минем дөньяга чыкмый ятуымны — «беткә ачу итеп тун ягу — дип, бераз чуклап, койрыклап җибәргәнсең. Монысы бигүк туры түгел. Син минем эшли икәнне үзең беләсең. Былтыр, быел гына да түгел, 20 ел! Нинди тискәрелек турында сөйлисең

икән син? Бер минутка да собатаж ясаганым юк. Казанда дүрт ел торам, язган «нәрсәм»не ара-тирә басарга да итәм. ЦК карарларыннан соң күнел бигрәк тә күтәрелеп китте. Редакцияләрне бер йөреп әйләнеп чыгам. Бар да исәнлек сорыйлар. Кул сузам, алалар. Хәтта, сөйләшәләр дә. Мәсәлән,— һавалар ничек? — дип. Бер кат тәрәзәгә карап алалар. Алалар да: — Көн җылытырга әйтә,— диләр.— «Черек күл»дә карусельне күчергәннәр...— дим.— Ие, ие... диләр; анар да җавап бирәләр.— Тәмәке тартасызмы? — дим. Рәхмәт,— диләр. Тарталар. Үзләре дә бирәләр.— Үзегезне күргәч, искә төште: сезгә моннан берничә ай элек берничә «нәрсә» калдырып киткән идем, каралдымы икән шулар — дим.— Ә,... «теге»ләрне әйтәсеңме? Әле, кем, редактор үзе читтә булды бит әле... Каралыр инде алар, каралыр..— диләр.— Сезоны үтмиме соң? — дим.— Кыяр түгел ич ул, сезоны үтәргә... диләр. Көлке чыга. Көләбез.— Шулай шул — дим. Бер тискәрелек тә күрсәтмим, килешәм. Тартабыз. Ә син анда әллә ниткән Исәнбәт тискәрелеге турында сөйлисең. Беткә ачу. Тун ягу... Берсе дә юк, иптәш. Каян килде сиңа мондый фикерләр?

Шундый күңелле очрашулардан соң, мин тагын да рухланып китеп, өйгә кайту белән кызу-кызу язарга утырам. Дөрес, көне-төне язам дип мактанып булмый булуын. Төрле вакыт була. Менә, Гөлсем Мәскәүгә барып миңа бер бала бүләк итеп алып кайтты. Исменә «Трек» кушып, аңа шатланырга өлгермәдем, ул үлде. Нәни генә салкын тидергән. Өй бераз сырсрак. Утын да юк. Әнә шундый хәл дә була. Үлә. Күмәсең. Өстенә тере балаларың була. Алар кайта. Өйдә чыр-чу була. Ашарга-эчәргә рәтлисе була.— Бетмәс әле-дим,— язмакчы булам. Менә шундый яхшы тема башта кайный. Тик сызып-сызып кына ыргытасы. Башлыйм... Башымны кинәт күтәрәм. Янымда Гөлсем тора. Кулы әкрен генә минем кесәмдә йөри: — Кая, икмәккә акчаң юкмы? — ди. Юк.— Алайса бүген икмәк алып булмый? — Булмый... Булмаса! Барыбер кич инде, ятырбыз...— дим. Үзем туктамыйм, һаман язам.— Язган буш калмас әле, анда элек язган «нәрсәләр» дә бирелгән әле, сезгә бераз акчасы да чыгар шунда... дим. Янәсе, хатынны юатам. Мондый вакытларда Гөлсемгә бигүк мәхәббәтле күренәмдер дип әйтә алмыйм алуын. Кайчак шулай да булып куя, бер дә язарга мөмкин булмый. Бар да йөгерә! Хатын да, балалар да йөгерә. Савыт-саба, китап-кәгазь, икмәк карточкалары... бар да йөгерә! Андый чакта язмыйсың. Үзең дә йөгерә башлыйсың. Дөрес, син мондый объектив сәбәпләрне танымый торгансындырсың. Мин аз-маз таныйм шул, иптәш. Әнә шул чакларда язмый да торам. Но, бит анысы миннән түгел ахрысы. Ә син — тискәре дә, беткә ачу,... тун ягу — дип, Кремльдән торып царь-пушкадан атасың.

— Нәрсә язасың? — дип сорыйсың инде. Язмаган нәрсәм юк, иптәш. Үзеңә дә бит укып күрсәткәләдем. Пьеса язам. Критика... әдәбият теориясе... Фольклор... Дингә каршы материаллар... Тагын әллә-әллә-ниләр. Һәрберсе башка килә тора шунда. Үзеңә дә укып күрсәткәләдем ич. Менә сезгә «Идегәй-Морадын»ны эшләп җибәрдем. Тагын кирәк — дип бер сүзегез килсә, тагын эшләргә әзер торам.— Басылмый калса? Югалса? Мордар китсә? Кире кайтса? Кәгазь-кара хакы да кайтмаса?... Кайтмаса?

Тагын син — беткә ачу итеп тун ягу дип көләрсең инде. Беләм, көләрсең. Син — усал малай. Анысы да анысы, но син мине Мәскәүгә чакырып әйбәт иткәнсең. Бик кәефем килде. Мәскәүне бик күрәсе килә, бик сагынган идем. Бармасам да, барган кебек булдым. Тиздән отпускам була, Идегәй белән Морадын кебек батырлар ат-тун бирсә, барып та чыгар идем әллә? Барсам-бармасам да, синең чакыруың яхшы. Вообще, син Фәез, зерә откровенно — һәйбәт итеп, турыдан-туры хат язгансың. Бер үзем генә идем. Бүлмәдә көлә-көлә укыдым. Менә монысы иптәшләрчә булган ичмаса. Аннан, укып чыккач, болай дип куйдым: күрәсең дөньяга Болак күпереннән генә торып карамый торган егетләр дә бар; шулай булгач, минем революцион иҗадым да бушка гына ятып калмас, аларның да эчке мәгънәсен аңлаган иптәшләр булыр! Булырмы?

Шулай булмаса, мин нәрсәмә дип дөмегеп язып утырам соң? Яз. Хуш. Сүгенсәң дә ярый. Анысы үзара. **Н. Исәнбәт.**

Сораган материалларыгызны җибәрдем. Тагын кирәк булса, гарәп хәрефе белән җибәреп булмасмы?

Монда башкортча текстны татарча — бастырып, яздырып, төзәтеп чыгасы — вакытны күп ала.

**Фаяз Хуҗин,**
тарих фәннәре кандидаты, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты.

# БОРЫНГЫ КАЗАН:

## кичәге һәм бүгенге археологик ачышлар

Республикабыз территориясендә борын-борыннан яшәп килгән халыкларның биш меңгә якын тарих-археология истәлекләре (шәһәрлекләр, авыл урыннары, зиратлар һ. б.) сакланып калган. Шуларның ике меңгә якыны болгар чорына карый. Болгар, Биләр, Суар, Җүкәтау, Тубылгытау, Кашан, Чаллы, Кирмән кебек болгар шәһәрләрен укып-ишетеп кенә булса да белмәүчеләр юктыр, дип уйлыйм. Без ул истәлекләрне хаклы рәвештә, горурланып, халкыбыз тарихының җәүһәрләре дип йөртәбез. Шул җәүһәрләр арасында Казан Кремле дә бар.

Гаҗәеп үзенчәлекле һәйкәл ул безнең Кремлебез! Аның мәһабәт таш диварлары, мәшһүр Сөембикәсе, калынлыгы дүртәр-бишәр метрга җитә торган культура катламы халкыбызның бөтен тарихын үзенә сыйдырган, сендергәндер кебек. Ләкин менә шул тарихны әле һаман да юньләп укый алганыбыз юк. Бер уйласаң, чынлап та гаҗәп: башкалабызның нәкъ үзәгендә урнашкан, борынгы елъязмалар да күп тапкырлар телгә алынган, риваять-легендаларга, тирән серләргә күмелгән изге һәйкәлебез — Казан Кремле — шушы көннәргә кадәр диярлек галимнәр тарафыннан җентекләп тикшерелә алмады. Таш гасырларны өйрәнү өчен махсус экспедицияләр оештырып, дистәләрчә-йөзләрчә чакрымлык җирләргә чыгып китәләр. Ә безнең археология бүлеге дә булган Татарстан фәннәр академиясе бинасыннан Кремльгә кадәр җәяүләп, күп булса, ун-унбиш минутлык юлдыр...

Хан заманнарыннан башлап, Кремль эчендә төрледән-төрле дәүләт һәм хөкүмәт учреждениеләре, хәрби гарнизоннар урнашкан булган. Кремль казылмаларыннан табылачак материалларның Казан ханлыгы, болгар-татар халкының чын дөрес тарихын язу мөмкинлеген бирүе куркыткандыр, күрәсең, кайбер түрәләрне. Менә шул куркак сәясәтнең нәтиҗәсе буларак, үзебезнең Казан ханлыгы чоры тарихын без гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар beləбез. Әле хәзер дә Михаил Худяковның Казан ханлыгы турында 1923 елда гына нәшер ителгән мәгълүм китабын классик әсәрләрдән санап, аңа табынып яшибез.

Заманалар үзгәрде. Ниһаять, Кремльдә дә узган ел киң күләмле археологик казу эшләре башланып китте. Бу эшләрне башлап җибәрү алдыннан без, гадәттәгечә, архивларда, фәнни китапханәләрдә «казындык», безгә кадәр үткәрелгән казылмалар, табылдыклар турында кызыклы гына мәгълүматлар тупладык. Ни генә булмасын, без бит Кремль территориясенә аяк баскан беренче археологлар түгел идек.

Әле узган гасыр урталарында ук Казан Кремле археологларның даими күзәтү объектына әйләнә. Һәрхәлдә, 1861, 1878, 1893, 1909 елларда табылган һәм XIV—XVI гасырларда сугылган акча хәзинәләре турыдан-туры тарихчылар, нумизматлар кулына килеп керә. Шушы табылдыкларга нигезләнеп, алар Казанның барлыкка килү вакытын Алтын Урда чорына бәйләп аңлаталар. Төрле төзелеш, җир казу эшләре вакытында килеп чыккан очраклы табылдыкларны да (чүлмәк китекләре, эш һәм сугыш кораллары, бизәнү әйберләре, йорт кирәк-яраклары һ. б.), югалтмыйча, археологларга тапшыралар һәм алар күбесе әле дә Татарстан дәүләт музеенда саклана.

1881 елда Кремльнең төньяк-көнбатыш өлешендә (Юнкерлар училищесының ишек алдында) төзелеш-ремонт эшләре башлангач, археолог П. А. Пономарев белән Н. П. Загоскин зур булмаган траншея казып, анда ниндидер борынгы агач корылмаларга юлыгалар. Хәзерге Кремль диварларыннан аз гына эчкәрәк кереп урнашкан бу корылмаларны алар, Казан ханлыгы чорына караган саклану ныгытмаларыннан калгандыр, дип фаразлыйлар. Бу фараз, бер китаптан икенчесенә күчә-күчә, аксиомага әверелеп, галимнәр арасында әлегә кадәр яшәп килә: 1552 ел вакыйгалары алдыннан Кремль имән диварлар белән уратып алынган булган, ә хәзер без көн дә күрә торган таш-кирпеч диварлар Иван Грозный фәрманы белән салынган, имеш...

Советлар хакимияте чорында, 1920 еллардан башлап 1950 елларның ахырына кадәр, Кремль археологиясе белән күренекле галим, тарихчы һәм археолог Николай Филиппович Калинин шөгыльләнә. Аның күпъеллык күзәтүләре һәм максатчан тикшеренү нәтиҗәләре «Казанның иң борынгы чорлардан алып XVII гасырларга кадәрге тарихы» дигән докторлык диссертациясендә урын алган. Кызганычка каршы, бу диссертацияне, төрле сәбәпләр тапкан булып, яклаттырмыйлар. Мәскәү рөхсәт бирми, чөнки ул чакларда Казан тарихы тыелган темалар исемлегендә була әле.

Архив материалларыннан күренгәнчә, 1925 елда Н. Ф. Калинин профессор В. Ф. Смолин белән бергәләп Сөембикә манарасы янында, суыткәргеч торбалар өчен казылган бер траншеяда Кремльнең борынгы культура катламнарын өйрәнә. Бирердә ул, беренчеләрдән булып, Казан ханлыгы чорында тупланган катламнарны аныклый, аның үзенчәлекләрен күрсәтә. Табылдыклар арасыннан XV—XVI гасыргы болгар-татар керамикасын аерып ала, әмма ләкин XIV гасырга һәм аннан да элгәрерәк чорларга караган материалларны да шул ук төркемгә кертеп тикшерә.





*Рис. 2.* Казань в первой половине XVI века. Реконструкция Н. Ф. Калинина.

1. Булак. 2. Казанка. 3. Ворота Нур-Али. 4. Дворец. 5. Большая северо-восточная башня. 6. Соборная мечеть. 7. Тезицкий ров. 8. Кладбище. 9. Большие ворота. 10. [illegible] XVI века. 11. Посад. 12. Аталыковы ворота. 13. Тюменские ворота. 14. Даировы бани.

XVI гасырның беренче яртысында Казан шәһәренең гомуми күренеше. *Н. Ф. Калинин реконструкциясе.*

1928—1929 елларда Казанда, болгар-татар тарихы һәйкәлләрен кинрәк өйрәнү максатыннан чыгып, зур гына экспедиция оештыралар. Биләр һәм Җүкәтау шәһәрләре белән берррәттән, Кремльдә дә тикшерү эшләре үткәргән кыланалар. Бу эшләрнең җитәкчесе профессор И. Н. Бораздин Благовещение чиркәвеннән төньяк һәм көнчыгыш юнәлешләрдә сынамак өчен генә бераз казып карый. Соңыннан: «Бу казылмалар Казан тарихы өчен берни дә бирмәде»,— дип нәтиҗә ясый ул. Ләкин Н. Ф. Калининның фикере башкачарак була. Беренчедән, ди ул, казылган барлык урыннарда да ханлык чорына караган катламнар ачыла һәм ул катламнарда болгар-татар керамикасы табыла; икенчедән, чокырларның берсендә, Кремль калкулыгы кырыенда, моңарчы билгеле булмаган таш дивар калдыклары килеп чыга. **Аның салыну вакыты XVII йөз булырга тиеш, дип уйлыйлар, чынлыкта исә ул XII гасыр ахырларында ук төзелгән — без моны узган ел гына**

**ачыклый алдык.** Ниһаять, Сөембикә манарасы янында урнашкан Сарай чиркәвенең нигезләрен чистартканда Н. Ф. Калинин бу чиркәүнең ханлык чорына караган таш бина өстендә «утыруын» исбат итә. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: әлеге таш бинаның, дөрестән дә, атаклы Нур-Гали мәчетеннән калган булуын хәзер инде күпләр инкяр итми диярлек.

1935 елда Н. Ф. Калинин Кремльнең төньяк диварлары тирәсендә кызыклы тикшеренүләр үткәрә. Бер караганда, аның казылмаларында искитәрлек табылдыклар да юк кебек. Шулай да, галимнең архивта сакланып калган материалларында безнең өчен бик тә әһәмиятле фактлар теркәлгән. Дүрт-биш метр калынлыктагы культура катламын ул 11 горизонтка бүлеп чыга. Астагыларын XV—XVI гасырларда тупланган, дип белдерә һәм, Кремльнең төньягындагы хәзерге таш диварлар, төгәлрәк әйткәндә, аларның җир астындагы өлеше ханлык чорында ук салынган булырга охшый, дип йомгак ясый. Н. Ф. Калинин үткәргән әлеге күзәтүләрнең нәтиҗәсе, аянычка каршы, фәнни әйләнешкә кертелмәде, күпләр өчен билгесез булып кала бирде. Ә бит ул үзенә күрә олы ачыш иде. Яшереп торасы юк, әле дә күпчелек очракта, Кремльнең таш диварларын Иван Грозный төзеткән, дип язалар. Баксаң исә, урыс баскыннары болгар-татарлар салган диварларны гына торгызганнар булып чыга түгелме соң? Кремльнең көнбатыш ягында безнең тарафтан үткәрелгән быелгы күзәтүләр дә нәкъ шуны раслый.

1947 һәм 1949 елларда борынгы Казанның тарихи топографиясен өйрәнү өлкәсендә яңа ачышлар була. Кремльнең көньяк һәм Көньяк-көнчыгыш өлешендә су үткәрү траншеялары, канаулар казый башлыйлар. Н. Ф. Калинин 150 метр озынлыктагы бер траншеяның стеналарын чистартканда ике урында мөселман зираты эзләренә — каберлекләргә юлыга. Аларның берсе, борынгырагы, Мәдәният министрлыгы ишегалдында (хәзер ул урында 1960 елларда салынган ашханә бинасы), икенчесе, соңгырагы, көньяктарак, Авыл хуҗалыгы министрлыгы ишегалдында урнашкан була. Шул тирәдә үк, Спасс манарасын үтеп бераз баргач, ханлык чорында казылган тирән чокыр — Н. Ф. Калинин фаразлавынча, саклану ныгытмаларының эзләре — килеп чыга. Нәкъ менә шушы, әлегә кадәр юньләп ачыкланмаган материалларга нигезләнеп һәм П. А. Пономарев белән Н. П. Загоскинның 1881 елгы күзәтүләрен дә искә алып, күпчелек тарихчылар бүген дә, 1552 елга кадәр Кремльнең территориясе аннан соңгыга караганда кечерәк булган, дигән шикле фикерне алга сөрәләр.

Археология методикасының бөтен шартларына җавап бирерлек дәрәҗәдә оештырылган казу эшләре Кремль территориясендә беренче мәртәбә 1953—1954 елларда гына үткәрелә. Экспедициянең җитәкчесе Н. Ф. Калинин Казан археологиясен иң яхшы белүче абруйлы галим буларак танылa. Нур-Гали (Тайницкий) капкасыннан бераз эчкәрәк үтеп салынган казылмалар уңышлы үтә, ханлык чорына караган бик күп әйберләр табыла (савыт-саба, көн аяк киемнәре, орчык башлары, пычак-кайчы, ачкыч-йозак ише көнкүреш әйберләре — барысы да Татарстан дәүләт музеенда саклана). Казылмаларның берсендә яхшы гына сакланган агач корылмалар ачыла. Бу конструкцияләрне җентекләп өйрәнеп, Н. Ф. Калинин, алар Кремль эчендәге хан сараен уратып алган өстәмә ныгытмалар — агач дивар һәм почмак манара эзләре булырга тиеш, дигән кызыклы фикер әйтә. Бу фикер, кызганычка күрә, бүгенге көнгә тикле яңа археологик фактлар белән исбатланмаган килеш кала бирә.

Игътибар иттегезме икән: заманында Кремль археологиясен иң яхшы белүче археологлардан саналса да, Н. Ф. Калинин казылмаларда ачылган культура катламнарында бары тик соңгы урыс һәм аннан элгәреге ханлык чорына караган горизонтларны гына аерып ала алган. Аның казылмаларында болгар катламнары булмадымы икәнни? — дигән сорау туа. Булган, әлбәттә! Шулай икән, нигә ул аларга игътибар итмәгән? Моның җитди сәбәпләре бар. Беренчедән, ул вакытларда болгар археологиясенең үсеш дәрәҗәсе хәзерге югарылыкта түгел иде әле. Теге яки бу катламның, корылманың датасын билгеләүдә төп рольне үтәүче керамика (гади тел белән әйтсәк, чүлмәк китекләре) Н. Ф. Калинин заманнарында бик начар өйрәнелгән иде. Болгар керамикасының хронологик классификациясе дигән проблема өстендә күренекле археолог Т. А. Хлебникова 1960 елларда гына эшли башлады. Икенчедән, бу хәл Н. Ф. Калининның борынгы Казан тарихы буенча үз концепциясенә ахыргача тугрылык саклавыннан да киләдер, дип уйлыйм. Аның концепциясендә монголларга кадәрге һәм Алтын Урда чорындагы Казанга урын юк иде. Дәресрәге, Кремль калкулыгында бар-

лыкка килгән хәзерге Казанның элгәресен ул, риваять-легендаларга тулысынча ышанып, «Иске Казан»нан (Камай каласы һәм Урмат авылы, XIII—XIV гасырлар) һәм аннан соңгы Җылантаудан («Яңа Казан», XIV гасыр ахыры) эзләде.



Борынгы Казан Кремленең гомуми күренеше *Э. Турнерелли гравюрасы.*

Н. Ф. Калинин концепциясе буенча, Җылантауда «Яңа Казан» берничә ел гына яшәгән булса кирәк, чөнки 1399 елда урыс кенәзе Юрий җитәкчелегендәге илбасарлар Казан кенәзлегенә бик каты һөҗүм ясаганнар. «Һәм Казан тиз арада буйсынды, күздән төште һәм җимерелеп, 40 ел буш торды». Шуннан соң, XV гасырның 30—40 нчы елларында, Казанны яңадан аякка бастыралар. «Казан өченче урында, хәзерге Кремль калкулыгында төзелә» (бу турыда карагыз: Калинин Н. Ф. Казан. Тарихи очерк.— Казан, 1957.—31 бит). Шулай икән, галимнең фикеренчә, Кремль калкулыгында XV гасырның 30—40 нчы елларына кадәрге катламнарны эзләп торуның кирәге дә юк.

Н. Ф. Калинин тикшеренүләреннән соң Кремль территориясенә археологларны ике дистә ел чамасы аяк та бастырмадылар.


1970 еллар башында да атаклы галимебез, күренекле татар археологы һәм тарихчысы профессор Альфред Хәсән улы Халиков Казанның барлыкка килүе турында өр-яңа фәнни концепция белән чыгыш ясый. Галимнең игътибарын билгесез авторның «Казан тарихы» исемле публицистик әсәрендә (1564—1566 елларда язылган дип исәплиләр) шәһәргә нигез салу уңаеннан телгә алынган «1177 ел» датасы җәлеп итә. Казу эшләренә рөхсәт алганчы, ул әле борынгы Казан тарихы белән бәйле барлык язма чыганакларны өйрәнә, музейларда эшли, бигрәк тә үзенең остазы Н. Ф. Калинин казылмаларыннан табылган коллекцияләрне җентекләп тикшерә. Нәтиҗәдә А. Х. Халиков, Казан Кремлендә элегрәк табылган әйберләр арасында, һичшиксез, монголларга кадәрге (XII гасыр ахыры—XIII гасыр башлары) үрнәкләр дә бар, дигән фикергә килә. «Казанга 1177 елда нигез салынган» дигән фаразны яңа археологик казылмалардан чыккан материаллар белән генә дәлилләрсе кала.

Шушы олы максатны күздә тотып, ниһаять, Казан Кремлендә казу эшләрен башлап җибәрергә рөхсәт алына. Биш ел эчендә (1974—1978) профессор А. Х. Халиков җитәкчелегендәге археологик экспедиция күп кенә ачышлар ясарга өлгерә.

Беренче казылмаларны хәзерге Президент сарае каршындагы бакчада салалар. Бу урында галимнәрне кызыксындырган борынгы катламнар ярыйсы гына сакланган булып чыга. Тикшерелгән объектлар арасында төсле металлдан төрле әйберләр ясау белән шөгыльләнгән һөнәрче остаханәсе, ашлык саклау базлары, хуҗалык чокырлары бар. Аларның күбесе ханлык чоры белән бәйләнгән XV—

XVI гасырларга карый. Тирәндәрәк ятучы катлам XIII гасырның икенче яртысында—XV гасыр башларында тупланган, дигән нәтиҗәгә киләләр. Казанның барлыкка килү вакытын һәм аның иң борынгы, монголларга кадәрге тормышын чагылдырган астагы катламның урыны-урыны белән генә сакланган булуы ачыклана. Аның калынлыгы да 5—10 сантиметрдан артмый. Табылдыклар арасында XII—XIII гасырларда эшләнгән чүлмәк китекләре дә күп түгел. Әмма ләкин, ни генә булмасын, монголларга кадәр тупланган катламны табу, аны башка катламнардан дөрес итеп аерып алу, датасын ачыклау — Кремль археологиясе тарихында беренче мәртәбә! — шөбһәсез, принципиаль әһәмияткә ия иде.

1975 елгы казулар (җитәкчесе Л. С. Шавохин) Благовещение чиркәве янындагы бакчада үткәрелә. XII—XIII гасырларга һәм соңгырак чорларга караган катламнар биредә яхшырак сакланган була. Табылдыклар да аз түгел: торак йорт һәм хуҗалык корылмалары, савыт-саба ватыклары, тимер ук очы, сөяктән ясалган әйберләр. Яңа археологик материаллар Казанның 1177 елда салынган булу ихтималлыгын тагын бер тапкыр раслыйлар.



Казан Кремленең төньяк өлеше. Бу фрагмент Эльшлегер китабыннан алынган. *(Кара: Н. Халитов. Казан мәчетләренең архитектурасы. Казан, 1991, 35, 36 бб. Рус телендә.)*

1976 һәм 1977 елларда киң күләмле казулар башлыча Сөембикә манарасы тирәсендә алып барыла (бу эшләрдә А. Х. Халиковтан башка Ә. Г. Мөхәммәдиев һәм Л. С. Шавохин катнашалар). Кызыклы һәм, әйтергә кирәк, көтелмәгән ачышлар арасыннан берничәсен генә санап үтәм.

Сөембикә манарасыннан бераз көньяктарак борынгы Казанның саклану ныгытмалары ачыла. Алар (балчыктан) өелгән биек валлар рәвешендә булып, өстән тагын нииндидер агач корылмалар белән ныгытылганнар. Бу ныгытмаларны болгар бабаларыбыз XII гасыр ахырында төзегәннәр, ә инде соңрак, XIV—XV гасырларда булса кирәк, алар җимерелгәннәр.

Сөембикә манарасы белән Сарай чиркәвен тоташтыра торган таш койма янындагы казылмаларда монголларга кадәр үк салынган ике таш бина — мәчет һәм янәшәдә генә манара калдыклары табыла. Алар әле Алтын Урда чорында да җимерелмичә сакланганнар. Шунысы кызык: борынгы манара өстенә соңыннанрак хәзерге Сөембикә манарасын утыртып куялар (сүз уңаеннан, аларның дөнья якларына карата юнәлешләре төрлечә булуын да күрсәтеп үтик).

Казан ханлыгы чорында шушы борынгы мәчет янында, аңа терәлеп диярлек, ак таштан салынган мавзолейлар — төрбәләр торган. Ул төрбәләрнең дүртесе (кызганычка каршы, аларның барысы да бик начар сакланган) казып тикшерелә. Аңлашылса кирәк, төрбәләрдә гади халык вәкилләре түгел, ә бай феодаллар, ханнар күмелгән булырга тиеш. Моның чыннан да шулай икәнлегенә инану өчен археологлар тикшергән каберлекләрнең икесенә генә күз төшерик.

Биредә күмелгән мәетләрнең берсе ян-яклары җидешәр метрлы квадрат формасындагы таш төрбәдә, гаҗәеп матур бизәкләр төшерелгән каберташ астында, тирәнлеге ике метрга җитәрлек итеп казылган кабердә, ике катлы агач табут эчендә ята. Мөселман йоласы буенча күмелгән ир уртасы яшьләрендәге кеше. Табылган материалларга нигезләнеп, төрбәнең төзелү вакытын XV гасырның урталары яки икенче яртысы белән билгелиләр. Профессор А. Х. Халиков фикеренчә, бу төрбәнең 1467 елда вафат булган Казан ханы Мәхмүт истәлегенә куелган булуы ихтимал.

Икенче төрбә XVI йөз урталарында төзелгән, ул беренчесенә караганда зуррак (8,5x9 м), стеналарының калынлыгы да бер метрга җитә. Аны казып чистартканда матурлап бизәлгән каберташ ватыклары табыла. Бу мәһабәт төрбә берьюлы өч кешенең кабере өстенә куелган. Каберләрнең уртасындагысы бик тә үзенчәлекле булып чыга: мәетне зур (2,8x1,3 м) һәм тирән (ике метр чамасы) чокырга күмгәннәр; ике катлы агач табут яхшы сыйфатлы яшел күн белән тышланган һәм көмеш кадаклар, фигуралы калайлар белән бизәлгән. Табутта — урта яшьләрдәге ир кеше сөякләре, баш сөягенең арткы өлеше чәрдәкләнгән. Галимнәр, барлык мәгълүматларны җентекләп өйрәнеп, бу кабердә Казан ханнарының соңгыларыннан булган Сафа Гәрәй күмелгәндер, дигән фикергә киләләр.

Сенсацион ачышлар, югыйсә! Ләкин ул вакытта болар турында ачыктан-ачык язу мөмкин булмагандыр, күрәсең. Матбугатта да шау-шу кузгатмадылар. Фәнни публикацияләр дә күренмәде. 1988 елда басылып чыккан «Казан тарихы»ның беренче томында гына 1977 елгы казылмалар турында аз-маз мәгълүмат бар. Хәзерге көндә табылдыклар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология кабинетында саклана. Антропология материалларын тәртипкә китерү өстендә яшь галим Илгизәр Газимҗанов эшли.

1977—1978 елларда А. Х. Халиков Казан Кремлендә тагын бер зур ачыш ясады: Сәламәтлек саклау министрлыгы урнашкан бина тирәсендә (элек биредән Тайник чокыры үткән) башкалабызны көньяк-көнчыгыштан уратып алган иң борынгы таш дивар эзләре килеп чыкты. XII гасыр ахырларында ук салынган таш диварлар! Бу ачыш белгечләр арасында шик уятты һәм булмас нәрсә рәвешендәрәк кабул ителде. «Халиков сенсация ярата инде ул» — дип, мыек астыннан гына көлеп йөрүчеләр дә булды. Әмма дөреслек А. Х. Халиков ягында иде. Бу турыда түбәндәрәк язарбыз әле.

А. Х. Халиковның 1974—1978 еллардагы экспедиция нәтиҗәләрен бүгенге көн күзлегеннән карап бәяләгәндә, һич тә күпсенмичә һәм гаделлеккә тугрылык саклап, шуны әйтергә кирәктер: бу талантлы, энциклопедик белемле, тырыш һәм тынгысыз галим тарафыннан тупланган материаллар, башкалабызның борынгы тарихына кагылышлы проблемалар буенча әйтелгән төпле фикерләре әле безнең өчен дә, шушы өлкәдә эшләячәк киләчәк буыннар өчен дә ныклы нигез булып хезмәт итәчәкләр.

Югарыда без, кыскача гына булса да, Альфред Хәсән улы Халиковның кайбер әһәмиятле ачышлары турында сөйләдек. Әмма ул җитәкләгән экспедициянең төп фәнни казанышы, ни генә булмасын, борынгы таш диварлар һәм хан төрбәләре ачуда түгел, ә Казан Кремлендә тупланган күп гасырлык культура катламының стратиграфиясен һәм хронологиясен эшләүдә, нигезләүдә иде. Стратиграфия, гади тел белән әйткәндә, катламнарны тасвирлап язу дигән сүз. Безнең археология гыйлеме, нинди генә борынгы кала яки авыл урыны казылмасын, аның культура катламын өйрәнүдән башлана. Бу — эшебезнең иң җаваплы һәм иң катлаулы өлеше. Кайвакыт өйрәнелә торган истәлекнең стратиграфик шкаласын төзү күп елларга сузыла. Мисал итеп Болгар, Биләр шәһәрләрен һәм шул ук үзебезнең Казан Кремлен китерергә була. Югарыда без, Н. Ф. Калинин борынгы Казанның ханлык чорына караган катламнарын гына тапты, тагын да элгәрерәк тупланган катламнарны аерып чыгара алмады, дигән идек. А. Х. Халиков үзенең бөтен игътибарын нәкъ менә шул борынгы катламнарга юнәлтә, аларны таба, үзенчәлекләрен өйрәнә һәм нәтиҗәдә Кремльнең хәзерге көндә иң уңышлы, иң камил саналган стратиграфик шкаласын төзи. Менә ул:

I катлам — XIX—XX гасырларда тупланган (без аны кыскача гына «хәзерге заман катламы» дип атыйбыз);

II катлам — XVI гасырның икенче яртысында, XVII—XVIII гасырларда тупланган (гадәттә «урыс катламы» дип йөртәбез);

III катлам — Казан ханлыгы чорында, 1445—1552 елларда тупланган («ханлык катламы»);

IV катлам — Алтын Урда чорында, Казан мөстәкыйль кенәзлек үзәге булган вакытларда, ягъни VIII гасырның икенче — XV гасырның беренче яртысында тупланган («Алтын Урда катламы»);

V катлам — монголларга кадәрге чорда, ягъни XII гасырның икенче — XIII гасырның беренче яртысында тупланган («иң борынгы катлам»).



Рәссам Булат Гайльвановның «Урта гасырларда Казан Кремле» дигән картинасыннан фотокүчермә

Күргәнебезчә, А. Х. Халиковның, Казан шәһәренә XII гасыр ахырында, язма чыганакларга караганда, 1177 елда нигез салынган, дигән фикере инде 1974—1975 елларда ук шактый саллы археологик фактлар белән дәлилләнгән була. Иң борынгы катламның туплану вакытын билгели торган әйберләр дә берән-сәрән генә түгел: керамика, биш-алты ук очы, шәмәхә төсендәге йомшак таштан ясалган орчык башлары, пыяла беләзек (монголларга кадәр Киев Русенда беләзекләрне пыяладан ясаганнар!), сердоликтан эшләнгән муенса төймәләре һ. б.лар. Бу материаллар А. Х. Халиковка курыкмыйча «Казанга — 800 ел!» дип әйтергә нигез бирделәр.

Үзегез беләсез, төрле сәбәпләр аркасында башкалабызның юбилеен үткәрә алмадык. Бу нәрсәгә галимнәр арасында килеп чыккан бәхәс тә комачаулады, әлбәттә. Фәндә ныклап урнашкан традицион карашлардан җәһәт кенә баш тарту җиңел түгел бит. Кремльдәге яңа ачышлар белән бөтенләй дә таныш булмаган Мәскәү галиме В. Л. Егоров, Казан язма чыганакларда 1370 еллардан соң гына күзгә чалына башлый, ә 1177 елгы датаны күрсәтә торган «Казан тарихы» ышанычлы документ түгел ул, дигәнрәк эчтәлекле мәкалә бастырды. Менә шуннан башланды инде. Имеш-мимешләр китте. 800 еллыкны дәлилләү өчен археологлар борынгы әйберләрне, башка җирләрдән табып, Кремль казылмаларына үзләре ташлаганнар, янәсе. Башка сыймас мәгънәсезлек! Шулай җиңел генә булса иде ул. Нәтиҗәсе бер дә күңелле түгел: Кремльдәге казу эшләрен туктаттылар. Шулай да «Башкалабызга ничә яшь?» дигән сорау һич тә көн тәртибеннән төшмәде. Ниләр генә булып бетмәсен, үз намусларына тап төшермәгән татар һәм урыс галимнәре Казанның монголларга кадәр төзелүенә ышаныч белдерделәр һәм бу турыда үз хезмәтләрендә бер дә курыкмыйча, ачыктан-ачык язуларын дәвам иттерделәр. Хәтта күптән түгел Мәскәүдә басылып чыккан «Россия шәһәрләре» исемле энциклопедик сүзлектә дә Казанның барлыкка килү вакыты 1177 ел итеп күрсәтелгән.

Әмма бу датага каршы килүчеләр бүгенге көндә дә җитәрлек әле. Алар арасыннан, беренче чиратта, А. Х. Халиковның хөрмәтле шәкертен, Казан Кремлендә озак кына эшләп, юбилей үткәрү мәсьәләсендә заманында җан атып йөргән археолог Л. С. Шавохин исемен атарга мөмкин. Казанның 800 еллыгына багышлап күпме мәкаләләр язган иде югыйсә, ә менә соңыннан, Мәскәүдә кандидатлык диссертациясен яклар вакыт җиткәч, үзенең фикерләреннән баш тартып, В. Л. Егоров концепциясенә ияреп китте. Күренекле галимебез Равил Фәхретдинов үзенең шулай ук Мәскәүдә яклаган докторлык диссертациясендә һәм аннан элегрәк чыккан «Идел Болгарстаны тарихы буенча очерклар» (1984 ел)

китабында башкалабызның барлыкка килү вакытын 1390 елларның ахыры белән билгели. Борынгы Казанны ул легендар «Иске Казан» белән тәңгәлләштерә һәм хәзерге Биектау районының Камай, Рус Урматы авыллары тирәсеннән эзли. Кызганыч ки, беренчи фактлар белән дә расланмаган шушы теория аның узган ел урта мәктәп укучылары өчен чыгарылган «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» исемле дәреслегендә дә урын алган.

Кыскасы, шул: 1925 елдан башлап 1978 елга кадәр Кремльдә күп мәртәбәләр археологик күзәтүләр үткәрелгән, хәтта махсус казу эшләре оештырылган, тик бүгенгә көнгә кадәр башкалабызның «туган елы» һаман да юньләп ачыкланмаган әле. Борынгы Казан үзенең серләрен тиз генә ачып салырга җыенмый кебек.

1994 елның гыйнварында Казан Кремлен Дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы дип игълан итү турында Татарстан Президентының махсус Указы басылып чыкты. Шушы Указ нигезендә музей-тыюлык Кремльне төзекләндерү һәм анда археологик казулар үткәрү эшен тулысынча үз өстенә алды. Хәзерге Кремль территориясендә, Сөембикә манарасыннан кала, Казан ханлыгы һәм болгар чорына караган бер генә бина да сакланмаган. Булган ич алар! Хан сарае, атаклы Кол Шәриф, Нур-Гали мәчетләре, кәрван-сарайлар, ханнар зиратындагы изге төрбәләр... Аларның барысы да соңыннан урыс баскыннары тарафыннан җимерелгәннәр, хәзер җир астында харәбәләре генә ята. Эзләргә, табарга, тикшерергә һәм яңадан торгызырга кирәк аларны! Югыйсә, Кремлебездә болгар-татар рухы юк. XVIII—XIX йөз биналары да, алтын гөмбәзле һәм тәреле урыс чиркәүләре генә биредә.

Менә шуларның барысын да истә тотып, изге мирасыбызны халкыбызга яңадан кайтару өчен көчләрен-белемнәрен кызганмаучы бер төркем фидакарь галимнәр «Казан Кремле ансамблен саклау, яңадан торгызу һәм файдалану» турында фәнни концепция нигезләрен эшләделәр. А. Х. Халиков һәм С. С. Айдаров җитәкчелегендә әзерләнгән концепциянең төп юнәлешләре Татарстан Министрлар кабинетының 1994 елгы 4 август карары белән рәсмиләштерелде. Бу карарда Кремль территориясендә алып барылачак археологик казулар белән җитәкчелек итү эше Татарстан Фәннәр академиясенә йөкләтелгән иде. Тиздән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының археология бүлеге каршында тәҗрибәле белгечләрдән торган «Казан Кремле» фәнни-тикшеренү группасы барлыкка килде. Алдыбызда бик тә җаваплы һәм катлаулы эшләр тора иде. Казан археологиясе белән шөгыльләнердәй белгечләребез дә аз булып чыкты. Шулай да тәвәккәлләргә булдык.

1994 ел безнең өчен олы вакыйгалар елы булды: егерме еллап дәвам иткән «тәнәфестән» соң профессор А. Х. Халиков Кремльнең төньягында, аның иң борынгы өлешендә, казу эшләрен яңадан башлап җибәрде. Кояшлы июнь көннәре иде. Күңелләр күтәренке. Бераз дулкынланабыз да: бу юлы нинди табылдыкларга юлыгырбыз? Юк-бар бәхәсләргә нокта куярлык итеп, Казаныбызның барлыкка килү вакытын ачыклый алырбызмы? Кол Шәриф мәчетенең эзенә төшәрбезме? Көннәр бозылып китеп, эшебезгә комачаулык итмәсме?..

Менә инде ике җәйне уңышлы гына уздырып җибәрдек. Альфред Халиков, үкенечкә каршы, эшебезнең тәүге нәтиҗәләрен күрә алмыйча, арабыздан китеп барды. Иртәрәк китте. Яңа табышлар белән сөендереп булмады үзен. Ә табышлар-ачышлар, чыннан да, сөенерлек иде.


Ике сезон эчендә без гомуми мәйданы 920 квадрат метр булган казу эшләре үткәрдек. Әле тагын 80 квадрат метрлы мәйданда Казан дәүләт университеты профессоры Ә. Г. Мөхәммәдиев җитәкләгән экспедиция эшләде. Казылмаларның беренчесе Кремльнең «Пушечный двор» дип аталган төньяк-көнбатыш өлешендә иде. Кол Шәриф мәчетен тапмабызмы дигән өмет белән Благовещение чиркәвеннән көньяктарак урнашкан бакча эчендә тикшеренүләр алып бардык. Алабуга (Воскресение) манарасы янында башланган эшләр дә нәтиҗәле булырга охшаган.

Казу эшләрен, табигый ки, Кремльнең иң соңгы культура катламнарын өйрәнүдән башлыйбыз. XIX—XX гасырларда тупланган җирне, мөмкинлек булганда, экскаватор, бульдозер ише техника белән генә алдырабыз. Ә менә 1552 елдан соңгы урыс катламын, кайберәүләрнең ай-ваена карамыйча (нәрсәгә кирәк ул урыс катламнары, янәсе), җентекләбрәк тикшерәбез. Ни өчен, дисезме? Чөнки анда тирәндәрәк яткан катламнардан эләккән болгар һәм ханлык чоры әйберләре дә еш табыла. Аннан соң, Кремльнең колонизаторлар чорында нинди үзгәрешләр кичергәнен дә өйрәнү кирәктер ич. Христиан чиркәүләре татар мәчетләре өстенә салынган, диләр. Урыс катламын тикшермичә торып, моның чыннан да шулай икәнлеген ничек расларга соң?

Узган ел Благовещение соборы янындагы бакчада (элек бирөдә Архиерей йортының ишегалды булган) XVII—XVIII йөзләргә караган ике кирпеч бина хәрабәләрен казып чыгардык. Аларның берсе, ихтимал, архимандрит йорты булгандыр. Икенчесенең нигезендә ханлык чорында салынган ниндидер зур таш корылма ята. Мәчет түгелме икән? Бәлки, Таҗик чокыры буйлап үткән саклану диварларының капкалы манарасыдыр? Ахырынача тикшереп бетерә алмадык әле, кирпеч бина калдыкларын алып ташламыйча, тәгаен генә әйтеп булмас. Һәрхәлдә, урыс чорына караган соңгы биналарны яңадан торгызу турында авыз ачарга да ярамый. Кремль болай да шыплап тулган инде алар белән. Урыс катламы астында ятканнарын якты дөньяга чыгарырга кирәк.

Кызганычка каршы, нәкъ менә шулары начар сакланганнар да инде. Шулай да гаять кыйммәтле мәгълүмат чыганагы алар. Бер генә мисал. «Пушечный двор»да казыганда XVI йөзнең беренче яртысында (1530—1540 еллар?) җиткерелгән кечкенә генә йорт эзенә тап булдык. Нигезенең һәм ике як стенасының бер өлеше генә калган. Нигезе яхшылап шомартылган эре ташлардан, стенасы кирпечтән салынган. Бер караганда юк кына нәрсә кебек. Туристлар да күп вакыт күз салмыйча да үтеп китәләр иде. Ә менә безнең өчен кызыклы гына ачыш булды ул. Ни өчен дисәгез, монда тикле әле безнең төгәл Казан ханлыгы чорына караган бер генә кирпеч бинабыз да юк иде (Сөембикә манарасының төзелү вакыты әлегә кадәр бәхәсле). Хәзер без ханлык чорында сугылган кирпечләрнең үлчәмнәрен, формасын беләбез. Баксаң, алар XVII—XVIII гасыр кирпечләреннән әлләни аерылып та тормыйлар икән. Димәк, Сөембикә манарасы — бик соңгы корылма, чөнки ул XVIII гасыр кирпечләреннән төзелгән, дигән уйдырмалар дөреслектән ерак торалар.

Ханлык чорына караган объектларны өйрәнү турында сүз кузгалгач, укучыларыбызга берочтан безнең казылмаларда ачылган күп санлы агач йортлар, амбарлар, базлар һәм төрле хуҗалык чокырлары турында да бераз мәгълүмат биреп китү урынлы булыр. Бу агач корылмаларның күбесе 1552 елда җимерелгәннәр, янып юкка чыкканнар. Янгын катламында еш кына кеше сөякләре, сугыш кораллары, шул исәптән, таштан шомартып ясалган, яисә тимердән коелган эре-эре ядрәләр табыла. Ашлык амбарлары торган җирдә күмерләнгән бодай, тары бөртекләре сибелгән. Югары температура астында янып формаларын югалткан савыт-саба ватыклары, башка төрле әйберләр очрый. Кыскасы, 1552 ел фаҗигасе Кремльнең культура катламында ачык чагыла.



XVI гасырның беренче яртысында Казан Кремленең гомуми күренешеннән бер фрагмент. *Археологик мәгълүматлар, язма истәлекләр һәм риваятьләр буенча Ф. Х. Вәлиев реконструкциясе.*

Благовещение чиркәвенә каршы яктагы «Пушечный двор» территориясендә эшләнгәндә без ихтыярсыздан йортларның урнашу тәртибенә игътибар иттек. Бик кызык килеп чыга: йортлар һәм тирә-юньдәге хуҗалык корылмалары төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба бер-бер артлы сузылып, ике рәт булып урнашканнар, рәт арасы 5—6 метр чамасы. Борынгы урам бит бу! Хәтта калын тakталар, урталай ярылган бүрәнәләр белән түшәлгән булган ул! Бу урам урыслар Казанны алгач та юкка чыкмаган, күрәсең: 1565—1568 елларда төзелгән «Писцовая книга» исемле документта «переулок напротив Благовещения» исеме астында теркәлеп калган.



Казан Кремле XVI гасырның беренче яртысында. Хан сараена керү ягыннан сурәтләнгән күренеш. *Ф. Х. Вәлиев реконструкциясе.*

Биредә тормыш гөрләп торган. Табылдыклар шул турыда сөйли. Алар арасында Казан һөнәрчеләре ясаган әйберләр дә, читтән китерелгәннәре дә күп. Болгар татарлары белән янәшә чирмешләр, урыслар яшәгәннәр. Иген иккәннәр, бер-берсе белән сату итешкәннәр, таштан-кирпечтән йортлар, мәчетләр төзегәннәр.

Алтын Урда чорында Казан кенәзлекнең (билекнең) башкаласы булган. Казан тарихының әлеге чоры, язма чыганаклар юк дәрәҗәсендә аз булганлыктан, бик начар өйрәнелгән. Безнең экспедиция материалларын да бай дип әйтмәс идем. Шулай да алга китеш бар. Казан шәһәре безнең төбәктә иң алга киткән сәүдә үзәге булган. Бу фикерне раслаучы күп кенә әйберләр, шул исәптән, бакыр һәм көмеш акчалар, Урта Азия шәһәрләреннән, хәтта ерак Кытайдан китерелгән керамик эшләнмәләр табылды. Алар XIV гасырга караган йорт урыннарын, хуҗалык чокырларын казыганда килеп чыкты.


Дөресен әйтим, мин үзем, озак еллар буе болгар археологиясе өлкәсендә эшләүче галим булгангадыр, иң дулкынландыргыч минутларымны башкалабызның «балачагын» чагылдырган астагы катламга төшеп җиткәч кичердем. «Яңа ачышлар-табышлар булырмы?» — дигән сорау башымнан китмәде.

Кремльнең иң борынгы культура катламы калын түгел, 10—20 сантиметр чамасы гына. Уртача алганда 3,5—4 метр тирәнлектә ята. Сакланып калган корылмалар (башлыча хуҗалык һәм багана чокырлары) күп түгел, җимерелеп беткәннәр. Табылдыклар да аз. Шулай да... Ачыш дип атарга ярыймы-юкмы, анысын белмим, ә менә нәкъ мин көткән әйберләр табылды: Муенса төймәләре, йомшак таштан ясалган орчык башлары, ук очлары, бронзадан эшләнгән беләзек һәм, әлбәттә инде, археологлар өчен иң кыйммәтле, иң кирәкле табылдыклар — чүлмәк кисәкләре. Юк, һич тә шаяртып әйтүем түгел, чыннан да, керамика археологиядә үзләренә әллә никадәр мәгълүмат тупланган табылдыклардан санала. Шуңа күрә бик җентекләп, кызыксынып өйрәнәбез аларны.

Минем өстәлемдә Кремльнең борынгы катламыннан чыккан табылдыклар ята. Монысы — чүлмәк кисәкләре. Мин аларны өч төркемгә бүлеп куйдым. Зур гына төркемдә махсус җайланмаларда формалаштырылып яхшылап яндырылган, кызыл-көрән төстәге югары сыйфатлы савыт-саба ватыклары. Аларны болгар бабаларыбыз, һичшиксез, монголларга кадәрге чорда, XII—XIII гасыр башларында ясаганнар. Моның шулай икәнен башка археологлар да берсүзсез расладылар. Шулай булгач, санап кителгән һәм, өстәмә әле А. Х. Халиков казылмаларыннан чыккан әйберләрне дә искә алып, башкалабыз Казан шәһәренә XII гасырда нигез салынган, дип хәзер инде бернинди шикләнүләрсез әйтергә мөмкин. Язма чыганакларда телгә алынган дата — 1177 ел — кайберәүләр уйлаганча, бер дә очраклы түгел, димәк. Болгарларның хәрби ныгытмасы һәм бер

үк вакытта күрше мари-удмурт кабиләләре белән тыгыз элемтәдә торучы сәүдә үзәге буларак, Казан шул елда «туган». Бу табышлардан соң: «Башкалабызга ничә яшь?» — дигән сорауга җавап бәхәсле булудан туктар, дип ышанырга кирәк.

Хәзер инде икенче төркемдәге керамикага күз төшерик. Тупас кына итеп кулдан әвәләп ясалган кара-көрән төстәге чүлмәк китекләре. Дулкынга охшатып һәм сырлап төшерелгән бизәкләре дә бар. Бик кызыклы табылдыклар! Мин үзем Кремльдә мондый әйберләр булыр дип башыма да китермәгән идем. Хәер, күпләребез өчен көтелмәгән яңалык булды ул. Эш шунда ки, мондый савыт-сабалардан безнең болгар бабаларыбыз VIII—X гасырларда, әле алар Хәзәр каганлыгына буйсынып яшәгән дәвердә үк файдаланганнар. Ләкин, кайберәүләр уйлаганча, хәзәр керамикасы түгел ул, элгәреге болгарларныкы. Ул XI гасырга, бигрәк тә аның беренче яртысына караган болгар истәлекләрендә дә очрый. Ә менә XII гасырда бөтенләй юк. Моннан, беренче карашка, бик кызык нәтиҗә килеп чыга түгелме соң? Әйе, әле шәһәр барлыкка килгәнче үк, ягъни 1177 елга кадәр, булачак Кремль территориясенә болгарларның кечкенә бер төркеме килеп утырган булгандыр, күрәсең. Башкача аңлатып булмый безнең табылдыкларны.



Сөембикә манарасы. 1645—1650 еллар. Э. *Турнерелли гравюрасы.*

Мин бу фаразны шикләнә-шикләнә генә, киләчәктә, бәлки, тагын да саллырак дәлилләр табылыр дигән өмет белән беренче тапкыр 1994 елгы казулардан соң әйткән идем. Узган ел чыннан да андый дәлилләр табылды. Һәм керамика гы[illegible] да түгел.

Менә алар.

Сердоликтан (кызыл карлыган төсендәге асылташтан) ясалган шарсыман муенса төймәсе хуҗалык чокырын казыганда килеп чыкты. Мондый төймәләрне археологлар башлыча VIII—XI гасыр катламнарында табалар. XII йөздә бик сирәк очрыйлар.

Тагын бер төймә, ул — тау хрусталеннән. Элгәреге (мәҗүси) болгарларның Танкеевка зиратында күп табылган алар. XI гасыр урталарына кадәр генә модада булып, аннан соң юкка чыгалар яисә бик сирәк кулланылалар.

Өченче төймә тагын да борынгырак. Ул кара төстәге пыяладан ясалган, ак түгәрәк эчендәге зәңгәр «күзләр» белән бизәлгән. Мондый төймәләрдән җыелган

муенсаларны, ялгышмасам, VIII—X гасырларда гына тагып йөргәннәр; XI гасыр башларында әкренләп модадан чыгалар.

Коңгырт-кызыл төстәге пыяладан ясалып, өслегенә дулкынсыман ак бизәкләр төшерелгән озынча төймәнең датасын археологлар бары тик X гасыр белән билгелиләр. Кем белә, Биләр-Болгар, Суар, Җүкәтау ише эре калалардан ераграк урнашкан Казан якларында мондый төймәләр бәлки әле XI йөз башларында да модадан чыгып бетмәгәндер?

Ниһаять, иң борынгы катламнан чыккан тагын бер әйберне күрсәтеп үтим. Бакырдан чүкеп ясалган беләзекләр ул. Без күреп гадәтләнгән яссы һәм киң пластина рәвешендә түгел, аркылыга киселеше квадратка якын. Өслеге кечкенә генә түгәрәкләр белән капланган. Мондый беләзекләрне болгар һөнәрчеләре күрше фин халыкларына сату өчен IX—X гасырларда күпләп җитештерә торган булганнар. Борынгы мари каберлекләрендә бик еш табыла. Сирәк-мирәк кенә XI йөз башларына караган истәлекләрдә дә очратырга мөмкин.

Менә шундый табылдыклар. Әлегә күп түгел алар, әмма, Кремльнең иң борынгы болгар катламы X—XI гасырлар чигендә үк туплана башлаган, дип раслар өчен җитәрлек.

Алдымда ята торган керамиканың өченче төркеменә күз салыйк әле. Түгәрәк төпле чүлмәк китекләре. Эре бөртекле елга комы кушып изелгән балчыктан эшләнгәннәр. Бизәкләре берничә рәттән торган вак дулкын сыман. Археологлар аны «җүкәтау» тибындагы керамика дип йөртәләр, чөнки мондый чүлмәкләрне болгарлар бары тик Җүкәтау шәһәрендә (хәзерге Чистай янында урнашкан) һәм аның тирә-юнендәге авылларда гына ясый торган булганнар.

Бу керамикага махсус тукталып китүнең сәбәбе бар. Соңгы елларда мина, Казан Кремленнән тыш, Җүкәтауда һәм Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылы янында урнашкан борынгы Чаллы шәһәрләрендә казу эшләре алып барырга туры килде. Җүкәтау Каманың сул ягында, ә Чаллы аңа каршы якта урнашкан. Аралары 20—25 чакрымнан артмас. Чаллыда «җүкәтау» керамикасы күпләп табылды. Шунлыктан миндә, Чаллы каласына нигез салучы болгарлар бирегә шул Җүкәтау якларыннан күчеп килмәделәрме икән, дигәнрәк сорау туган иде. Менә хәзер, «җүкәтау» керамикасын Кремль казылмаларында да тапкач, телисеңме-теләмисеңме дигәндәй, шуңа охшаш тагын бер сорау туа: Казанга нигез салучылар арасында Җүкәтау-Чаллы төбәкләреннән күчеп утырган болгарлар да булмадымы икән?

Мәгълүматларыбыз әлегә азрак булса да, нишләптер бу сорауга уңай җавап бирәсе килә. Күптән түгел «Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар» (Казан, 1987) китабын актарып утырганда бер бик кызык риваятькә тап булдым. Кыскача эчтәлеге болай:


Чаллы каласы урнашкан тау башыннан ханнар ук ата торган булганнар. Бер болгар ханы җәясен күтәреп ук атарга җыенганда әйткән: «Угым кая төшсә, каланы шунда күчереп салам»,— дигән. Аның угы хәзерге Казанның Сөембикә манарасы — хан мәчете тирәсенә төшә.

Укны шуннан барып табалар. Шуннан соң ук төшкән урынга эт күмәләр. Хан каланы шунда салырга боера.

Кызык бит, ә? Бу риваятькә ышансаң, Казанны Чаллы ханы салдырткан булып чыга. Хәер, мөмкин булмастай эш түгел — археология материаллары да шул фикерне куәтлиләр ич. Ләкин Кремльдәге табылдыклар арасында башлыча Биләр һәм Суар калаларында киң таралган керамика төрләре дә бар. Шуңа күрә, Фәнни күзлектән чыгып караганда, Казанга борынгы Чаллы кешеләре генә нигез салган, дип раслау, йомшак кына итеп әйткәндә, беркатлылык булыр иде.

Бер башлагач, Казанның барлыкка килү вакытына караган фикерләремне тагын да тулырак һәм төгәлрәк итеп әйтеп бетерәсем килә.

Сүз дә юк, соңгы ике ел эчендә Кремльдә кызыклы гына ачышлар булды. Башкалабызга XII гасыр ахырында нигез салынган булуын яңа археологик материаллар белән исбатлый алмабызмы, дип кенә тотынган идек, үзебез дә сизмәстән, ике гасырга диярлек тирәнгәрәк тә төшеп киттек. Ә соң югарыда санап үтелгән иң борынгы табылдыклар Казан каласының XI йөздә үк яшәгәнен чыннан да раслыйлармы? Мин үзем, мәсәлән, бу сорауга кистереп кенә: «Әйе!» — дип җавап бирергә ашыкмас идем. Материаллар аз. Атап әйткәндә, XI йөзгә караган бер генә объект та (торак йорт, хуҗалык чокырлары һ. б. ш.) табылмаган. Киләчәктә, бәлки, табылыр да. Бүгенге көндә исә, ничек кенә кызыктыргыч тоелмасын, Казаныбызга мең яшь тә, тугыз йөз яшь тә биреп булмый.



Иске һәм Яңа Казаннан табылган XIV—XVI гасырлардагы керамика үрнәкләре. *Н. Ф. Калинин һәм Ф. Х. Вәлиев реконструкцияләре*

Казылмалардан XII гасыр материаллары күбрәк чыкты. Ләкин барыбер XII йөз урталарына кадәр Казанны нәкъ менә шәһәр, кала итеп күрсәтә алырлык материаллар юк. Монголларга кадәрге дәвердә — тарих фәнендә шулай кабул ителгән — махсус ныгытылган поселокларны, торак пунктларын гына кала дип йөрткәннәр. Кала (шәһәр) халкы, авылныкыннан аермалы буларак, башлыча һөнәрчелек, сәүдә, хәрби эш белән шөгыльләнгән. Фәкать XII гасырның икенче яртысында гына — һич тә элегрәк түгел! — хәзерге Кремль калкулыгында барлыкка килгән кечкенә генә болгар поселогы көчле хәрби ныгытмага һәм сәүдә үзәгенә, ягъни калага әверелә. Фактларыбыз, Аллага шөкер, ышандырырлык. Шушы вакытка караган иң борынгы таш диварларны, хәтерләсәгез, А. Х. Халиков әле 1978 елда ук ачкан иде. Быел аларның дәвамы Ә. Г. Мөхәммәдиев казылмаларында килеп чыкты. XII гасыр ахыры белән төгәл даталанган, яхшы гына сакланган таш диварлар. Коллекциябызда болгар ювелирлары өчен Балтыйк буеннан кайтарылган гәрәбә, Шәрык илләрендә җитештерелгән затлы савыт-саба ватыклары, борынгы урыс шәһәрләрендә ясалган әйберләр бар. Менә шул мәгълүматларның барысын да бергә туплап караганда, безнең археология материаллары белән «Казан елъязмасы»нда телгә алынган 1177 ел датасының тулысынча тәңгәл килүләрен күрербез. Шуңа күрә, кабатлап әйтәм, Казан шәһәренең барлыкка килү вакытын 1177 ел белән билгеләсәк, тарихи дөреслектән әллә ни ерак тайпылмабыз кебек.

Биредә 1177 ел датасы турында өстәмә белешмә биреп китү урынлы булыр. Бу датаның кайдан килеп чыкканын беләсез инде: 1564-1566 елларда ниндидер бер мәгърифәтле урыс тарафыннан язылган «Казан тарихы» исемле әсәрдән. Нигездә шовинистик рухта иҗат ителгән бу публицистик әсәрне кайвакыт «Казан елъязмасы» дип тә атыйлар. Аның авторы (исеме билгесез) егерме еллап Казан әсирлегендә яши (урыслар тарафыннан махсус җибәрелгән шымчы булмадымы икән?), югары даирәләрдә кайнаша, болгар-татар тарихы белән кызыксына, хәтта кайбер борынгы кульязмалар белән дә таныш була. Ул язган әсәрнең төп нөсхәсе сакланмаган, ә соңгы күчермәләренең саны 280 чамасы. Казанга нигез салыну датасы менә шул күчермәләрнең бары тик дүртесендә генә күрсәтелгән. Аларында да әле төрлечә: берсендә — 1177 ел, өчесендә — 1172 ел. Белгечләрнең раславынча, 1177 ел датасы борынгырак текстта теркәлеп калган.

Яшермим, хәзерге заман урыс һәм кайбер татар тарихчылары (В. Л. Егоров, В. А. Кучкин, И. Г. Добродомов, Л. С. Шавохин, Р. Г. Фәхретдинов) бу датаны танырга теләмиләр. «Казан тарихы»ның төп нөсхәсеннән күчереп алганда өстәп куелган, «һавадан алынган» мифик дата гына ул, дип тәкрарлыйлар. Ә менә нишләп соң «Казан ханлыгы — Алтын Урда кыйпылчыгы» дигән рәсми теория яшәп килгән заманнарда башкалабызның төзелү вакытын «мифик» 1177 ел белән күрсәтергә кирәк булды икән? Аңлашылмый. Югарыда әйтелгәнчә, 1177 ел датасы һич тә очраклы түгел, бәлки, «Казан тарихы»ның төп нөсхәсендә объектив рәвештә күрсәтелеп, аннан соңгы күчермәләреннән алып ташланган дата булуы да мөмкин ич. Һәрхәлдә, моны тарихчылар үзләре ачыкларга тиеш. Матди чыганаклар белән эшләүче галим буларак, мин бу датаның археологик материаллар белән тулысынча раслануын гына кабатлап әйтә алам.

Монда язылган фикерләрнең кайберләрен мин әлегә фараз кылу рәвешендә генә әйттем. Казулар дәвам итәчәк. Яңа мәгълүматлар тупланачак. Димәк, безне кызыксындырган сорауларга да иртәме-соңмы дөрес җавап табылачак.

# АК КҮБӘЛӘК САФЛЫККА ДӘШӘ

*«Фатих Хөсни кем ул? Сорауны болай кую, ихтимал, сәер яңгырар. Аны кем генә белми.»*

*«Бер яшьлектә, бер картлыкта» исемле җыентыкка тәнкыйтьче Фоат Галимуллин язган кереш сүздән. 1988 ел.*

*— Кызлар, сез миңа «Йөзек кашы»н табып бирә алмассызмы икән?*
*— Нәрсә соң ул?*
*— Шундый китап. Берзаман аны белмәгән татар кешесе юк иде бугай.*
*— Шулаймыни? Авторын әйтсәгез, эзләп карарбыз алайса.*

Китапханәдәге сөйләшүдән. 1995 ел.

Шәп китап, гадәттә, җиңел, бер тында укыла. Һәм шуннан соң киң итеп тагын бер тын аласы да китапны кабаттан укып чыгасы килә башлый. Укыйсың да, беренчесендәге кебек үк көчле хис-тойгылар кичерәсең, нәкъ элеккесендәге кадәр дулкынланасың һәм шулай була алуына үзең дә гаҗәпләнәсең.

Ә менә минем кулга бүген килеп эләккән повесть, шәплеге бәхәссез булса да, алай җиңел үк укылмый. Ялгыш әйтәм: Рафаэль Сибатның «Ике гашыйк һәм җыр тыңлаучы ат» әсәрен тиз-тиз укып булмый. Чөнки аны укыганда туган кичерешләрнең күплеге тынны кыскандай итә, туктап уйлануны сорый. Аннары, Канәфи белән Катифә язмышында укыган саен нииндидер хәвеф сиземләү повесть басылган «Казан утлары» журналының (1995 ел, 5 сан) яңа битләрен ачудан тыеп тора. Билгесез куркынычны азга гына булса да кичектереп торасы килә. Ә бәхетсезлек, һичшиксез, булыр кебек. Повестьта тасвирланган һәм бик күп яклары белән безнең бүгенгебезне хәтерләткән тормышта хәвеф килмичә кала алмый. Ни өчен дигәндә, әхлакый бозыклык «балык башыннан» — авыл рәисе Усал Батталдан башланган. Ә «ил башында карга утырса, илне үләксәгә тарта» инде,— халыкның мең еллык тормыш тәҗрибәсендә расланган мәкаль бу. «Түрә азса — ил башына» — дигән сүз дә бар. Өстәвенә, андыйларны «ил башы» итә алган халыкның әхлаксызлыктан үз-үзен саклый алуы да, моңа каршы тора алуы да икеле. Әсәрдә Канәфи белән Катифәнең гыйшкын да бәхетле төгәлләү мөмкин булмас кебек. Безнең татар:

Тигез мәхәббәт яшәми,
Йә аерыла, йә үлә,

— дип буыннан-буынга гыйбрәтле җыр калдырган бит инде. Ә Канәфиләр мәхәббәте тигез генә түгел, дуамал да. Әтисе дә тынгысыз-дуамал булган Канәфинең. Шул холкы, «отчайный татарин»лыгы аркасында немецлар белән сугышның мәгънәсез бер бәрелешендә ятып калган. «Безне нимескә тураттылар, юри тураттылар инде. Нимеснең пүләсе кимесен дип тураттылар»,— ди Канәфигә әтисенең соңгы сугыш көне турында авылдашы Котдус. «Юри тураттылар» — сугыш хәйләсен аңламаган гади авыл татарының хата сүзе түгел, андый хәлләрнең чынлыгына тарих безне ышандырып кына тора. Илнең көнбатыш чикләрен ачык куеп, «максатлы» репрессияләре белән армияне башсыз һәм акылсыз кал-

дырып, сугышның якынлыгын бөтен дөнья күреп торганда да аны күрмәмешкә салышып — «халыклар атасы» үз балаларын, беренче чиратта кыюрак фикерле украин һәм белорусларны, Кавказдагы җирдәшләрен Гитлердан бераз туратып алу сәясәте алып бармадымыни? Әмма ул мәкерле исәбендә шактый ялгышты: гитлерчылар ил казаныннан бераз пар чыгару, системадагы кан басымын йомшарту өчен «борын канату» белән генә тукталып калмадылар. Корбаннарын да сайлап тормадылар. Ике тиран бер-беренең ниятен аңлап бетермәделәр һәм Гитлер кулы җитмәгән кайбер халыкларны сугыштан соң Сталинның үзенә кырырга туры килде. Әзерләнүеннән башлап бүгенгесенә кадәр Чеченстан сугышы да халыкны «юри турату» сәясәтедер. Элекке СССР генералы Х. Дудаев та, бер яктан, халык каһарманы һәм, икенче яктан, шул мәкерле сәясәт корбаны түгелме соң? Аның: «Соңгы чечен калганчы сугышачакбыз» кебек сүзләре каршы яктагыларның күңеленә бигрәк тә хуш, ниятләренә тәңгәл килде бугай ич. «Ярар, соңгы чеченгәчә кырабыз алайса», дигән тавыш ишетелә һәм гамәлләр күренә Мәскәүдән.

«Отчайный»ларның тормыш агышында да охшашлык күп була, гомер азаклары да бер төслерәк төгәлләнә шул. «Батырларның шашкынлыгына җырлыйбыз без җырны» дип бөек язучы да акылсыз хәтәрлекләргә безне күп чакырды, «бердәнбер дөрес» идеология шуны каннарыбызга ук сеңдерде. Канәфи боларның берсен дә белмичә, алар хакында бөтенләй берни уйламыйча гына Катифәгә көннән-көн ныграк гашыйк була бара һәм нәкъ шул Катифә белән Актай аны кечкенә-кечкенә хәтәрлекләргә дә тарта. Бик яшь шул әле ул, повестьтагы Ильяс карт философлыгына кадәр тагын ярты гасыр яшисе бар аның. Яшәүнең авырлыкларына да исе китеп тормый. «Сине беркем дә чакырып китермәгән ич тормышка. Килгәч, яшә, түз. Әнисе гел шулай ди Канәфинең».

Канәфинең «абыйсын» да сугыштагы урыс офицерлары «Молодец, гололобый!» дип үсендерә торган булганнар. Тик анысын без бүтән китаптан укыган идек. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» исемле повесте иде ул. Кайчандыр аны укыган безнең буын Айдар белән Канәфинең якын туганлыгын бик тиз, «яшь» повестьның беренче битләреннән үк тоя. Алай гына да түгел, Канәфи белән Катифә мәхәббәтенең алда ихтимал булган фаҗигасен тулы күзаллау өчен Айдар белән Вәсилә язмышын белү, «Йөзек кашы»н онытмаган булу кирәк. Әдәбиятны аңлау, гомумән дә, укучыдан эзлеклелек һәм әзерлек сорый.

Айдарның Вәсиләне тәүге күрүен танылган тасвир остасы Фатих Хөсни болай сурәтли:

«Атын күргәнмен, арбасын күргәнмен, алмасын күргәнмен, ә менә алма әрҗәләре арасында кысылып утырган кечкенә генә кызны, түгәрәк ак беләкле, чем-кара күзле, башына салам эшләпә кигән кызны моңа чаклы күрмичә торганмын. Алма сатучының үз кызыдыр инде ул, шөпшә төслерәк икән. Алай дисәң, шөпшәнең күзләре кара булмый бугай. Нинди була соң әле шөпшәнең күзләре? Аты әйбәт, арбасы әйбәт, алмасы әйбәт, кызы барыннан да әйбәтрәк, шөпшә төсле дип юри генә әйттем мин, бөтенләй шөпшә төсле түгел».

Кыз белән дә таныштыралар, шул ук вакытта Айдарның малайларча эзлексезлеген дә җанлы итеп күз алдыннан үткәрәләр «өлкән» повестьтагы бу юллар. Ә менә Канәфи — үз авылдашы Катифәгә беренче кат игътибар итеп караганда Айдар яшеннән узган, дөньяны таный башлаган егет инде. Шуңа күрә күз алдындагы сурәт тә бүтән. «Кинәт кызга күз төшергән егет шаккатты: аның алдында урман кызы, урман Гүзәле тора ич. Әллә шайтан, пәри кызымы бу? Карәле, ничек матур икән ич Катифә. Эре бөдрә чәчләр, җылы матур күзләр, аз гына калынрак кечкенә иреннәр, килешле аяк, алма битләр... Йә хода!»

Монысы Катифәләргә дип урманга утынга баргач, унсигез яшьлек егет күзенә күренгән көндезге матурлык. Мондый сурәтләү үзенең дәвамын да сорап тора инде. Анысын кич, Канәфи «бияләен эзләп» Катифәләргә килгәч күрәбез: «Аның аяк басулары, йомры балтырлары, матур төртелгән күкрәк алмалары, нечкә биле һәм билдән соң кинәт киңәеп киткән түбән ягы — болар барысы, барысы да Канәфине һуштан яздырды».

— Нигә безнең очка төштең? — дип сорый кыз, әнисеннән фатиха алып урамга чыккач.

— Синең янына, Катифә!

— Нишлисең минем белән?

— Минем дә сине үбәсем килә, — дип әрсезләнә «отчайный татарин» улы.

«Минем дә... «Димәк, унбиш яшьлек Катифәдән кемдер «авыз итәргә» өлгергән инде. Бу хакта Канәфи дә белә, кыз үзе сөйләде. Һәм ул кеше — авыл рәисе Усал Баттал. «Бер үптерсәң, бирәм» — ди ул утын кисәргә бару өчен балта сорап

кергән Катифәгә. Ә кыз әле мәкер аңларлык хәлдә түгел, «шаккаткансың иске чикмәнгә, мә үп» дип, бит уртасын сузып тора.

Яшьләр мәхәббәтенә зур хәвеф менә кайдан — авыл һәм балта хуҗасыннан яный икән. Ул инде Айдарның ат чабышындагы һәм Василәне сөюдәге көндәше-дусты Госман гына булмаячак! Азгын рәисләр белән көрәшү күпкә авыр, чөнки алар ялгыз түгел. Әнә Батталның үзеннән дә үчлеклерәк куштаны Кара Мәлик бар. Дөрес, Шамиләсен «бозган» өчен Кара Мәлик тә бик ачулы Батталга. Бер җай чыгарып, аннан шәп кенә үч тә ала хәтта. Әмма аның шушы «эше» дә, Усал Батталдан битрәк, Канәфинең тормышын җимерә язып кала.

Куштаннары күп, ә оятлары юк Батталларның. Канәфи бу рәиснең кемлеген бераз белә инде. Шул хакта дуамаллык белән Катифәгә дә әйтеп сала:

— Ә син беләсеңме... беләсеңме... Усал Батталның ярты авыл хатыннарын...

Баттал бу яктан, бозыклык символы буларак, соңгы еллар әдәбиятыннан Таһир Таһировның «Ак йортта җәнҗал» романындагы Шатмановларга, Фәүзия Бәйрәмованың «Кара урман» әсәрендәге «кара» геройларга килеп тоташа, аларның элгәре сыйфатында гәүдәләнә. Ләкин, монда телгә алынган ике әсәр белән чагыштырганда, Рафаэль Сибат повесты үзенең күпмедер дәрәҗәдә аклыгы, романтиклыгы белән аерылып тора, исеме үк шуңа мәҗбүр итә. Биредәге мажаралы мәхәббәт драмасы да Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану»ын түгел, «Асыльяр»ын күбрәк хәтерләтә. Шуңа күрә Усал Батталда Исмәгыйль үзсүзлелеге юк. Теләсә нинди юллар белән үз дигән әшәкелеген итү, беркемнән дә каршы сүз әйттермәү һәм этлеген яшереп калдыру өчен бүгенге Усаллар җинел эшли торган «батырлык»ларга Рафаэль Сибат Батталы сәләтле түгел әле. Аның көчсезлек сәбәбе, гаҗәпкә күрә, күп яктан повестьның җыйнаклыгындадыр. Әгәр вакыйгаларга район югарылыгында гына берәр Шатманов килеп кушылса һәм ул, билгеле инде, авыл рәисенә терәк-таяныч булса, Баттал абзаң Мансурларга, Канәфиләргә үзенә каршы авыз да ачтырмас, авылдагы Катифә белән үзен ат караучы Шамилә янындагыдай «иркен» тотар иде. Әлегә ул Катифәне бер электереп, кулыннан ычкындыруны артык һаваланууларсыз, ярсуларсыз гына үткәреп җибәрә.

Әгәр Канәфи холкында Айдар дуамаллыгы булмаса, ат тыңларлык мәхәббәт җыры Усал Батталның бу уңышсыз омтылышыннан гына ертылып та китмәс иде. Автор, Батталның артык узынып китүеннән үзе дә курыккандай, аны «бәйдән» ычкындырып бетерми. Бу хәл, ихтимал, Рафаэль Сибатның үз повестенда кайсы чорны тасвирлавын исеннән чыгармавы белән дә бәйледер. Тормыш башындагыларның «вседозволенность» оҗмахына беренче кирпечләр генә салынган чак бит әле. Эшчесенә күп айлар эш хакы да түләмәгән килеш купшы автомобильләр сатып-алып «уйнау» кайда ул! Усал Баттал әнә Канәфи кулындагы «калхуз атын» — җыр тыңлаучы Актайны тартып ала алмый. Чөнки, күп очракта ахыры хәерле бетмәсә дә, әле Канәфиләр, аның әтисенең энесе Мансурлар гаделсезлеккә һәм явызлыкка каршы торып маташалар. Әле биредә авыл аксакалы Ильясның акыллы һәм тирән мәгънәле сүзләрен дә җиргә салмыйлар.

— Син, Баттал абзый, район юлында исерек килеш йөреп Каратайны яндырдың ич, — ди Канәфи, аны Актайсыз калдырырга теләгән рәискә. Шатмановларга мондый сүзне әйтсәң, имин калу мөмкин түгел инде. Аларның хәтәрлеге — үтә явызлыкларында гына түгел, өер башы булуларында! Шуңа күрә бөтен җәмгыятьне әхлаксызлык баткагына әйдәп керттеләр бит инде. Каршы як та ара-тирә бер чәбәләнеп ала — алуын... Туй кичендә шул туй табынына тәрәзә аша таш томыргач, сөйгәнен ак агач караватта калдырып билгесезлеккә китәчәк Айдар нәрсә ди әле: «утка янсын кровать аягы». Канәфинең дә җанында ут, телендә ут.

— Тиеп кенә кара минем Ак Күбәләккә, өеңә кызыл әтәч җибәрермен! — ди ул ярсып. Повестьның башыннан ук зур хәтәр көтеп тынычсызланган укучы бу урында тагын бер сискәнеп куя. «Йөрәккә бер-бер хәл булыр кук...» Шулай да хәтәрлек башы Канәфиләргә түгел, Усал Батталларда, Кара Мәликләрдә.

«Бер-бер хәл» куркынычының чираттагысы алдына Канәфи һич уйламаганда килеп баса: Шамилә кыяфәтендәге су анасы аны үз кочагына чакыра. Монысы да, ягъни Шамилә дә — Баттал «җимеше». Укучы бу урында журнал битләрен тизтиз ачып, повестьның азагына кадәр калган өлешен чамалый. Әгәр егетнең дуамаллыгы бозыклык чиген үтеп чыкса, әсәр шушында төгәлләнергә тиеш кебек. Чөнки гашыйкларның ат булып ат тыңларлык сөю җырын шушыннан соң да суратләп маташу — мәхәббәтне хурлау гына булыр иде. Автор да кыен хәлдә: Канәфине Шамилә кочагына салды-салуын да, тик гөнаһсыз килеш ничек йолып алыр инде менә?

Егетне әхлаксыз Батталлар төркеменә кушылу бәласеннән күңелендәге Катифәсе — аның «дөньяны яңгыратып матур итеп көлеп җибәрүе» коткара. Ә чынбарлыктагы Катифә бу минутларда үзе дә Баттал кулыннан ычкынырга тырышып бәргәләнә. «Гүя кешеләр бер-берсенә зыян салу, комачау итү өчен генә яшиләр» — ди автор.

Үткән чорыбызның бер кыйпылчыгын тасвирлаучы бу әсәр нәкъ шушы фикере белән бүгенге көн фәлсәфәсенә килеп тоташа. Үзара мөнәсәбәтләрдә миһербансыз заманның «джунгли законнары» нык чагылган, әдәп һәм шәфкатьнең, оят һәм кешелеклелекнең, бөтен рухи кыйммәтләрнең җиргә, аяк астына салына барган чоры түгелме бу? Әдәбият бу хакта элегрәк тә кисәтмәдеме безне? Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясеннән дала кызы Шәфәкъ мең еллар аша: «Әйтерсең лә, кешеләр бер-берсенә хәсрәт өчен генә яратылганнар» дип кычкырмадымы безгә? Нилектән шулай килеп чыкты соң әле? «Әгәр ирекләрендә булса, күпме шатлык китерер иде алар бер-берсенә» — дип, бу сорауларга җавап биргәндәй дә итә Шәфәкъ үзе. Ә безнең ирегебезне үз-үзебездән яхшырак булу хокукын кем кыса? Бозыклыгыбызның бар сәбәбен үткәннәргә сылтыйкмы? Тик анда, безнең үткән тормышыбызда, изгелек һәм пакьлек тә күп булган ич — нигә аларын үзебез белән алмадык? «Безгә үткәннәребездән көлне түгел, ялкынны алырга кирәк» — дип кем әйткән әле? «Онытма, улым, кояш чыгышы — җан өчен, кояш батышы — тән өчен»,— ди «Ике гашыйк...»тагы Ильяс бабай үз авылдашы Канәфигә. Ләкин Канәфи бу сүзләр аша аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңламый кала. Без дә аңламыйбыз шул менә: акыл белән араларыбыз ерагайган, зиһенсез калганбыз. Һич югы, шулар хакында бер уйлансак икән!

Повесть авторы Рафаэль Сибатның йөгерек сурәтләү осталыгы аркасында болай да атлар чабышындагыдай еш-еш алмашынып торган күренеш-вакыйгалар әсәр азагына таба тагын да тизләнәләр. Яктылыгын, укучыда бүгенге тормышыбызга өметне югалтып бетермәү нияте белән булса кирәк, автор ахырдан ике гашыйкны җиңел генә маҗаралар аша уздырып, бәхетле йомгакка алып килә. Моңа ышанып та җитәсе килми хәтта. Фаҗига көтеп хафалануыбыз юкка булган, димәк. Усал Баттал да төзәлмәс кеше түгел икән, әнә Мансурлар белән бергә Катифәне Канәфигә алып кайтышырга килгән. Аларны кыз алырга Ильяс карт җибәргән. Канәфинең үзенә дә соңгы тәвәккәл адымга шул Ильяс фатиха биргән иде: «Ашык, улым, ашык. Дирбия — чөйдә, Актай — утарда, үзең — монда, Катифә — тегендә».

Тукта, яшьләр тормышының бу куанычлы мизгелендә аксакал үзе ник катнашмый соң әле? Кайда ул? «Ильяс карт камытлар өеннән юкка чыга. Эзлиләр, эзлиләр, таба алмыйлар». Укучы күңеле повестьның буеннан-буена менә нинди фаҗигане сизенеп шомланган-көйгән икән? Ильяс карт йөзендә авыл үзенең акылын, изгесен, рухи таянычын югалтты ич. Алардан башка Усал Батталлар тормышны, кешелекне кая алып барырлар? Җыр тыңлаучы Ак күбәләк чакырган пакь юллардан чыгып китүебез шушы түгелме? Атка бу шигъри исемне Катифә кушкан иде.

Ике гашыйкны — сугышның ике ятимен — Ак Күбәләк тә хыялдагы бәхет йортына алып барып җиткерә алмастыр инде...

Бүгенге чынбарлыгыбыз шушы шикләрне раслый ләбаса.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,**
Балтач.

## Әсгать Айдар
## (1906—1959)

Әсгать Айдар (Әсгать Харис улы Айдаров) — Бөек Ватан сугышыннан исән-сау әйләнеп кайткан аз санлы язучыларыбыздан.

Ул 1906 елның 6 июнендә Самара губернасының Иске Сорочино авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Яшүсмер малайны әти-әниләре, 1921 елгы ачлыктан качып, Урта Азия якларына алып китәләр. Анда Әсгатьне балалар йортына бирәләр. 1923 елда Уфа совет-партия мәктәбен тәмамлап, Ә. Айдар комсомол эшенә чума, аннары Үзбәкстанда гәзит журналисты була.

1927 елдан ул — Казанда. Төрле редакцияләрдә эшли, армиядә хезмәт итеп кайта.1938 елда Ә. Айдар Сталин террорыннан котылып калу нияте белән яңадан Үзбәкстанга китеп бара.

1941 елда Ә. Айдар үзе теләп фронтка китә. Батыр сугышчы булып таныла. Авыр яралар алып, орден-медальләр тагып, Казанга кайтып төшә. 1948 елда, сәламәтлеге какшау сәбәпле, Үзбәкстанга китә. 1959 елның 24 гыйнварында шунда вафат була.

Ә. Айдарның «Ак каенлыкта» (1929), «Ташбай» (1932), «Соңгы сулышта» (1935) исемле повестьларын укучылар яратып укыйлар. Сугыштан соң «Солдат хикәясе», «Таулар легендасы» дигән китаплары дөнья күрә.

Ә. Айдар 1944 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

## Абдулла Гомәр
(1906—1974)

Абдулла Гомәр 1906 елның 15 июнендә Оренбурда туа. Урыс мәктәбендә укый. 1925 елда Казанга — университетка укырга килә. Ләкин укуын тәмамлаганчы ук эшли башларга мәҗбүр була. 1928—1942 елларда ул «Яңалиф» һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында башта әдәби хезмәткәр, аннары җаваплы сәркатип вазифаларын башкара. Күзе начар күрү сәбәпле, сугышта катнашмый. А. Гомәр 1952—1954 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире була. 1954—1963 елларда ул — «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш мөхәррире.

А. Гомәр, нигездә, тәрҗемәче буларак таныла. Аның тәрҗемәсендә егермедән артык әдәби әсәр дөнья күрә. Алар арасында Л. Толстой, А. Толстой, А. Барбюс, Я. Гашек, Д. Фурманов, П. Павленко, М. Шолохов, А. Фадеев, Д. Мамин-Сибиряк, Э. Войнич h. б. күренекле язучыларның әсәрләре бар.

А. Гомәр 1974 елның 7 июлендә Казанда вафат була.

Ул 1941 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

## Ләбиб Гыйльми

(1906—1947)

Ләбиб Гыйльми (Гыйлманов) — Сталин лагерьларында ятып калган язучыларның берсе.

Ул 1906 елның 12 июнендә Әлмәт районы Иске Баграж (хәзерге Ялховой) авылында дөньяга килә. Кече яшьтән ятим кала. 1923 елда Чистай совет-партия мәктәбенә укырга җибәрелә. 1928 елдан — коммунист. Аны Казанга чакырып алалар һәм комсомол өлкә комитеты инструкторы итеп билгелиләр. 1930 елда Л. Гыйльми, Мәскәү боерыгы белән, Монголиягә яшьләр оешмасына киңәшче сыйфатында җибәрелә. Аннан кайткач, 1932—1934 елларда комсомол эшендә була. 1935—1937 елларда «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») гәзите һәм «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналының баш мөхәррире вазифаларын башкара.

Талантлы язучы һәм оста җитәкче булып үсеп килгән Л. Гыйльминең тормышы 1937 елда чәлпәрәмә килә: аны шпионлыкта гаепләп кулга алалар. Расланып җитмәгән мәгълүматлар буенча, ул 1947 елдан вафат санала.

Әдәби әсәрләре: «Сәнәклеләр» (1930), «Аучы Хәмит» (1931), «Чалкаш», «Чимит Дурже» (1933) повестьлары, «Чын мәхәббәт» (1936) романы.

Л. Гыйльми 1934 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

◆

## АЛДАН ХӘБӘР ИТӘБЕЗ

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

Редакция хәзинәсендә сезнең өчен кызыклы булган байтак кына әсәрләр, язмалар бар. Менә аларның кайберләре:

**Гомәр Бәширов. «Гыйбрәт».** *Роман.* Октябрь инкыйлабы нәтиҗәсендә капма-каршы рухи дөньяның бәрелеше, татар язмышы, иман югалтуның фаҗигасе хакында.

**Зәки Зәйнуллин.** Теге заман мафиозлары — ат караклары турында яңа әсәр. «Герой»ларның эш масштабы киң — казах җәйләүләре, Оренбур далалары, Эстәрлебаш тугайлары...

**Суфиян Поварисов. «Пәйгамбәр таңы».** *Роман.* Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның яшьлек еллары турында.

**Фәрит Яхин. «Ахырзаман пәйгамбәре».** Кыйссаның II кисәге. Әсәрдә Мөхәммәт пәйгамбәрнең дин юлында күргән михнәтләре, көрәше, җиңү һәм җиңелүләре сурәтләнә.

**Хәсән Туфан.** Классик шагыйребезнең моннан 30 ел элек язылып та моңарчы басылмаган хезмәте. Мәкаләдә сүз 60 еллардагы яшь шагыйрьләр иҗаты турында бара, «Нюанслар иле» дигән шигырьләр циклы анализлана. Шигъриятттә «аталар һәм балалар» проблемасының үзенчә бер чагылышы.

**Шәриф Хөсәенов.** «Газап диңгезе эчеп...». Күренекле драматургның бөек композитор Рөстәм Яхин турында истәлек язмасы. Автор үзара иҗади хезмәттәшлек һәм Маэстро холкының кайбер сәер яклары турында яза.

Рәис Риан

# БИЛ КУЗГАЛУ

(ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ)

Һич уйламаганда билем кузгалды. Хәзер менә хастаханәдә ятам. Билем кузгалуга килгәндә, моңа иң элек слесарь Гаделшин гаепле. Чөнки минем канга ул туктаусыз тоз салып торды. Башта нервымда уйнады, ә аннан соң бөтенләй хаслык кылырга тотынды.

Мин үзем торак-коммуналь хуҗалыгы башлыгы бит инде. Барысына да ярарга тырышасың. Ә кайберләре әләкләшергә генә тора. Мисал китерәм. «Коммуналь хуҗалык җитәкчесе Гәптиев — ялагай. Начальникларның гына квартираларын карый. Бер шундый өйне ремонтлауда гына да коллективның яртысыннан артыгы эшләде. Квартираны берничә тапкыр буядылар. Хәтта хуҗабикәнең таләбе буенча, кәбестә, кыяр түтәлләрен дә ясап куйдылар. Ә шул ук вакытта үзәк урамдагы берничә колонкадан күз яше кадәр дә су акмый, чөнки аларны төзәтүче юк»,— дип газиткә шикаять язганнар.

Минем моңа ачу килде, билгеле. Иң элек кабинетыма слесарь Гаделшинны чакырып керттем:

— Кара әле,— мин әйтәм.— Гаделшин иптәш, эшеңнән халык канәгать булмый башлады бит әле. Әнә, газиткә жалу язганнар. Колонкаларны нигә төзәтмисең? Соңгы тапкыр кисәтәм!

Минем бу сүзләремә слесарь һич тә аптырамады.

— Моңа тиклем колонкаларны карарга чират җитмәде, электрикларга булышырга куштыгыз бит,— диде дә чыгып китте.

Кичен теге шикаятьне тикшерергә багышланган шау-шулы җыелыш булды. Аның авторы да ачыкланды. Гаделшин үзе язган икән. Бу эшен фаш иткәч тә, һич куркып калмады. Өстәвенә, нәрсә ди бит әле:

— Безнең хөрмәтле начальнигыбыз Гәптиев нык азды, бозылды. Һәр көнне сәгатьләр буена коммуналь мунчада пуф-пуф килеп туйганчы чабына. Үземнең кулда чакта эссе парның рәхәтен күреп калыйм, дип уйлыйдыр инде. Аннан соң йомшарып, көн буе берниндн кимчелеккә исе китмичә йөри...

Җыелышта тешне кысып түздем, бер сүз дә әйтмәдем. Шулай да иртәгәсен иртүк янә теге, тел бистәсе — Гаделшинны чакыртып алдым.

Сүз кыска булды.

— Эт симерсә, иясен талый,— минәйтәм,— син үзеңә икенче урында эш эзләп кара инде, әфәндем...

Көн тыныч кына үтте диярлек. Ә менә кичен нәрсә булды.

Әлеге слесарь кисәге үзе әтмәлләгән, колорадо коңгызына охшаган җиңел машинасына утырып килеп, безнең өй янына туктаган да, шул шайтанын менә кычкырта, менә үкертә! Әлбәттә, мин үзем тешне кысып түзәм бу хәлгә. Ә карчыгым Дәһедиянең, пенсиягә чыккан авыру кешенең, кан басымы күтәрелде. Минем белән слесарь арасындагы мөнәсә-

бәтнең ниндирәк икәнен белә иде Дәһедиям. Шуңа тегенең, безнең янга килеп, машинасын ямьсез үкертеп утыруы өчен мине әрләп ташлады. Нәтиҗәдә, кан басымы күтәрелде.

Гаделшинга ни, машинасын үкертте-үкертте дә китеп барды. Мин урамга чыкмадым. Тиргәшмәдем.

Аның караву, икенче юл таптым. «Коткарыгыз Гаделшинның әшәкелегеннән! Безнең өй янына килеп, машинасын үкертеп-кычкырта. Шунлыктан хатынымның кан басымы күтәрелде. Хулиганга чара күрегез»,— дип, профсоюз комитетына гариза язып бирдем. Тикшерделәр. Башы эшли дуңгызның. Нәрсә дип аклана бит. «Машина белән урамнан узганда, безнең Хәнәфи Мөрсәевич Гәптиев шунда тора иде шикелле дип, күтәрелеп караган идем, рульне ялгыштрак боруымны абайламый калганмын. Машинам кинәт юлдагы пычракка чумды. Нишлим, аптырагачйөдәгәч, сигнал бирдем инде. Кем дә булса килеп ярдәм кулы сузар дип уйладым. Әмма беркем күренмәде. Хәтта менә Гаптиев үзе дә чыкмады».

Шуннан ни булды, димсез? Ни булсын, комитет членнары күтәрелеп көлделәр дә шуның белән эш бетте. Юк шул, бетмәде икән әле. Шул ук кичне Гаделшин котсыз машинасы белән янә безнең турыга килеп, яман итеп сигнал бирергә, моторын үкертергә кереште.

Бу юлы түзмәдем. Кулга юан күсәк тотып, тегенең янына чыктым... Гаделшинның сыртына күсәк белән тондырыйммы дисәм, ни күрим: машинаның ике тәгәрмәче пычрак эчендә зыр-зыр әйләнә. Килеп чумган да кузгалып китә алмый.

— Күзең тонганмы әллә? Киләсең дә шул пычракка чумасың! — дип кычкырдым моңа.

Ә теге миннән дә яманрак акырды:

— Начальник булып йөрисең шунда, җан көеге! Үзең торган урамга бер-ике машина чуерташ китереп сала белмисең. Каер күсәгең белән, ичмасам. Этеш, димен, машинаны арттан!

Күсәкне машинаның арткы күчәре астына тыгып, күтәребрәк каерып җибәрүем булды, котсыз «шайтан», минем өскә пычрак сибеп, кузгалып та китте... Шунда билем кузгалды, нәгъләт! Бил кузгалуга да түзәр идем, минем урынга Гаделшинны куярга уйлыйлар икән. Ай-ай-ай! Һай! Инде билеңне кузгатып кына калмас, сындырып ук куймаса ярый...

*Башкортстан, Караидел авылы.*

Әзәл Яһудин

# Күргәннәр, белгәннәр, ишеткәннәр, баштан кичкәннәр

**Илле елдан артыкка сузылган сәхнә эшчәнлеге дәверендә баштан бик күп вакыйгалар үтте, сәнгатебез һәм әдәбиятыбызның бик күп күренекле эшлеклеләре, артистлары, белгечләре белән очрашырга, бергә иҗат итәргә, сөйләшергә, бергә эшләргә туры килде. Шул вакытлардан күңелдә санап бетергесез көлке-мәзәк хәлләр дә саклана. Шуларның кайберләрен яраткан журналым — «Казан утлары»на тәкъдим итәм.**

**АВТОР.**

## «Собачий дуэт»

1951 ел. Урта Азиядә гастрольдә йөрибез. Ниндидер бер район үзәгендә ачык сәхнәдә концерт бара. Ачык зал дигәнең — балчык койма белән әйләндереп алынган, җир идәнле һәм сәхнәдә җир өеп эшләнгән биеклек кисәге. Сәхнә арты юк, сәхнә почмагына чаршау эленгән, без чаршау артында киенәбез. Сәхнәдә Рокыя Бәхтиева җырлый. Менә залда шау-шу кузгалды. Чаршаудан башны чыгарып карасам, Рокыя җырлый, ә аның янында бер эт Рокыяның әле бер ягына чыгып утырып тора, әле икенче ягына чыга. Халык кугач, эт куркып, сәхнәгә Рокыя янына менеп сыенган икән. Сәхнәдән чыккач Рокыя:

— Бүген без собачий дуэт башкардык,— дип көлде.

## Артомонов ник керми?

1940 елдагы гастрольдә Татар дәүләт академия театры (ТДАТ) Бөгелмә шәһәр театры бинасында Тажи Гыйззәтнең «Ташкыннар» спектаклен уйный.

Спектакльдә Хәлил ага Әбҗәлилов — Биктимер карт ролен, Фатыйма апа Ильская — аның килене Айсылуны, ә Нәҗип Гайнуллин Артомонов ролен башкаралар.

Сәхнәдә Хәлил ага һәм Фатыйма апа Ильская. Алар сөйләшкәндә Артомонов керергә тиеш. Ә ул юк та юк, нишләргә? Болар аптырап калмыйлар: Фатыйма апа (Айсылу): «Кара әле, капка төбенә кем килеп туктады икән?» Хәлил ага (Биктимер карт): «Ә-ә, бу Артомонов бит, атын бәйләп маташа. Нишләп йөри икән? Безгә килүе микәнни?» Фатыйма апа (Айсылу): «Шулайдыр, ахры, нигә бик акрын маташа соң? Һаман керми?» һ. б., һ. б.

Ә бу вакытта сәхнә артында без дөнья бетереп, Гайнуллин — Артомоновны эзлибез, кычкырып та карыйбыз. Юк кына бит Артомонов!

Ә бит сәхнәдәгеләр нишләргә тиеш инде? Шулчак Хәлил ага: «Кара инде, кермәскә булды микәнни? Атын чишеп китеп барды»,— дип, спектакльне дәвам иттерделәр. Артомонов кисәге төшеп калды.

Ә безнең Гайнуллин нишләгән? Ул театр йортындагы машинаның кабинасына кергән дә, рәхәтләнеп, йомшак утыргычта йоклап ята икән...

## Борынны сындырырлык су

Атаклы артист Ситдыйк Айдаров бик тапкыр, җор артист иде. Сәхнәдә көтелмәгәнрәк хәл килеп чыкса, бер дә югалып калмый, җаен таба иде. Әле дә хәтеремдә: ниндидер бер спектакльдә ул үзенә гумуздан шактый зур һәм озын борын ясап куеп, уйный иде. Менә бервакыт уен барышында стаканнан су эчәм дип, стаканны авызына китергән иде, ясалма борын стакан кырыена ябышты да калды. Ситдыйк ага «ә» дигәнче стаканнан борынны куптарып алып, ялт иттереп үз урынына ябыштырып та куйды. Тамашачылар сизми дә калды. Шулай да: «Тешне түгел, борынны сындырырлык салкын икән суы»,— дип әйтүне кирәк тапты.

## «Стреляй его!»

Югары Баскунчак клубында «Галиябану» спектакле бара. Тамашачы чуар: татар да, казах та, руслар да байтак. Шуның өчен Касыйм ага Шамил һәр пәрдә алдыннан булачак вакыйгалар белән бераз таныштырып бара.

Соңгы пәрдәдә Хәлил көндәше Исмәгыйльнең револьверын кулга төшерә. Шул вакыт залдан русчалап кычкыру башланды:

— Стреляй его... бога мать, стреляй сволоча, ну зачем не стреляешь?..

Хәлил револьверны җиргә ташлый.

— Эх! Надо было стрелять его... бога мать, эх! Зря не стрелял сволоча!..

## «Үтрек үлде!»

«Галиябану» спектакле белән Әстерхан өлкәсе колхозларында гастрольдә йөрибез. Бер колхозда спектакль урамда бара. Анда гомергә артистлар булмаган, спектакльләр куелмаган, шуның өчен сәхнәдәге вакыйгаларны чын итеп карыйлар. Соңгы пәрдәдә Исмәгыйль Хәлилне «атып үтергәч», халык, бигрәк тә хатын-кызлар елаша башладылар. Шул вакыт дөнья күргәнрәк бер тамашачы:

— Еламагыз, еламагыз, чынлап үлмәде ул, үтрек үлде, үтрек кенә үлде!» — дип, халыкны юата башлады. Ягъни: «Чынлап үлмәде. Юри генә үлде»,— дигәнe.

## Сүз һәм тоз

Югары Баскунчактан Түбән Баскунчакка, ягъни, тоз күленә барырга кирәк, ләкин бернинди транспорт юк. Ничек барырга, дип, баш ватабыз.

— Ә сез болай итегез. Түбән Баскунчактан тоз төяп вагоннар таккан состав килә, киткәндә ул буш китә, менә шунда утырыгыз,— дип киңәш бирделәр. Состав килде. Вагон дигәннәре кечкенә генә савыт-вагонетка икән, бер вагонга әйберләре белән бары бер яки ике кеше генә сыя. Шулай да итәкне-җиңне җыеп, утырыштык.

Поезд шылтыр-шылтыр бара, ә һәрбер вагонеткада бер-ике баш күренеп-кылтырап бара. Шулай итеп, 15—20 вагонеткадан без — артистлар бер-беребезгә эндәшеп, кунакка чакырышып, җырлашып, уйнап-шаярып, көлешә-көлешә Түбән Баскунчакка «комфорт» белән барып җиттек.

— Инде менә безгә сүзегезнең тозы юк, дип әйтеп карасыннар,— диештек.

## Файдасын файда, ә балы кайда?

1936 елда җаен гастрольдә йөргәндә, колхоздан концерт өчен исәп-хисап ясыйм. Шунда боларның бирергә акчалары җитми, ә расчет ясамый китеп булмый. Нишләргә? Җитмәгән акча исәбенә 6 кило бал, 2 кило май алып, расчет ясадым. Майны иптәшләр бик тиз бүлеп алдылар, ә балны берсе дә алырга

теләми. Балны йөртергә савыт та юк. Үзебез кунган йорттан бер чиләк сорап алып, балны тутырып киттем, нәүбәттәге авылга баргач, тагын фатир хуҗасыннан чиләк сорап алып, татлы ризыкны теге авылдан алган чиләктән ашык-пошык бушатып, чиләкне олаучылар артыннан кире җибәрдем. Бу авылдан алган чиләкне тагын барган авылдан алган чиләккә бушатып, чиләкне кире озаттым. Шулай итеп, чиләктән чиләккә бушата-бушата, атна-ун көн дигәндә бал юкка чыкты. Ә бал өчен акчаны миңа түләргә туры килде. Ягъни файдасын файда, ә балы кайда? булып чыкты бу.

## Кыен эш

Ватан сугышы елларында, беләсез, бөтен әйбер талон белән сатыла иде. Без — артистлар беркетелгән ябык кибеттә аракыны талон белән сата торган бер агай эшләде. Ул чагында аракы шешәләр белән түгел, ә мичкәдә килә. Аракы сатучы агай мичкәгә резин көпшә тыгып, авызы белән суыра да, аннан безнең савытка агыза, ләкин һәр суыруда бер генә йотым булса да тамакка китә бит. Шул иртән аек килгән агаебыз кичкә ләх исерек була һәм:

— Мин-нем эшшем кыен! Иртәдән кичкә кадәр суууыррам да сууыррам,— дип, көч-хәл белән сөйләнеп утыра иде.

## Нигә көләсез?

Сәет ага Булатов «Тукай» драмасында уйнаганда, борын астына нәни генә мыек ябыштырып чыга, ә тәнәфестә ул мыегын куптарып, алып куя торган иде.

Бер спектакльдә, тәнәфестән соң мыегын яңадан ябыштырырга онытканда сәхнәгә мыексыз гына чыкты бу. Сәет аганың мыексыз чыгуын күреп, уйнаучы артистлар аңарга мыштым гына көлеп карый башладылар. Моны күргән Сәет ага артистлардан шыпырт кына: «Нигә көләсез, нигә көләсез?» — дип сорады. Бер артист борын астын сыйпап куйгач, Сәет ага да борын астына капшап алган иде, мыексыз икәнен белеп, үзе дә көлеп җибәрде.

## Әтәчләрне вакытсыз кычкыртып буламы?

Замандашлары атаклы артист Барый Тархановның бик оста итеп, әтәч булып кычкыруын сөйлиләр иде.

Әтәчләрнең, беләсез, төнлә өч тапкыр кычкыра торган үз вакытлары бар. Элек авыл халкы беренче әтәч кычкыргач, икенче әтәч кычкыргач, өченче тапкыр кычкыргач, дип эшләрен планлаштыралар иде.

Бер авылда төнлә, спектакльдән соң, артистлар клубтан кайталар. Әле әтәч кычкыра торган вакыт җитмәгән. Барый Тарханов шунда:

— Әтәчләрне кычкыртыйммы? — дип куя. Иптәшләре гаҗәпләнәләр:

— Ничек кычкыртасың, алар әле йоклыйлар бит,— диләр. Барый ага:

— Ә мин аларны хәзер уятам,— ди һәм «Кик-ри-күүк!» — дип кычкырып җибәрә. Берничә тапкыр кычкыргач, авылдагы бөтен әтәч уянып, вакытсыз кычкыра башлыйлар.

## Ватык барабан

1930 еллар эчендә театрга, филармониягә сәнгать белән бигүк таныш булмаган кешеләр директор булып киләләр иде. ТДАТта мондый мәзәк йөрде ул чагында.

Салих Сәйдәшев оркестр белән репетиция ясый. Менә яңа директор килә дә, боларның уйнавын кызыксынып карап тора. Репетиция барышында барабанчы бер сугып ала барабанга, бераздан тагын бер сугып куя, тагын беркадәр вакыттан соң, барабанчы тагын барабанга бер кундырып куя.

Репетициядән соң, директор барабанчыга ымлап, Сәйдәшевкә эндәшә:

— Бу барабанчы сиңа бик кирәкме инде?

Сәйдәшев:

— Әлбәттә кирәк,— ди.

Директор:
— Өч мәртәбә суккан өчен эш хакы түләп булмас. Зур эш түгел, кирәк чакта мине чакырырсың, үзем төшеп, сугып менәрмен,— дип, шаккаттыра. «Вәт ватык барабан!» — дип, тел шартлаталар.

## Кемгә нәрсә...

Бөек Ватан сугышы елларында безгә Әгерҗе районының карт кына бер колхоз рәисе килде. Ялгышмасам, ул тегермәндә җыелган көрәк онын колхозчыларга өләшкән, эше судка киткән, шуның өчен Верховный судка килгән.

Мин аны кичен театрга «Алтынчәч» операсын тыңларга алып бардым. Пәрдә ачылып, спектакль башланды. Сәхнәдә тамаша: ирләр, хатын-кызлар, егетләр, гаскәриләр, оркестрда — музыкантлар. Сәхнә халык белән (артистлар белән) кайный, гөрли!

Беренче пәрдә беткәч, мин аңардан сорыйм:

— Ничек соң абзый? Спектакль ошадымы?

Ул җавап бирмичә бераз уйланып торды да, үзалдына сөйләгәндәй әйтеп куйды:

— Әйе! Бу кадәр халыктан ничә бригада төзеп булыр иде икән?

## Җаен таба белсәң...

Гастрольләрдә айлар буе йөрү артистларны бик арыта, талчыктыра. Шуның өчен алар үзара төрле шуклыклар, мәзәкләр уйлап, күңелләрен күтәрергә тырышалар.

Бер гастрольдә Рәшит Ваһапов белән Динә Сираҗетдинова ядәч аерышалар. Ләкин һич кенә дә берсен-берсе ота алмый болар. Көннәр үтә. Рәшит концертның ахырында җырлый, соңгы җырны Динә белән бергәләп «Башмагым»нан дуэт башкаралар. Динә җырларга чыккач, Рәшиткә: «Тиреңне сөрт»,— дип кулъяулык тоттыра. Һәм аның колагына «ядәч» дип пышылдый. Рәшит җырлаганда билгеле «исемдә» дип әйтә алмый кала. Шулай итеп, оту өчен Динә тәки җаен таба.

## Балык мае

Танылган гармунчы Гали Җәмлихановның фатирга кергәч әйтә торган бер сүзе бар иде. Өйгә килеп керү белән:

— Әй, апа! Тормышмыни бу, балык мае да булмагач?! — дип куя.

Бер квартирага кереп ул шул сүзне әйтүе була, фатир хуҗасы — апа юкка чыга. Кичкә таба гына ул арып-талып, карга буялып кайтып керә һәм:

— Менә улым, күрше авылга барып, сиңа балык мае алып кайттым,— дип, куеныннан ярты литр балык мае чыгарып куя.

## Әртистләрне күп күргән

Бер колхозда фатирга кергәч, Рәшит йорт хуҗасы — бабайга эндәшә:

— Безнең концертны карарга барасыңмы, бабай?

Бабай:

— Юк, барып тормам инде, улым.

Рәшит:

— Ник барырга теләмисең, бабай, әллә минем җырлаганны яратмыйсыңмы?

Бабай:

— Җырлавыңны яратам да, мин әртистләрне күп күргән инде.

Рәшит:

— Кайда күрдегез соң әртистләрне, бабай?

Бабай:

— Япун сугышы вакытында, лазаретка килгәннәр иде...

*ТУКАЙНЫ ОЛЫЛЫЙЛАР*

## КАЗАНДА

22—23 майда Татарстан Фәннәр Академиясе урнашкан бинада «Г. Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте» дигән темага халыкара фәнни конференция булып үтте. Аны ТФА президенты — академик М. Хәсәнов ачты. Пленар утырышта академиклардан М. Зәкиев, Р. Нәфыйков, Т. Галиуллин, Ф. Мусин, Төркиянең Измир университеты галиме Мостафа бәй Өнәр, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясады.

Конференциягә килүчеләр «Әдәбият һәм халык иҗаты», «Тарих, сәнгать һәм әдәби бәйләнешләр», «Тел һәм мәгариф» секцияләре эшендә актив катнаштылар.

* * *

23 майда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында Г. Тукайның тууына 110 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш уздырылды. Анда Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, бөек шагыйребезнең иҗатын югары бәяләп, чыгыш ясады һәм 1996 елда Г. Тукай бүләгенә лаек булган өлкән әдип Г. Бәширов белән җырчы Ф. Кудашевага лауреат грамоталарын һәм билгеләрен тапшырды. Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, ТР Фәннәр Академиясе президенты М. Хәсәнов, Мәскәүдән килгән шагыйрь — Социалистик Хезмәт Герое Е. Исаев, Башкортстанның халык шагыйрьләре М. Кәрим, Н. Нәҗми, Төркия кунагы — галим һәм тәрҗемәче М. Өнәр, «Литературная Россия» атналык газетасы мөхәррире В. Еременко һ. б. чыгышлары да тыңлаучыларда тирән тәэсир калдырды.

Тантанада катнашучылар соңыннан «Шүрәле» балетын карадылар.

## КУШЛАВЫЧТА

24 майда Тукайга багышланган бәйрәм бөек әдипне дөньяга бүләк иткән Арча төбәгенә күчте. Иң элек күпсанлы кунаклар, автобусларга, җиңел машиналарга утырып, Тукай туган авылга — Кушлавычка килделәр. Биредә Тукаевларның музей-утарын ачу тантанасы булды. Тантанада ТР Мәдәният министры М. Таишев, республикабыз Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Ә. Еники, Башкортстанның халык шагыйре Н. Нәҗми, Кушлавычта туып-үскән язучы Ә. Галиев, шагыйрә Ф. Гыйззәтуллина, Төркия галиме М. Өнәр, Мәскәү кунагы Е. Исаев, язучы Ф. Бәйрәмова, Татарстан берләштерелгән Дәүләт музееның бүлек мөдире А. Хәйруллина, Тукай исемендәге күмәк хуҗалык (Кушлавыч) рәисе Р. Фәйзиев, Татарстан Мәдәният министрлыгының фәнни-реставрацияләү идарәсе башлыгы Н. Йосыпов һ. б. чыгыш ясады.

Музей-йортка керә торган тасманы кисеп, Тукай туган нигезгә иң беренче булып быелгы лауреатлардан Г. Бәширов белән Ф. Кудашева һәм башка кунаклар (алар арасында ерак Австралиядән килгән әниле-уллы Зәкия ханым белән Шәүкәт әфәнде дә бар иде) аяк басты. Музей-утар белән якыннан танышканнан соң, алар зиратта — Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф хәзрәт кабере янында да булдылар. Соңыннан Тукай-Кырлайга юл тоттылар.

## ТУКАЙ-КЫРЛАЙДА

Арча районы хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты В. Минһаҗев җитәкчелегендә кунаклар Кырлайда Тукайның яңартылган музее белән таныштылар, шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Аннары үзәк мәйданда шигырь бәйрәме башланды. Анда шагыйрьләрдән Р. Харис, Ш. Галиев, Е. Исаев, И. Юзеев, Н. Нәҗми, Р. Фәйзуллин, Р. Миннуллин, Л. Шагыйрьҗан, З. Мансуров, Р. Кутуй, В. Ганиев, Р. Әймәт, Р. Рахман, Р. Җамал һ. б. чыгыш ясадылар.

Әлеге тантанада Г. Тукай исемендәге бүләк лауреаты — Татарстан җыр һәм бию ансамбле коллективы, шулай ук Татарстанның халык артисты Ш. Әхмәтҗанов, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты — җырчы һәм тальянчы Ф. Вәлиәхмәтов, нәфис сүз остасы Ф. Салихов кебек талантлар катнашты.

## БАЛТАЧТА

Тукай юбилеен балтачлылар да тантаналы төстә билгеләп үттеләр. Районга кунаклар булып Татарстан Җөмһүриятенең Аксакаллар Шурасы Рәисе Р. Хәмидулла, танылган язучы М. Хәбибуллин, академик Ф. Мусин, «Мирас» журналының баш мөхәррире Ә. Сәхапов килгән иде. Алар күпсанлы әдәбият сөючеләр алдында чыгышлар ясадылар. Аннары Казан кунаклары Г. Тукайның әнисе Мәмдүдә Зиннәтулла кызы күмелгән Сосна Пүчинкәсе авылына барып, мәрхүмәнең каберенә чәчәк куйдылар, аның рухына дога кылдылар, зират янәшәсендә салынган яңа мәчетне ачу тантанасында катнаштылар. Авыл халкының теләген искә алып, җыен әлеге мәчеткә Мә-

мдүдә Тукаева исемен бирү турында карар чыгарды.

*БАШКА ТӨБӘКЛӘРДӘ*

## МӘСКӘҮДӘ

Тукайга багышлап, биредәге Язучылар йортында уздырылган бәйрәм Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллеге һәм Халыкара Язучылар берлекләре бердәмлеге тарафыннан оештырылган иде. Кичәне кереш сүз белән күренекле шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе С. Михалков ачып җибәрде һәм алып барды.

Иң элек бөек шагыйребез турында ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев чыгыш ясады. Тантанада Татарстанның Россиядәге даими вәкиле Ф. Мөхәммәтшин, Мәдәният министры М. Таишев, армия генералы М. Гәрәев, шагыйрьләребездән Р. Гаташ, Г. Рәхим, язучы-тәрҗемәче В. Ганиев һәм Мәскәүдә яшәүче татар зыялылары катнашты.

Соңыннан Мәскәү һәм Татарстан сәнгать осталары көче белән зур концерт күрсәтелде.

## УФАДА

Тугандаш Башкортстан башкаласында мәшһүр шагыйребезгә багышланган тантаналар элеккеге «Сабах» китапханәсе урнашкан бинага — заманында Г. Тукай туктаган йортка мемориаль такта куюдан башланып китте. Аннары Башкортстан Дәүләт опера һәм балет театрында тантаналы кичә булды. Анда Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Бикбаев Тукай турында доклад белән чыкты. Татарстан кунаклары — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Р. Фәйзуллин, Татарстан халык депутатлары — драматург Т. Миннуллин, академик И. Таһиров, башкортстанның халык шагыйрьләре М. Кәрим, Н. Нәҗми h. б. чыгышлары көчле алкышлар белән бүләкләнде. Соңыннан сәнгать осталары зур концерт бирде.

Әлеге чараларны оештыруда Башкортстандагы Татар телле язучылар берлеге дә (җитәкчесе — профессор Р. Әмиров) актив катнашты.

## УРАЛЬСКИДА

Яшь Габдулланың 12 ел гомере үткән (1895—1907) Уральск шәһәрендә дә Тукай юбилеен олылап билгеләп үттеләр. Көнбатыш Казагыстанда 1996 ел «Тукай елы» дип игълан ителде. Шул уңайдан биредә «Г. Тукайның Уральск үзәге»н төзү буенча зур чаралар тормышка ашырыла башлады. Бу өлкәдә әлеге үзәкнең җитәкчесе — Уральск педагогика университеты профессоры, педагогика фәннәре докторы Разак Абдрахман улы Әбүзәров нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтә.

## ЙОШКАР-ОЛАДА

Мари-Эл башкаласында да Г. Тукайның туган көнен зурлап билгеләп үттеләр. «Звездный» микрорайонындагы бер урамга (ул Казан юлы янәшәсендә генә урнашкан) халкыбызның сөекле шагыйре исеме бирелде.

*ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

## ТАТАРСТАН РӘССАМНАРЫ КОРЫЛТАЕ

23 апрельдә Татарстан Рәссамнар берлегенең X корылтае булып үтте. Үзенә 254 рәссам-сынчыны берләштергән әлеге иҗат оешмасы Россиядә иң зурлардан санала. Берләшмә рәисе Абрек Абзгильдин, сәркатиб Шамил Нигъмәтуллин һәм художество фонды директоры Владимир Бабаков ике корылтай арасында башкарылган эшләр, алда торган бурычлар турында доклад ясадылар. Аннары фикер алышулар булды, уставка өстәмәләр һәм төзәтмәләр кертелде. Корылтайда Татарстан Рәссамнар берлегенең яңа җитәкчелеге сайланды. Бу юлы да рәссамнар А. Абзгильдинга ышаныч күрсәттеләр.

## ХАЛЫКАРА БАЛЕТ ФЕСТИВАЛЕ

Мәшһүр биюче — милләттәшебез Рудольф Нуриев истәлегенә багышлап, май аенда Казанда халыкара классик балет фестивале үткәрү инде бер матур күренешкә әверелде. Быел бу чара уникенчы мәртәбә уздырылды. Аңа дөньяның төрле төбәкләреннән атаклы биючеләр чакырылган иде. Шунысы куанычлы: фестиваль репертуарында үзебезнең «Шүрәле» балеты да бар. Әсәрдәге үзәк бию партияләрен Казагыстанның халык артисты, бишь халыкара ярыш лауреаты Бәхетҗан Смагулов, Казаннан Вадим Яруллин, Елена Щеглова кебек талант ияләре зур уңыш белән башкарды.

## ТАГЫН БЕР АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

16 майда Качалов исемендәге рус драма театрында «Театр кичә, бүген һәм иртәгә» дигән исем астында бәйрәм тамашасы үткәрелде. Ул әлеге театрга «академия» исеме бирелү уңаеннан оештырылды. Әлеге тантанага Казанның барлык театрлары артистлары, әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүче зыялыларыбыз чакырылган иде.

## КИТАПХАНӘЧЕЛӘР БӘЙРӘМЕ

27 майда яңа профессиональ бәйрәм — Китапханәчеләр көне беренче тапкыр билгеләп үтелде. Ул Россиянең һәркем файдалана алырлык беренче китапханәсенең 200 еллыгы уңаеннан 1995 елда билгеләнгән иде.

Шул уңайдан Татарстан Милли китапханәсендә бәйрәм тамашасы уздырылды. Биредә ветераннарны котлап, аларга истәлекле бүләкләр тапшырылды. Аннары сәнгать осталары концерт күрсәттеләр.

## СӘЙДӘШТӘ КУНАКТА

«Шигърият остаханәсе» үзенең чираттагы утырышын мәркәзебезнең С. Сәйдәшев музей-йортында үткәрде. Ул күренекле ша-

гыйрь Р. Харисның «Сәйдәш яры» дип исемләнгән яңа поэмасын укып тикшерүгә багышланды. Әсәр унсигез яшьлек Сәйдәшнең Буада яшәгән чорын, аның уналты яшьлек Бибисарага булган мәхәббәтен тасвирлый.

Шагыйрь әсәрен укыганда, аның туганы С. Гарифуллин Сәйдәш көйләрен фортепьянода уйнап торды. Остаханә утырышында катнашкан шагыйрьләрдән И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Г. Зәйнашева, Р. Гаташ, язучылардан Батулла, Ә. Гаффар, музыка белгечләре К. Тажиева, И. Исәнбәт, музей-йортның директоры Я. Рәхмәтуллин һ. б. поэма турында үзләренең уй-фикерләре белән уртаклаштылар.

## ӘГЕРЖЕ ТАЛАНТЛАРЫ — ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ

Күренекле драматург Таҗи Гыйззәткә, композитор һәм шагыйрь Ләбиб Айтуганова багышлап, Әгерже районының Барҗы-Умга, Нарат авылларында искә алу кичәләре үткәрелде.

Бер үк вакытта районда яшәп иҗат итүче авторларга да җитди игътибар бирелә. Бу юнәлештә мәдәният бүлеге мөдире Мәҗит Исрафилов һәм үзәк китапханә хезмәткәрләре зур тырышлык күрсәтәләр. Мордыбый авылында яшәүче Чыңгыз Мусинның «Язмышым — үзәннәрдә» дигән шигырьләр китабы чыгу уңаеннан Әгерже район мәдәният йортында тәкъдир итү кичәсе үткәрелде. Кырынды авылында гомер итүче прозаик Габдулла Галиевның Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Үкенеч» исемле җыентыгы хакында да кызыклы сөйләшү булды.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Язучы һәм тәрҗемәче Солтан Шәмси белән «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире, балалар язучысы Ләлә Сабирова-Гыймадиева Биектау районының Юртыш, Мәмдәл, Суыксу авылларында якташлары белән очраштылар.

* * *

Казан шәһәрендәге 155 нче татар-инглиз гимназиясе (директоры — Илсур Һадиуллин) яшьләргә эстетик тәрбия бирү буенча нәтиҗәле эш алып бара. Соңгы вакытта, мәсәлән, гимназия укучылары янында «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррирләре — танылган язучылар Шамил Маннапов белән Рәдиф Гаташ кунакта булдылар. Сөйләшү-әңгәмә барышында укучылар саф татарча итеп шигырьләр укыдылар, очрашу җыр-музыка белән аралаштырып алып барылды.

## ЯҢА ГАЗЕТА

Чаллы шәһәрендә «Киңәш» дип исемләнгән күп битле яңа газета (баш мөхәррире — Газинур Вәлиев) чыга башлады. Ул, исеменнән үк күренгәнчә, файдалы киңәшләргә бик бай газета. Бер үк вакытта аның битләрендә әдәбият сөючеләр өчен «Шигъри кунакханә» сәхифәләре дә дөнья күрә.

Газетаның индексы — 54147. Алдагы яртыеллыкка язылу бәһасе — 7320 сум.

## ҖИҺАНОВ КҮКТӘН НУР СИБӘ

1975 елда ачылган һәм 5930 саны белән халыкара каталогка кертелгән кече планетага татар халкының күренекле композиторы, җәмәгать эшлеклесе Нәҗип Җиһанов исеме бирелде. Шул уңайдан Мәскәүдә, Россия Композиторлар берлегендә тантаналы утырыш булды. Анда Н. Җиһановның хатыны, кызы һәм Татарстан Композиторлар берлегеннән Мирсәет Яруллин катнашты.

## КАМАЛ ТЕАТРЫ — ГАСТРОЛЬЛӘРДӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт драма академия театры артистлары Финляндия башкаласы Хельсинкида булып кайттылар. Гастрольләр барышында әлеге театрның сәнгать осталары күренекле драматург Т. Миннуллинның инде классик әсәргә әверелгән «Әлдермештән Әлмәндәр»ен һәм зур концерт күрсәттеләр.

Финляндиядән кайтуга, камаллылар Башкортстан башкаласына юл тоттылар. Уфада алар төрки халыклар театрларының «Туганлык» дигән икенче халыкара фестивалендә катнаштылар.

## БӘЙРӘМ БҮЛӘГЕ

Киноның 100 еллыгы һәм Балаларны Халыкара яклау көне уңаеннан, Татарстан кинематография дәүләт комитеты республика кинотеатрларында «Таң батыр» исемле беренче татар мультфильмын (авторлары — режиссер Г. Сәйфетдинова, рәссам-куючы И. Маханова) яшь тамашачыларга бушлай күрсәтте.

## ЯҢА ИҖАТ БЕРЛӘШМӘСЕ

Күп санлы тамашачыларның сорауларын искә алып, Чаллы хакимияте (җитәкчесе — Р. Алтынбаев) үзләрендә яңа концерт-иҗат берләшмәсе төзеде. «Энергетик» мәдәният сараенда аны тәкъдир итү кичәсе булды. Шәһәр хакиме урынбасары Ф. Мостафина, мәдәният идарәсенең яңа башлыгы Ф. Белецкая артистларны, шушы тантана уңаеннан, ихластан котладылар.

Хәзер әлеге берләшмә «Болгар» дәүләт бию ансамбле, «Камичи» халык музыка ансамбле, «Звоны» халык җырлары ансамбле, «Ритм» бал биюләре ансамбле, Чаллы циркы студиясе, «Джиззи» джаз капелласы, камера хоры һәм аерым артистлардан Фән Вәлиәхмәтов, Лилия Букеева, Гөлүзә Зыятдинова, Дания Сибгатуллина кебек талантлы җырчыларны үзенә бер бөтен итеп туплап, халыкка игелекле хезмәт күрсәтә.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Фольклор өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле фәнни эшчәнлек алып барганы өчен, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының халык иҗаты бүлеге мөдире, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Урманчиев Фатыйх Ибраһим улына «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

# АК АТ

Сәнгатьтә һәм әдәбиятта аеруча зур уңышка ирешү өчен, мөгаен, талантлы булу гына житмидер, тагын әле гуманист булу да мәжбүридер. Безнең милли сынлы сәнгатебездә төп юлны салучы һәм дәвам иттерүче даһи рәссамнарның ижатына бәя биргәндә, әлбәттә, Бакый Урманченың әсәрләрендәге образларның миллилегенә һәм төсләрнең-буяуларның жетелегенә хәйран каласың; Лотфулла Фәттаховның картинага искиткеч оста сюжет коруына һәм буяуны шулчаклы да тәвәккәл салуына гаҗәпләнәсең; Илдар Зариповның нәзакәтле нәкышендә исә төсләрнең үзара бәйләнешы олы бер гармония китереп чыгаруын һәм шуның нәтиҗәсендә әчке бер моң барлыкка килүен күреп сөенәсең.

Әгәр Испаниядә туып-үскән мәшһүр Сальвадор Далиның картиналарында аратирә арыслан сурәте очраса, татар сәнгатькәре Илдар Зариповның киндерләрендә без еш кына ат сурәте күрәбез.

Моның шулай булуы бер дә очраклы хәл түгел: безнең халык борын-борыннан ат белән дустанә яшәгән, көнкүрешендә һәрчак атны гаять оста файдаланган: жирен сөргән, ашлыгын басудан төяп алып кайткан, утынын-мазарын ташыган, саладан калага ат жигеп барган... Халык атны ир-егетнең юлдашы да, канаты да дип юкка гына атамыйдыр, атсыз көн күрүне хупламаса, атлы кешенең дәрәҗәсе зур булуын — «Атың булса, ил таный», дип юкка гына бәяләмидер, күрәсең.

Менә ни сәбәпле милли образлар иҗат итүче сәнгатькәр Илдар Зарипов әледәнәле үзенең киндерләренә ат сурәтен дә теркәп куярга ярата. Кайчагында рәссамның нәкышь әсәрләрендә ат сурәте үзебезнең жирлекне тәгаенләр өчен арткы планда, бәп-бәләкәй итеп кенә бирелсә, аерым очракларда ат алгы планда, каһарман сыйфатында калкып чыга. Һәрхәлдә, татар авылын тасвирлаганда рәссам ничек кенә булса да атны кертмичә калмау ягын карый, шунсыз аның күңеле булмый.

— Татар халкы үзе дә бит эшчән халык, уңган халык, ат шикелле эшли,— дип әйтүе белән автор үзенең әсәрләрендә өстәмә бер мәгънә ятканына ишарә ясый, безне уйланырга мәжбүр итә, сәнгать әсәрләрен аңлау өчен тирәнгәрәк керергә өнди.

Ат образын тулырак чагылдыру нияте белән рәссам аңа махсус картиналар да багышлый. Шуларның берсе — «АК АТ» киндере. Аны Илдар Зарипов 1995 елда иҗат итә. Гап-гади сюжет: күркәм кыяфәтле, чибәр генә бер егет үзенең тугрылыклы җан дусты ак ат янына тезләнгән дә курай уйный. Тамашачыга аның кәләпүш астыннан чыгып торган кара чәче, өстендәге буй-буй күлмәге, камзулы яхшы күренә. Әмма автор игътибар үзәгенә чибәр егетнең озын музыкаль бармакларын куя һәм әнә шул нәфис деталь ярдәмендә курай моңын ишетергә мөмкинлек тудыра.

Нәкышь әсәрен язганда автор камиллеккә ирешсә, ул инде тамашачыга бөтен йөрәк серләрен әйтеп бирә, аны үзенчә фикер йөртергә өйрәтә — әлеге киндерендә исә кешенең ат белән чыннан да дус икәнлегенә беркемдә бернинди шик-шөбһә калдырмый. АК АТны да матурлап яза автор: аның сибелгән озын ялына чәчәкләр тезеп чыга. Аннары инде үз әсәренә чит кешедәй таләпчән күз белән карап ала да:

— Әкият аты шикелле...— дип соклануын белдерә.

Җөмһүриятебезнең Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Илдар Зариповның гуманистлыгы, кече күңелле шәхес икәнлеге әнә шулай һәр нәкышь әсәрендә тулаем чагыла.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Илдар Зариповның «Ак ат» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Халыкара ПЕН-клубның Татарстандагы әгъзаларыннан бер төркем. Беренче рәттә: Р. Мостафин, Н. Фәттах, И. Юзеев, Ә. Еники, М. Госманов, Т. Миңнуллин; икенче рәттә: Р. Вәлиев, Р. Фәйзуллин, Ә. Мушинский, Р. Зәйдулла.

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. **Дәгъва.** *Хикәяләр, публицистика, әдәби тәнкыйть.* Казан. Татар. кит. нәшр. 1995. 256 б. Тиражы — 5000 данә.




«Мин хакыйкатькә хилафлык итмәскә тырыштым, күз уңында дөреслекне, миһербанлыкны тотып, кеше җанын аңларга ниятләп юлга чыктым... Публицистик язмаларда да, бүгенге әдәбиятка караган уйларымда да шул ук уйхисләргә өстенлек бирдем.» Авторның «Башлам кәлимә» дип аталган кереш сүзеннән бу юллар. Ә автор үзе кем соң диючеләргә болай дибез: ул — профессор, Казан университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, танылган галим һәм язучы. (Быел журналыбызның 1—2 саннарында аның «Тәүбә» исемле романы басылып чыкты). «Дәгъва» китабы өч бүлектән тора: хикәяләр, публицистика, әдәби тәнкыйть. Анда язучы, галим, публицистның соңгы елларда иҗат иткән хезмәтләре тупланган.

Марат ӘМИРХАНОВ. **Сөн моңы.** *Повесть һәм хикәяләр.* Казан. Татар. кит. нәшр. 1995. 120 б. Тиражы — 3000 данә.




Марат Әмирханов — Актаныш якларында туып-үскән язучы. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Х. Ямашев исемендәге бүләк иясе. Журналист-язучының бу китабына (аның элегрәк елларда «Безнең лауреатлар», «Таш һәйкәл», «Чулманның ак йолдызы» исемле җыентыклары дөнья күргән иде). «Сөн моңы» повесте һәм «Күктәге торналар», «Кое», «Салкын яңгыр», «Пәри», «Ир хатыны», «Ләйлә», «Саба җиле»h. б. хикәяләр кергән. Табигатьнең илаһи матурлыгын автор үз әсәрләрендәге каһарманнар язмышы, аларның самимилеге, әдәпле-инсафлы сыйфатлары аша оста бәйләп тасвирлый.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)